

# КАЗАН УТЛАРЫ

8
АВГУСТ
1982

## ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

### «Казан утлары» журналын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләү турында

*Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм беренче саны чыгуга 60 ел тулу уңаеннан Татарстан Язучылар союзы журналы «Казан утлары»н Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләргә.*

**Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе** С. БАТЫЕВ.

**Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре** Д. ДӘҮЛӘТШИНА.

Казан, Кремль.
4 июнь, 1982 ел.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ЗНАК ПОЧЕТА

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

8

АВГУСТ

1982

## *Бу санда*

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 60 ЕЛ

Р. МИҢНУЛЛИН. Батырлар җыры. Шигырь . . . 3

М. ХӘБИБУЛЛИН. Сулар үргә акса да. Роман . . . 4
ЗӨЛФӘТ. Йөрәкләрдә — үлмәс дастан. Поэма . . . 40
М. МӘҺДИЕВ. Исәнме, Кәшфи абый! Повесть . . . 52
РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ. Мәхәббәт исәнлегенә! Шигырьләр . . . 113
Ю. САФИУЛЛИН. Менә без дә үсеп җиттек. Комедия . . . 119

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 60 ЕЛ

И. ЗАРИПОВ. Дуслар тугрылыгы . . . 147

ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

Ә. ЗИННӘТУЛЛИНА. Бер хикәя поэтикасы . . . 150
Р. ЮНЫСОВ. Фантастикага чынлык кирәк . . . 153
Ә. СӘХӘПОВ. Табигать исеменнән . . . 156

ӘДӘБИ МИРАС

Д. БАҺАВЕТДИНОВА, М. ӘХМӘТҖАНОВ. Такташ хатлары . . . 158

СӘНГАТЬ

Ә. АЙДАРСКАЯ. Хыял канатларында . . . 167

ТӨРЛЕСЕННӘН

И. ГЫЙЛӘҖЕВ. Экспедицияләр эзеннән . . . 174

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һәм
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

А. НИГЪМӘТУЛЛИН. Кул гына чыдасын. Шигырьләр . . . . . . 180

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

С. ШАКИР. Димнең җырчы егете . . . . . . 182
Х. КУМЫСНИКОВ. Оста да, остаз да иде . . . 184
Ф. ИЛЬСКАЯ. Саф күңел . . . . . . . . 187
Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. Сәхнә фидакаре . . . . 189

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 191

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(баш редактор урынбасары)*, РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

---

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63; сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 27/IV-1982 ел. Басарга кул куелды 14/VII-1982 ел. ПФ 09034. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049 экз. Заказ Ю-173. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.

# СССРның төзелүенә 60 ел

## Роберт Миңнуллин

### Батырлар җыры

Изге яулар дәвереннән
Дастаннарга әверелгән
Батырлар даны.
Ялкынлана-ялкынлана
Мәңгелек ут булып яна
Батырлар җаны!
Батырлар җаны!

Соңгы көрәш якынлаша,
Тик барыбер ялкын аша
Батырлар юлы.
Ялкынлана — җаныбыз да!
Ялкынлансын! Барыбыз да
Батырлар улы!
Батырлар улы!

Ак болытлар аксын өчен,
Алсу булып атсын өчен
Киләчәк таңы,
Булачак әле, булачак,
Туачак әле, туачак
Батырлар тагы!
Батырлар тагы!

Иртә әле — тынмаячак,
Бер дә тынып тормаячак
Батырлар җыры.
Батырларга яу бетмәгән,
Үтмәгән әле, үтмәгән
Батырлар чоры!
Батырлар чоры!

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# СУЛАР ҮРГӘ АКСА ДА

РОМАН

Эштән кайткач, Якуб ишегалдындагы тупыл агачы ышыгына куелган эскәмиядә утырырга ярата. Тымызык кына яңгыр сибәли. Шуңамы, ишегалдында һичкем юк, бала-чага өйдә мультфильм карыйдыр. Ике өй арасында колач җитмәстәй тупыл үсеп утыра, тупыл астында — эскәмия. Кояшлы җылы көннәрдә өстәлнең һичкайчан буш торганы юк, берише домино сугар, ә аларны вакыт әрәм итүчеләр уратып алган булыр. Якуб шомарып беткән өстәлдә бармакларын биетеп алды. Өстәл өстендә юеш тупыл яфраклары ята, очып та китә алмыйлар, ботакта җилфердәп торудан да мәхрүм ителгәннәр, кемдер өзеп, язгы яфракларны иснәп, хушланып утырган. Якуб яфракларны бер төшкә җыйды һәм җәелеп үскән тупылга башын күтәреп карады. Үз гомеренә бик күп тапкырлар яфрак яргандыр, бик күп тапкыр аларны койгандыр бу мәшһүр агач. Алай да җирдән алган иң тәмле төнәтмәне эчереп үстергән яфракларын вакытсыз югалту кыендыр аңа.

Башка әллә ниткән уйлар килә. Эңгер иңә башлады, ә яңгыр тымызык кына ява да ява. Нигәдер аның квартирында ут та күренми. Гөлбикә, баланы күтәреп, Юлия Борисовнага чыккандыр. Тәрәзәдә ут булмагангамы, өйгә керәсе килми. Биредә ышык, саф һава, тымызык кына яңгыр ява, уйлануы рәхәт. Кинәт җил исеп куйды, тупыл яфраклары кемгәдер зарланган сыман шыбырдашып, сөйләшеп алдылар... Ун катлы өйнең тәрәзәләрендә берәм-берәм утлар кабына башлады, әллә ничек шунда өй шахмат өстәлен хәтерләтеп җибәрде. Тәрәзәләрнең төсләре алышынды, кызгылт, яшел, зәңгәрсу төстәге тәрәзәләр дә бар, әнә сарылары кабынды. Ә менә куе зәңгәр төс юк та юк. Куе зәңгәр төстәге тәрәзә — аларныкы.

Биредә уйланып утыруы аңа рәхәт. Кинәт аның зиһене ачылып киткәндәй булды. Бит аңа Гөлбикә, баланы Юлия Борисовнада калдырып, концертка барам дип шалтыраткан иде, бәлкем әле кайтып та җитмәгәндер. Концерт дигәндә Гөлбикәнең җаны фида. Әйдә, йөри бирсен концертларга. Менә ни өчен ул биредә икән бит. Гөлбикәсен көтә!

Хатынын концерттан каршы алу, аңа менә мин сине көтеп алдым дип үк әйтмәсә дә, шул турыда Гөлбикәгә сиздерү Якубка әлегә үзе дә аңлап бетермәгән куаныч бирә иде. Якуб хатыны алдында гаепле

Дәвамы. Башы 7 нче санда.

түгел, Гөлбикәнең көнчелеге дә юкка гына. Василә Хакова белән аның арасында һични булганы юк.

Якуб тирә-юньгә күз төшереп алды. Тәмам эңгер инде. Беренче каттагы тәрәзәдән өй каршында үсеп утырган сирень агачына кызгылт ут яктысы төшә, сирень яфракларын куе кызгылт төскә буйый. Сиреньнәр кичәле-бүгенле генә чәчәк аттылар, ишегалдына хуш ис таралган. Хәер, бу озакка бармас, малай-шалай чәчәкләрне берәм-берәм сындыра башлар, һәм агач моңаеп, ямьсезләнеп калыр. Әмма сиреньнәр яныннан үткәндә ул барыбер шул исне тояр. Тукта әле, нигә аңа Гөлбикәсе кайтуга сирень чәчәге тотып тормаска ди? Якубка бу уе ошады гына түгел, хәтта шулай булырга тиеш шикелле тоелды. Һәм ул торды да әкрен генә күрше өй каршындагы куакка таба атлады. Сәер бер халәттә иде ул: күрсәләр дә, аны гаепләргә тиеш түгелләр кебек иде. Ә бит агачны утырткан хуҗаларның чынлап та күрүләре бар. Малай-шалай, житкән егет булса бер хәл, монда бит милиция майоры чәчәк сындыра. Тәртип саклаучы үзе. Әллә соң кереп рөхсәт сораргамы? Оялтып чыгарсалар? Булмас димә... Юк, сорамыйм, мин нибарысы бер тәлгәш сындырып алам, нибарысы берне...

Якуб сиреньнең бер ботагын сындырып алды да иплән кенә урам якка таба китеп барды. Чәчәктән бөркелеп хуш ис килә иде. Якуб зур урам ягына чыкты, ипи кибете янына басты. Аның исәбе буенча Гөлбикә нәкъ менә шул төштән үтәргә тиеш иде, башка җирдән аларның ишегалдына кереп булмый, ураткыч, ә Гөлбикә ашыгып кайтыр, чөнки ул балаларны Юлия Борисовнада калдырган. Ипи кибете каршында, ябалдашларын киң җәеп, тупыл утыра, тиздән тупыл мамык коя башлар, тупыл тәлгәшләреннән шул тиклем күп мамык чыга ки, көннәр җылы торганда ачык тәрәзәләрдән бүлмәләргә тула, тупыл мамыгыннан һичничек котылып булмый, күп кешедә шушы мамыктан аллергия чире кузгала, бигрәк тә йөкле хатыннарга ярамый ул мамык: тупыл мамык койганда Гөлбикә урамга чыгарга куркып йөргән иде. Ә малай-шалайга уен булсын, алар җыелып калган мамык өеменә ут төртәләр, мамыкның дөрләп янганын күреп, ни кылырга белми кычкырышалар. Тупыл мамыгын аеруча Юлия Борисовна яратмый, ул аңардан гомер буе интеккән. «Якуб, әллә соң берәр нәрсәгә ярыймы бу тупыл мамыгы, ни дип шундыйны утырталар микән, бит аның мамык коймый торганнары да була»,— ди ул бик аптырагач.

Якуб ни әйтсен аңа: «Була»,— дип кенә куя. Алай да шәһәрне яшелләндерү идарәсеннән ниндидер йомыш белән баш агроном килгәч: «Шул тупылны башка агач белән алыштырып булмыймы?»— дип сораган иде. Теге аңа тупыл агачының яз көннәрендә һаваны сафландыруы турында ярты сәгатьлек лекция укыды, бер үзенә бер лекция.

Якуб әкрен генә өйгә таба атлады. Күңелендә ниндидер моңсулык, кимсенү бар иде. Җитмәсә яңгыры һаман туктамый. Сәер, нигә кеше күңеле табигать үзгәрешенә бирелүчән икән? Дөрес, үз хиссияте вә кәефе белән үзләре идарә иткән кешеләр дә юк түгелдер бу дөньяда, әмма Якубка калса, алар да табигать тәэсиреннән читтә кала алмыйлардыр. Карак, мәсәлән, урлашу өчен шыксыз, яңгырлы көнне сайлый, чөнки эз җуярга җиңелрәк. Карак дигәннән, бер көнне пенсиядәге этисе килгән иде. Тотты да эти кеше Якубны (формадан түгел, әлбәттә) Сорочий базарына алып китте. Бер кешене күрсәтеп каласым бар сиңа, улым, ди. Без аның белән менә егерме биш ел инде тарткалашабыз. Ул үзенчә яшн, мин үземчә, ди. Әйтик, ул үз гомеренә караклык кылып йөрде, ә мин аны бу эше өчен эзәрлекләдем. Шулай итеп мин пенсиягә чыктым, ә ул, эт ялаган нәмәстә, һаман ташламый, күңеле һаман этлектә. Кушаматы Серый. Кыяфәте — бүре дә бүре, бу да бүре. Чын исеме Сираҗетдин, Сирай, димәк. Иң хәтәре: яшьләрне котырта, котыртып кына калса ярый, тегеләрне караклыкка өйрәтә, эт ялаган нәмәстә.

Хәзер әнә тагын кайткан. Спец ул, саклык кассалары басу буенча белгеч. Димәк, Якубҗан, тиздән бер-бер хәл көт. Ике көн элек кенә Васильево поселогында магазин басканнар. Сирай эше диясем килми, ул магазин белән вакланмас. Ә минем урынга калган участковый моны милициягә дәшеп алган. Сирай — хикмәтле карак, Якубҗан, андый вак-төяк кармакка эләгә торган карак түгел. Аңа куш булса куш булсын, булмаса — керешми. Хәзер әнә Сорочида бутала. Үзенә дуслар эзли, эт ялаган нәмәстә, бер дә бүтән түгел. Үзең беләсең, безнең Сорочида күгәрчен сөте генә юк, алам дигән кешегә аны да юнәтүчеләр табылыр.

Кыйшаеп, такталары уңып беткән койма буеннан атлаганда Якуб, кызыксынып, әйбер сатучыларны күзәтте. Арада яп-яшь кенә хатыннар да очраштыргалый. Әйтик, менә бу чибәр хатын панбәрхет күлмәген нигә сата? Якуб, туктап, хатын кулындагы күлмәкне карады. Бик аз киелгән булса кирәк. Бәясен дә артык сорамый. Димәк, яшь хатынны ниндидер нужа китергән. Шулай да, нигә Сорочига килергә, нигә комиссионкага илтмәскә?.. Аңлашыла инде, комиссионкада күлмәкнең айлар буе сатылмый ятуы бар, ә монда көне-сәгате белән кулга акча керә. Күлмәк матур иде, ләкин Якуб барыбер нигә сатасыз, дип сорарга яхшысынмады. Әтисе ашыктырды. Якуб күрде бит, хатын үзе сата, үзе күзләрен яшерә, димәк, аңа хәтта үз әйберен сатуы да оят, ә менә кайберәүләр күзеңә карергә тора. Товарын бетереп мактый, имеш, гомер буена да киеп туздыра алмассыз, үз гомерегездә миңа рәхмәт укырсыз. Никадәре дефицит әйбер биредә. Барысы да үзенекен сата микән? Ә бит универмагта да биредәге товарларны сирәк күрәсең. Нинди юллар белән килә икән бу базарга затлы дефицит әйберләр?..

Рәтләр буйлап атлый торгач, ниндидер склад коймасына килеп җиттеләр, ары юл юк иде. Койма буена тезелгәннәр бөтенләй башка әйбер саталар. Чегән базары диярсең. Якубның кабыргасына әтисе терсәге белән төртеп алды. Янәсе, әнә сул якка кара әле. Сул якта яшь-җилбәзәк уратып алган сары мыеклы таза гына ир кеше басып тора, ул яшьләргә нидер сөйли, ә тегеләре, авызларын ачып, тыңлап торалар. «Серый шул инде,— диде әтисе.— Күрче, эт ялаган нәмәстәне, ничек «тәрбияви» эш алып бара. Караклар телендә ул алтын кармакка маймыч тоту дип атала. Күреп кал үзен, Якубҗан, эш дәверендә очрап куюы бар. Миңа күп мәшәкать тудырды бу кеше, сезгә дә тудырачак әле ул. Кайтуына ике-өч ай үтмәде, бире чыккан, базардагы дефицит әйберләр белән кызыксына. Ләкин ул болай гына йөри, әйбер алганы юк аның. Хикмәтле карак. Күрәмсең, маймычлар аулый, шулар арасыннан ул иң кыю егетләрне генә сайлап ала, анннары айлар буе бушлай ашатып-эчертеп йөри, шуннан соң гына задание бирә. Башта бик җиңел эш куша, ишек ачарга өйрәтә. Ачкыч туры китерепме, ватыпмы, каерыпмы — эш анда түгел, ишекне ачтымы — кабул итә, юк икән, куып җибәрә. Дөрес, берничә көннән ул аны гафу итә һәм яңадан шайкасына чакыртып ала, тегеңә җиңелрәк задание бирә. Үзе квартирлар басуда бик сирәк катнаша, керем күп булганда гына бара, вак-төяккә йөрми, андый җирләргә әнә шул сирәк мыекларны җибәрә. Уң кулында басып торганы — үз малае. Аңа нибарысы биш-алты яшь чамасы гына әле, ләкин күзләренә, күзләренә кара син аның, гел бүренеке инде. Кем белә, малае, бәлкем, әтисе юлыннан китмәс тә. Хикмәт анда түгел, Якубҗан, хикмәт — малайның шушы яшеннән үк юньсез атага ияреп йөрүендә. Әниләре ниндидер складта эшли бугай. Моның белән талканы коры, ләкин күпме генә коры булмасын, бу бит, эт ялаган нәмәстә, теле белән төлке тота торган адәм, төрмәгә китә — озата, кайта — кабул итә хатыны. Әмма караклык — чир бит ул, кеше бер шуңа күнелен салдымы, агач корты сыман кимерә дә тора тегене, соңыннан агач тәмам яфраксыз калгач, тегеңә безнең брат дару сиптергән була, мәгәр бактың исә, соң икән инде, агачыбыз корыган, ботаклары күккә карап,

алладан мәрхәмәт сорый. Караклык вак-төяктән башлана, Якубҗан. Хак әйтәбез, әмма котыртучылар бар, әйтик, мисалга ерак барасы түгел, Сирай — шуларның берсе. Булачак карак өчен әнә урлау да — мәктәп, инде кулына сәгать төшерә икән — институт тәмамлаган кебегрәк була, шуның янына квартир басарга да өйрәнсә — аспирантурага гына җибәрәсе кала тегене. Хикмәт шунда ки, Сирай котырта белә, гомерендә булган мавыктыргыч хикмәтләрне сөйли, акчаны мунча ташы урынына күрә. Ә без каракны тоткач кына җәзалыйбыз, чөнки закон шулай куша. Сирайны нык хәтереңдә калдыр, Якубҗан. Фәлсәфә сатарга ярата, үзенә күрә психолог, юрист, тагын әллә кем шунда. Кайчандыр яшь чагында җырлап йөргән, техникумда укып маташкан, ләкин алган белемен караклыктан ары җирдә кулланганы юк».

Якуб өчен мондыйлар дөньясы ят түгел иде, тикшерүче буларак, ул әлеге типлар белән һәркөн диярлек очраша, ләкин әтисенең ниндидер Сирай турында тәфсилләп сөйләве, житмәсә исеңдә калдыр дип кисәтүе аның күңелендә кызыксыну уятты. Әйтәсеме, Сирай кебек караклар үз гомерләренә урлашып яшиләр һәм моңа шул тикле күнегеп китәләр ки, бу эшләрен табигый хәл итеп кабул итә башлыйлар. Житмеш яшьләренә житкәч тә урлашып йөргән караклар бар. Бу шуларның берсе булыр, күрәсең. Бер тапкыр аңа картаеп барган ике каракны төрмәгә озатырга туры килде. Шунда барганда аларның берсе:

— Шайтан алгыры, бүген мунчага бара торган кенем иде, булмады инде,— дип сөйләнде. Хикмәт шунда иде: бу сүзләрне ул шул хәтле табигый итеп әйтте ки, әйтерсең чынлап та шулай иде, каракның иң зарур эше рәхәтләнеп мунча керү иде. «Димәк,— дип нәтиҗә ясаган иде шул вакытта ук Якуб,— каракларга карата безнең законнар йомшаграк, артык гадел, ахры».

Ул арада әтисе Сирайны үзенә дәшеп алды. Пенсиядәге милиционер алдына килеп баскач, Сирай башта аптырабрак калды. Юк, каушап калу галәмәте түгел иде бу, кинәт дәшүдән килгән халәт иде бугай, ләкин карак үзен шундук кулга алды, алдында гади киемнән торган пенсионерны абайлап алгач, ул әүвәл авыз чите белән елмайды:

— Әфган сагызы кирәк булдымы әллә, иптәш начальник?— диде һәм икенче мәлдә инде мыскыл иткән бер кыяфәттә: — Хәер, сагыз чәйнәргә тешләрең юктыр инде синең, картлач,— дип авыз ерды.

— Юк, миңа түгел, менә кунакка дип соравым. Тәмәке ташлаган чагы.

— Чегән,— диде артына әйләнми генә Сирай,— Чегән дим, анаңны ак бүре бугазлаган нәмәстә, бир әле теге әфган сагызын. Берәүнең тәмәке ташлаган чагы, ди әнә. Карале, Гата абзый, пенсиягә чыккач та шул этлегең ташламыйсың, ә?.. Неужели туймадың? Әйт әле честно гына, бу — кемең? Күргән дә бар кебек үзен... Хәтер саекты хәзер, әлек бер күрүдә таный торган ием лягавыйларны. Бу кеше лягавый түгелдер, аңа охшамаган. Шулай да кемең, ә?

— Минем малай булыр бу, Сиражетдин. Малай Урта Азиядә шахтада эшли, ялга кайтты. Эш табылса, бөтенләй дә калырга исәбе юк түгел.

— Әйтәм, Чыңгызда күргән бар кебек үзен. Картаябыз, хәтер саегайды. Эш табып булмый менә, рәтле эш.

— Теләмәвеңме, чынлап та эш юкмы? Эшкә тизрәк кер, житәр. Өч ел ял итеп кайттың.

— Санаторий түгел шул анда, Гата абзыкаем... Ә шулай да малаең үзеңә охшамаган.

— Әнисенә охшаган.

Гата аңа бер сум акча бирде.

— Сагызың өчен. Малай чынлап та тәмәке ташлап маташа. Яр-

дәме тимәсме, дим. Үзең беләсең, яман гадәтләрне ташлаулары ай-һай кыен.

— Хак әйтәсең, яман гадәт ярга илтер, әйбәт гадәт ялга илтер, ди торган иде бер тәрбияче теге йортта. Күнелең булсын, картлач, мин ул мәсьәләдә завязал. Добился своего, как никак ты — мой наставник. Ишетәсеңме, завязал! Ә бер сум акчаңны алмыйм, сагыз минеке түгел, ә чегән миңа бурычлы иде. Шулаймы, Чегән?

Сумаладай кара чәчле егет Сирай белән килешеп аяк какты.

— Мин сезне нигәдер хәтерләмим,— диде Якуб.

— Анысы хак. Ләкин белмәү — бер хәл, ә миңа белергә теләмәү бөтенләй икенче нәрсә бит.

— Күеп тор әле син минем малайны, Сиражетдин. Әйт әле, нигә үз тирәнә җыен тар балакларны җыясың. Янәдән кармак саласыңмы?

— Биллаһи-валлаһи, Гата абзый, алар үзләре мине эзләп таптылар. Мин дә тәмәкене ташладым ич, хатын көн бирми, тартасың икән шул черегән тиресеңне, куам да чыгарам, ди.

— Тирес дигәнең гашиш кушкан тәмәкеме?

— Гөнаһыга батма, Гата абзыкаем. Андый хәлләр тирәсенә якын барасы кеше түгел мин, әйттем бит, завязал. Ышанмасаң, менә Хәлилдән сора. Әй, Хәлил! Тәэминатчы егет ул. Менә дигән егет. Җаның ни тели, шуны табып бирә. Беләсең килсә, Хәлил, бу кеше — пенсиядәге милиционер. Бер урамда торабыз, капка аша гына күршеләр диярлек. Ике тапкыр яшерде бу абзыкай мине теге өйгә.

Сирай, авыз ерып, янәшәсендә басып торган Хәлил атлы егетнең шап иттереп җилкәсенә сугып алды. Коңгырт чәчле, урта буйлы егет Сирайның сугуына иңбашын тотып, чүгеп куйды.

— Сындыруың бар, Сирай абзый.

— Кара аны, Сиражетдин, соңы булсын,— диде Гата.

— Иртәгә эшкә керәм, Гата абзый.

— Нигә малаеңны Сорочига алып чыктың?

— Сагыз сорады. Җитмәсә американыкы булсын, ә ул нәмәстәне бер монда табып була. Шулай бит, улым!

Якуб этисе артынарак баскан бәләкәй генә малайга күз төшереп алды. Малай түп-кебек түгәрәк гәүдәле иде.

— Әйт әле, Сиражетдин, миңа ачуланмыйсыңмы? Как никак мин сине ике тапкыр утырткан кеше?

— Юк, ачуланмыйм, Гата абзый. Син булмасаң, башка берәү утырткан булыр иде. Аның шулай бетүе яхшырактыр да әле. Эләктермәгән булсаң, һаман саен узынып идем. Нәфеснең чиге юк бит аның. Без синең белән, Гата абзый, күптән мәче белән тычкан уены уйныйбыз бит инде. Нишләмәк кирәк, дөнья яратылганнан бирле шулай булган. Патшалар хәзинәсен берәүләр талаганнар, берәүләр саклаганнар. Син гадел булдың, Гата абзый. Какмадың-сукмадың, хөкем тарафдарларына илтеп тапшырдың. Үзем дә җитәр дим, Гата абзый. Әнә малай үсеп килә, хатын да бүтән ул эшеңә керешсәң, бусагамнан да кертмим, дип яный... Ярый, бигайбә, Гата абзый...

— Күрдеңме инде Серыйны?— диде Гата янәшәсендә басып торган Якубка, теге китеп баргач.— Күреп кал. Мәшәкать тудырачак әле бу кеше сезгә. Болай гына мескен булып күренә ул. Эче тулы ачу аның. Кемгә файда мондайларны иректә йөртүдән? Менә шуны аңламый йөдим мин, Якубҗан. Кайбер хатыннар ирләре эштән соңга калып кайтканда да ду киләләр, эшләр әллә кайларга барып җитә. Ә бу, эт ялаган нәмәстәнең, хатынына кул күтәргән чаклары була, әмма тегесе ник бер тапкыр җалу белән килсен. Шул хикмәтләрне аңламый йөдим мин. Вакыт бар, тирә-юньгә күз-колак саласың һәм шаклар катасың. Күп икән ул гыйбрәтле хәлләр бу дөньяда, бик күп икән, Якубҗан.

Этисе белән бу сөйләшүгә атна-ун көн узмады, Якуб үзе дә хатыны

тарафыннан бинахакка рәнҗетелде. Гөлбикә аны чын мәгънәсендә гаепләде. Тик торганда Вәсилә Хакованы Якубның сөяркәсе итте дә куйды. Нәкъ менә шул көннән ир белән хатын арасына салкын йөгерде бугай. Читтән караганда семьяда барысы да искечә, барысы да ал да гөл кебек иде, ә менә җентекләбрәк баксаң, тәүге татулык, эчкерсезлек гелән юк, ниндидер ясалмалылык, икейөзләнү яши иде хәзер тандада. Ике кыз бала үстерәләр, күп тә үтмәс, Гөлбикә дә әби булыр, Якубның да бабай буласы бар. Үткән гомер үтә бит ул, зурысы әнә быел мәктәпкә керәчәк. Кечесен Юлия Борисовна карый. Гел үз кызы итеп бетерде күршеләре балаларны. Олысына хәзердән үк җырлар өйрәтә, бала күңелендә музыкага кызыксыну уятты. Кыскасы, тыштан караганда бар да үз урынында кебек иде.

Якубның күңел түренә кереп калган хикмәтле хәбәр, агач корты сыман, аны һаман саен эчтән кимереп торды. Хатынын өйгә каләр кемнеңдер озатып куюы турында аңа бер милиционер әйткән иде. Ярый, берәү аны өйгә каләр озата да килде, ди. Озата бирсен, рәхмәт кенә аңа моның өчен. Якуб белә, Гөлбикә ир-ат компаниясен ярата. Соңгы вакытта аларга начальник урынбасары Бахтин килгәли башлады. Бахтин күп сөйли, дөнья күргән кеше, хатыны да аннан калышмый, әмма ире халыкара хәлләр турында сөйләргә яратса, хатыны күбрәк чүпрәк тирәсендә әвәрә килә иде. Бахтин үзе дә, хатыны Сария дә Якубка ошамыйлар, ләкин нишләмәк кирәк, алар Гөлбикә белән бергә эшлиләр, Якуб аларның гамь-гапләрен сәгатьләр буена тыңлап утырырга мәҗбүр. Бәхәсләрдә Бахтин кызып-кызып китә, кешеләр турында үз фикерен кистереп әйтә, мин алай итмәс идем, болай итәр идем, дип шапырына.

Ул да түгел:

— Һәр семьяның үз бәхете бар,— дип, Бахтин урыныннан кузгала

Якуб белә, шул җирдә аларның дөньяви хәлләр турында бәхәсләре тукталачак. Бәхәс сөреше һәрчак фәлсәфәгә көйләнгән Бахтин, ниһаять, шкафтан китап ала, тавыш-тынсыз гына укып утыра башлый. Ул арада Гөлбикә белән Сария әйләнеп керәләр, Сария Кәримәне җитәкләгән.

— Бер халык та культурасыз була алмый, культурасыз халык булмаган кебек, уйлап тапкан культура да була алмый,— диде бер мәлгә тынып калган Бахтин.— Мин моны нидән әйтәм, ясалма сәнгать тудыру мөмкин түгел, ә кайберәүләр аны булдырырга маташалар. Сәнгатьнең иң югарысы — халыкта.

Якуб дәшми, аңа урамалы фәлсәфәләр ошамый. Бахтин китабын читкә куя, Зөлфия янына килә дә, аның алдына чүгәли.

— Кем булырга инде исәбең, Золушка?

— Җырчы.

— Oho!— ди Бахтин.— Молодец,— дип кызның аркасыннан сөя.

— Ә син?— дип Кәримәгә борыла.

— Милиционер,— ди кыз.

Якуб елмаеп куя, хатыннар көлешәләр, Бахтин гаҗәпләнеп күзләрен зур ача.

— Менә җавап инмасам. Молодец, кызым!

Карт иманга аркасын терәп, Якуб бик озак уйланып басып торды.

Лифт эшләми иде, Якуб бишенче катка әкрен генә күтәрелде, шулай ук сабыр гына кыңгырау төймәсенә басты.

— Син!— диде Гөлбикә, аның шактый соңга калып кайтуына гаҗәпләнүен яшермичә.— Кая болай йөрдең?

— Эш чыкты,— диде Якуб, чишенә башлап.

— Бер дә бүтән түгел, теге кәнтәен янында булгансыңдыр әле.

Якуб, иелеп, туфли бавын чиште, кәнтәй сүзен ишетүгә, тураеп басты.

— Ни булды сиңа? Нинди сүз таба бит, шаккатырсың бу хатын-кызга. Мин бит синнән беркайчан да кем белән кайтасың, кем сине озата, дип сораганым юк.

— Сора, нигә сорамыйсың?

— Сорасам, ни әйтерсең?

— Бер яшь егет озатып куйды, диярмен. Син каршы алмагач, концертларга йөрмәгәч.

— Рәхмәт, куандырдың. Ул сине һәркөнне озатамы?

— Озатса гына бер хәл, ярата хәтта. Һәм мин аңа син мине яратма, минем, һәр көн булмаса да, көн аралаш ике-өч сәгатькә соңга калып өйгә кайта торган ирем бар, дип әйтә алмыйм. Әйтүдән ни файда... Ул мине барыбер яратыр иде.

— Һәм син аның шул сүзләренә ышанасыңмы?

— Без, хатын-кызлар, ялган яратуга да ышанучан, чөнки чынын бик аз күрәбез.

— Димәк, мин сине яратмыйм булып чыга.

— Мин алай дип әйтмәдем. Бар әле, әүвәл балаларны алып чык, аннары кем кемне яратуын ачыкларбыз.

«Күрче, нинди гап-гади хәл икән бит бу ярату дигән нәрсә,— дип уйлады Якуб.— Әгәр дә мәгәр кем дә булса сине ярата икән, син бит аңа мине яратма дип әйтә алмыйсың. Әйтүдән ни файда, ул барыбер сине яратудан туктамас иде».

— Тәрәзә төбендәге алтын булавка Вәсилә Хаковanыкы идеме?

— Җитмәсме шул булавка турында!

— Җенем сөйми ялганлаган кешене. Юлия Борисовна сине коткарды да, котылдым дип уйлыйсыңдыр? Юк, Якубҗан, юк, мин бу хәлне гомерем буена онытмаячакмын. Бәлкем, синең белән аның арасында берни дә булмагандыр, әмма син аңа барыбер битараф түгелсең. Ашханәләргә дә бергәләп йөрисез икән. Син, Якубҗан, күзгә ташлана торган кеше бит, гади кеше түгелсең. Иң әүвәл шул турыда онытмасаң иде.

— Тагын шуңа охшаш берничә яңа хәбәр җиткерсәң, мин сине, биллаһи дип әйтәм, үз бүлегемә эшкә алам. Иманым камил, менә дигән тикшерүче чыгачак синнән, Гөлбикә.

— Нинди әйбәт тикшерүче булсаң да, яхшы конспиратор була алмыйсың, шуңа күрә хатын-кыздан сер саклама. Хатыннан сер саклаган ир я үлә, я туңа. Уңганы сакламый, туңганы — уңмый. Иң яхшысы: моннан ары миннән сер саклама, Якубҗан.

— Ярый, шулай итәрмен, син дигәнчә булыр. Беттеме сүзең? Бетсә, чәй эчик тә ятыйк, арыткан...

Балаларны йокыга салгач, урынга алданрак ауган Якуб, хатыны да килеп яткач, әйтә салды.

— Әллә нишләдең әле син, Гөлбикә.

— Ә син, Якубҗан? Син барысына да әйбәт булырга телисең. Ә мин — хатын-кыз, ә хатын-кыз ирләрнең бу сыйфатын үзенчәрәк күрә. Кемдер озаткан икән, шикләнмә син, мин аны якын да китермәячәкмен... Без бит бергә эшлибез. Иртәгә шимбә, балаларны курчак театрына алып барырсың. Ә хәзер йокла. Арыдым мин,— диде Гөлбикә.

Иртән аш янына утыргач, Гөлбикә аңа карап-карап торды да:

— Кичәге өчен гафу ит, Якуб, яме? Ишетәсеңме, Якуб, сиңа әйтәм, куеп тор әле баланы. Зөлфия кызым, бар әле апаең янына чык.

Зөлфия күрше бүлмәгә чыгып киткәч, Якуб шым булды. Ирнең нерв җепселләре, каравылда торган солдатныкыдай, тартылып китте. Тагын ни әйтер? Ирнең кызыксынуы соң чиккә җитте.

— Кичер мине кичәге өчен, Якуб...

— Кил әле бире,— Якуб хатынының кулыннан алды.— Моннан соң син дә юк-бар белән мине борчыма, яме?— Һәм Якуб беренче тапкыр

үзенең ялган сөйләвен тоеп алды, шул хәлгә колакларына хәтле кызарып чыкты. Ярый әле аның бу халәтен Гөлбикә сизми калды.— Тату яшик, кем дә бу дөньяга ике гомер яшәү өчен килмәгән.

Якуб хатынының күзләренә карады һәм гаҗәпләнеп калды: ул аңа ышанмый, ирен чите белән генә елмаеп тора иде.

— Кирәкми ул турыда, Якубҗан. Бар, эшеңә кит, соңга калырсың.

— Зөлфия быел укырга керә, Кәримәне комбинатка бирикме әллә? Юлия Борисовнадан яхшы түгел, акча бирсәң, алмый...

— Риза булгач, карый бирсен.

— Алайса үзең сөйләш.

— Бар, бар инде эшеңә, соңга калуың бар,— диде Гөлбикә.

5

Кәримәгә өч яшь тулгач, әтисе кызны балалар бакчасына илтергә иткән иде, Юлия Борисовна бирмәде. «Кирәкмәс, Якубҗан, аерма балаларны, үзем карыйм»,— диде. Чынлап та, беренче көннәрдә Зөлфия сеңелесеннән башка күңелсезләнде, әмма тора-бара күнекте, музыка мәктәбенә йөри башлады, әнисе шулай теләде, Якуб каршы килмәде. Яши-тора алтын булавка да онытылды. Гөлбикәне коллективта хөрмәт итәләр, профсоюз комитетына член итеп сайладылар. Җитмәсә квартир мәсьәләләре буенча комиссия члены иттеләр. Ничәмә ел узды. Кайчандыр артыннан киләп сарган Хәлил дә югалды. Гөлбикә аның тормышы белән кызыксынмады, үз борчулары үзенә бик җиткән иде.

«Өйләнгән синең теге хикмәтең, эчә икән»,— дип әйтте Гөлбикәгә көннәрдән бер көнне Бахтин хатыны. Гөлбикә бу хәбәрне җиткерүчегә ачуланмады, әмма бик үк кинәнү дә тоймады. Күңелдә нindidер, менә кадәр үзе дә аңлап та, төшенеп тә бетмәгән кимсенү бар иде. Кем өчен? Хәлил өченме, үзе өченме?.. Менә шуны аңламый иде ул. Бер карасаң, Хәлил аңа дөньяда әллә бар, әллә юк, шул ук вакытта аның кемгәдер өйләнүе, эчә башлавы кызганыч иде. Ир-ат иң әүвәл, гаиләдә мәхәббәтен югалтса, эчүгә башын сала, аннары — эшендә уңмаса...

Әнә шулай дөнья куып яшәп ятканда, ике елдан артык вакыт узгач, көтмәгәндә, Хәлил контроль һәм ревизия идарәсендә пәйда булды.

Гөлбикә аны идарәгә килеп кергәч тә күрде. Хәлил борынгы бинаның сырлап ясалган диварына сөялеп тора иде, Гөлбикәне күрүгә, аңа таба китте.

— Гөлбикә!

Ул кыю кыланды, чәче җиткән, башында бүреге юк (хәер, ул хәтле суык та түгел иде әле, октябрь ае), юка пальто якасын күтәргән, куллары кесәдә.

— Исәнме, Хәлил.

— Исәнме, Гөлбикә. Сине күрер көн дә бар икән, бәгырь.

— Нигә алай дисең, Хәлил?

— Ишеткәнсеңдер инде, өйләнгән идем бит... Аерылыштык,— диде ул, күзләрен каядыр читкә яшереп.— Эчәсең дип бугазга баса. Ә мин кеше, кеше, Гөлбикә,— дип әйтеп, хәтта күкрәген дә киеребрәк куйды Хәлил.

— Син әле дә эчкәнсең түгелме, Хәлил?

— Эчтем. Аңа ачу итеп эчтем, ну, киттем мин аннан.

— Ул куып чыгарды, диген.

Хәлил аңа, моңсу күзләрен күтәреп, туры карады.

— Каян ишеттең? Син һәрчак минем уй-фикеремне укыдың, Гөлбикә. Син — фәрештә, алиһә минем өчен, бәгырь. Шулай булып калырсың да. Ә мин сине һаман оныта алмыйм...

— Их, Хәлил, Хәлил. Минем кызларым үсә, көт, олысын кияүгә бирермен.

— Мыскыл итәсең.

— Итмәслекме. Минем ирем — подполковник, әйбәт кеше. Син кем?

— Төшеп калган бер бәндә.

— Хак әйтәсең, эчү ихтыяр көче булмаган ир-атка гына килешә, Хәлил.

— Әйе, мин подполковник түгел, мин кечкенә кеше. Әмма бу матди дөньяга карата минем дә үз фикерем бар.

Башта Гөлбикә аны битараф бер төстә генә тыңлады, егет белән бөтенләй сөйләшәсе килми иде аның.

— Хәлил, минем кәефем юк бүген...

— Нигә син бер дә минем кәефем турында сорамыйсың? Нигә соң син гел-гел үз кәефең турында гына кайгыртасың?— дип, кисәк кенә үпкәләп куйды Хәлил.

Гөлбикә күзләрен күтәреп караса, аларга таба идарәнең начальник урынбасары Бахтин килүен күрде. Бахтин килә килешкә — исәнмесез юк, саумысыз юк — Гөлбикәне култыклап алды һәм, начальник чакыра дип, олы коридор буйлап кабинетка таба алып китте.

— Гөлбикә,— диде аңа Бахтин, мәгънәле елмаеп.— Үртәмә син аны. Ишетәсеңме, үртәмә. Килешми.

Гөлбикә, күзләрен елтыратып, гаҗәпләнеп, урынбасарга карап алды, шул ук вакытта күңелендә нинди дер ризасызлык тууын сизде.

Начальник кабинетыннан чыкканда Хәлил шунда, сырлы диванга сөялгән килеш, басып тора иде әле. Артыннан чыгып килгән Бахтинга ачулы караш ташлап, Гөлбикә янәдән Хәлил янында тукталды.

— Начальнигың нигә чакырган?— дип сорады Хәлил.

— Японияга туристик путевка бар. Миңа бирергә булганнар.

— Японияга?! Барасыңмы, риза булдыңмы?!

— Бармый, ди, җүләр, барам.— Гөлбикә аңа көлемсерәп, хәтта бераз мыскыллап карады.— Японияга китә дип боектыңмы әллә? Аның каравы, кавышулар күңелле булыр.

Хәлил күзләрен түбәнгә төшерде, берчак аякларына карап торды, аның аягы идәнгә түгәрәк сыза иде.

— Син көләсең, һаман миннән көләсең,— диде Хәлил, көрсенеп.

— Их, җүләр син, җүләр...

— Мәхәббәттә кеше һәрчак җүләр булды. Мин синең белән очрашу көннәрен һәрвакыт зарыгып көттем, Гөлбикә.

— Тирә-юньдә ниндәен кызлар, Хәлил...

— Миңа синнән башка берәү дә кирәкми, Гөлбикә.

Ул шулай итеп карады Гөлбикәгә, хатын ни әйтергә белми тотлыгып калды. «Чынын сөйләсә?»— дигән уй яшен тизлеге белән миен көйдереп узды.

Гөлбикә Японидә өч атнага якын йөреп кайтты. Машинага балаларын, Юлия Борисовнаны утыртып, Якуб вокзалга үзе төште.

Перронда бит очларыннан тыенкы гына үбешеп күрештеләр. Аннары Гөлбикә балаларын кочагына алып:

— Я, сандугачкайларым, кайсыгыз ныграк сагынды инәкиегезне?— дип сорады.

— Мин! Мин! — диештеләр балалар, бер-берсен уздырырга тырышып.

— Ничек йөреп кайттыгыз?— дип сорады Якуб, машинага таба кузгалгач.

— Әйбәт йөрдек. Дөнья кадәр могҗизалар күрдем, Якубҗан, сөйләрмен, барысы турында да җентекләп сөйләрмен үзегезгә.

Шул вакытта Гөлбикә бер читтәрәк басып торучы Хәлилне күреп алды һәм йөрәге дерт итеп китте. Ул караган якка Якуб та күз ташлап алды, һәм ул да егетне күрде, ирен чите белән генә елмаеп куйды. Боларны сизеп өлгергән Юлия Борисовна һәммәсен машинага таба әйди башлады. Хәлилнең кулында чәчәкләр иде.

Гыйнвар ае. Коры салкын, әмма түзмәслек суык түгел иде. Гөлбикә, Якуб биргән чәчәкләрне тотып, машинага таба атлады. Арткы урындыкка балалары янына кереп чумуы булды, Зөлфия анын тезләренә менеп утырды, моны күреп, кечкенәсе дә кузгалган иде, Юлия Борисовна аны алгы урындыкка алды. Алга утыргач, бала тынычланды, анасы турында әллә онытты да инде. «Кече кызым миннән әллә ятсына инде, әллә бизеп беткән»,— дип уйланды Гөлбикә.

Алдында утырган Зөлфия: «Инәки, инәки, телисеңме, яңа жыр жырлыйм үзеңә»,— дип сырпалана, ә Гөлбикәнең күз алдыннан перронда чәчәкләр тоткан Хәлил китми. «Җүләр, килгән бит, житмәсә чәчәкләр тотып килгән. Нигә кирәк инде. Ә шулай да рәхмәт сиңа, Хәлил. Каршы алырга килгәнең өчен рәхмәт, онытмаганың өчен».

Гөлбикә балаларның икесенә дә маймыл-курчаклар алып кайтты, өйгә керү белән балаларына шул курчакларны бирәчәк. Якубка — бәрхет костюм, ә Юлия Борисовнага чуклы шәлъяулык һәм роза чәчәкләре төшкән атлас халат кайта. Юлия Борисовнага Гөлбикәнең рәхмәте чиксез зур. Зөлфияне балалар бакчасына бирдертмәде, үзе карады. Кәримәсен дә карый. Зөлфия инде матур гына жырлый белә башлады. Бер тапкыр шулай МВД работниклары чыршысына бардылар. Зөлфиянең яңа тәпи йөри башлаган чагы (соңга калыбрак йөреп киткән иде). Кыш бабай Зөлфияне, житәкләп, чыршы янына алып китте. Шунда бер хикмәт булып алды. Бала, күрәсең, Кыш бабай чыршы янына алып килгән балаларның жырлавын күреп, күзәтеп торган. Чыршы янына килеп басуга, Зөлфия Юлия Борисовна өйрәткән «Чишмә» көен башкарды. Әйләнә-тирәдәгеләр һәммәсе тын калдылар. Бу ни хикмәт, бияләй зурлыктагы кыз нинди матур көй чыгара. Ә бит сөйләшә дә белми кебек әле. Жыр беткәч, Кыш бабай Зөлфиягә капчыгыннан бер кушуч конфет алып бирде, ә жырчы кызчык аңа хәтта рәхмәтне дә «ләхмәт» дип кенә әйтә алды. «Сөйләшә белми әле ул»,— диде шунда Гөлбикә.— «Сөйләшә белми, ә нинди жыр башкара!»— дип гажәпләнде Кыш бабай һәм кызга тагын бер кушуч конфет бирде. Халык көлеште. Ышанмаган кешеләр дә булгалады, кайберләре — аеруча кызыксынганнары — Гөлбикә янына килеп, баланы сөйләштерергә тырышып карадылар. Бала чынлап та сөйләшә белми иде әле. Әмма үтә кызыксынган бер ханым: «Әйдә алай булгач, жырла»,— дигәч, бала янә көйләп жибәргән иде. Әй шатланган иде дә соң Зөлфиясе өчен ана. Хәер, Якуб та бик шат иде кебек, ул да анын янында басып тора иде.

Бөтен жирдә ап-ак кар. Туган илгә исән-имин кайту Гөлбикәнең дә күңелен ап-ак кардай агартты. Якубы, ике баласын утыртып, аны каршы алырга килгән, кайтуына шат, шатлыгы йөзенә үк чыккан, әнә бара-бара да әйләнеп карый, карый да елмая.

— Юлия Борисовна,— дип сорады Гөлбикә,— өйдә бик суык түгелме?

— Якуб батареяләр өстәтте, бик жылы. Балалар рәхәтләнеп идәндә аунадылар. Син беләсеңме әле, Кәримәң син юк чакта кубиклардан «әти» сүзен жыярга өйрәнде.

— «Әни»не жыя белмиме?

— Әтисен күрә дә «әти»не жыя. Менә хәзер әнисе дә кайтты, «әни» дә жыярбыз, әйеме, Каракүз,— дип Кәримәне күкрәгенә кысты Юлия Борисовна.

— Рәхмәт инде, Юлия Борисовна, сез булмасагыз, нишләр идем икән мин, белмим.

— Беркая да чыкмас иден, шул гына. Халык анда, Япониядә ничегрәк яши соң?

— Ярлысы — ярлы, бае — бай анда, Юлия Борисовна. Болай начар яшәмиләр кебек. Аларда бездәге кебек түгел шул, өсләренә бер кием житә. Безгә генә ул кышын-җәен биш-алты төрле кием-салым тотарга туры килә. Якуб, Якуб дим,— диде Гөлбикә, үзе дә тәүге сүзне онытырга тырышып,— этиләр, энкәйләр ни бетереп ята? Исән-саулармы? Бер барып мунча керәсем килә үзләренә.

— Таштай-тукмактай дөнья куып яталар. Инәй генә чирләштергәләп йөри, кан басымы күтәрелә төшкән бугай, әтәй миләш төнәтмәсе юнәтеп йөри иде үзенә.

— Сагындыра икән чит-ят җирләрдә. Ил чиген үткәч, күңел тулышып китте. Кайтып төшүгә, һичнигә карамый кар өстенә ятып аунармын дигән идем, сезне күргәч, барысы да онытылды тагын.

## 6

Якуб моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Перронда кыска тун, мескен бүрек кигән, житмәсә кулына роза чәчәкләре тоткан егетне искәргән иде ул. Гөлбикәне күрүгә, егет ничектер аңа таба ымсынып куйды. Егетнең гәүдәсен күз алдына китерүгә, Якуб, бәйләнчек черкиләрдән арынырга теләгәндәй, баш-кулын чайкап куйды. Бу хәлнең чын булуына әллә нигә ышанасы килми иде аның.

Кухня ягында эшләре саега төшкәч, Гөлбикә ире янына килеп утырды.

— Нигә уйга баттың, Якубҗан?..

— Уйланырдай гасырда яшибез, Гөлбикә. Үзең ничек йөреп кайттың соң? Бик кыен булмадымы, безне искә төшергәләдеңме?

— Якуб, Якубҗан, бу ни дигән сүз инде тагын. Мин сине бик тә, бик тә сагындым.

«Ә теге роза чәчәкләре тоткан егет?»— диясе килде Якубның, әмма әйтмәде, тыелып калды. Гөлбикә өстенә чит илдән алып кайткан эреэре парчалы ефәк атлас халат кигән һәм, шуңа күрәме, Һинд киноларындагы кайсыдыр артистканы хәтерләтә иде.

Ул арада бүлмәгә Зөлфия белән Кәримә килеп керделәр.

— Кызларым-йолдызларым! Килегез әле, килегез, икегез ике теземә утырыгыз. Менә шулай,— балалар ананың икесе ике тезенә менеп утырдылар,— хәзер әйтегез инде, кайсыгыз ныграк ярата инәкиегезне?..

— Ул,— диде Кәримә, апасына төртеп күрсәтте.— Мин — этине.

— Әһә, мин юк арада сез этиегез белән икәвебезне бүлеп тә куйдыгызмыни әле! Кара син боларны, этиләре! Ә менә мин дә этиегезне сагындым.

— Этием — минеке,— дип янә кабатлады Кәримә һәм, энисе тезеннән төшеп, этисе алдына кереп утырды.

— Я ходаем, күрче берәүне,ниләр кылана бит!— Гөлбикә тезенә утырган Зөлфияне бер читкә бастырды да этисе алдында утырган Кәримәне йолкып алды.— Юлия Борисовна, Юлия Борисовна, күрче әле монда берәүне, ни ди. Эти минеке, эни Зөлфиянеке, дип маташа.

Гөлбикә баланы үчтеки итеп сөя-сөя, чут-чут үбә башлады, күкрәгенә кысты, аркасыннан ләпәде.

— Ә ул кызың чынлап та этисен ярата төшә,— дип килеп керде бүлмәгә Юлия Борисовна.— Сине, ичмасам, исенә дә төшереп карамады. Эттәсе булса, беркем кирәкми аңа. Шулаймы, Каракүз. Ай күзләре, тач этисенеке инде, чем кара кашлары тагы! Моннан соң мин аңа Каракүз дип дәшәм әле. Ярыймы, дәшимме шулай?— Юлия Борисовна баланың кулыннан алды.

— Э-эк, кирәкми,— диде бала.
— Минә синә мә, Каракүз кирәкми була димени.
— Һай алла, гел онытып җибәрә язганмын бит. Кая әле, этиләре, китер әле әнә теге зур сумканы. Мин бит сезгә бүләкләр, күчтәнәчләр алып кайттым.
...Гаҗәп хәл, Якуб Гөлбикәне көнләми иде. Сыек кына гәүдәле, өрсән, мамыктай очарга торган егет-җилбәзәкне арага кертү ничектер аңа килешмәстәй бер нәрсә кебек тоелды. Юк, ул Гөлбикәне чынлап көнләмәде, бары тик гайбәттән генә курыкты. Ул хәзер дәрәҗәле кеше, милиция подполковнигы. Ә бит Якуб аз гына соңга калган булса, Гөлбикәне әлеге егет каршы алачак иде. Кызык, Гөлбикә ни әйткән булыр иде икән аңа? Алыр иде микән егет кулыннан чәчәкләрне? Кыш уртасында роза чәчәкләре кимендә ун-унбиш сум торадыр. Якуб хәтта егеттән бераз көнләшеп куйды. Аның чәчәкләре канәфер генә иде, ә егет кулында роза чәчәкләре... Әй, куйсана! Кырык яше тулып килә, ике баласы бар һәм шул яшендә көнләшеп тор имеш. Кемнән диген әле. Кимендә үзеннән ун-унбиш яшькә яшьрәк бер тар балактан. Дөрес, Гөлбикә белән аның бу турыда сөйләшәсе килмәде, ул гынамы, егетне гел күрмәгән дә, белмәгән дә кебек йөри бирде. Әмма моның белән генә Якубка җиңеллек килмәде. Юк-юк та, роза чәчәкләре тоткан егет күз алдына килә. Нигәдер егетнең күшеккән кулларына күзе төшкән иде аның. Шактый салкын иде, ә аның куллары ялангач. Чәчәкләргә салкын тияр дип тә уйламады микәнни? Роза чәчәкләренең таҗлары зәгыйфь була, аз гына салкыннан да куырылырга тора, ә ул шундый суык көнне чәчәкләрне ачып куйган. Күрсеннәр дип кылануы булдымы? Нигә, шулай булуы да бик ихтимал. Ире өч бөртек канәфер чәчәге алып килгән, җитмәсә аның да берсен Кәримә сындырды, ә менә теге егет роза чәчәкләре тоткан. Бер уйлаганда офтанып урын да юк кебек, мәгәр күңел ни сәбәпледер гел шуңа әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта.
Әнә шундый хикмәтле уйлар белән саташып йөрде Якуб соңгы вакытта. Куанасы гына иде югыйсә, өч атнадан артык чит илдә йөргән хатыны исән-сау әйләнеп кайтты. Өйгә шатлык керде, балалар, Юлия Борисовна нишләргә белми куандылар. Ә ул менә куанмый, уйлана.

— Бабайларга җиттек, бабайларга җиттек,— диде Зөлфия, машина урыс капкалы йорт янына килеп туктауга. Барысы да коелып төшеп калдылар, машина китеп барды.
— Түү-ү китте,— диде бәләкәй Кәримә.
Ул арада капкада Якубның этисе Гата карт күренде.
— Күрче боларны, киленне .дә алып килгәннәр. Саумы, килен, исәнме! Исән-сау йөреп кайттыгызмы?.. Бәй, шулай дими, күрше өлкәгә генә бару түгел лә. Ә син нигә дәшми торасың?— дип, кечкенә Кәримәне кулына күтәреп алды карт.— Әбиең сине коймак пешереп көтеп тора анда.
— Мин дә коймак яратам,— диде Зөлфия.
— Җырламыйча беркемгә дә коймак бирү юк,— дип кырт кисте Гата бабайлары.
— Анысын тиз эшлибез без аны, кызым, шулаймы,— диде Якуб, икенче баланы кулына алып ишегалдына юнәлде.
— Инәй ни эш бетереп ята?
— Коймак пешерә дим ич,— диде Гата карт.— Без сезне иртәрәк көткән идек. Мунчаны иртәнге сигездә үк уздырып куйган идем инде.
Ишегалдына кергәч, Гата карт Кәримәне болдырга бастырды һәм: «Бар, әбекәеңә йөгер»,— дип өйгә кертеп җибәрде. Зөлфия дә Якуб кулыннан төшеп, өйгә ашыкты. Гөлбикә аларга иярде.

Якуб әтисенең янагында зур булмаган яра эзен күреп алды, Гөлбикә өйгә кереп киткәч, сорап куйды.

— Ни булды, утын тидеме әллә?

— Утын, ди. Сукты бер тилесе, көтмәгәндә-нитмәгәндә. Ике-өч өй аша гына менә дигән бер кеше яши, заводта слесарь булып эшли. Сирай шуны тик торганда эчерткән. Тыныч кына кеше инде теге. Җырлап-җырлап эчерә Сирай моны, бу эчә, исерә. Күпме кирәк эчми эчкәнгә. Шуннан, эт яламаган нәстә түгел диген син аны, көпә-көндез аракы урларга котырталар. Урлап килсәң, имеш, менә сиңа йөз сум акча. Урлый алмасаң, үзең бер литр куясың. Бер литр аракы һәм йөз сум. Тәмам күзе кыза теге бичараның. Бәхәсләшәләр. Караклар арасында бәхәс яман бит ул, үзең беләсең. Ну, теге бичараны, әлбәттә, башта эчергәннәр, кәртле уйнарга мәҗбүр иткәннәр, аннары, тегенең бер тиен акчасы да калмагач, бәхәсләшкәннәр. Аларга, әлбәттә, кызык. Кеше ни аларга. Теге арткы ишектән килеп керүгә, милициягә шалтыраталар. Килеп тә җиталәр, безнең егетләр дим, теге бичараны эләктереп тә алалар, милициягә үк алып килмәкчеләр. Җитмәсә сатучысы... әллә инде Сирай белән бер сүздән булган: «Бу кешенең безнең кибеткә беренче тапкыр гына аракы урларга керүе түгел инде»,— дип тора. Ярый әле вакытында килеп җиттем. Беләм бит ул иләк авыз кибетченең кем икәнен. Оят түгелме сиңа, дим. Шуннан теге шым булды. Сирайның эзе дә юк. Алып калдым, үземә бирегез, бу кеше минем күршем, гомер эчкән адәм түгел, кичерегез бер юлга, дип алып калдым. Тегене өенә илтеп куйдым. Юлда бер егет бәйләнде бит. Шома гына киенгән, әдәпле генә сөйләшә бу. Бәйләнепме бәйләнә. Бу кеше минем биш сум акчамны эчте, дип бәйләнә. Я акчаны кайтарып бирә, я мин аның пинжәген салдырып алам, ди. Салдырырмын мин сиңа, дим. Шуннан килде дә бу теге бичараның изүеннән алды, ә миңа: «Батя, яхшы чакта китеп котыл!»— дип яный. Түзмәдем... Пенсиядә бит инде... Андый нахалларның ипи шүрлегенә менеп төшәргә дә ярый, милициядә эшләгәндә икеләнеп торадыр ием әле. Ямадым мин моңа берне. Чәчрәп барып төште. Кай арада таш тапкан, кай арада ыргыткан диген син аны, күздән утлар чәчелгәндәй булды. Үзе сызды, белгәндер, тотсам, ботарлап ташласымны. Күрше хакы, тәңре хакы, диләр бит, илтеп биргәч, хатыны күрде дә моны аһ итте. Соң, гомер булмаганны. Язвенник икән үзе, эчкәне булмаган бичараның... Әле әнә күргән саен: «Гата абзый, сез булмасагыз, үтерәләр иде мине бандитлар,— дигән була.— Имеш, черт попутал»...

— Кайчан ташлыйсың инде шул гадәтеңне. Синең үзеңә дә элгүе бар бит.

— Менә нинди гадәттер инде, шушындый эшләргә катнашмаска ант эчәм, әмма яман эш эшләүчеләрне күрдемме, гел антым онытыла да китә.

— Аксак көенә. Пенсиягә чыккач, пенсионер булырга вакыт инде.

— Син улым, миңа кагылма. Син миңа менә шуны әйт. Нигә соңгы елларда шәһәрләрдә хулиганнар ешайды, социаль сәбәбен ачып бир син аның миңа. Бар да сез сөйләгәнчә генә барса, кимергә тиеш иде югыйсә. Тик әллә нигә арта баралар. Ә сәбәбе бер аның, менә миндәйләр азайды, битараф халык килә милициягә. Мин сиңа тимим, син дә миңа тимә. Менә аларның принциплары. Барысыныкы да димим...

— Атасы, коймак ашарга керегез!— дип тәрәзәдән кычкырды әниләре.

Агач өйнең исе үк тәмле иде, бүлмәләргә таба исе дә тулгач, Якуб әллә кайчан үткән яшьлеген, малай чагын исенә төшерде. Шушындый ук кыш көнендә, уйнап туйгач, я тәгаен туңа башлагач, өйгә кайтып керер иде дә Якуб, итек-тунын тиз-тиз салып, мич башына менеп китәр иде. Мич башында үзенә бер дөнья, үзенә бер оҗмах, җылы, рәхәт, укып бетермәгән Жюль Верн китабы. Әтисе өйдә юк, әнисе борчымый.

Салкын тыштан җылы өйгә кергәч, нигәдер Якуб шул чакларны искә төшерә. Кайтарып булса икән шул чакларны!.. Юк шул инде. Ике балаң, хатының бар.

— Инәй, исәнлек-сәламәтлекләр ничек?.. Әйбәтме?.. Әтәй бик рәнҗетмиме?— дип елмайды Якуб, табын янына утыра-утыра.

— Кем кемне рәнҗетә бит әле,— дип әлеп алды Гата карт.— Инәңнең талканы коры аның. Кичләрен капканы бикләп куя башлады. Ике тапкыр капка өстеннән кердем инде.

— Йөрмәссең биләмдә ярты төнгә чаклы. Йомшак түшәгем, җылы юрганым суытып сиңа капка ачып йөрим тагын. Элек зарыгып көткән көннәрем өчен дә үкенеп бетә алмыйм әле. Китәр иде дә, ике-өч көнгә югалыр иде. Ни хәбәре, ни үзе, тәрәзәдән карап зарыгып бетәр идем үзен, төн йокыларым йокы булмас иде. Аллага шөкер, пенсиягә чыкты, күрше-күләндә белән әкият сатып соңга калса калыр, кайтмый калмас, кайтыр.

— Син, карчык, ул хәтле яманлама әле картыңны. Хәзерге балалар башка камырдан әвәләнгән, әллә син бар аларга, әллә юк. Ә менә картың сине төннәрен торып капшап карый, урындамы, янәсе, шайтан күтәреп алып китмәгәнме карчыгын.

— Шайтанга да кирәк түгелмендер инде мин хәзер, картыкаем.

— Алай димә. Тигез картаюга ни җитә. Әнә Нәҗметдин, карчыгын алданрак озатты да бер ялгызы тик каңгырып йөри. Өйләнер иде — рәтле карчык калмаган; кайсының итәк тулы оныклары, кайсы үзен көчкә йөртә, кайсы артык яшь. Дөнья дигәннәр аны картлар. Карчыгы исән чакта, бахыр, кадерен белмәде, кул тидергәне дә булгалады, бер ялгызы калгач, әнә сагына бичараны, юкка рәнҗеткәнмен икән, дип куя хәзер... Әй, гел онытып язганмын, килен, әллә мәйтәм, балалар белән баш мунчага сез барасызмы? Мунча тиккә суынмасын иде, диюем.

Гөлбикә белән балалар мунчага киткәч, Гата карт улына сәерсенебрәк карап куйды.

— Килен ничек йөреп кайткан?.. Ник дип, кәефе юк сыман. Түгәрәкләнгән дә бугай бераз, әллә мәйтәм, өченчегә тырышуыгызмы? Малайга...

— Син нәмәстә сөйләп торган буласың тагын, картлач. Үзләре белерләр. Барысына да кысыла.

— Шаулама әле син анда. Әнә камырың сүрелмәсен.

— Нигә ипине кибеттән генә сатып алмыйсыз?— диде Якуб, сүзне икенчегә борып җибәрергә теләп.

— Әтиең мичтә пешкән әпәй ярата. Гомер шулай ипи салдырып интектерде инде ул мине...

Әнисе мич янында кайнаша, билендә алъяпкыч, күлмәк итәген билбавына кыстырган.

— Син, карчык, тәк юкка сукранма әле. Мичтә пешкән әпәйне син үзең дә бик яратасың. Кибет ипиен ашарга теше үтми, имеш. Онытың мени, үзең ипи кибетендә эшләгән кеше бит син. Үз өем булса, мич салдырам һәм гомер буена мичкә салган ипи ашатырмын үзеңә дип әйткән иең...

— И-и, шаярып әйткән нәмәстәне онытмый икән тагын үзе.

— Үзеңә кагылган нәрсә онытыламы, тиле...

Якуб әтисе белән әнисе арасында булгалый торган бу үртәшүләрне ярата иде. Шаярып әйтәләр кебек, ә ничек күңелләрен рәнҗетми генә бер-берсенә җиткерәләр. Ул хәтта картлардан, аларның үзара тату яшәүләреннән көнләшеп куйды.

— Совет районында үтерелгән карчыкның эшен кемгә бирдегез?— дип сорады әтисе.— Ялгыз карчык булган икән. Көпә-көндез. Керәләр дә балта түтәсе белән...

— Синең Сираең түгелдер бит?

— Юк, ул беркайчан да мондый эшкә бармады
Этисе аксый-туксый ишекле-түрле йөренергә тотынды.
— Эшне кемгә бирдегез соң?
— Бер яшь егеткә. Серый дигәнең нишләп йөри?
— Эшли, ул-бу ишеткән юк.
Совет районында булган фаҗиганы Якуб белә, ул аны бер яшь тикшерүчегә биргән иде һәм Васил Хакова кирәк вакытта аңа булышырга тиеш.
— Серыйның өенә дә килеп киттеләр.
— Тикшерүче үзе генә килдеме?
— Юк, янында бер ханым да бар иде.
«Димәк, Васил дә килгән»,— дип уйлады Якуб. Ә ул аңарга поселокта күренеп йөрмәскә кушкан иде. Әлбәттә, кеше үтерү белән бәйле булган җинаятьне яшь егеткә түгел, тәҗрибәле тикшерүче Хикмәтулла абзыйга тапшырырга булгаң, я булмаса Куликовка. Тик әллә нигә алай итмәде. Яшь тикшерүче Гыйльметдинов Васил Хакованы үзе сораган иде. Васил эшне егет белән әйбәт кенә башлап җибәрде.
— Карале, Якубҗан,— диде этисе, Якубның уйларын бүлеп,— куй әле шулар группасына мине дә. Билләһи дип әйтәм, мин аларга комачауламам, мәгәр ярдәмем тияр.
— Булмаганны сөйләмә әле, этәй. Алтмышны тутырып узган кешегә иң әйбәт чара — өйдә яту.
— Мин бу тирәдәге халыкның сулыш алуына хәтле беләм, ышан. Әйтик, кая булса саклык кассасын басалар икән, туры үземә кил. Сирай эше булыр.
— Рәхмәт. Тик яңадан ул моңа бармас дип уйлыйм. Төрмә — ял йорты түгел, анда тәртипләр ай-һай...
— Ни сөйләп утыра бу тагын!— дип сүзгә кысылды мич янында уралган әнисе.
— Әнисе, ат дагалаганда бака ботын кыстырмый, тик кенә тор әле ир-ат сөйләшкәндә,— диде карт, ачуы чыга төшеп.— Чын, Якубҗан, беләм мин ул токымны. Сирайны да беррәттән тикшерермен.
— Сирай бездә учетта.
— Менә кая ул учетта, эт ялаган нәмәстә. Кәкре агачны ут турайтса турайта, Сирайга мындәй кешеләр кирәк,— диде карт күкрәгенә суга-суга.— Менә кай тарафта утыра ул Серый. Без аның белән, беләсең килсә, егерме ел сугышабыз инде. Кем кемне җиңәр, бер алла үзе белә.
— Якубҗан, балаларны алырга барырга вакыт түгелме сиңа?
— Әйе шул. Ярый, этәй, ул турыда уйлашып карарбыз. Эшлисең килсә, җайларбыз аны...
— Эшләми торсын әле,— дип янә сүзгә кысылды әнисе.— Бар инде, Якубҗан, килен көтәдер мунчада...
Иртән этисе аларны озата чыкты.
— Килен,— диде Гата карт, Якуб ягына карамый гына.— Әйбәт торыгыз. Түм-түгәрәк балалар үстерәсез, тату яшәгез. Тату яшәүгә ни җитә.
— Эти, ни дигән сүз инде ул тагын...
— Син миңа әйтмә, мин сорамадым, шулай, килен. Ә атаңның күзе күрә, арагызда боз бар, эрет син аны, бу дөньяда бар да хатынкыздан тора. Ирне эт иткән дә, кеше иткән дә хатын.
— Ярый, эткәй, шулай итәрмен,— диде Гөлбикә һәм мәгънәле итеп, Якуб ягына карап алды.— Хушыгыз, үзегез дә килегез...
— Ризык булса, кем белә, барып та чыгарбыз. Бәләкәчкә салкын тия күрмәсен, тәрәзәне кыса төшегез,— диде Гата карт. Барысы да

машинага утыргач, шофер ягына чыгып, нидер әйтте дә янә Якуб янындагы ишекне ачты.— Кайчан килим?

— Нигә тагын?

— Оныттың да мыни инде. Гади бәндәләрнең гозерен оныту килешми нәчәлник кешегә.

— Ә-ә, син һаман шул турыда икән. Ярый, әйтеп карармын...

— Син миңа әйтеп кенә калма, приказ язып куй. Мин сиңа мыек типмәгән малай-шалай түгел, шул тәбәктә эшләп, пенсиягә чыккан кеше.

— Ярый, этәй, син дигәнчә булыр. Тик син анда бик комачауламассың...

— Комачауламам, ышан.

Кузгалып киткәч, Гөлбикә иренә елыша төште һәм иңенә башын салды, кулын эзләп тапты, дустанә үз итеп кысты.

Хикмәтле бу күңел дигән нәрсә, аз гына ягымлылык булдымы, житмәсә ул кеше үз хатыныңда булса, эри дә китә икән җан дигәнең. Якуб як-ягына көрт салынган кышкы юлны да, итәгендә утырган Кәримәне дә күрмәде, аның күңеле бөтенләе белән Әлмәт шәһәрендәге хатирәләргә чумды. Анда, Әлмәттә, Гөлбикәне беренче тапкыр очраткан чакта, күңел түрендә нәкъ шундый яктылык бөркелеп киткән иде. Җанын үртәлдергән нәрсә һәм кайсыдыр ягы белән әллә кайчангы ләззәтле минутларны уяткан нәрсә Гөлбикәнең: «Мин сине яратам, Якуб»,— дигән сүзе булды. Я хода, ул аны әле булса ярата икән ләбаса. Бик аз кирәк икән бит кешене бәхетле итү өчен, аз гына татлы сүз кирәк һәм ул бәхетле.

## 7

Апрель ае яңгырлап килде. Ике көн тоташтан яңгыр яугангамы, шәһәрдә кар эреп бетте диярлек, асфальт юллар ачылды, урамнарда язгы туфли кигән хатын-кызлар күренгәли башлады. Якуб та язгы һәм җәйге туфлиләрне чыгарып, чистартып тезеп чыкты. Эштән кайткан Гөлбикә моны күрде дә бер тын башын чайкап торды.

— Иртәрәк түгелме соң әле җәйге аяк киемнәрен чыгарырга, Якубҗан?

— Иртә түгел, туфлидән йөриләр инде.

— Әүвәл балаларны кереп алыр идең.

— Юлия Борисовна аларны курчак театрына алып китте.

— Кәримәсен нигә йөртә инде, нинди театр ди аңа, тәмам узындырып бетерде инде бу Юлия Борисовна балаларны.

— Уйласаң да алай дип әйтмә, күршең булмаса, нишләр идең. Кәримәңне сигез айдан алып карый башлады. Зөлфиянң балалар концертында катнашып йөри. Кемнең баласын шулай карый пенсиядәге карчыклар?.. Кояш кыздыра башлауга ишегалдына чыгып утыралар, бала карыймы хәзерге карчыклар, аркылы яткан кирпечне атлап түгел, уратып узалар,— диде Якуб,— Юлия Борисовна безнең өчен хәзинә.

Гөлбикә дәшмәде, чишенде дә аш пешерергә керешге, бүген концертка билет алган иде, шунда баруы турында әйтте.

— Нигә миңа да алмадың?— дип, Якуб кабинетына узды, газета-журналларга күмелде. Гүя ул өйдә үзе генә калган иде. Ярата иде Якуб буяу исе килеп торган яңа газета-журналларны актарырга. Ул арада бүлмәгә Гөлбикә килеп керде.

— Я, ярый, мин китим инде, Якубҗан. Балалар кайткач, ашатырга онытма.

— Ярый. Син миңа да һич югы бер тапкыр булса да билет алыр идең...

Ишек ачылды, ябылды. Элек гадәтләнгәнчә, Якуб аны битеннән үбеп озатып калмады. Элек ул хәл дә булг... вакытта ку

цел дигәнең моны да теләми башлады. Шулай бизенәдер инде күңел дигәнең.

Кичә аңа доклад белән Хакова керде. Бик озак сөйләшеп утырдылар. Элек ул алай Якуб янында озаклап утырмый торган иде. Теге җинаятьне ачуда әтисенең дә ярдәме зур булган. Докладында группа башлыгы Гата Азатов исемен ассызыклап әйтеп узды. Карчыкны үтерүдә Сирайның катнашы булмаган, шулай да әтисе һаман: «Сирай бу «эштән» читтә калмас, җинаятьчеләр аның исемен яшерәләр»,— дип бара. Ни генә булмасын, кулга алынды, тикшерү тәмамланды, әмма Сирайны гаепләрлек бер генә җеп очы да чыкмады. Дөрес, җинаятьче белән Сирай кайчандыр бер «өйдә» утырган. Ләкин бу хәл генә Сирай Яһудинга тап төшерми иде. Җинаятьче, Сирайны белмим, дип бара. Нәрсәдер бар монда. Ни өчен бөтенләй белмим, ди?.. Хикмәтле хәл. Катнашмаган булса, ул аны беләм, дияр иде, мөгаен. Әйтик, гаебе булмаган кешене нигә аңа яшереп торырга. Димәк, кемдер иректә калырга тиеш, кемдер аларны ашатырга тиеш бит.

Якуб газета-журналларны бер читкә куеп уйланды. Вәсилә Хакова группасы җинаятьче белән Сирай арасында бәйләнеш булмаган дигән нәтиҗәгә килә. Моның киресен исбат итәрдәй һичнинди дәлил таба алмый. Судка корыч логика белән расланган фактлар гына бирелергә тиеш. Хәзер инде соң. Эш тәмамланды дип, район прокуроры документларга кул куйды. Алай да Якуб әтисеннән Сирайга күз-колак булып торуны үтенде. Пенсиядә булсаң да, рәнҗемә инде, дигән булды. Ә картның исә моңа ачуы чыкты. Имеш, син һаман миңа ышанмыйсыңмыни әле!

Якуб үзендә тикшерүчегә хас үҗәтлек белән күзәтүчәнлек тәрбияләнүен тоя. Ләкин ул хәлиткеч нәтиҗә ясарга ашыкмый. Мөһим фикер әйтү өчен, мөһим эшләр башкарырга кирәк, тикшерүче өчен бу сыйфат бик тә зарур нәрсә. Тагын бер психологик момент: ихтыяр көчеңне беркайчан да җуйма, төшенкелеккә бирелмә.

Ул арада театрдан балалар кайтты. Алар шау-гөр килеп, үзләре белән апрель һавасы алып керделәр. Юлия Борисовна шат, балалар белән курчак театрына бару, аларның кечтеки генә булса да капризларын үтәү аңа үзе бер дөнья, күрәсең, кайтып керү белән, нәниләрнең театрда ни тамаша кыланулары турында сөйли башлады.

Рәхәт иде балаларның тыкылдавын тыңлавы, Якуб аны сәгатьләр буена тыңларга да риза.

— Чәй әзер, әйдәгез бергәләп чәйләп алыйк,— дип килеп керде Юлия Борисовна.

— Әйдәгез соң... Зөлфия, куеп тор китабыңны.

Бергәләп утырып чәй эчтеләр, балалар һаман театр турында такылдыйлар. Якуб Юлия Борисовнага карап-карап алды. Пенсиядәге артистка нигәдер аның күзенә туры карамаска тырыша кебек иде.

— Юлия Борисовна,— диде Якуб кинәт кенә басынкы, юаш тавыш белән.— Юлия Борисовна, әйтегезче, соңгы арада Гөлбикәгә ни булды? Бәлкем, сез беләсездер?..

Дөнья күргән артистка тиз генә җавап бирмәде, көмеш калагы белән чәен болгата-болгата бер мәл тәрәзәгә, эңгер иңеп килгән тышка карап торды.

— Һәр хатын-кыз сер тубалы ул, Якубҗан...

— Бар да ал да гөл кебек, шул ук вакытта әллә ни булды...

— Ярата ул сине, Якубҗан. Яраткан кешесе күңелен рәнҗетсә, хатын-кызга авыр була, бик авыр була, яман...

— Мин аңа нинди начарлык кылдым соң әле? Ә ул минем белән үз-үзен мәҗбүр итеп кенә сөйләшәдер сыман тоела миңа.

— Тоела. Тикшерүче шиге генә бу. Аның алласы да, патшасы да— син.

— Шулай гына булса икән...

Шулай дисә дә, Юлия Борисовна белән сөйләшкәннән соң, Якуб күңелендә нииндидер яңарыш кузгалып куйгандай булды. Шомлы уйлар, киеренкелек төшкән күңел офыклары киңәеп китте.

— Чәй бик вакытлы булды, рәхмәт, Юлия Борисовна.

— Зөлфияне мин үземә алып чыгам, яңа җырлар алып кайткан идем, Сара ханым биреп җибәрде,— диде карчык.

— Зөлфия,— диде Якуб.— Бар, Юлия әбиләреңә кер...

Бала бик теләп сикереп торды. Якуб хәтта Юлия Борисовнадан көнләшеп куйды. Бала хәзер әнисен дә, әтисен дә белми диярлек, Юлия Борисовна булса, бер кем кирәкми үзенә.

Якуб ал якка чыкты, телевизорны кабызды, Кәримә аның тезләренә менеп утырды.

— Мультик калыйбыз...

— Мультик түгел, халыкара хәлләр, кызым...

Бала шундук ата тезеннән шуып төште, түр бүлмәгә, курчаклары янына чыгып китте.

Шыпырт кына Гөлбикә кайтып керде. Ишек тавышын ишеткән бала коридорга йөгереп чыкты, әмма әнисен күргәч, кире борылды. Моны искәреп алган Гөлбикә, үпкәләгәндәй:

— Кызым, Кәримә, кил әле, кил, бер нәрсә бирим үзеңә,— дип баланы янәдән чакырып алды.

Бер нәрсә дигәч, бала янә йөгереп чыкты.

— Шиколат...

— Шиколат түгел, шоколад. Мәле, мә. Кил инде, ал инде. Апаң кая соң?.. Юлия Борисовналарда мени...

— Алар анда яңа җыр өйрәнәләр,— диде Якуб.

— Тәмам үз итте бу Юлия Борисовна баланы. Бар алып чык әле үзен.

— Үзең генә керсәң икән, Гөлбикә.

— Син кайчанга хәтле бер баланы яклап, икенчесен читләштерүдән туктарсың икән, Якуб?..

— Ни-ни, нәрсә дисең?— дип коридорга чыкты Якуб.— Үз акылыңдамы син? Ни сөйлисең?!

— Аллага шөкер, синнән акыл сорарга җыенмыйм, булганы бик җиткән.

— Зөлфияне үзең җырчы итмәкче түгелме соң?! Ә Юлия Борисовна аны җырларга өйрәтә. Гомумән, оялыр идең Юлия Борисовна турында шулай уйларга.

— Оялыр идең. Балалар үз аналарын танымый башладылар. Әллә мин бар аларга, әллә юк. Юлия Борисовна да, Юлия Борисовна...

Гөлбикәнең күзләрендә яшь иде, тавышы калтырап китте.

— Нишлисең, хезмәтең шундый булгач, күч башка эшкә, гел өйдә булырсың...

— Явыз син, Якуб. Мине эшемдә хөрмәт итәләр, миңа ышаналар.

— Ишеткәнем бар, әмма минем ни гаебем бар соң, әйтче зинһар!

Гөлбикә кулъяулык чыгарып, күзләрен сөртте.

— Күптән алып чыктымы баланы?

— Эт кояшы булмасаң иде, Гөлбикә. Әле ничә көн элек кенә Юлия Борисовнаны фәрештә итеп күрә идең түгелме...

— Күрсә соң! Мин хатын-кыз!..

— Хатын-кыз. Ярый, хәзер үзе дә кайтыр. Җырдан да бик тиз туя башлады ул кызыбыз хәзер.

— Кеше җырдан туямы, Якуб...

— Үзем алып чыгыйммы, үзең керәсеңме?

— Үзем керәм,— диде Гөлбикә, өстен салды да тиз-тиз күз тирәләренә пудра сөрткәләп алды.

Аңлап бетермәгән чаклары күп иде Якубның үз хатынын. Хәзер генә дөнья аның өчен дөм караңгы, күп тә үтми мөлдерәп кояш чыгашаяра, көлә, берни булмаган кебек кылана, аларның тормышлары да шулайрак үтә түгелме?.. Кем кемнең көен көйләп яши...

Урам яктан гөрелдәп трамвай узды, машина тавышы тәрәзәләрне зыңлатты. Сулыш алырга һава җитмәгәндәй, Якуб барып, тәрәзәнең бер канатын ачты, күлмәгенең өске төймәсен ычкындырды. Шул мәлдә ул арка калагы астында чәнчү тойды. Авырту түгел иде бу, әмма чәнчү кабатлануга, аңа курку килде. Ни булыр бу? Ләкин чәнчү ничек кинәт килгән булса, шулай бетте дә. Якуб тынычлана төште, тәрәзәне япты, кухня ягына чыгып чәй куйды. Якуб иңнәрен киереп, күкрәген тутырып сулыш алды. Баягы чәнчү булмаган да кебек иде. Нинди авырту ди, сау-таза, яшь бит әле ул, һәрхәлдә ир уртасы.

Якуб китель сәдәфләрен ялтыратып чистартты. Кичә иртә белән бүлек хезмәткәрләрен тезеп, тегеләрнең формаларын тикшереп чыккан иде. Сәдәфләре күкселләнеп күгәрә башлаган егетләрне икенче тапкыр мондый форма белән күрсәм, үпкәләмәгез, дип кисәтте. Кисәтте, әмма кабинетына кереп утыргач, үзенең кител сәдәфләренә күзе төшкәч, аптырап калды. Сәдәфләр яшелле-зәңгәрле булып күгәргәннәр иде. Якуб үзалдына көлемсерәп куйды. Шунда гына исенә төште. Хезмәткәрләрнең формаларын тикшерә башлагач, икенче булып басып торучы Старостин авыз чите белән генә елмаеп куйган иде. Билгеле инде Старостинның нидән көлгәне. Шуннан соң Якуб формадан бик йөрмәде. Хәер, аның бүлегендәге хезмәткәрләргә нинди киемнән дә йөрергә рөхсәт иде. Ләкин, ни сәбәпледер, ул бүген эшкә формасын киеп барган булды. Милиция подполковнигы Якуб Азатовны формадан күреп, бүлек хезмәткәрләре дә үзләрен җыйнаграк тоталар иде. Әмма икенче көнне үк Якубның гадәти костюмнан эштә күренүе була, бүлек хезмәткәрләренең йөзләренә башка мимика куна.

Чәй кайнап чыкты, шул чак кухняга бала килеп керде.

— Әт-ти, мульт...

Якуб баланы кулына күтәреп алды, зал ягына чыгып, телевизорны кабызды.

— Ә син каян белдең мультфильм күрсәтәчәкләрен, ә!..

Бала сәгатькә төртеп күрсәтте, Якуб, кызының бу кадәр сизгерлегенә исе китеп, көлеп җибәрде. Ләкин мультфильм вакыты җитмәгән иде әле, бала әтисенең кулыннан шуып төште дә, уклары кул белән әйләндереп борыла торган картон сәгать алып килде. Картон сәгать нәкъ мультфильмнар бара торган вакытка куелган иде.

— Үзең куйдыңмы, апаңмы? — дип сорады ул көлә-көлә.

— Үзем,— диде бала.

— Тукта инде алай булгач, дәү сәгатьнең шул вакытка җитүен көтик тә, бер-бер хәл кылырбыз, яме?

Ул арада шау-гөр килеп, Зөлфияне ияртеп, әниләре кайтып керде.

— Якуб, кил әле, кил, кызың ничекләр җырлый. Яле, Зөлфия кызым, җырла әле Юлия Борисовна өйрәткән җырны.

Бала зал уртасына чыгып басты, җырларга хәзерләнде. Аның, олыларча ук булмаса да, кулларын җәя төшебрәк җыр башлавы, ияген чөеп, күзенә төшкән чәч тәлгәшен нәфис озын бармаклары белән сыпырып куюы, «Сәрвиназ» көенә җиңелчә селкенеп торуы, гомумән, үзен гаять тәкәббер, эре тотуы, кыланчыклануы Якубны чынлап та сөендерде. Зөлфия мондый көйне беренче тапкыр башкара иде. Әмма апасы җырлый башлауга, үч иткәндәй, кече кызлары Кәримә телевизорны көчәйтеп җибәрде. Бу хәлне күреп, әниләре «җен көзгесен» шундук сүндерде. Балага шул җитә калды, үпкәләде, турсайды, җитмәсә, «әһ, син шулай мыни әле», дип әниләре аның йомшак җиренә шапыл-

датып сугып та алды. Бала чырыйлап, әтисе янына килде. Якуб баланы күтәреп алды да, күрше бүлмәгә чыга башлады.

— Тыңламыйсың мыни кызыңның җырлавын,— дип калды Гөлбикә ире артыннан, аннары кинаялэп:— Җыр ни дә сиңа, кызым...

— Гөлбикә,— диде үртәлүен сиздереп Якуб,— бу ни дигән сүз инде тагын. Узындырма баланы. Вакыты житкәч, барысы да урынына барар. Миңа калса, иртәрәк әле баланы болай узындырырга...

— Юлия Борисовна балада талант күрә, ә син...

— Мин ни?..

— Бу хәтле закон кешесе булырсың икән. Ишетәсеңме, балада талант, талант!..

— Талантны да үстерә белергә кирәк. Ә син, миңа калса, ашыктыра төшәсең...

— Миңа калса, миңа калса,— дип мыгырданды Гөлбикә.—Җырла, кызым. Бар, бар, милиционер итәсе баланны ал да күрше бүлмәгә олак...

— Шаулама юкка. Ана булсаң, ана бул, булмасаң...

— Уф, Якуб, мин сине болай ук надан булырсың дип уйламаган идем. Сәнгать бит ул — алмаз, ә син күмер турында сүз алып барасың. Минем җыр тыңлыйсым килә, ишетәсеңме, тыңлыйсым килә! Миңа бернинди дә мультфильм кирәкми...

Гаҗәп хәл: ата белән ана ду килгәндә, балалар, һич ни булмаган кебек, бергәләшеп, телевизорны тоташтырдылар һәм, урындыкларын җайлабрак куеп, мультфильм карарга утырдылар. Моны күреп, Гөлбикә тәмам шаша язды.

— Бу ниткән хәл инде. Күр инде, күр... И-и ходаем, ниләр генә кылыйм икән!..

Гөлбикә сикереп торды да күрше бүлмәгә чыгып китте һәм караватына капланып, үксеп-сыктанып җылый башлады. Якуб аңа ияреп керде, аяк астында аунаган маймыл-уенчыкны алып урындыкка утыртты. Маймыл-курчак йомшак, сыйпаган саен сыйпыйсы килә иде һәм Якубны шул хәрәкәт тынычландыра төште.

Гөлбикә караватка капланган килеш бер тын үкседе дә тынып калды.

— Балалар алар талашалар да, татуланышалар да. Минә без синең белән ачуланышсак... Надан, имеш. Җырны тыңлау өчен югары белем кирәкми, аның ачкычы сиңа да, миңа да бер дулкында яңгырый — йөрәк кабул иттеме, димәк, җыр матур. Бер баланы күккә чөеп, икенчесен милиционер дип үртәвеңне мин, гомумән, аңламыйм. Аларның икесе дә миңа да, сиңа да газизләр. Җырларга теләге бар икән баланың, әйдә, җырлат, инде юк икән, гафу ит, көчләмә.

— Дәшмә миңа... Кит, кагылма миңа! Күземә күренмә!..

«Күземә күренмә»,— дип кабатлады Якуб баскычтан төшкәндә.— «Күземә күренмә». Шул сүздән соң ул өйдә кала алмады.

Күк йөзе йолдызлар белән чуарланган, алар арасында адашып калгандай ялгыз ай кыйпылчыгы йөзә.

Ике квартал чамасы үткәч кенә Якуб туры милиция идарәсенә баруын абайлап алды. «Карасын әле балаларны үзе генә, салсын әле йокларга үзләрен бер. Юкса балаларны җырлатырга булса — ул, йоклатырга — мин...»

Дежур торучы милиционер аңа баш кагып кына калды. Якуб әкрен генә икенче катка күтәрелде, кабинетының ишеген ачты, бер мәл бүлмә уртасында ут алмый басып торды. Караңгыда капшанып килеп, стена буйлап тезелгән урындыкларга чүмәште. Сәер хәләттә иде ул. Һич ни уйлыйсы килми. Гөлбикә белән булган аңлашудан соң аның тәмам кәефе кырылды. Урындыкларга сузылып ятты, күзләрен йомды. Дежур милиционер аны нинди дә булса эш белән килгән, дип уйлады әлбәттә.

...Аның кабинетына беренче булып килеп кергән һәм Якубның сте-

на буендагы урындыкларда йоклап ятуын күргән Вәсилә Хакова телдән калгандай булды. Беренчедән, ул аны шулай иртә күрермен дип һич тә уйламаган иде, ни өчен иртән-иртүк нәкъ менә Якуб Азатов кабинетына килеп керде — үзе дә төгәен генә белми. Бүлек начальнигы Вәсилә Хакова эшкә гадәттәгедән иртәрәк килә, берүзе бер кабинетта уйланып утырырга ярата иде. Ләкин Якубның болай иртә килүен, җитмәсә әле урындыкларда йоклап ятуын Хакованың беренче күрүе иде. Ишеген дә бикләмәгән... «Димәк,— дип уйлады Вәсилә,— ул кичтән үк килеп яткан. Ни мәҗбүр иткән бүлек начальнигы подполковник Азатовны кабинетына килеп йокларга?.. Бәлкем, нинди дә булса бик тә җитди эш чыккандыр? Әлбәттә шулай.»

Вәсилә Хакова ничек акрын гына керде, шулай ук тавышсыз гына кабинеттан чыгып та китте.

Бераздан Якуб уянды. Баш астындагы кулы оеган, чемер-чемер итеп тора. Торып утырды, оеган кулын ышкыштырды, башын чайкап куйды. Әле генә саташулы төш күргән иде, шуны күз алдына китерергә тырышып карады, әмма ул турыда уйланырга да өлгермәде, кабинетка ашыгып, Хакова килеп керде.

— Гафу итегез, мөмкин булырмы, Якуб Гатович?

— Керегез, мөмкинлек сорыйлармыни. Әйдәгез, керегез. Ни бар?

— Якуб Гатович, 79 нчы сберкассаны басканнар!

— Кайчан?

— Әле шалтыраттылар.

Якуб сәгатенә күз төшерде, вакыт тугызынчы кырык биш минут иде.

— Оперативка киттеме?

— Әйе.

Якуб янә сәгатькә күз салды, пистолетын барлады. Өстәл янына килеп, детектордан машина чакыртты.

— Сез дә барасыз мыни, Якуб Гатович?

— Әйе.

— Мин дә сезнең белән.

— Әйдәгез.

— Чыңгыз поселогына!— дип боерды Якуб машинага утыруга.

— Нигә анда, сберкасса Бауман районында...

— Поселокка,— диде Якуб һәм:— Чыңгыз урамы, 19 нчы йорт,— дип өстәде.

Шофер, машинаны кузгатып, урта юлга төште дә элдереп алып китте.

— Якуб Гатович, нигә анда?— дип кыюланып сорады кабат Вәсилә Хакова.

Ни өчен менә нәкъ шул фикергә килүенә Якуб үзе дә аптырый калган иде инде, ләкин шоферга приказ бирелгән һәм хәзер кире борылу мөмкин түгел. Якуб үзенең эчке бер нерв җепселе белән тоя, этисе янына барып дөрес эшли. Әтисе сөйләве буенча, Сирай гомер буена саклык кассалары баса, аның бу өлкәдәге тәҗрибәсе белән уртаклашучылар булмый калмас. Хак анысы, каракларның читтән килүләре дә бар, әмма чит-ят шәһәрдә мондый эшкә керешү алдыннан, ул кеше кимендә ике-өч ай шәһәрдә яшәргә тиеш булачак. Димәк, касса басуны Сирай оештырган булырга тиеш. Кайтуына өч елдан артык гомер үтте, аның әле кыл да кыймылдатканы юк. Чын карак үз һөнәренә хыянәт итә алмый. Бу котылгысыз хәл, әмма бу чирдән бөтенләйгә котылучылар да булгалый, ләкин Сирай түгел. Әтисенең әйтүенә караганда, Яһудин яман юлга унбиш яшендә баса һәм кайда гына, кем генә булып эшләмәсен, ул инде унбиш яшьтә алган һөнәрен ташламаячак. Кайсы шәһәрдә генә саклык кассасын бассалар да, бу эш Сирайдан башка булмас, дигән иде аңа әтисе бер тапкыр. Ул вакытта Якуб ышанды да

этисенә, ышанмады да, көлемсерәп: «Ай-һай» дигән иде. Әтисенә улының кинаяле көлүе ошамаган иде, ачуы чыга төшеп: «Күрсәтер әле Сирай сиңа күрмәгәненне»,— дигән иде.

Гата карт ишек алдында йөрена иде, машина тавышын ишетүгә, эт һау-һаулап өреп алды, әмма капкадан кереп килүче Якубны тануга, койрыгын болгый-болгый аңа таба китте.

— Ни булды?— дип сорады көрәк сабына таянган Гата карт.

— Шәһәрдә саклык кассасын басканнар.

— Мин баскан дип уйлавың түгелдер бит. Кассаны шәһәрдә басканнар дисең, ә үзең бире килгәнсең...

Әтисенең тел төбен аңласа да, Якубның бер дә шаяртасы килми иде.

— Әтәй, синең ярдәмең кирәк. Серый эше булырга тиеш, күңелем сизә.

Карт шундук үзгәрде, подполковник улының нәкъ менә аңа киңәшкә килеп керүе аны дәртләндереп җибәргән иде.

— Мине дә аласыңмы?

— Мөмкин булса, этеңне дә ияртсәң иде.

— Сабыр, инәңә генә әйтим. Әнисе!— дип кычкырды тәрәзәгә килеп капланган карчыгына Гата.— Мине малай алып китә...

Карчыгы, китмә, нидер әйтәсем бар, дип, тәрәзә аша кул селтәде, әмма Гата карт, этен ияртеп, урамга чыгып бара иде инде.

— Сирайны эзләсәң,— диде карт милиционер, машина кузгалып китүгә,— яшь кәләшеннән башлыйк. Хәтерем ялгышмаса, ул чибәр хатын Дербышкада тора, квартирын чамалап беләм...

Шул сүзләрне әйткәч кенә Гата карт янәшәсендә утыручы Вәсилә Хакова һәм шофер белән исәнләште.

— Дөрес, саклык кассасын басучы Сирай булмавы да бар,— диде Якуб, юлдан күзен алмыйча.

— Безнең тирәдә бу эшкә Сирайдан да оста белгеч юктыр. Кем генә саклык кассасын басарга ниятләмәсен, телиме моны, юкмы, ул Сирайдан фатиха ала. Ә бит, эт ялаган нәмәстә, эшкә керде, яңадан кыек юлга басмам, дип антлар эчкән булды. Юк шул инде, бөкрене кабер генә турайтса турайтадыр...

— Син, әтәй, бик үк аны гаепләп тә бетермә әле. Кем белә, бәлкем, Сирайның ул турыда ишеткәне дә юктыр.

— Ни әйттең иде дә бит... Күңел дигәнең әллә нигә ышанып җитми. Аның катнашыннан башка булмагандыр. Сабыр, улым, әнә шул урамга борыл әле. Чаттан икенче өй, ишек алдына ук керсәң дә ярый. Син кузгалып маташма, Якубҗан, әүвәл үзем керәм, хатыны мине белә, ә сезне күреп шиккә калуы бар,— диде карт милиционер, машина туктауга. Җиңел генә төште дә, аксый-туксый подъездга юнәлде.

— Хатын белән сезгә сөйләшергә туры килер, Вәсилә Хаковна. Хатын-кызларча иплап кенә сорагыз.

Баскычта Гата карт белән иңенә чегәннәргә охшатып шәлъяулык салган хатын күренүгә, Вәсилә машинадан чыкты һәм аларга таба китте. Гата карт, чыга-чыгышлый ук, эшнең асылын аңлаткан күрәсең, хатын аңа һични әйтергә теләмичә башын чайкый-чайкый чыгып килә иде, үзенә таба атлаучы Хакованы һәм машинада утыручы подполковникны күрде дә кисәк туктап калды.

— Абау, ни булды, нигә болай машина белән үк, минем нинди гаебем булсын ди,— дигән сүзен ишетте Якуб. Шунда аны Вәсилә Хакова култыклап алды һәм карт милиционердан бер читкәрәк алып китте. Ни сөйләгәндер иңенә чегән шәле салган хатынга Вәсилә Хакова, берәздән алар машинага таба кузгалдылар.

— Якуб Гатович,— дип мөрәҗәгать итте Хакова,— Сирайның Күчтем авылында өе бар икән, күптән түгел сатып алган...

— Елдан артык була инде...

— Сезнең анда булганыгыз бармы?— дип сорады Якуб хатыннан. Хатын шәленә төренә төште, иңен сикертеп куйды.

— Белә, белә, әйдә утыр, барып килик әле Күчтемгә. Үзең машинадан да чыкмассың. Күрсәтмәбез без сине,— диде карт милиционер аңа икеләнер урын калдырмыйча.

— Утырыгыз,— диде Якуб.

Күчтем авылы бередән ун чакрымнар чамасы икән, машина шунда таба элдерде, Якуб үтеп-сүтеп торган машиналарга, юл буендагы агачларга карап барды. Аның әле беркайчан да болай күңеле сизенүенә ышанып, интуициягә бирелеп, карак артыннан чыгып киткәне юк иде. Авылга килеп кергәч, хатын:

— Әнә, ундагы яр буй урамга борылыгыз,— диде, аннары өстәп куйды: — Иптәш подполковник, минем болай добровольно әйтеп йөрүләремне исәпкә алырсыз бит?.. Мин аны рәтле кеше дип йөридер ием, ә ул...

— Шәлне ул алып бирдеме? — дип сорады Гата карт.

— Нигә?— дип гаҗәпләнгәндәй итте хатын.— Туган көнемә китергән иде. Ничек инде туган көнеңә китергән бүләкне алмыйсың ди. Хатын-кызга бала табу белән бүләк алу бер диләр бит. Ир-аттан бүләк алдыңмы, ничектер аның алдында үзеңне бурычлы тоя башлыйсың. Башта ул миңа бүләкләр китерде, аннары мене шул авылдагы өенә алып килде. Түр як бакчада, Идел ярына таба мунчасы бар. Өйдә бер карт кына тора, ап-ак сакаллы.

— Башка беркем дә юкмы? Әйтик, хатын-кыз?..

— Юк, мин булганда күренмәде.

— Кайда эшлисез?

— Сатучы мин.

— Сатучы?— дип кайтарып сорады Якуб, машина Яр урамга килеп кергәч, кобурасын капшап алды һәм артына борылды.

— Әнә шул урыс капкалы өй...

— Вәсилә Хаковна, сез минем әтәйне прикроете. Әтәй, син, капкага барырсың. Мин арт бакчага китәм. Өй — елга буенда гына, анда таба сукмак төшәдер. Сирайның бу эшкә катнашмаган булуы да бар, бәлкем ул өендә чәй эчеп утырадыр. Әгәр шулай икән, димәк, мин ялгыштым булып чыга. Кем әйтмешли, служба.

— Ялгышусыз булмый безнең эштә, улым, тәвәккәллик.

— Миша, машинаны күрше өй капкасы каршына туктат. Ачыктан-ачык килеп кереп булмас,— диде Якуб шоферга.— Ә сез, ханым, җәяүләп кенә кайта торыгыз. Без сезне куып җитәрбез.

Машинадан төшкәндә Якуб артта утырган хатынның затлы муенсасын, кулындагы энҗе кашлы йөзекләрен искәреп алды. Ул аның башта иңендәге шәленә генә игътибар иткән иде, шәл чит илнеке — кыйммәтле, матур иде. «Димәк, Сирай әйберләрне сайлый белә,— дип уйлады ул чыга-чыгышлый.— Бәлкем аңа бу шәлне Хәлил табып биргәндер».

Әтисе урыс капкага барып җиткәнче, Якуб күрше өйнең койма буенда торды.

— Ишегалдында машина бар, «Жигули»,— диде әтисе борылып.

— Миша, капка каршына ук машинаңны куй да ишекләрен бикләп. Үзең әнә теге бүрәнәләр артына пос. Вәсилә Хаковна, сез әнә шул тупылдан да ары якын бармыйсыз.

Сирайның өе каршында кәүсәсе кантарланып беткән тупыл үсеп утыра, Хакова тупыл артына барып җиткәнче Якуб кузгалмады. Аннары күрше коймасы аша сикереп чыкты да, елга артына таба юнәлде. Сирай бакчаны ике метрга якын биеклектәге койма белән уратып алган, елга яклап капка күрмәгәч, Якуб сукмак буйлап ары китте. Яр астына

чокып ясалган оя кебек бер нәрсә күреп алды. Күзгә моторлы көймәнең койрыгы чалынды. Якуб йөгереп аска төште, көймәгә керде. Моторын тотып карады. Блок кайнар иде. Якубның йөрәге кисәк дерт итеп куйды. Яңа гына кайтканнар. Бәлкем, балыктандыр? Шулай да ул тиз генә көймәдән чыкты һәм яр өстенә менә башлады. Төшкәндә җиңел булса да, ярга менүе ансат түгел иде. Шунда ул ату тавышлары ишетте. Якуб җан-фәрманга ярга үрләде. Аңа каршы койма астыннан кемдер чыгып килә, кулында кара скрипка тартмасы.

— Стой!

Якуб ашыга-ашыга кобурасыннан пистолетын алды. «Музыкант булса, адәм көлкесенә калачакмын»,— дип уйлап өлгерде, ләкин икенче мәлдә инде ул кеше кулында пистолет ялтырап китүен күрде һәм бер сикерүдә яр астына очты. «Көймә белән китәргә исәбе иде, мин комачауладым»,— дип уйлады, бәрелә-сугыла яр астына шуганда. Ниндидер чокырчыкка аягы эләгеп туктады һәм янәдән яр өстенә таба үрләде. Ул ярдан башын калкытканда теге адәм авыл читендәге урманга таба йөгерә иде инде. Ул нигәдер яр буйлап йөгерә, турыга сукса, урманга тизрәк җитәчәк иде югыйсә, качак ни сәбәпледер уравыч юлны сайлады. Якуб аның кем икәнен танып өлгермәде, хәер аның кем икәнен белү кирәкми дә иде. Кулында пистолет күрде һәм моннан чыгып нәтиҗә ясавы кыен түгел, скрипка савыты күтәргән, үзен гади бер музыкант итеп күрсәткән кеше, шикле бәндә. Урман яклап кешеләр күренә, ерак түгел автомобиль тора. Якуб, алан аша чыгып, каракның юлын кисәргә булды. Куаклар артына яшеренә-поса йөгергән Якубны карак күздән җуйды булса кирәк. Хәер, аның яр өстенә менеп карарга вакыты да юктыр, ул сыналган юлдан, яр буеннан чаба иде. Ә мин аның юлын кисеп, каршы төшәчәкмен, дип уйлады Якуб. Якубның тыны кысылды, күкрәгендә нидер чәнчеште. Үтәр, үтәчәк ул. Урман буендагы кешеләр көтүче малайлар иде, сыерлары урман яклап утлап йөри, үзләре кәртле уйнап утыралар. Абыйларыннан калган киемнәрне туздыралар, дип уйлап өлгерде Якуб һәм шундый җитди вакытта, сулышы-тыны кысылып җан-фәрманга чапканда, шул турыда уйлап куюына үз-үзенә гаҗәпләнә калды. Менә ярга егерме метрлар чамасы гына калды, яр буендагы казыкка бау белән бозау бәйләгәннәр. Якуб килеп җитәрәк бозау өркеп китте һәм, казыгын суырыпмы, бавын өзепме, койрыгын чәнчеп, авылга таба чапты. Якуб чапкан шәпкә җиргә ятты һәм чокырсу җиргә тәгәрәп төште. Шул мәлдә ул шартлау тавышы ишетте, иңбашын нидер көйдереп алгандай итте. Якуб йөзен яшел үләнгә куйды. Иңбашы кайнарлануын сизеп-тоеп торса да, урыныннан кузгалмады, карак аның үлгәненә тәгаен ышанырга тиеш иде, юкса икенче пулясын да кызганмас. Ике-өч секунд кына үтсә дә аңа бик озак яткан кебек тоелды. Түзмәде, терсәгенә таянып күтәрелде, юк, яр яклап беркем дә күренми иде. Аягына басты. Иңбашындагы кайнар кан уч төбенә хәтле агып төште. Авыл яклап кемнәрдер болай таба йөгерәләр. Якуб ярга таба кузгалды, нәкъ шул мәлдә яр астыннан янә баш күтәрелде, Якуб пистолетын сул кулына күчереп атып җибәрде, ләкин шунда ук яр астындагы карак та атып өлгерде, Якуб кинәт сөрлегеп куйды һәм йөзтүбән җиргә капланды...

Аның йөзтүбән каплануын йөгереп килүчеләрнең икесе дә күрделәр һәм икесе дә аңа ярдәмгә ташландылар.

Якуб, күрше коймасы аша сикереп чыгып, Сирай йортының бакча артына таба юнәлгәндә, Гата карт барып туктаган кече капка янннан ап-ак сакаллы карт өйгә кереп китте. Ул да түгел, өйдән янәдән өч кеше килеп чыктылар. Аларның берсен Гата таныды — Сирай иде ул.

— Сиражетдин, бу мин,— дип кычкырды капка ярыгыннан Гата.— Ач әле капкаңны, йомышым бар ие.

Сирай сүгенеп алды, хәлнең асылына төшенергә теләп, сакаллы картка капканы ачып, урамны карарга кушты бугай, сакаллы тырык-тырык капкага юнәлде, тегеләре болдырда калдылар. Сакаллының кече капканы ачуы булды, ихатага һау-һау-лап, Гата картның эте килеп керде. Йорттагы эт тә бәйдән җибәрелгән иде инде, ике җанвар йорт уртасында ду килеп ауный-ауный сугышырга керештеләр. Болдырдагыларның берсе өйдән ау мылтыгы алып чыкты, этләргә каратып атып җибәрде. Ул өч-дүрт тапкыр атты бугай, шуннан соң ул мылтыгын яңадан корды һәм капкага таба килә башлады.

— Җаның ике булса кер, картлач!

Гата юан багана артына басты, тупыл артында посып торган Васил̈ә Хакова кече капканы күзәтә иде. Аның кулында корулы пистолет, мылтык белән капканы ачып килеп чыккан бандитка ул ике дә уйламый атачак иде. Ләкин капка ачылмады, киресенчә, шудыргычны тагын да ныграк этеп бикләделәр бугай. Ул да түгел, сакаллы яңа боерык алдымы — олы капканы ача башлады. Теге ике егет машина янында әвәрә киләләр. Сирай аларга нидер кычкыра башлады.

Йорт эчендә ыгы-зыгы купты. Эчтәгеләрнең берсе, кап-кара йөзлесе, каударланып килеп, сакаллыга капканы ачарга булышты. Шуннан соң сакаллы йөгереп барып, машинага утырды. Зур капка ачылды, ләкин капка каршында милиция машинасы күреп, «Жигули»дәгеләр аптырый калдылар. Сирай, ишек тәрәзәсеннән пистолетлы кулын чыгарып, кече капкага таба төзәмичә атып җибәрде. Икенче атуда пыяла коелган тавыш ишетелде, өченче пулясы машинаның алгы баллонына тиде. Капка каршындагы милиция машинасы сөрлегеп куйган аттай уң якка авышып, җиргә иңә төште.

— Ал машинаңны капка каршыннан! Тинтәк! — дип кычкырды Сирай шоферга.

Гата күрде: машина янында әвәрә килүчеләрнең икесе кавказ ягы кешеләренә охшаганнар иде. «Якуб дөрес әйткән, болары эш башкаручылар, әмма барыбер Сирайсыз булмаган».

Шул вакыт ул Хакованың тавышын ишетте.

— Гата абый, бире килегез, тупыл артына, Яковлевич боера.

Гата күрше өйнең бүрәнәләре артына чүгәләгән шоферның: «Китегез, кит, посыгыз тупыл артына!» — дигән ишарәсен хәзер генә аңлап алды. Гата карт әпен-төпен артка чикте һәм тупыл артына яшеренде. Капканы ачкан карак кире «Жигули»гә таба ташланды. Әмма аны Яковлевичның пулясы куып җитте. Ул ничектер сөрлегеп китте, тез капкачын тотып, җиргә иелде.

— Чыгыгыз машинадан! Тиз! — дип боерды машинадагыларга урам угындагы бүрәнәләр артына яшеренгән милиция шоферы. Ул аларны рәшәткәле ихата аша күреп тора һәм боерыкны бик белеп бирә иде. Аның кулында пистолет күреп, егетләр ни кылырга белми аптырап калдылар. Шул вакыт Сирай, беренче булып, машинадан чыкты да, ике сикерүдә сарайга җитте һәм күздән дә югалды. Ә яраланганы, аягын сөйрәп, «Жигули»гә килеп җитте һәм ишеген ачып кереп тә утырды. Машина кабынды һәм зур тизлек белән бакча ягына борылды. Идел буенда тирән яр, биек койма. «Нишләргә исәбе бу тилеләрнең?» — дип уйлады Гата. Ул Хакова кулыннан пистолетны алды да бакча ягына таба йөгерде.

Бакчада «Жигули» агачлар арасында йөрде, артыннан пистолет тоткан Гатаның килүен күреп, караклар машинаны тыкрык як коймага юнәлттеләр. Шартлап койма җимерелде, машина ялт итеп тыкрыкка килеп чыкты. Һәм яман гүләп, урамга, аннан инде авыл башына таба очты. Ул арада милиция шоферы машинасына утырып, «Жигули»-ның номерын, төсен әйтеп, рация аша шәһәргә хәбәр итеп өлгерде.

Өй тирәсенә халык җыелды, Хакованың якын килмәгез, дип боеруына карамастан, малай-шалай коймаларга ук менеп баскан иде. Гата, вакытны югалтмый, Сирай артыннан куарга булды. Хакова аңа иярде. Качып китүче караклар аны әллә ни кызыксындырмады. Сирай кирәк иде аңа, Сирайны тотсалар, барысы да табылыр. Аны Хакова куып җитте.

— Сез кая, Гата абый!

— Бандитның иң яманы елгага таба качты. Якуб куа киткән булырга тиеш. Әйдә әле. Кая соң боларның капкалары! Күр әле, яшерен капка ясаткан, эт ялаган нәмәстә.

Гата ике тактаны тибеп сындырды да Идел ягына чыкты. Хакова аңа иярде.

— Әнә, яр буйлап чаба. Тегене куа булса кирәк. Сез яшьрәк, мәгез пистолетыгызны, йөгерегез алдан, ярдәмегез кирәк булуы бар. Бер дә бүтән түгел, урман аша олы юлга чыгарга исәбе моның да, тегеләре машина белән аны күтәргә булганнардыр.

Гата хәлне үзенчә аңлады. Сирай кеше үтерүгә бармас. Аның беркайчан да кеше үтергәне булмады. Этләр кызганыч, ике дә уйламый аттылар бит. Эт өчен берсе кирәген алды, аяксыз ук калдырмаса да, Яковлевич ару итте үзен. Качтылар качуын, ләкин ерак китә алмаслар. Яковлевич баллонын алыштырыр, ул аны тиз эшли. Аннары «Жигули»ның юлын бүлеп каршыга да чыкканнардыр инде. Ерак китә алмаганнардыр. Ә менә Сирайның урманга кереп югалуы бик мөмкин. Аннан соң эзлә ул мөртәтне.

Хакова бик тиз йөгерде. Гатаның тыны кысылды, күкрәге чәнчеште, аяк буыннары сизмәс булды, шуннан ул атлауга күчте, теләсә-теләмәсә дә, күзенә яшь тулды. Ул ни өчен елавын да белмәде, гомере узугамы, көче-гайрәте бетүгәме, күкрәген ачу ташы салгандай нидер өтерә керә көйдергәнгәме, хәзер генә үлем белән уйнагангамы... белмәде. Үз гомерендә милициядә эшләп, кеше атарга аңа туры килмәде. Ә монда... «Якуб, Якубҗан, тот син аны, җибәрә күрмә, тота күр, шул эт ялаган нәмәстәне. Мин аны гомерем буе кеше итәргә тырыштым, әмма юкка тырышканмын булып чыга, бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карар, дигәннәр бабайлар һәм әнә шулай булып чыкты да. Кан кою да гел аның аркасында булды. Тот син аны, Якубҗан, җибәрә күрмә!»

Сирайны ул үзе тотарга тиеш иде, ычкындырды мөртәтне, ычкындырды. Хәзер әнә Якубҗан куа. Ерак китә алмас ул, тотарсың син аны, Якубҗан. Әнә хәзер Хакова барып җитәр һәм икәүләп...

Ниһаять, аксый-туксый булса да, Гата аланга килеп чыкты, шунда ул ерактан ук күреп алды, яр буена җитәрәк, Якуб кинәт сөрлегеп китте һәм җиргә тәгәрәде, шунда ук аткан тавыш ишетелде.

— Сирай, явыз, нишләвең бу?! — дип кычкырып җибәрде карт милиционер йөрәге әрнешүдән һәм чарасызлан.— Нишләвең бу, явыз?! Бит сине моның өчен, беләмсең, нишләтәләр? Беләмсең?! Вышка сиңа, вышка! Вышка булмаса, на всю катушку... на всю!

Аның рәтләп тавышы да чыкмый инде, ләкин ул һаман титаклап йөгерде, һаман Сирайны сүкте. Әнә Якуб тагын торып басты. «Тегеата башлагач кына яткандыр, тимәгәндер, дип уйлады карт милиционер.— Тукта, явыз, менә мина ат син, тимә. Ул минем...»

Шул чак Якуб янәдән йөзтүбән капланды. Ату тавышлары Гата колагына бераз соңарып килеп җитте.

Якуб аңына килә алмады, больницага алып килгәндә юлда үлде. Гата улының башын беләгенә салган да һушы киткән сыман утыра. Врач аңа яралының башын җибәрергә куша, ә карт милиционер аны

гүя ишетми, шул рәвештә утыра бирә. Ниһаять, ул башын күтәрде, яшьле күзләре белән врачка:

— Коткарып булмасмы? — дип сорады ул ялварулы итеп.

Врач башын гына селекте, ул кулыннан килгәннең барысын да эшләгән иде инде.

— Пуля йөрәк читенә эләккән. Бандитны тоттылармы? — дип сорады врач.

— Белмим. Ул ерак китә алмас, оператив группага хәбәр иткәннәр,— диде Гата, күрмәс күзләре белән почмакка карап.

— Кансыз,— диде карт милиционер. — Менә шулай ул безнең эштә, туганкайлар, менә шулай...

## 8

Кәриманең китүе турында Гөлбикә икенче көнне генә белде. Кыз беренче тапкыр диярлек өйгә кунарга кайтмады. Башта ул: «Классташында куна калгандыр»,— дип үз-үзен юатты, әмма икенче көнне өйлә вакытында да кызы өйдә күренмәгәч, тәмам пошаманга калды, шунда ук күршесе Юлия Борисовнага кереп китте.

— Походка киткәннәрдер. Борчылма юкка,— диде пенсиядәге артистка.— Киемнәре өйдәме соң?

Чынлап та, киемнәрен карамады лабаса ул. Гөлбикә йөгереп, квартирына кайтты, дөбер-шатыр килеп, шкаф-шифоньерларны актара башлады. Юлия Борисовна хаклы, Зөлфиянең юлга чыкканда йөртә торган сумкасы юк иде. Әйберләрен апасының сумкасына төягән. Димәк, кай тарафкадыр баш алып чыгып китүе хак булып чыга. Гөлбикә креслога утырды да, чигәләрен кысып, уйга калды.

Уйланырлык иде анага. Өлкән кызы Зөлфия дия-дия кечесен гел кулдан ычкындырган икән лабаса! Юк-юк, табарга, табарга һәм өйгә кайтуын үтенергә кирәк. Ана буларак мин аңа Зөлфиягә караган кебек карый алмадым шул, дип уфтанды ул.

Кече кызының көннән-көн үзеннән читләшә баруын сизмәде мени ул, сизде, әмма һични кыла алмады. Кай арада Кәримәсе үскән дә, кай арада җиткән кыз булган диген син аны. Инде менә үзенчә, үзе белгәнчә, үзе аңлаганча тормыш турында фикер йөртә. Ул гынамы, Зөлфия апасына үзенчә бәя бирә башлады! Моңа кем гаепле? Кем?! Зөлфияме?! Юк, Зөлфия түгел, Хәлил, Хәлил, мокыт җан, бер ул гына! Күрде бит, күреп яшәде бала әнисенең шул алкаш алдында ничек түбәнсенүләрен. Ә ул, мөртәт, эчеп кайтыр иде дә: «Гөлбикә, мин синнән китәм»,— дип үртәр иде. Гөлбикә чынлап та курка калыр, балалары алдында аңа ялыныр, ялварыр, түбәнсенер иде.

Хак анысы, Гөлбикә Якубы исән чакта ук кече кызын рәнҗеткәләде, булмады түгел, булгалады андый хәлләр. Ул чакта балалар бик кечкенәләр иде әле. Кай арада үсеп җиттеләр дә, кай арада үзләре ничек тели шулай яши башладылар соң бу балалар?

Гөлбикә Якубның үлемен шул милициядә эшләүче хатыннан күрде. Әйе, ул котыртып алып китә аны караклар артыннан. Якуб һәлак булганнан соң, (фамилиясе Хакова бугай) ул хатын каядыр күчеп китте, диделәр. Гөлбикә аның язмышы белән кызыксынмады, үз кайгысы үзенә бик җиткән иде. Әмма соңыннан булса да Якубның начальнигына барып, әйтмәгәнен калдырмады. Имеш, иренең үлемендә әнә шул милиция капитаны Хакова гына гаепле. Идарә начальнигы аны кабинетыннан чак куып чыгармады. Кыскасы, Хакова турында бер дә яман сүз әйттерергә теләмәде, ахыр чиктә хәтта: «Бу сүзләрегез өчен сез

аңардан гафу үтенергә тиешсез»,— диде. Гөлбикә аңа: «Сез барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән»,— дип җилләнеп чыгып киткән иде. Шул хәлләрне исенә төшереп утыра торгач, кәефе тагын да кырыла төште. Әле булса хәтерендә, шул турыда балаларына сөйли башлагач, Зөлфиясе тыңларга да теләмәде, борылды да йокы бүлмәсенә кереп китте, Кәримәсе исә: «Инәки, бәлкем ул хатынның бер гаебе дә юктыр, нигә шул тикле каргыйсың аны!» — дип акыл өйрәтергә тотынган иде. Кәримәнең шулай әйтүенә Гөлбикә янә чыгырыннан чыкты, кызының чәченнән тотып селкә-селкә: «Ниндәен сүз инде ул тагын, син дә шул кәнтәйне яклыйсыңмыни инде!» — дип, тешен кыса-кыса тукмаган иде. Шуннан соң Кәримә ике көн буе кайдадыр, кемдәдер кунып йөрде. Гөлбикәгә кызын мәктәпкә барып, директор ярдәме аша алып кайтырга туры килде. Шуннан соң күз яше белән елаша-елаша килештеләр тагын. Алар елаштылар, ә Зөлфия авыз ерып: «Ике бәби балавыз сыга»,— дип көлде. Гөлбикә шунда Зөлфиясен дә тиргәп ташларга иткән иде дә, бу тилесе бөтенләй чыгып китәр дип тыелып калды. Әмма соңыннан кочаклашып елаша-елаша аңлашса да, кече кызы белән барыбер ачылып сөйләшә алмады Гөлбикә. Гүя ана белән кыз арасыннан кара мәче узган иде.

Тормыш булгач кеше дигәнең абынмый тормый, бәла-каза кичерми бер кайгысыз яшәгән кешеләр бөтенләй юктыр бу дөньяда. Гөлбикәгә исә ул кайгы-хәсрәтләр берсе артыннан берсе килеп кенә торды. Һәм күбесен ул үзе табып алды бугай. Бәлкем, чынлап та ул хатынның бөтенләй гаебе булмагандыр? Кем белә? Ә ул буза куптарды, Якубын рәнҗетте, ирен өйдән чыгып китәр дәрәҗәгә китереп җиткерде. Бик күп икеләнә торып та, ниһаять, тәвәккәлләп, Хәлилне йортка кертүе дә, ичмасам, онытылып тормаммы дип уйлавыннан гына иде. Үзеннән яшь булган егетнең ничәмә ел аңа күз атып йөрүе тәкәбберлегенә тидеме, бердәнбер көнне ияртте дә алып кайтты өенә тегене. Бу хәл Якубның үлүенә ел тулгач булды. Нибарысы өч-дүрт ай адәм рәтле торып калдылар. Хәлил ныклап эчә башлады. Кесәсендә һәрчак йомарланган акчалар булыр, бушлай килгән акча ла ул, дип мактаныр иде... Ә бит Гөлбикә аңа өйрәнеп, гадәтләнеп килә иде инде. Бик еш салмыш баштан кайта башлагач, бер тапкыр: «Куам да чыгарам үзен»,— дип тә тузынган иде, тегесе кайтып керүгә, үзе дә сизмәстән, елмаерга мәҗбүр булды, кулындагы тортны алды, табынга утыртты. Тоташ эчү Хәлилне юньлегә илтмәде, күп тә үтмәстән, аны эшеннән кудылар. Шул төнне кайтып (янә исерек иде), башын Гөлбикәнең күкрәгенә төртеп, төне буе елап чыкты. Имеш, аны аңламыйлар, имеш, ул теләсә эчми дә тора ала. Шулай итеп антлар итсә дә, яман гадәтен ул ташлый алмады. Башта кая алдылар шунда кереп, эшләштереп йөрде-йөрде дә торабара бөтенләй Гөлбикә кулына калды. Гөлбикә көндезен регистратурада утырды, төннәрен больницада няня булып эшләде. Ничек тә гаиләне тотарга кирәк иде. Хәлилне ул ничек кайтса да елмаеп каршы алды, чишендерде, юындырды, җылы постельгә салды. Ул аңа ышана иде әле. «Сабыр ит, бәгырь, сабыр ит,— дип юата.— Башта эчүеңне ташла, аннары барысы да рәтләнер. Бәлкем әле элекке эшеңә дә алырлар. Үзем барып сөйләшермен. Эчмә генә».

«Менә күрерсең, бәгырь, капмыйм да, авызыма да алмаячакмын моннан ары. Чынлап та, барырсыңмы, сөйләшерсеңме?.. Сине анда беләләр, син бит Казанга бер ревизор иден, белми буламы, җүләр, сиңдәйләрне...»

Хәлил шулай сөйләнә-сөйләнә йокыга китте, Гөлбикә төне буе уйланып чыкты. Яшь иренең мондый тәүбәләрен күп ишетте инде ул. Соңгы мәлдә бөтенләй ышанычын югалта башлады, әмма барыбер куып чыгара алмады. Хәзер инде өмете бетте. Ничек кенәләр йортка кертте

соң шул Хәлилне, нигә кирәк булды. Яшәр иде әле, ике баласы бар иде...

Тугызынчы-унынчы классларда Кәримәсе гел дүртле-бишле билгеләренә генә укыды. Врачлар арасында эшләп, аларның табигатьләрен белгәнгәме, нигәдер, Кәримәсен врач итәсе килә иде Гөлбикәнең.

Якуб үлгәч, ул ревизорлыктан китте, эшли алмаудан түгел, командировкаларга йөри-йөри салкын тидерде һәм айга якын больницада ятып чыкты. Йөрәге начарланган иде, врачлар аңа эшен алыштырырга куштылар, һәм кайсыдыр (өлкән сестра бугай) әнә безгә регистратор булып килегез, вакантный урын бар, дип ычкындырды. Гөлбикә икенче көнне үк аларга гариза китерде. Йөрәге чынлап та бик шәптән түгел иде, врачлар күзәтүе астында яшәде, житмәсә Хәлил болай да авыру йөрәкне кайта-килә талкыды. Гөлбикә көне белән картайды, алсу йөзенә лимон сарысы йөгерде, чәчләренә кырау төште. Кәримә һаман үзенекен үзәккә чыгара, әнисе теләгән институтка бармаска исәп тота. Имеш, инәки, сиңа түгел, миңа эшләргә врач булып, мин ул һөнәрне яратмыйм, кая телим, шунда барам. Гөлбикә бәрелеп-сугылырга иткән иде, йөрәге чәнчешә башлады, ул белә иде: аңарда тәүге гайрәт күптән юк инде, Якуб белән бергә яшәгәндәге сәламәтлеге өч-дүрт ел эчендә кояшта уңган ситсы кебек төссезләнде, рәтсезләнде, уңып калды. Гөлбикә еш кына көзге каршына килеп баса һәм, гадәттәгечә, йөзен көзгедән күзәтә һәм курка кала: күз тирәләренә гүя үрмәкүч пәрәвез корган, ике каш арасына тирән җыерчык сузылып яткан, хәтта күзләре дә уңа төшкән сыман. Кайчак аңа больницада сәламәтләнеп килгән ир-атлар әллә шаяртып, әллә чын-чынлап: «Гөлбикә, әйдә чык үземә кияүгә, балда-майда гына йөздерермен», — дигән була. Гөлбикә аларга дәшү түгел, күтәрелеп тә карамый. Юк, житәрдер инде, яшь булса да, үз гомерендә ике ир күрде. Берсе аны чынлап та балда һәм майда гына йөздерде, икенчесе... Юк инде, Гөлбикәгә хәзер берни дә кирәкми. «Дәшмәгез миңа, ирләр! Ишетәсезме, шаяртып та дәшмәгез! Тимәгез, кагылмагыз болай да ярсу-кимсетелгән күңелемә! Якубымны югалттым, олы кызым тыңламый, дорфаланды, яшь кызым баш бирми, дәшмәгез миңа. Житәрдер бер ана башына шул кайгылар, житәрдер...»

Идән уртасына басып, кече кызы Кәримәнең мәктәп формасын тотып торганда Гөлбикәнең башыннан әнә шундый аянычлы хатирәләр узды. Нигәдер нәкъ менә баш алып чыгып киткәч, кече кызы аңа аерата кадерле булып китте. Бик авыр халәттә иде ул. Кайчан аңа шулай булган иде әле?.. Әйе, Якубның үлемен ишетүгә, йөрәге әллә нишләп киткән иде, скорый чакырдылар, уколлар кададылар. Менә хәзер тагын баскан җиреннән кузгала алмый тора. Кузгалмаса, бер адым гына ясаса да, йөрәге туктар да, сыгылып төшәр сыман.

Бу кичне Гөлбикә эшкә бара алмады, тел астына валидол салган килеш караватында ятты. Шушылай берьялгызы калгач, үлеп китәр кебек тоела башлады, йоклап китәргә курыкты. Ичмасам Зөлфиясе кайтсын иде. Сәгать тугыз бит инде, кайларда йөри икән шул кыз!.. Юлия Борисовна да керми. Кая булса китте микәнни?..

Аңласа, бүген аны бер Юлия Борисовна аңлар кебек иде.

## 9

Алар сабый чактан ук танышлар иде. Зөлфия бабаларына кунакка килгән вакытта бер тауда чана шудылар, кар кешеләре ясадылар, әллә ниткән уеннар уйлап таптылар. Үсә-үсәя төшкәч тә хәтта бергә булгаладылар — чаңгыларда чыктылар, дискотекага йөрделәр. Котбый белән Барый Зөлфиянең музыка мәктәбендә укуын беләләр, шуңа күрә ме, аларга да музыка җене кагылган иде, мәктәптә оркестр оештырды-

лар, интернациональ җырлар башкардылар. Мәктәпара конкурста катнашып, Барый белән Котбый җитәкләгән оркестр икенче урынны алды.

Өлгергәнлек аттестаты алгач, документларын консерваториягә беренче булып Котбый илтеп бирде, моны күреп, Барый да шулай итте. Ләкин Котбый да, Барый да беренче имтиханда ук төшеп калдылар. Күп тә үтми, Барый элемтә техникумына юнәлде. Караса, шаккатты: Котбый Яһудин дә шул ук техникумга имтиханнар тапшырырга әзерләнеп йөри икән. Консерваториягә керә алмагач, кәефләре кырылып, бер-берсенә гелән йөрми башлаган егетләр техникум коридорында кочаклашып күрештеләр. Беренче имтиханга бергә керделәр. Барый — математикадан, Котбый физикадан алдыра төшә иде, бер тезмәгә утырдылар һәм дөрес эшләделәр. Икесенә дә бер вариант мәсьәләләр туры килде.

Беренче имтиханнан соң сибелеп, коридорга чыктылар.

— Берсен җиндек,— диде Котбый.

Шунда алар Чыңгыз поселогы мәктәбендә укыган тагын ике егетне очраттылар.

— Димка, Хәйри! — дип кычкырып җибәрде Котбый.— Во, егетләр! Барысы да мыштым гына элемтә техникумына. Әйтмәделәр дә.

— Ә мин башта ук монда ниятләгән идем,— диде сары чәчле Димка.

— Мине КАИга алмадылар, конкурс зур булды,— диде сипкелле битле, җирән чәчле Хәйри.

— Болай булгач, егетләр, кердек без бу техникумга. Бер тирәгә утырырга, кем ни белми, ярдәм итәргә. Шпаргалкалар барыбызда да җитәрлек...

Котбый ничектер төркем башы булып китте. Ул ни әйтсә, барысы тыңлады, көнде.

Өч көннән техникум коридорында эленгән исемлектә дүртесенең дә фамилияләрен күргәч, егетләр бу җиңүне юарга булдылар. Котыртучы, акча табучы Котбый булды. Үзәк парк ресторанында ике шешә вино салып алгач, егетләр Казанка буена төшеп киттеләр.

Көн болытлы. Иделгә барып кушылган Казанка елгасы буенда кеше-фәлән күренми, аулак. Вино эчкәннән соң каннары кызган егетләр юл өстендә очраган бер нәрсәне кузгата бардылар. Өс киемнәрен алыштырырга куелган чишенү оялары аударылды, чүп савытлары читкә очты, тишек туплар суга ташланылды, егетләр акырыша-бакырыша елга буйлап алга атладылар, аулак калган елга буенда ни теләсәләр, шуны эшләделәр, төрлесен кыландылар, биеделәр, җырладылар, хәтта баштүбән дә йөреп карадылар.

Шулай шау-гөр килеп үзләренчә күңел ачып йөргәндә алар ике затның Казанка буйлап үзләренә таба килүен күреп алдылар. Котбый егетләргә туктарга әмер биреп, кулын күтәрде.

— Стоп! Кемнәр килә безгә таба?!. Борау, күрәсеңме, таныйсыңмы Зөлфияне, кем белән гүләйт итә... Сабыр, братва... Башта үзем...

Кыз белән егет якыная барган саен, Котбый гасабиланды, бертуктаусыз яңак итен чәйнәде. Зөлфияне ул шунда ук таныды. Ә бит алар шул Зөлфия өчен бит инде документларын консерваториягә тапшырган булдылар. Ә ул... Кем белән, кайда?

— Ша, егетләр, минем команданы тыңлыйсыз! Капшап карыйк әле бу кәкре сыйракны, ниндирәк камырдан әвәләнгән икән. Барый, Борау дим, син уң якка чык...

Егет белән кыз гүя аларны күрмиләр дә, мавыгып сөйләшәләр, аларның үз дөньялары дөнья. Кыз гына, егетләрне күргәч, нидер сизенеп булса кирәк, кисәк туктап калды. Ул арада егетләр аларны уратып алдылар.

— Ятлар белән гүләем?! — дип, Котбый Зөлфиягә таба кузгалды, ләкин кинәт борылды да кыз янәшәсендәге егетнең күкрәгенә төртеп җибәрде. Бу хәл шундый тиз эшләнелде ки, егет һични аңламый калды, аптырап як-ягына каранды әпен-төпен артка чикте, ул арада кайсысыдыр аны түгәрәк уртасына төртеп тә кертте.

— Кагылма аңа! — дип чырыйлап җибәрде кыз. — Ишетәсеңме, кагылма!

Котбый гүя кызны күрмәде дә, ул тимер дагалы ботинкасы белән бар көченә егетнең аркасына типте. Егет аһ! итте һәм кисәк бөгелеп төште. Котбый аңа тагын, тагын типте.

— Инәки! — дип ике кулы белән битен каплады кыз һәм борылып шәһәр ягына таба йөгерде.

Егетләрнең берсе аны куып тотарга итте, ләкин Котбый аны туктатты.

— Стой! Китсен... Тимәгез аңа!

Зөлфия яшьтәшләренә караганда иртәрәк өлгерде. Тугызынчы класста ук олы кызының күкрәкләре тулышып, балтырлары түгәрәкләнеп китүен күргән әнисе яшь-җилбәзәкнең ишек төбеннән китмәвенә борчылып, тәмам йокыдан калды. Зөлфия ярты төннәргә кадәр каядыр йөри, соң кайта башлады. «Инәки, мин аз гына йөреп керәм»,— дип чыгып китә дә югала, чыгып китә дә югала.

Ачуы чыгып, кызын егет-җилбәзәк арасыннан әлеп-йолкып алып кайткан чаклары да булгалады ананың. Әйтте, орышты, мәгәр кыз моны колагына да элмәде, әллә әнисе аңа үгет сөйли, әллә моны аңа чит-ят берәү әйтә: «Җитмәсме, инәки, йокым килә»,— ди дә икенче бүлмәгә кереп китә.

Олы кызы Зөлфия консерваториягә кереп кайткач, Гөлбикәнең шатлыгы эченә сыймады. Көне белән булмаса да, Зөлфия янына өерләре белән йөри торган егетләр каядыр таралып беттеләр, әллә хәрби хезмәткә алдылар үзләрен, әллә үзләре дә кая булса укырга кердеме, ни генә булмасын, Зөлфия консерваториядә ныклап укый башлагач, Гөлбикә тынычлана калды.

Зөлфиясе өчен ана һични кызганмады. Кирәк икән, Сорочий базарына барды, ике-өч бәя артык түләп, джинси чалбар сатып алды, кыскасы, кулыннан килгәннең барысын да эшләде.

Кече кызы Кәримә холкы-фигыле белән апасына һич кенә дә охшамаган иде, әйтерсең алар ике анадан туганнар. Әнисенә мыскал да борчу китермәде Кәримә, әйбәт укыды, ни кушсаң да, җиренә җиткереп эшләде, соңгы елларда тегү-бәйләм эше белән мавыгып китте. Кәримә Зөлфия кебек орды-бәрде холыклы түгел, әкрен-сабыр итеп уйлар, һәр сүзен үлчәп, гүя бизмәнгә салып әйтер. Кыскасы, ышана иде Кәримәсенә Гөлбикә, начар юлдан китмәс кече кызы, нәкъ менә шул житдилегенә артык ышанганга күрә дә моңа кадәр кече кызы игътибар ягыннан күләгәдәрәк калып килгәндер... Моны ана үзе дә сизеп килде килүен, әмма өзеп-сызып кына әйтмәде.

Зөлфиягә егетләр бик тиз гашыйк булалар. Әлбәттә, җырчы кыз булганы өчен генә түгел, Зөлфия төскә-йөзгә дә бик чибәр, матур, мөлаем итеп елмая белә, һәм шул елмаюга егетләр магнитка тартылган энәләр кебек тартылалар. Зөлфиянең холык-фигыле генә үзенчәрәк: бик тиз үпкәли, көйләтә, кирәксә-кирәкмәсә дә гел урынсызга назлана башлый. Егет халкының берише, кызлар көйләргә өйрәнмәгәннәре, чибәр кызның холкын кабул итмиләр, тизрәк аның тирәсеннән читләшү

җаен карыйлар. Мәгәр кызның моңа бер дә исе китми, әйдә, китә бирсеннәр, чөнки аның урынына иртәгә үк икенчеләре табылачак.

Котбый һәм Барый белән дә араларын Зөлфия кырт итеп өзде дә ташлады, бер дә икеләнеп тормады. Балачактан ук таныш иде алар аңа. Барый озын буйлы чибәр генә егет, Котбый исә юантыграк гәүдәле, кечерәк кысынкы күзле, мәгәр кыю, әрсез карашлы. Шул әрсезлеге белән ул Зөлфиянең күңелен биләп алды, шул әрсезлеге белән бизддерде дә, ахрысы. Әрсезлеге бер хәл, әмма Котбыйның теге вакытта Казанка буенда очрашкандагы кыяфәте күз алдына килдеме, Зөлфия бөтен җаны-тәне белән тетрәнеп куя. Шул Казанка буенда булган хәл аның күңелен һәрчак борчып, бимазалап, куркытып тора. Дөрес, егетнең ул исемен дә белми калды. Әмма эш андамы. Ул качты, егетнең берүзен калдырып качты. Гафу итәрлек хәлме бу?!.

Казанка буенда йөргән егет аның күңеленнән бик озак китмәде. Паркка ул еш чыкты, шул егетне очратырмын дип өмет итте. Әмма егет һаман очрамады да очрамады. Котбыйны исә аның бөтенләй дә күрәсе килмәде. Күзләрен акайтып, бөтенләй чит-ят кешегә ташлануы искә төшкән саен, аркасына гүя салкын су коела,— тетрәнеп-калтыранып китә Зөлфия. Кансыз, уенын-чынын бер күргән һәм уйнап әйтелгән сүздән дә, чыныннан да бер дәрәҗәдә үч ала торган Котбый нишләтте икән егетне? Алар дүртәү, ә ул, бичара, берүзе. Котбый өчен ала да, кола да юк, аның өчен дөнья бары тик ак һәм карадан гына торадыр кебек тоела Зөлфиягә.

Әйе, Зөлфия Котбыйны яхшы белә. Әле булса бүгенгедәй хәтерендә: кышкы каникулларын уздырырга бабаларына килгәч, сеңелле-апалы энә шул Барый һәм Котбыйлар белән кар атышлы уйнаганнар иде. Котбый, Барый, Зөлфия — бер якта, ә бөтен урамның ыбыр-чыбыры, ягъни бала-чагасы — Кәримә ягында. Уен кар атышудан башланды. Ун метр ара калдырып, кардан диварлар өелгән, бер якта зурраклар— җиденче класс балалары, ә икенче якта Кәримәнең «сугышчылары». Гаҗәбе шул иде; алар Кәримәгә буйсыналар, сеңелесе ни әйтсә, шуны эшлиләр иде. Чын командир менә. Бер генә кычкырып әйтә бу тегеләргә. Хәтта Котбый булып Котбый да: «Чык, Кәримә, безнең якка!» — дип карады. Кәримә аны ишетми, ул командир, аңа бөтен «армия» буйсына.

— «Огонь! Огонь!» — ди ул, уен белән мавыгып, «дошманнарга» кар атучы «сугышчыларын» куәтләп. Ә дошман дигәннәре — Котбый белән Барый һәм Зөлфия. Зөлфия сеңелесеннән көнләшеп куя, әмма нишли ала ул, рәтләп кар ата да белми, шуның өчен баштан ук Барый белән Котбый аңа үзенә бер кар сарае ясап куйдылар; Зөлфия сарайдан чыкмый, кар йомарламнары ясап, малайларга бирел тора.

— Башың калкытма! — дип кычкыра аңа «дошман» якыная башлагач Котбый. Ә тегеләр күбәү бит, җитмәсә иң алда кара-тутсыл йөзле, башына куян бүреген батырып кигән, уен шаукымыннан бит алмалары алсуланган Кәримә килә.

— Ура, ура! — дип кычкыра ул. — Королева сараена атмаска, королеваны пленга алырга! — дип боера ул «сугышчыларына». Ә тегеләр Барый белән Котбыйны сарай стенасына ук китереп кыстылар. Менә берсе сарай эченә төшә, Котбый аны бер читкә тәгәрәтеп җибәрә, аның артыннан икенчесе, өченчесе... Ул да түгел, кул-аяклары бил каешы, пальто путалары белән бәйләнгән «әсир сугышчылар» кар өстендә яталар иде инде. Ыбыр-чыбырның командиры Кәримә аяк астында яткан, инде кымшанырга да хәлләре калмаган Котбый белән Барый тирәли тәкәббер кыяфәттә әйләнеп чыга. «Сугышчылары» аңардан әмер көтәләр. Боерсын ул аларга «әсирләрне» кар белән күмәргә, икедә уйламый күмәчәкләр, «әсирләр» өстенә бөтен бер кар тавы өеп куячаклар. Әмма командирлары андый боерык бирми.

— Королеваны сарай төрмәсенә ябарга! — дип боера ул. — Пленга төшкән сугышчыларга минем бер тәкъдимем бар.

— Өчесен дә сарайга ябабыз да кар белән күмәбез,— диештеләр Кәримә яклылар.

— Юк,— ди командир.— Башта без аларга болай дибез. Кем дә кем безнең якка чыга, аңа — ирек, ә кем дә кем безнең якка чыгарга теләми — аңа төрмә.

Барый Кәримәнең бу уенын да кабул итте: «Чишегез мине, сезнең якка күчәм».— диде. Аның бу сүзләренә Котбыйның күзләре акайды, җен ачулары чыкты.

— Сатлык җан, — диде ул, кулларын бәйләгән баудан ычкына алмаудан гаҗиз калып, яңак итен чәйни-чәйни.

— Молчать, пленный! — дип кычкырды аңа Кәримә.

Ләкин уенның уты сүрелгән иде инде. Кәримә Котбыйның яшелсоры күзләрендә яман ачу чаткылары күреп, аның кул-аякларын чишәргә кушты. Котбый сикереп торып, аягына басуга, томырылып Барый өстенә ташланды. Яшь әтәчләр, умарта күче кебек, Котбыйны шунда ук сырып алып, аяктан ектылар. Менә шунда инде Котбый чыдамады: кайсыныңдыр колагын тешләде, кемнеңдер борынын канатты, тибешә башлады, аннан соң инде, уенның көе китүгә хәйран калып шым булган малайларга күтәрелеп тә карамыйча, өенә таба торып чапты. Олы абыйлары чын-чынлап сугыша башлагач, бәләкәйрәкләр дә берәм-сәрәм таралыша башлады.

Кәримә әле йөгереп китеп барган Котбыйга, әле авызы-борыны канап, шыңшып торган «вак күзләргә» карап торды-торды да: «Дурак!»— диде. Һәм ул да бабаларына кайтып китте. Зөлфия шунда апасын гелән күрмичә китеп барган сеңелесенең җитдилегенә шаккаткан иде. Ә Котбыйның бу кыланышын Зөлфия бик күп еллар оныта алмады. Гомумән, Котбый утсыз-шырпысыз дөрләп янып китәргә генә тора иде. Ул Зөлфияне күп тапкырлар яклап, аралап та калгалады, аңа тел дә тидертмәде. Бу хәлләрне күрә-күрә Зөлфия: «Ул көчле, ул мине һәрвакыт яклаячак»,— дигән нәтиҗәгә килде. Бу тугызынчы класска кадәр шулай барды. Ә бер тапкыр бабаларына килгәч, шундый хәл булды. Гадәттәгечә, Котбый аны дискотекага чакырды. Болай барысы да әйбәт кенә башланган иде югыйсә. Кызлар да, егетләр дә матур гына биниләр, шунда Котбый белән биегәндә, Зөлфия янына (этә-төртә дияргә була) чибәр генә егет килеп басты һәм үзе белән биергә чакырды. Котбыйга егетнең бу кыланышы ошамады. Әмма Зөлфия чибәр егет янынарак күчте һәм тегенең бию ритмына ярашып селкенә башлады. Моны күреп, егет тагын да дәртләнебрәк китте. Ярый ла элек икәүдәникәү генә биегәннәр, хәзер бит өч-дүрт кеше бергә бии ала. Әмма бөтен хикмәт шунда: кыз кемнең, кайсы егетнең хәрәкәтләрен кабатлый, кемгә туры карый, кемгә елмая, кем тирәсендә бөтерелә — шул аның сайлаганы. Башта Котбый Зөлфиядәге бу үзгәрешне күрмәмешкә салышты, ахыр сабыры төкәнде, йолкып алды да егетне тышка алып чыгып китте. Аннан ул авыз читен канатып, ияк астына чыпчык күкәе чаклы шеш утыртып килеп керде.

— Без аңлаштык, ул хәзер синең белән бер тапкыр да биемәчәк,— диде Котбый, Зөлфиянең агарынып, куркынып китүенә игътибар итмәстән, музыка ритмына ияреп биергә тотынды...

Дискотекадан соң Котбый Зөлфияне бабаларына кадәр озата килде. Капка төбенә җиткәч, моңа кадәр ишетмәгән сүз әйтте Зөлфиягә: «Мин синең өчен утка-суга да керергә әзер, Зөлфия»,— диде. Әлегә чаклы Котбыйның аңа мондый сүзләр әйткәне юк иде. Моны ишетүгә, Зөлфия аптырый калды. Әмма җилкәсен сикертеп кенә куйды. Янәсе, һи, нәрсә ул ут-су. Ул вакытта Зөлфия бу сүзләренең асылына төшенмәгән иде әле, бу сүзләргә ул соңрак, консерваториягә кереп, Котбый

аның артыннан чын-чынлап киләп сара башлагач төшенде. Көннәрдән бер көнне, лекцияләрдән соң озатып куйгач, Зөлфиянең кулыннан алды да: «Зөлфә, мин сине башка егетләр белән күрергә теләмим, ни генә булмасын, мин сине якларга һәм сакларга телим»,— диде. Нәкъ менә «сакларга» дип әйтте.

Бу юлы инде Зөлфия гаҗәпләнүдән җилкәсен сикертмәде, Котбый әйткән сүзләрнең чын мәгънәсенә төшенә бара иде ул. Әйе, ул аны саклаячак, ләкин кемнән? Нигә?..

Казанка буенда булган хикмәтле хәлдән соң Зөлфиянең Котбыйны күрәсе килми иде. Ләкин менә язмыш аларны тагын очраштырды. «Котбый усал кеше. Ул минем күз алдымда мин исемен дә белмәгән егетне кыйнады. Һәм мин аңа бүген тагын елмаерга тиеш. Юк, тагын бер тапкыр юк!» Шулай дип уйлады Зөлфия эченнән, әмма егетне күргәч, борылып китә алмады. Котбый аны гүя үзенә магнит белән тартып китерә иде. Көзге яфраклардан төшәлгән йомшак келәмнән атлаганда әнә шундый уйлар йөгереп үтте Зөлфия башыннан. Әле соң түгел иде, борылып китә ала иде. Уң якка борылса — тар сукмак, әмма егетләр, ни сәбәпледер, нәкъ менә шул якка карап торалар иде, сул якта мәшһүр Тукай һәйкәле, һәйкәл тирәли чәчәкләр утыртылган. Борылып китәргә соң иде инде. Алар аны күптән күреп алганнар. Күргәннәр һәм кул күтәреп торалар.

— Һэлло, Зөлфә!

— Чао, егетләр. Кемне эзлисез?

— Сине, Зөлфә.

— Ә мин инде сезне беркайчан да очратмам дип уйлаган идем.

— Ни өчен?.. — диде Котбый.

— Себердә урман кисәсез дип уйлаган идем...

— Очрап шәп иттең, Зөлфә, как-никак старые друзья... Тем паче минем бүген туган көнем...

— Ресторан эшли,— диде Барый.

— Точно, картлач. Әйдәгез ресторанга.

Нигәдер Зөлфия Барыйның күзләренә төбәп карады. Егет кыенсынып, күзләрен түбән төшерде.

«Син әйт, Барый, нигә теге вакытта тиктомалга кыйнадыгыз егетне?!» — дип сорыйсы килде Зөлфиянең, әмма сорарга җөрьәт итмәде.

Әйе, күрер күзгә чибәр генә егет иде Барый. Озын буйлы, күзләре дә мәрхәмәтле, ояла да белә, иң мөһиме — күзләре Котбыйныкы шикелле кечкенә түгел, ә үзен менә нигәдер баштан ук күңеле кабул итмәде. Котбый башка иде, аның эчендәге — тышында. Котбыйда ул үзенә җитмәгән әрсезлекне тапты бугай. Тик менә күзләре... Нәкъ урман мәчесе инде.

— Минем бер тәкъдимем бар,— диде Котбый.— Әйдәгез, чынлап та ресторанга!

Парк эчендәге «Ял» ресторанына Зөлфиянең беренче тапкыр керүе иде, кергәч, ул беравык каушабрак калды, шау-шу, буш урын да юк сыман, әмма Котбый шунда ук түр почмактагы буш өстәлне күреп алды һәм тәвәккәл рәвештә шунда юнәлде. Ләкин аны официант егет туктатты. Котбый, чарасыз калып, Барый белән Зөлфия ягына карап алды. Официант егет белән нидер аңлашканнан соң гына Котбый, Барый белән Зөлфиягә кул изәде.

Килеп утырышуга, Барый аңардан:

— Ничек ышандырдың? — дип сорады.

— Мәхрүм итмә, бүген минем туган көнем, дидем. Паспортымны чыгарып күрсәттем. Ә син бу өстәлнең чынлап та хуҗалары булгандыр дип беләсеңме әллә? — Котбый кулларын угалап алды.— Я, ни эчәбез? Ашауны Зөлфә заказать итә...

Зөлфиянең алдына меню китабын китереп салды Котбый.

— Мин эчмим,— диде Зөлфия. — Миңа ярамый.

— Ихтыярың. Тәкъдим итү — минем эш, эчү-эчмәү — синең эш, дигәнме әле бер шагыйрь.

Ул арада официант егет тә килеп җитте, кесәсеннән блокнотын алды.

Ресторannan чыккач, алар парк сукмаклары буйлап йөрделәр. Барый белән Зөлфия тыңлап кына бардылар, туган көнендә сүз Котбыйга бирелгән иде бүген. Зөлфия аның тел төбеннән шуны белде: Котбыйның әтисе Себердә — эштә, әнисе сәүдә базасында эшли икән. Котбыйның бай китапханәсе, стерео уйнаткычы бар, имеш.

— Машинаң да бармы, Котик? — дип көлемсерәп сорады Зөлфия.

— Захочу, анысы да була, Зуленька. Нииндиен алыйм, кызыл төстәгенеме, яшелнеме?

— Кайсы да ярый,— диде Зөлфия, уенга кушылып.

Хикмәтле хәл, җитди тормыш һәрчак уеннан башлана, диләр, соңыннан чынлап та шулай булып чыкты түгелме. Зөлфиягә шушы Котбый дигән егет ошамаса да, ул аңа күнегә башлады, шушы очрашудан соң егет аны һәр көн булмаса да, көн аралаш диярлек була, консерваториягә каршы алырга килде, өйләренә кадәр озатып куйды. Зөлфия әкренләп гадәтләнде аңа, Котбый бер-ике көн күренми башласа, ул инде юксыну, ялгызсыну хисе тоя башлады. Шулдыр инде күнегү дигәннәре.

Октябрь аеның соңгы көннәре җитте. Сары яфраклар коелган тротуардан егет белән кыз атлый. Егет кызның иңбашына үзенең күн тужуркасын салган һәм җайлап кына кызның биленнән кочып алган. Шуннан алар Толстой урамына килеп чыктылар, Үзәк парк каршына җиттеләр, мәңгелек ут яныннан әйләнделәр. Көн кич якка авышкан иде инде. Зөлфия, миңа кайтырга вакыт, диде. Котбый аны тыймады, аңа каршы берни әйтмәде, сүзсез генә алар яшәгән урамга таба борылды. Котбый кызны подъездга хәтле озатты. Зөлфия, иңенә салган күн тужурка турында да онытып, кереп китә башлады, ләкин шунда ук исенә килеп, кире борылды һәм Котбыйга тужуркасын салып бирде. Шунда Котбый аның кулыннан эләктереп алды һәм сак кына кызны үзенә табарак тартып китерде.

— Котбый, кирәкмәс... Башка вакытта яме,— диде кыз.

— Бар соң,— диде егет, үпкәләмәде дә бугай.— Тыныч йокы сиңа.

Зөлфия борылды да кереп китте. Чынын әйтергә кирәк, ул бу хәленә мыскал да үкенү тоймады. Ул егетне ошатмый иде, ул аңа әле өйрәнеп, гадәтләнеп кенә килә. Ни өчен аның кочагына керергә ашкынып торырга тиеш соң әле ул. Моның өчен аңарда ташып торган теләк булырга тиештер бит инде!

«Мин аңа гашыйк булмадым, мин аны яратмыйм»,— дип, үз-үзен ышандырырга тырышты Зөлфия. Әмма алай әйтү белән генә егет аның күз алдыннан китмәде. Котбый әрсезләнеп аның күңеленә керде һәм йөрәк түреннән урын сорый башлады, ә Зөлфиянең аңа урын бирәсе килми иде. Мөмкин хәлме? Алай дисәң, кем соң аның күңелен биләп тора? Беркеме дә юк ич аның... Ә теге егет, Казанка буенда кыйналып калган егет? Ул бит аның хәтта исемен дә белми калды. Әмма ошаган иде Зөлфиягә егет, бер күрүдә гашыйк булырлык иде.

Әниләре кайвакыт: «Сез, ахыр заман яшьләре, үзгәчәрәк яратасыз бугай. Кәримгә дә беркем дә ошамый, сиңа да»,— дия иде. «Юк, инәки, миңа әнә шул Котбыйның минем арттан бер тотам калмыйча йөрүе ошый. Минем арттан йөри башлагач, ул егет концертлардан калмый башлады. Хәзер ул минем белән бергә заман музыкасын гына түгел, классик әсәрләрне дә бик яратып тыңлый. Ә чын күңелдән музыка сөйгән кешенең уй-фикерләре изгелектә булырга тиеш»,— дип уйлады

Зөлфия, әмма әнисенә ул хакта әйтергә никтер теләмәде, аңламас дип уйлады.

Бер тапкыр шулай, концерт беткәч, Зөлфия бөтенләй онытылып чыгып барганда, Котбый аны дәшеп туктатты:

— Зөлфә, тукта әле, кая болай ашыгасың?..

Зөлфия уңайсызланып туктады. Аннары һавага чыктылар.

— Уйланып бара идем, сизми дә калганмын. Кәримә сеңелем юкка чыкты. Кая булса китеп барганмы? Берәр яман кешегә тап булмаса инде...

— Ә син Барыйдан сора. Соңгы вакытта сеңелең белән бергә Барый булгалады. Һәм, ялгышмасам, алар арасында гади дуслык кына түгел...

— Чушь все это, Котик.

— Анысына керешмик, Зөлфә. Мәхәббәткә тикшерүче кирәкми, аның хөкемдары да, тикшерүчесе дә, яклаучысы да — ышану булыр. Син миңа ышанган кебек.

— Эх, Котик, Котик, син үз-үзеңә артык ышанучан түгелме? Кем әйтте әле, мин сиңа ышанам дип?

Котбый җилкәсен җыерып куйды, аяк астындагы таш кисәген тибеп җибәрде.

— Ышану турында кычкырып әйтмиләр. Ышану ул гел фәрештә кебек, күп кабатлый башласаң, бизеп китә, диләр.

Бер көнне ике сеңел арасында сүз ара сүз чыгып, Кәримә апасыннан сорап куйды:

— Нигә кирәк сиңа шул Котбый, ни таптың син аңарда, ни сакалы, ни акылы дигәндәй, китче! — диде.

— Ә синең лекцияләрдән соң бер ялгызың караңгы урамнар аша кайтканың бармы?.. Юк шул менә. Дөрес, яратып бетермим мин аны. Ә бәлкем, ялгышамдыр.

— Тиң түгел ул сиңа, апа җаным!

— Тиң түгел? Ә бәлкем, тиңдер,— Зөлфиянең сеңелесенә ачуы чыкты.— Катышма миңа. Йөри бирсен. Кирәк булса, җаныма тиң кеше очраса, көне белән отфутболю мин аны.

— Соңыннан үч итеп берәр ни кылса?!

— Үч?! Нинди үч, ни өчен?

— Ни өчен үч алалар?

Янә Зөлфия тетрәнеп куя, янә күз алдына Казанка буендагы хәл килә.

— Тимә син миңа, Кәримә. Аңа да тимә... Ул минем өчен утка да, суга да керергә әзер.

*Ахыры киләсе санда.*

## Зөлфәт

# ЙӨРӘКЛӘРДӘ — ҮЛМӘС ДАСТАН

ПОЭМА

*Джанни Родари истәлегенә*

### Әфсен-төфсен!

— А-у, сылу Зөһрә! Айлы төндә Җиргә
Көмеш нурлар булып сагышларың төшсен,
Миһербанлы булсын язмыш — Үги ана —
Әфсен-төфсен!

Терел, Шаһрезадә! Әкиятең кирәк!
Кайда кичәләрнең мең дә икенчесе?
Оныттырсын сүзең кара максатларны —
Әфсен-төфсен!

Яшәрткеч су тибеп торсын чишмәләрдән,
Тик саф җаннар шушы суны эчсен,
Чынга аша күрсен бары якты хыял —
Әфсен-төфсен!

Югалмагыз череп, агач тамырлары!
Сезгә дә бу язмыш озын гомер бирсен!
Күрсен яңа Эрьзя һәм сын итсен сезне —
Әфсен-төфсен!

Җирдә патша булып гомер сөрүчеләр
Кигәвенле җәйдә көтү көтеп йөрсен...
Һәм хөкемдар булсын көтүчесе җирнең —
Әфсен-төфсен!

«Туйда мин дә булдым...» Егет-кыз хакында
Һәрбер кыйсса шулай тәмамлана күрсен,
Тигез гомер бирсен гашыйкларга язмыш —
Әфсен-төфсен!

Гел җиңелә бирсен явыз кара көчләр,
Шулай була күрсен — гел дөреслек җиңсен!
Һәм җир йотсын чынлап җансыз-вөҗдансызны —
Әфсен-төфсен!

Чынлап Җиргә төшсен «очкыч-тәлинкәләр»,
Чиксезлектән килеп дуслар сәлам бирсен
Һәм елмайсын алар кешелекне күреп —
Әфсен-төфсен!

Бөек мәңгелеккә тәрәз чиертсен кеше,
Гади генә әйтсен: «Ач ишекне, Сим-Сим!»
Яшә, тылсымлы сүз — шаян хыял кызы —
Әфсен-төфсен!

Әкияти хисең саумы, кешем, җанда?
Җуймадыңмы Җирдән күчкән тылсым көчең?
Әкиятне җую — кешелекне җую.
Әфсен-төфсен!

Җаннан-җанга күчсен серле әкиятләр!
Яз җилләре булып, Җирне назлап иссен!
Котсыз яшәп Җирнең котын алучыга
Ачы каргыш төшсен! —
Әфсен-төфсен!

## Джанни Родари варианты

*Шагыйрь һәм бөек әкиятче белән әңгәмәдән. Мәскәү, 1979 ел.*

— Тотып кала агач тамырлары
Һәм туктата
                    таулар ишелүен —
Ни коткарыр,
               иптәш Родари,
Бүген
          Кешелекнең кешелеген?

...Карашлары уйчан Родариның:
— Җан җылысы — ышанычлы терәк;
Юк, бөекләр түгел, бүген Җиргә
Игелекле җаннар кирәклерәк...

Елмайган күк якты уйларының мәгънәсеннән,
Нәкъ кыл уртасыннан,
Җавап бирә иптәш Родари.
Үсеш сыман катлаулы бу җавап
Һәм гади ул — спагетти сыман:

— Әкиятне саклап калу кирәк,
Бөтен килеш саклыйк дисәк Җирне.
Һәркайда бер — Җирнең сабыйлары,
Тик өлкәннәр генә төрле-төрле!

...Родари вариант тәкъдим итә,
Әле — вариант,
               бәлки,
                    бер минуттан —
Гондольерлы шәһәр Неапольдә,
Шикле дан оясы Голливудта,

Һичбер шиксез зәңгәр Ык буенда,
Яшел Миссисипи ярларында,
Ялгыз каплан җаны күккә ашкан
Килиманжароның карларында,

Яңа Сәет дигән тын авылда,
Ерак-ерактагы Камерунда,
Дуслык лагеренда — Аю-Дагта,
Ак Чилинең кара лагеренда.

Алсу кукләрендә Һиндстанның,
Ниагараның ярсу ыргуында —
Планетада — кеше төсе иңгән,
Кеше исе килгән һәр урында —

Котылырга сукмак эзләр кеше,
Булган барлык сукмакларны барлап! —
Чираттан тыш тикшерелер шулчак
Родари тәкъдиме иткән вариант.

Үкенечтән сыкрап куяр җаннар
Һәм кысылып куяр һәрбер йөрәк:
Бөтен килеш саклыйк дисәк Җирне,
Әкиятне саклап калу кирәк!

Исән калса җанда шушы якты,
Сугышлар да кирәк булмас бәлкем —
Саклау өчен Җирдә балачакны,
Балачакны — димәк, киләчәкне —
Галәмнең иң серле әкиятен.

Яклаучы һәм Саклаучы дип бары
Яд итсеннәр, Кеше, исемеңне...
Сөйләп туймас әкият бу дөнья.—
Әкият соң начар бетсен мени?

...Йокла, имеш, матур төшләр күреп,
Кочакла да лазер, радарыңны! —
Зур, галактик борчу сеңгән иде
Күзләренә иптәш Родариның...

## Җәза

*XXI гасырның Дуңгыз елына оештырылган экспедиция җитәкчесе N ның Вакыт машинасындагы борт журналындагы язмаларыннан*

Зур һәм мәгърур кала. Үзәк мәйдан.
Биекләргә ургый кара төтен.
Без юлыктык бүген зур шау-шуга:
Әкияткә булды бүген хөкем.

Мәйдан уртасында — гигант учак.
Ташыганнар төне буе утын.

— Ашык, Әкият кызы! Тезлән! Җыла!
Бисмиллаң әйт, я булмаса — чукын!

...Соң сәгатең сукты! Ялган белән
Аздырганың өчен балачакны —
Син, битеңә каплап уйдырмаңны,
Уйдырмасыз утта яначаксың!

Ышандырдың, һәрбер хыянәтне
Җиңеп чыга диеп изге сафлык.
Муеныңа ура ул сафлыкны —
Ургый-ургый бүген яначаксың!

«Борын заманнарда...» — дигән булып,
Бүгенгене сөйләп юләр саттың,
«Әйдәгез,— дип,— Тылсым илләренә!» —
Балаларны дәшеп син чаң кактың!

«Канатлы ат!» — дидең. Ышандырмый —
Хет маңгаең булсын ындыр чаклы,
Ат канатлы булмый — этлар була
Я иярле, яки ыңгырчаклы!

Әкият кызы! Нигә кирәк булды
Аздырулар сиңа шуның чаклы?
Агач атка атландырмакчымы? —
Бетте! Җитте сиңа — яначаксың!

Гражданнар! Учак әкрен яна...
Кымшаныгыз инде шундый чакта! —
Әкиятнең калдык-постыкларын
Һәммәсен дә — һоп-па! — шул учакка!

Уенчыклар белән кызыктырып
Коткы салдың һаман балачакка,
Уйнап түгел, уйлап үссен сабый —
Уенчыкны — һоп-па! — сал учакка!

Җитештерүчәнлек бик нык кимер
Шул гап-гади хыял аркасында —
Арт битенә аның — кызган тимер!—
Һоп-па! — Шул учакның уртасына!

Күптән баш тарттык без хыяллардан,
Ни пычакка ЭВМ бар чакта?! —
Тот ботыннан фантазияләрен —
Болгап томыр — һоп-па! — сал учакка!

...Янып бетте учак. Кисәүләрен
Факел итеп тотып гражданнар —
Җиргә хуҗа булу өчен, яуга —
Зур сугышка бүген кузгалдылар.

Уйга калдык: һәр сугышның башы
Һәр дәвердә бер үк төрле икән —
Әкият кызы — тарих дәвамында
Күпме кыргый учак аша үткән!

Тетрәндерде: бик охшарга теләп
Утлы факел тоткан абыйларга,
Кыргый сафта
жанында әкиятнең
Көле генә калган сабый бара!

...Әкият яндырганда вәхшиләргә
Нинди рәхәт иде, жылы иде —
Киләчәкнең шушы Дуңгыз елы
Чын мәгънәдә чучка елы иде...

Шомлы, кара иде бу килер көн...
Сез... Сез аннанниләр көтәсездер? —

Юлга чыктык... Безне каршылагыз,
Тизрәк кисәтергә ашыгабыз
Бүгенгене!
Әкиятне! Сезне!

## Тукай догасы

Әкият ул — барлык халыкларның
Хыялыдыр бәхет хакында:
«Суга төшкәч — суда батмасаңчы...
Янмасаңчы — кергәч ялкынга...»

...Әкият янган учак... көл-күмергә
Калдырды ул жирдә күпләрне —
Эшафоттан — бронза пьедесталга
Күтәрелгән Жәлил күкләрне!

Бар иманын көйдерергә теләп
Яндырды ул жирдә күпләрне —
Мәйданнарда түгел, тар бүлмәдә
Янып үлгән Тукай күкләрне.

Сугышлымы яки солыхлымы —
Нинди генә чорда булмасын,
Шагыйрь өмете ул — һәрбер чорның
«Ярлыкагыл!» — дигән догасы.

Йолу өчен безнең гөнаһларны,
Исән саклау өчен дөньяда —
Хаклык дигән алла каршысында
Туры сүзле Тукай догада.

Пышылдый ул — хәтта иреннәре чатный —
Күзләренә карап Хаклыкның:
— И, Дөреслек, ходам... Күтәрсәң дә,
Үтерсәң дә безне хаклысың...

Ләкин бөтен үткәннәре өчен
Һәм дә киләчәге хакына —
Ярлыка син, шәфкать нурыңны сип
Рәнҗетелгән мескен халкыма.

Хаклык — ходам! Авыр чорда язмыш
Шагыйрьле бит итте милләтне...
Тик минем күк кыска гомерлене
Шагыйрь итү нигә кирәкте?!

Җылы сүздән мәхрүм бу халыкны
Ничек юатыйм мин — бичара —
Җитмәс иде аңа шагыйренең
Мең ел яшәрлеге булса да!

Кабул кыл догамны, бөек Хаклык!
Тыңла сиңа тугры кешеңне —
Гомер бир син... Бир син бәхетлесен,
Гомер сорыйм халкым өчен мин...

Гел кагылып, кимсетелеп һаман,
Яшәгәне өчен тилмереп,
Җандай күргән газиз халкымны син
Киләчәкле итә күр берүк!

Ул шагыйрьле булсын, музыкантлы,
Рәссамнары булсын, и, Хаклык!—
Күкрәгендә аның югыйсә бит
Тышауланган куәт ни хәтле!

Тышауларын өз син күкрәкләрдә
Ирек көтеп яткан толпарның —
Соң догасын берүк кабул кыл син
Шушы шагыйренең татарның!

Һәр шигырем минем — утлы догам,
Шуның өчен җиргә туганмын —
«Киләчәкнең «Амин!» дигәненә
Туры китер, Хаклык, Догамны!

...Ярсуларга күчте бу ялвару,
Киләчәккә барып иреште —
«Аврора»ның күкрәк тавышы белән
Җавап сүзен әйтте Дөреслек.

...Чорлар учагына үзен ягып,
Бер җылытыр өчен халыкны
Һәр дәвернең Туры Тукайлары
Газаплы ут булып калыкты.

Ялваралар алар Киләчәккә:
«Тылсым куәсе бир халкыма:
Суга төшкәч — суда батмасачы,
Янмасачы — кергәч ялкынга!..»

## Биеклек

*Лаеш районы, Зур Отар авылында туып үскән кызның — альпинизм буенча күп мәртәбәләр республика чемпионкасы Зәйтүнә Даутованың Морис Эрцог пигында — упкын читендә — һәлакәт алдыннан соңгы монологы*

«Җирнең күкләргә иң якын ташы!
Кайсы биеклектә син яшисең?
Сабый килеш төштә күрдем сине,
Уйлап таптым сиңа мең-мең исем...

И, бөек Таш! Син бит әкияткә
Илткән якты, биек баскыч сыман:
Чын альпинист өчен һәр таш — баскыч,
Куйсалар да аны... баш очына.

Упкын өстендәге таш ныклыгы!—
Яшәү булып җанга син тоташтың...
Мин — Зәйтүнә Даутова — бүген
Сөйгән ярым итеп сайлыйм Ташны —
Бердәнберем бөек, биек Ташны!

И биеклек! Табынганым минем!
Гүзәл дә син, горур, дәһшәтле дә!
Сөйгән ярың була алырмын мин —
Дәһшәтеңә лаек яшәп кенә...

Мин эзләдем сине күпме таудан,
Хәтта кошлар менмәс биекләрдән!
И әкият — ташым! Бүген тагын
Йөрәгемне сиңа мин күтәрәм.

Бу мин — татар кызы — түбәннәрдән
Түбәләргә күтәрелү өчен —
Рюкзагымда — ипи, йөрәгемдә —
Ватанымның үргә үрләү көче.

«Түбән» сүзе хурламасын безне! —
«Түбән» димим, кат-кат әйтәм: «Түбәм!»
Мин җиңгән тау! Синең түбәңдәге
Күкләргә иң якын Ташны үбәм...

Мин — Зәйтүнә Даутова — бүген
Гомерлек яр итеп сайлыйм Ташны —
Һәлакәтем белән тәмамлыйм мин,
Шуның белән гомеремне башлыйм.

Назлап үптем сине, иң биек Таш,
Пышылдадым: «Көт син кабат...» — диеп,
Тезем — җирдә иде... Ә хыялым
Очты якты йолдызларга тиеп.

Һәм ишеттем шулчак, эндәштең син:
«Ничә гасыр көттем бит мин сине,
Үзән кызы — серле әкиятем!
Әкиятсез тагын үтсенмени,

Бәхет мәлем тагын китсенмени
Ялгызлыкта яңа гасырларым?!
Кал мәңгегә горур биеклектә —
Минем янда, биек җанлы ярым!

Төшмә, кал, Зәйтүнә!.. Миндә Җирнең
Һәм Галәмнең бердәм, зур көче бар...
Мәңге ялгызлыкның җиңеп булмый,
Аңлап булмый торган зур үче бар!»

...«Көт син кабат» — диеп пышылдадым
Төшеп барган чакта биеклектән,
Уяттың син биек тау тынлыгын,
Үкердең син дәһшәт булып куктән.

Ярсыдың син:— «Ник уяттың мине?!»
Сыкрандың син: «Нигә үптең шулай?!
Наздан дәһшәт көтеп була, ләкин
Син дәһшәттән назлар көттең бугай!..»

Мин — Зәйтүнә, җавап бирәм сиңа:
«Дәһшәтләр — наз миңа, назлар — дәһшәт.—
Кабул итәм синең чакыруны!
Мөмкин түгел миңа синсез яшәү!

Я, кушылыйк бергә — куенында
Гарасатлы карлар ташкынының!—
Куркыныч һәм газаплы бу минут,
Котылгысыз, серле, ашкынулы!»

...Юк, үлемем түгел — җиңүем бу,
Сөюем бу! Һәм мин соңгы чиктә
Дәшәм сезгә: — Газиз гомерләрне
Багышлагыз бары биеклеккә!

...И, Биек Таш! Серле зәңгәр тауның
Карлы кодрәтенә чорналып без
Очтык бергә... Юк түбәнгә түгел —
Түбәсенә биек чорларның без!

Онытмагыз ләкин — күтәрелдем
Җиргә сезнең күпләрегез өчен.
Әйттем: «Килер буын хурланмасын,
Гади куркаклыктан үлгән, диеп,
Бу халыкның күтәрелү хисе!»

«Очраклы хәл» диеп теркәмәгез
Актларга, рәсми язуларга.
...Мәхәббәтем тау гөлләре булып
Мәңге алсуланыр якты карда...

## Циркта бунт

«Мин — Арыслан — соңгы углы
Алты Бархан ыруының —
Алты Бархан, бер Оазис,
Бер Зәңгәр Күк һәм бер Чишмә —
Туу гимнын Бөек Анам
Ярсып ырылдаган урын!

Шул авазда н йөрәгемә кодрәт керде,
куәт керде —
Алты Бархан, бер Оазис,
Бер Зәңгәр Күк һәм бер Чишмә —
Шул авазның куәтеннән,
кодрәтеннән тетрәп торды!

Арысланга лаек язмыш вәгъдә итте
шушы тавыш —
Горурлыгым иде минем —
Бөек Теш һәм бөек Тырнак! —
Көтә иде мине Җирдә
Бөек Ыргу, Бөек Чабыш!

Минем ризык — җилдәй җилеп чапкан
кайнар Җәйран иде —
Ә читлектә калҗа ялау
Лаек эшме Арысланга?
Кем үтерде минем кыргый,
минем ярсу Бәйрәмемне?

Адәми зат көлү диеп аңлый минем сыкрануны —
Арысланлык дәрәҗәмне
Никадәр мин мыскылласам —
Шуның кадәр алкышлыйлар
мине — Алты Бархан углын!

...Җәтмә белән чорнадылар
иң беренче сунарда ук —
Сусын баса алмый калды
Бөек Теш һәм бөек Тырнак! —
Дәһшәтле үч йөрәгемә
кереп посты йомарланып...

«Арт аягым берлә торам» —
публиканың сөеклесе! —
Тик ялыйсы калды кулын
Таяк белән сукканнарның —
Күзгә карап шыңшый-шыңшый
чүплектәге әнчек төсле!

Җиде төннең уртасында
һаман-һаман керә төшкә —
Хыянәтче кулларыннан
Үтерелгән дастан булып —
Алты Бархан, бер Оазис,
Бер Зәңгәр күк һәм бер Чишмә...

Вакыт җитте, и Бөек Теш!
Сәгать сукты, Бөек Тырнак!
Кантамырлар сузылдылар
Зыңлап торган кыллар булып —
Мин үләргә тиеш бүген
Бөек Сунар гимнын ырлап!

Синнән күчкән Зур Йолага
тугры калам, Бөек Атам —
Мин үземнән көчсезләргә
Әгәр беркөн сунар чыксам —
Онытылсын синең Исем,
синең Исең — Хуш Исле Кан!

Бөек Анам! Ирекка мин тугры калам —
бикле үсеп!
Әгәр сунар чыкмасам мин
Үземнән дә көчлеләргә —
Онытылсын синең Исем —
синең Сөтең — Ярсулы Сөт!

...Публикага күз кыса ул —
каршымда ук — адәми зат...
Авызыма башын тыгып
Көлдерәчәк үз ишләрен! —
Тешләремне кысмыйча мин,
күп чыдадым, түздем озак...

Ул көчлерәк миннән, Атам,
ул көчлерәк миннән, Анам —
Минем кыргый, минем бөек әкиятне
Үтерде ул —
Минем авыз — сәхнә иде,
һәм сәхнәне хәзер ябам.

Җиде төннәр уртасында
кабат-кабат керсен төшкә
Мең үлемнән исән калган
Әкиятләр төсе булып —
Алты Бархан, бер Оазис,
Бер Зәңгәр Күк һәм бер Чишмә...

## Дәшегез!

Арып йоклый икән әкият тә —
Карурманда — ботак тишегендә,
Каргалардан калган ояларда,
Аю ташлап киткән аулак өндә...

Йоклый икән ишек-тәрәзләре
Такта белән кадакланган йортта,
Иләшә су астында калган
Гаваньнарга, онытылган портка.

Экипажы күптән һәлак булып,
Ятим калган космик корабларда
Тып-тын гына йоклый әкиятләр —
Галәм чоңгылында — еракларда...

Йоклый алар кара савытында,
Күлмәгеңнең берәр бизәгендә;
Түбәсендә — үткер кыяларның,
Альпинистның аяк эзләрендә.

Йоклый алар кышкы әскертләрдә,
Морж мыегында, айсбергларда;
Җидегәннең көмеш чүмечендә,
Көймә ышыгында — төнге ярда...

Тик әйт кенә син тылсымлы сүзне:
«Борын борын заманнарда...» — диеп —
Мәңгелекнең тере кошлары күк
Күкрәгеңә кунар алар килеп!

...Онытылса кинәт, юкка чыкса
Бу тылсымлы сүзләр —
Җир шартласа?
Һәм беркем дә ерак әкиятне
Чакырмаса, дәшеп уятмаса?!!

Юкса, Җирдән көчлерәк бит Кеше —
Үсешләрнең менде түбәсенә:
Ул тынычлык төрепкәсен бүген
Кабызмакчы — атом гөмбәсеннән...

Чакыруны көткән елмаюлы
Килеш калыр бары иреннәре —
Очып йөрер үлгән әкиятләр
Шәүләләр күк — диңгез төбендәге...

Йокы басар ерак йолдызларны,
Биек булыр — түбән... Түбән — биек...
Бу — мәңгелек йокы.
Мондый йокы
Аталадыр космик үлем диеп...

## Сак бул!

Сак бул, Намус! Кемдер әкиятнең
Күкрәгендә мишень күргәндә,
Тышау тотып, планета буйлап
Ак толпарны аулап йөргәндә,

Шигырь укып куанасы малай
Кастет игәгендә таманлап,
Тере бавыр ашап — дошманныкын! —
Һәм бик тәмләп кенә — дусларныкын! —
Көч һәм дәрман алган заманда,

Һәм Чилида — ялгыз камерада
Сорау алган чакта яшь кыздан,
Көчләү өчен өйрәтелгән этне
Бәйдән ычкындырган бу чорда —
Эндәш, Намус! Дөрес аңлатма бир
Акылыннан шашкан гасырга!

Сак бул, Намус! Көрәшчеләр өчен
Сынмас куәт булып чык алга!

Җир — Әкият янар учак сыман...
Кабызырга кемнәр ут алган?
Кастет түгел,
                жанда әкиятнең
Калдыкларын иги яшүсмер:
«Өмет тә бит ачтан үлә икән —
Яңаларын китер, Ольстер!..»

Сак бул, Намус! Хаклык авазы бул
Халыклар һәм килер көн өчен —
Кемне саклый юкса бу цинизм,
Яуга чыга хаклык кем өчен?!

Ау сезоны бара — әкиятнең
Аркасына пычак кем тери?
Тышау тотып, планета буйлап
Ак толпарны аулап кем йөри?

...Канатлы ат чаба җир буйлатып —
Азат җан ул — Хыял һәм Өмет!
Йөрәгендә — үлмәс дастан: Бәхет!
Ул булырга тиеш мәңгелек...

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ИСӘНМЕ, КӘШФИ АБЫЙ!

ПОВЕСТЬ

## 1



Утызынчы елларда сәхнәдә концерт булса, трактор турында җыр җырламый калмыйлар иде. Бигрәк тә мәктәп балалары.

> Тракторның тәгәрмәче, тәгәрмәче
> Алга таба, алга таба әйләнә.
> Колхозчылар, сак булыгыз, сак булыгыз,
> Сезгә кулак, сезгә кулак бәйләнә.

Сәхнәдә генә түгел, трактор халык теленә дә шулай куәт иясе булып килеп керде. Крестьян агай телен шартлатып: «Трактор, трактор — сука бабай, ерак тор!» дип әйткәләп куюны гадәт итте. Кай сыдыр бер язны — утыз дүртенче елмы икән,— басу түренә җир селкетеп «ХТЗ» тракторы килеп туктады. Авыл халкы, эшен ташлап, шунда чапты. Трактор тирәсендә кара комбинезон кигән, куллары-битләре мазутка буялган таза өч егет кайнаша иде. Язгы дымга бүртенеп яткан җир өстенә янган керосин исе таралган, трактор эшләгәнгә йомшак җир өсте дерелдәп утыра иде. Колхоз җитәкчеләре әлеге кара егетләр белән байтак сөйләштеләр, тагылма сукаларны көйләшкәндә үзләре дә майланып беттеләр, әмма тимер тарткычларын чыкырдатып, җиргә дүрт сөрәнен батырып кузгалып киткән бу гыйфрит артыннан бөтен кеше сокланып карап калды. Халык кичкә кадәр таралмады — җир һаман актарыла, күперә, буразналар ишәя бара иде. Тракторны туктатмадылар, колхоз идарәсен карауч Мәһибәдәр түти төенчекләр белән кайнар аш, ипи, сөт күтәреп килде, кара егетләр чиратлап, кара җир өстенә утырып, майлы куллары белән кайнар сарык итен сыпырттылар, сөяк кимерделәр, калын күмәч телемен умырып сөт ашадылар. Болар серле, сүзсез егетләр иде, боларны МТСлы күрше авылдан, диделәр, боларга кичкә бик яхшы фатир табарга, фатирларына ит, бал, күмәч кебек ризыклар җибәртергә, мунча яктырырга кирәк иде. Халык басудан караңгы төшкәндә генә таралды.

Сөрелгән басу уртасыннан яланаяк атлап, иң соңыннан кайтып килүче яшүсмер Кәшфи иде.

— Ике кулың белән рәхәтләнеп ит ашыйсың, бал-май эчендә йөзә-

сең килсә, әнә шундый ак эшкә өйрәнергә кирәк,— диде Габделбарый агай Кәшфигә.— Кара эшне аны мәнди анасы да эшли...

Малай инде болай да тормыш юлын хәл иткән иде.

Кәшфи ата-анасына үтә кадерле бердәнбер бала иде, аны Ташлытауга тракторчылар курсына бик зурлап озаттылар. Колхоз идарәсенең карары буенча, әгәр Кәшфи әйбәт укып барса, аның өчен әнисенә аена ун хезмәт көне, Кәшфинең үзенә өч тәңкә акча түләнеп барачак иде. Бер-ике ай буе Ташлытаудан хат-хәбәр генә килеп торды: «Зәнәтиеләр бик авыр, инде кәлинвалларны өйрәнеп бәттек, хәзер карбюратор белән магнето өйрәнә башлыйбыз...»

«Фатирда торабыз, бәрәңге пешерә торган чуеннын эче кечерәеп бетте, әти килгәндә икенче чуен алып килсен...»

Өч айдан, ял көнгә дип, Кәшфи үзе дә кайтты. Күрше-тирә аларның чиста зур өйләренә җыелып, идәнгә утырды. Көзнең яңгырлы, караңгы киче иде, җылы өйдә әңгәмә куерды. Хәер, бер Кәшфи генә туктаусыз сөйләде.

— Цилиндрның поршене аска төшкән вакытта, шундагы паз ачылып китә дә, шуңа баетылган ягулык килеп керә. Ул инде газсыман бөркелеп килеп керә. Шуңа свичәдән очкын әләгүгә, теге гөлт итеп кабына да, киңәеп поршенны этә башлый. Теге поршен кәлинвалга тоташкан. Кәлинвалны әйләндереп куюы була — икенче цилиндрның пазы ачыла. Аннан карбюратор аркылы тагын газ сыман май бөркелә. Аңа тагын ут кабына...

Крестьян агайлар аңларга тырышып, авыз ачып утыралар. Кәшфи кыза:

— Ә узган ел имтихан вакытында, беләсезме ничек булган? Комиссия председателе сорый икән Мәтәскә егетеннән — безнең күрше Сәрвәр тәтәнең туганнары ул, сез аны беләсез,— шуннан сорый икән:

— Әгәренки,— ди икән председатель,— әгәренки,— дип әйтә икән,— трактор пулный хут барганда аның магнетосы өзелеп төшсә,— дип әйтә ди,— аны тракторның кайсы тәгәрмәче таптар?

Кәшфи бәхетле чырай белән әңгәмәдәшләренә карый. Әмма берәү дә җавап бирә алмый. Кәшфи отыры шатлана. Мич буенда утырган әти-әнисенең дә шатлыгы бәхете эчләренә сыймый. Кәшфи агай-эне өстендә тилгән булып кагына:

— Белмисезме? Белмисез шул. Мәтәскәнең Гаптерие дә менә шуның белән янган инде. Ул әйткән: арт тәгәрмәче таптый, диган.

Кәшфи тирән мәгънәле, мыскыллы елмаю белән агайларга өстән карый. Берәү дә каршы килми, Кәшфи үзе һөҗүмгә күчә:

— Арт тәгәрмәчеме? Артмы?

Берәү дә дәшми, Кәшфи аның саен бәхетле.

Һәм ул, мең сумлык отышлы билетны чыгарып салгандай, тантана белән әйтә:

— Магнето төшеп калгач, трактор бара аламыни, наданнар! Лып туктый бит ул!

Кәшфи, авылны дер селкетеп, бер тәүлектән соң китеп барды. Егетләр, малайлар арасында кәлинвал, карбюратор, эсвичә, магнето, радиатор диган мәгънәле сүзләр Кәшфи исталеге буларак отып калынды.

## II

Менә май аеның кояшлы бер көнендә Ташлытау МТСыннан Гәр Хуторга билгеләнгән НАТИ тракторына утырып, авылга Кәшфи кайтып төште. Трактор, дөнья селкетеп, урамнан узды да, Габделбарый агайның тавык үләне баскан капка төбенә килеп, кинәт туктап калды. Әтәчләр куркыныч команда бирделәр, тавык халкы кыраклап бәрәңге

бакчасына тайды, этләр баскыч астыннан гына торып гайрәт чәчеп алдылар. Кәшифинең әти-әнисе ишегалдында йөгерештеләр. Габделбарый агай хәтта, түр тәрәзәне ачып, тәрәзә төбенә патефон китереп куйды. Андыйның рәтен белә торган кеше шул! Трактор двигателенең лепелдәгәненә пластинкадан җыр кушылды:

Әрләнсен лә дошман,
Шатлансыннар дуслар
Өзелеп чыккан безнең җырлардан.

Кәшфи НАТИның рулен тоткан килеш горур кыяфәттә утырды. Төшмәде. Әле трактор тирәсендә бала-чага гына иде. Бераздан олылар җыелды. Шактый кеше җыелгач кына, Кәшфи тракторын сүндерде һәм өстә утырган килеш сөйләп китте.

— Юк, крәчин мае гына җитми. Аңа әле аптул (автол) да кирәк. Крәчин маен аптул белән бутыйсың (бөтен халык әсәренеп, куркынып, күрше чулак Абдулга карап алды, ул да трактор каршында тора иде). Шул аптул кушкач кына ягулык була ул. Ни өчен дисәң, аның өчен чөнки... крәчин үзе генә булганда, цилиндрның поршеннары бер-берсенә ышкылып ашалып бетәрләр иде, и һәм дә зазор ясалып, трактор бөтенләй эштән чыгар иде. Ни өчен дисәң, аның өчен чөнки... аптулны кушып яндырганда (халык яңадан дерт итеп, чулак Абдулга карап ала) экономия дә була и һәм дә трактор поршеннарына да йомшакка килә. Ни өчен дисәң, аның өчен чөнки...

...Трактор көн-төн эшләде. Басу түрендә берөзлексез гөрелте торды. Колхозда март-апрель айларында бик күп атлар кырылган ел иде ул. Язга бик ябык чыктылар да ташу вакытында күтәрәмгә калдылар. «Ат күтәрү» дигән яңа мәшәкать барлыкка килде. Яткан атны торгызып, корсак астына ызма[1] тыгып күтәртеп асып куялар. Әмма, ачлыктан йөгенгән атны ызма гына коткара алмый иде. Шулай атлар кырылды. Ташлытау юлындагы бер коры елгага ат үләксәсе ташыдылар. Үләт зираты дип аталган ул урында апрель аеның күген козгын, карга басты. Авыл халкы шомга төште. Козгын тавышлары җилсез көнне авылга ишетелеп, җанны өшетә иде.

Трактор боларны оныттырды. Кәшфи көндезге сменада эшләгән көннәрдә кичләрен алар капка төбендә кечкенә генә җыен була иде. Габделбарый абзый андый кичләрне бәхетенә чыдый алмыйча тәрәзәсен ача, патефонын бора һәм пластинка куя: тәрәзәдән кичке урамга моң сибелә. Ә Кәшфи сөйли. Әллә ниләр сөйли.

— Узган ел Ташлытау басуында беләсезме нинди хәл булды? Бер тракторны, тракторисы-ние белән җир йотты...

Халык дерт итә, чулак Абдул йөткереп ала, тәмәке төрә башлый, ә Кәшфи сөйли бирә.

— Аның өчен чөнки... ул җир куышына туры килгән. Трактор авыр — ул бит әллә ничә тонна, ә теге урынга җир яралганнан бирле андый авырлыкны спытайть итәргә туры килмәгән. И һәм шунда баткан теге егет НАТИ белән. Аста күл икән. Җир асты күле. Казаннан килеп тикшерделәр учуныйлар. Аның өчен чөнки... тракторны МТС чутыннан списәйт итәргә кирәк. Аңа акте кирәк. Ә актега МТС бухалтеры кул куймый. Аның өчен чөнки... ул җавап бирә. Егет әти-әнисенә бер генә малай булган. Анысына бухалтер бәйләнми.

Агай-эне шым калып тыңлый.

— Ә узган ел зәб сукасында ничек булды? Симет елгасының ярын күргәнегез бармы? Төнге сменада эшләгәндә Мәтәскә Гаптери нинди сырамга калды. Руль тоткан килеш йоклаган бу. И һәм нәрсә булды

[1] Ызма — ыңгырчак ызмасы. Брезенттан ясалган 7—8 см киңлегендәге тасма.

дип уйлыйсыз? Аның өчен чөнки... кеше шул хәтле ияләнә трактор та вышына, инде ул двигатель тавышына рәхәтләнеп йоклый ала. И һәм Мәтәскә Гаптери йоклап китә. Каграз бер кыз янында куна калып, сменага чыгар алдыннан төне буе йокламаган була бу. Аның өчен чөнки... йокламасаң, трактор тавышы гел оета гына. Вәт шул Симет ярына килеп җиткәндә генә уянып китсә — текә ярга ярты метр. Гаптери сикерә җиргә. Трактор оча. Гаптери әле һаман аңына килә алмый, аның өчен чөнки... трактор юк и һәм Гаптери бер үзе. Ярдәмчесе килеп җитә вагоннан чыгып. Гаптеринең авыз ачык, ди, үзе берни дә әйтә алмый, ди.

Шактый торгач, теленә килгән бу. Көлә, ди. Куркудан. И һәм әйтә ди:

— Вәт текә,— ди икән. И һәм шуннан соң Гаптеринең үз исеме бетте. Аны хәзер бөтен МТСта Гаптери дип түгел, «Вәт текә» дип йөртәләр.

Кәшфи ул елны җәй буе шулай аудитория тотты. Авылда укымышлы бердәнбер егет аучы Җәгъфәрнең олы улы Гадел бар иде, ул җәйне Гадел авылга кайтып, берәүне дә шаккатыра алмады. Чөнки үзенең тракторы белән Кәшфи барлыкка килгән, дөньяда трактор һәм Кәшфи генә бар иде. Әллә нинди институтта укып йөргән, авыл урамыннан велосипедның рулен тотмыйча уза торган, әтисе белән печән чабарга урманга кергәндә чалбарының арт кесәсенә (авыл халкы: аһ! Чалбарының артында кесә бар!) блокнот белән авторучка (үзе яза икән!) кыстырып йөри торган, авылга кайтканда бер кулына чемодан, икенче кулына китап тотып, әкрен генә атлап, укый-укый урамга килеп керә торган, ә кайвакыт, әйберләрен салып кайтырга ат туры килгәндә, авылның йомшак хәтфә чирәмле тыкрыгына кул-аяк белән тәгәрмәч ясап, гәүдәне мәтәлдереп кайтып кереп, халыкны шаккатыра торган Гадел бер тиенгә дә тормаган пүчтәк нәрсәгә әйләнде дә калды. Авылда трактор һәм Кәшфи генә бар иде. Трактор эшли иде. Трактор — вакыйга иде. Трактор хәтта эшләмәгәндә дә вакыйга иде. Андый көннәр дә булды. Мәсәлән, бер көнне трактор ындыр артында гына сүнде дә туктады. Кәшфи сменасы иде. Сүнгән трактор янына халык җыелды. Кәшфи үзенең ярдәмчесе белән, майга батып, тегесен сүтеп карады, монысын сүтте. Колхоз председателе тыз-быз килде, нервланды, ашлык сугу вакыты иде, тракторны молотилкага көйләү өчен кырдан әвеслеккә күчерү моменты иде. Кәшфи дәшмәде, көне буе актарынды. Халык та таралмады. Үч иткәндәй, әбәдкә дә кайтмыйча көтеп утыручылар булды. Габделбарый агай кызыл ашъяулык белән төргән бер савыт аш та алып килеп карады, әмма Кәшфи эндәшмәде. Кызыл ашъяулыкны майлы кулы белән этеп кенә җибәрде. Председатель кибеткә барып, «Пушки» дигән иң кыйммәтле папирос алып килде. Кәшфигә тәкъдим итеп карады, әмма Кәшфи аны да майлы кулы белән читкә этәрде.

...Көтү кайтыр алдыннан гына НАТИ төчкереп җибәрде. Кәшфи йөгерендә: тракторның бер алдына, бер артына төште. НАТИ аның саен ышанычлырак гөрелди иде. Габделбарый агай йөгереп килеп җитте: кулында һаман теге ашъяулыкка төрелгән савыт белән аш иде. Кәшфи йөгереп йөрешли, елмаеп, әтисенең ашъяулыгын кире какты һәм председатель янына барып, «Пушки» пачкасыннан берне алды. Әтисе бәхетле иде: әтисе барында Кәшфинең дә мондый хәрәкәте әлегә беренче тапкыр иде...

НАТИ өстенә менеп атлангач, Кәшфи кечкенә генә нотык тотты.

— Менә 40 ат көчле шушы машина бүген көне буе тик торды. Ни өченме дисез? Аның өчен чөнки... машина ул бик нәзберек. Сез карамагыз, шту ул кара майлы тимердән тора дип. И һәм авыр, тупас дип. Ул — аның өчен чөнки... гел кеше организмы кебек. Менә аның карбюраторыннан ягулык килә торган каналы бар. Диаметры бер миллиметр

И һәм шунда бер арпа кылчыгы кергән. Ничәмә ничә тонна авырлыгындагы, кырык ат көчле шушы куәт иясен әнә шул бер кылчык көне буе эшләтмичә тотып торды. Аның өчен чөнки... кеше организмы да шулай: күзеңә арпа кылчыгы керсен әле. Эшчеме син? Синнән ул көнне тулык бармы?

Трактор гөрселдәп төнге сменага чыгып китте, Кәшфи ул кичне капка төбендә шәһәр алган полководец ролендә чыгыш ясады.

— Шул арпа кылчыгын тапмасаммы? Һи-и-и... Ничә ат көче ул, белдегезме? Тракторның холкы — нәкъ кеше холкы. Әнә Мәтәскә Гаптери. Быел ХТЗда эшли. Подшипникларын каты тарткан. Белем җитмәгәч. Кабыза алмый. Алдан әйләндергән вакытта руль кирегә сугып нишләтте? Сул кулын шартлатып сындырды. Главный инженер әйтә: подшипникларын шулкадәр каты тарттырган ди, әгәр кулына тимичә, башына суккан булса, малаеңа ясин укытасы булыр иде, ди. Аның өчен чөнки... тракторны яратып тотарга кирәк. Адәм баласы кебек итеп.

Хәер, авыл халкы болай да инде кара тимер корсаклы, бакыр бавырлы, пыяла йөрәкле бу машинага тере адәм баласы итеп карый иде.

## III

Кәшфи белән Ахиярга повестка нәкъ бер көнне килде. Ахияр чит якларда ФЗӨ тәмамлап, берничә ел кайдадыр шахталарда эшләп, ике айлык ял алып, туган йортына бер хәбәрсез кайтып төшкән иде. Ул вакытлыча хәрби учетка басып кайтканның икенче көнендә сугыш башланды. Йортта буй җиткән сеңлесе Айзәрә, олыгайган бәхетсез үги ана яшәп яталар иде.

Кәшфи расчет алырга МТСка китте. МТС ишегалдындагы гудок торбасы әллә каян күренеп тора. Бу торба иртәнге сигезгә, көндезге уникегә, бергә, кичке алтыга гудок бирә иде. МТС мастерскоенда эшләүчеләр моңа инде ияләнгәннәр, көйләнгәннәр иде. Әмма райкомның яңа секретаре моңа чик куйды: колхозчыларны бозасыз, колхозчы сәгатьләп эшли алмый, авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерү гудокка корыла алмый, диде. Бичара гудок! Ике-өч ай буе дәшмичә ятим булып утырды да, егерме икенче июнь көнне төш вакытында өзелеп-өзелеп ярты сәгатьләр чамасы елады. Аның тавышы Гәр Хуторга да ишетелде, һәм Гәр Хуторның унике йортлы халкы гудокка кушылып яшь түкте.

Йөрәккә якын МТС коридоры. Шыгырдавыклы яссы идәннәр. Бөтен җирдән автол, солидол, керосин исе килә.

МТС кассиры Кәшфигә шактый акча тоттырды. Кәшфи санамады. Әллә йөз илле сум ук инде? Аны, тракторист булганы өчен, бронь биреп, менә бер ел инде хәрби хезмәттән азат итеп торалар иде. Кәшфи бу халәттән риза иде, броньне юкка-барга, килде-киттегә генә бирмиләр. Димәк, ул — кирәкле кеше. Әгәр инде маршал Тимошенко үзе рөхсәт иткән икән, Гәр Хутор егете Кәшфи Габделбарыев әлегә үзенең корыч айгыры белән илгә икмәк җитештереп торсын, Ватан чикләрен без әлегә аннан башка да саклый алабыз, дигән икән, димәк, Кәшфи монда кирәк. Ә менә бүген аңа әйттеләр: син — тегендә кирәк. Тракторист — ноль бөтен йөздән җитмеш биш процент танкист инде ул.

Һәм ул кичне Кәшфи бер ычкынып алды. Бичараның үз гомерендә портвейннан башканы авызына да алганы юк иде. Кайтты, акчасын әти-әнисенә бирде дә күз алларында бер кара унлыкны кире алды.

— Монысы — гүләйткә,— диде. Кызу-кызу өеннән чыгып китте.

Әтисе дә, әнисе дә, күз яше агызып, юл хәстәрен күрәләр, ризык әзерлиләр иде.

Ахияр, ни йомыш беләндер, Ташлытауга киткән булып чыкты. Ике «Перцовка»ны чалбар кесәсенә тыккан килеш Кәшфи унбер йортны да йөреп чыкты. Утырып эчәрлек бер кеше тапмады. Кызу-кызу урам буйлап йөренгәләде дә, авыл уртасындагы кое бурасы өстенә утырып, бер яртының яртысын авызыннан гына эчеп куйды. Әтисе гомер буе әйтә килде югыйсә: шешә авызыннан эчкән кеше харап була, ул бик каты исерә, дип сөйли иде. Әмма Кәшфигә күңелле булып китте. Шунда утырган җиреннән генә үрелеп учлап үлән умырып алды да, шуны чәйни-чәйни, теге шешәнең калганын да хәл итте. Тагы да күңелле булып китте. Ә көтү кайтканда Кәшфи урамнан җырлап узды:

Эчмибез без аракыны,
Без эчәбез «перцовка»,
Без эчмибез урык-сурык,
Без эчәбез бер сутка.

Читтән карап торган кеше моны гомер буе шулай, Габделбарый агай сүзләре белән әйткәндә, «гүләйт сындырып» йөргән кеше дип белер иде. Капка төбенә җиткәндә Кәшфи әти-әнисен таң калдырып тагын бер җыр ярып салды:

Алыйк әле, басыйк әле
Америка туласын;
Алыйк әле сөйгән ярын,
Бер утырып еласын.

Чит авыл кешесе моны, һичшиксез, кызларның башын әйләндереп йөргән, тәҗрибәле бер мут егет дип белер иде. Әмма, Кәшфинең көчле градуслы эчемлекне үз гомерендә беренче эчүе булган кебек, әлегә кадәр бер генә кызның кулын тотып та караганы юк иде. Әлегә ул үзе дә «Америка туласы» иде.

Кичен ул урамны тагын бер әйләнде, теге «Перцовка»ның икенчесен ул, Ахияр белән эчәрмен дип, кесәсендә йөртә иде, Ахияр һаман кайтмады. «Перцовка» җылынып бетте. Кәшфи тагын кое бурасына утырды. Кычкырып җырлады.

Без үзебез Уфа-фаныкы,
Уф-фада тормасак та,
Үк-кенеч-чен калдырмадык,
Бик матур булмасак та.

Аннан кычкырып елады. Кайтышлый чулак Абдул белән сөйләшеп бәхәскә керде. Бернинди начар уе юк иде, болай гына чулак Абдулның күлмәк җиңеннән тотты.

— Аның өчен чөнки... Аның өчен чөнки,— дип кабаланганда, чулак Абдул аның кулына сугып та җибәрде.

— Минем күлмәк җиңенә ябышырга яшең баш әле,— диде Абдул, кыза төшеп.

— Ә? — диде беркатлы Кәшфи.— Ә?

— Кәҗә б... мә! — диде Абдул да.

Шунда Кәшфи, чайкалып китеп, чулак Абдулның күлмәк якасына барып ябышты. Монда да начар фикере юк иде. Тегесе исә таза кулы белән (ә чулак кешенең таза кулында ике кулның көче була) Кәшфигә салып ук җибәрде. Кәшфи, бичара, сөрлегеп китеп, чирәмгә барып та төште һәм, бәхетсезлегенә каршы, сыер тәлинкәсенә яңагы белән чумды. Шул ятудан торып маташмады. Кычкырып елап җибәрде:

— Подшипникны мин эретмәдем. Минем сменадан соң бит ул! Аның өчен чөнки... Миннән соң бит. Аның өчен чөнки...

Тавышка Кәшфинең әти-әнисе йөгереп килде. Чулак Абдул дер-дер килә иде. Габделбарый абзый малайның бүгенге хикмәтләре шулай булып бетәчәген белә иде. Абдулга әйбер-кара әйтмәде, әмма Кәшфинең әнисе Шәмсениса түти җикеренде:

— Ул — тракторист! Районга барып әйтсә, нишләрсең? Ул бит юк-бар кеше түгел! Кара эшче дип белдеңме әллә син аны? Ак эштә эшләгән хөкүмәт кешесенә ничек кулың бара? Сабый бит әле ул!

Кәшфи үкереп елый иде.

— Аның өчен чөнки... И һәм дә...

Көтүдән кайтышлый койма буйларында кычыткан умыргалап йөргән бер сыер Кәшфинең сөяп куйган «Перцовка»сын аударды. Кызылга буялган үләнне күзен алартып, ямьсез итеп «поф» килеп бер иснәде дә, аунап яткан Кәшфигә таба борылып:

— Өм-м-м! — дип мөгрәп куйды.

Сыер теләндә бу инде, бер дә шиксез:

— Юк, эчмим-м! Яратмыйм-м! — дигән сүз булгандыр.

...Шул көнгә нәкъ бер ел тулганда Горький шәһәрендәге госпитальдән Габделбарый абзый белән Шәмсениса түтигә бер хат килде: малайның балтыр сөягенә снаряд кыйпылчыгы эләккән, гипста ята икән. Кәшфи үзенең ничек яралануын, снаряд кыйпылчыгы бәреп еккач, организмының һәр өлкәсе ниләр кичергәнен, нәрсә уйлаганын, госпитальдә операция вакытында ниләр булганын озын итеп, бик зур төгәллек белән хат язган иде. Анда, мәсәлән, мондый җөмләләр бар иде: «Шуннан соң носилкадан төшерделәр и һәм дә сразы операция өстәленә салдылар. Аңарчы ике санитар кыз (берсе безнең яктан икән, егерме икенче елгы, Сәрия исемле, үз теләге белән сугышка килгән, әтисе колхозда агротехник икән) чалбарны телеп алдылар, миңа бик оят булды. Дөрес, бөтенесе кан иде, аның өчен чөнки снаряд сколкысының баш бармак бите хәтлесе эләккән, мена шулай ялангач көе өстәлгә салдылар. Аннан наркоз бирделәр и һәм дә мин аңны җуйдым. Аның өчен чөнки...»

Хат ахырында бер җыр да бар иде.

Уфа яна, Уфа яна,
Төтенгә күмелмиме?
Янам гыйшык утларында,
Төтене күренмиме?

Шәмсениса түти бу хатны өйләренә килгән бер кешегә укып елый һәм һәрвакыт бер төзәтмә кертә иде:

— И, бала, бала... «Янам хәсрәт утларында» димәкче булган инде ул. Дару белән башы миңгерәүләнеп беткән инде аның...

## IV

Ахияр сугышны элемтә отделениесенең командиры буларак тәмамлады. Сугыш кырларында ул күтәреп йөгергән катушкалар, кышкы салкын төннәрдә чыбыкның өзелгән урынын эзләп шуышулар... Сине ашыктыралар, элемтә ротасының командиры взвод командирын кыздыра, взводныкы — отделение командирын... Актык чутта аларның бөтен киеренкелеген бер-ике солдат, яисә бер сержант хәл итә. Ахияр әнә шуларның берсе булды. Киеренке, мең мәшәкатьле эшне күп вакыт ут астында, былчырак ярып, катканактан шуышып, мәетләр, яралылар арасыннан үрмәләп башкарасың. Ахияр берсендә катушка кигән көе баш күтәрә алмыйча ятты. Фрицның прицелына эләккән иде. Пуля гык-тык итеп Ахияр ышыкланган, саперлардан җирдә аунап калган бер

киштәгә тия иде, ул киштәнең юанлыгы башны да каплап бетерми иде. Ә задание — ашыгыч — әле генә алга күчеп оборона тоткан рота белән КП арасында элемтә урнаштырырга кирәк иде. Үткен күзле фрицны дөньяның иң әшәке сүзләре белән сүгеп Ахияр биш минут, ун минут ятты. Нибары егерме метр араны йөгереп узарга да иңкүлеккә тәгәрәргә кирәк иде. Ун минут элемтәсез тору ротаны һәлак итүе мөмкин иде. Һәм Ахияр түзә алмады, кинәт кенә сикереп торды да, бөтен гәүдәсен турайтып, эре-эре адымнар белән торып йөгерде. Үзенчә планы бар иде: пуля башка яки йөрәккә тимәсә, теләсә нинди яра белән дә ул катушканы сүтеп, чыбыкны илтеп җиткерәчәк. Пуля разрывной түгел иде, киштәгә эләккәннәреннән ул моны чамалады. Егерме метр араны ул бәлки дүрт-биш секундта узгандыр, әмма бу секундлар, бу ара аңа бөтен бер гомер булып тоелды. Язмыштан узмыш юк! Ике пуля бер-бер артлы чак-чок итеп аркадагы катушканың тимер тәлинкәсенә бәрде. Соңгысы бик каты бәрде һәм Ахияр, янга чайкалып китеп, мәтәлеп барып төште. Әмма ул инде үзәнгә мәтәлгән иде. Тагын дүрт-биш минуттан Ахияр инде, трубканың рычагын кысып, тынына буыла-буыла кычкырып ята иде:

— Сокол! Сокол! Я — Ястреб! Как слышите? Как слышите? Прием.

Теге яктан тыныч тавыш ишетелде:

— Я — Сокол. Слышу тебя хорошо. Старик все видел. Выражает свое удовольствие. Прием...

Элемтәче әнә шундый мизгелдә бөтен михнәтен онытып тора.

Ахияр сугышны Венада тәмамлады. Венаның сихри паркларында сугышның эзе дә юк иде. Үтелгән озын солдат юлын искә төшермәгәндә, монда үзеңне бөтенләй икенче үлчәүдә, икенче масштабта сизәсең, җир оҗмахы шушында кебек тоела. Кырык бишенче ел, Вена мае, Вена июне кебек шатлыклы матур көннәр бу тормышта башкача булмас кебек тоела иде. Үги ана бик нык картайган, бетеренгән. Айзәрә күрше район кешесенә кияүгә чыккан иде. Үги ана улы кайтканга шатланды, үзенең хәсрәтен сөйләп, эчен бушатты. Бер серен заманында Ахиярнең әтисенә — Гарәфи агайга сөйләми калган икән. Моннан бик күп еллар элек ул, кайнанасы белән килешә алмыйча, дөнья күчереп ызгышып, имчәк баласын ташлап киткән булган икән. Бала авыру, хәлсез һәм бик елак булган, яшь килен, бу бала барыбер яшәми инде, дип кайнанасына шуны калдырып үч алган. Шул китүдән эзләр югалган, ул яклар белән элемтә өзелгән. Әмма менә хәзер, сугыш бетәсе елны гына, Ташлытау базарына килгән кешеләр аркылы теге ерак яктан — Тау ягыннан бер хәбәр ишетелгән: Факия җиңгинең баласы исән ди һәм айның ундүртенче кичәседәй көләч йөзле, сылу бер кыз булып үсеп җиткән. Факия җиңги шул хәбәрне ишеткәч, төн йокысын югалткан, ун елга картайган һәм апрель аенда йортын, малтуарын күршеләргә ышандырып, яшьлек хатасы эшләнгән Тау ягы авылына чыгып киткән. Күз яшен түгеп, кешеләр алдында үзенең гаебен сөйли-сөйли кызын озак эзләгән. Кыз аннан күптән киткән һәм Паратск шәһәрендә тегү артелендә эшли, тулай торакта яши икән. Факия җиңги анда барып чыккан, көне буе артель, тулай тораклардан эзләп йөри торгач, ниһаять, кызы белән күрешкән. Аны кочаклап, озак елаган, йөрәге тоткан, дежур сестраны чакырганнар, дарулар биргәннәр. Әмма, күпме генә еламасын Факия җиңги, кыз аңа «әни» дип дәшмәгән һәм чәй эчергәч:

— Сез ничәдәге поезд белән китәсез? — дип сораган...

...Кәшфи моннан ярты ел элек үк кайткан, теге ярасыннан соң әле тагын бер яраланган — ни хикмәт — пуля шул ук аякның шул ук уры-

нынннан ит умырып узган икән. Моны сөйләгәндә икесе дә көлештеләр. Кәшфи бу хәлне үзенчә аңлатмакчы булып карады:

— Аның өчен чөнки... болай ул, старшина. Бер эләккән урынга пуля и һәм дә снаряд сколкысы...

Әмма юньләп аңлата алмады. Венадан ук кайткан солдат күчтәнәче башына киткән иде.

Кәшфи — һаман шул Кәшфи икән. Сугышка беренче тапкыр кергәндә боларның колоннасын фашист авиациясе бомбага тоткан. Кәшфи шунда җир һәм күкнең ут белән тоташканын күреп, ниндидер мизгелдә куркудан аңын югалтып алган һәм нәзер әйтеп ташлаган: бу сугыштан исән-сау кайтсам, сыерны суеп, бөтен авыл халкына аш уздыртыр идем, дигән.

Кайткач, бу нәзерен әти-әнисенә сөйләгән. Габделбарый абзый каршы торган: ничек инде карап торган сыерыңны тик торганда суясың? Сыер хәтле сыер бит ул! Әнә узган кыш чулак Абдулның бура хәтле сыеры зыянлады. Нинди авыр елда ач калдылар. Ә монда — тап-таза сыерны!

...Шәмсениса түти, диндар кеше, ул вакытта каты торды, бозавы кала, бер-ике елга түзәрбез, баланы нәзере тотарга мөмкин, диде. Кәшфи һаман да бала иде әле. Һәм сыерны корбан аена туры китереп суйдылар. Корбан чалганда Шәмсениса түтинең таләбе буенча Габделбарый агай абзар артында ярым кычкырып азан әйтте. Шәһәрдә йөкче булып эшләгәндә, яшьлегендә, аз-маз Күл буе мәчетенә йөргәләгән иде, шул вакытта ишеткәләгән азанны ватып-җимереп хәтерендә яңартты: кулларын колакларына күтәрде дә кыйблага карады:

— Сөбхан алла, сөбхан алла, әшһәде ән-лә иләһе илля-аллаһ! Вә әшһәде эн-лә Мөхәммәде рәсүлүлла-а-һ!

Чулак Абдул белән ике мужик нәкъ шул вакытта абзар артындагы саламга Акбашны гөрселдәтеп ектылар. Акбашның соңгы тавышы Габделбарый абзыйның соңгы авазы белән бер булып яңгырады:

— Ым-му-а-аһ!

Габделбарый абзый азанын тәмамлаганда елый иде.

— Хәййә галь-әс-сала-аһ! Хәййә галь әл-фәла-а-аһ!

Ул көнне бөтен Гәр Хутор Кәшфине мактап, ике чиләк сөт бирә торган Акбаш белән Габделбарый абзый һәм Шәмсениса түтине кызганып, туйганчы ит ашады.

Шәмсениса түти бөтен авыл хатыннарына ул кичне китап сөйләде. Кәшфи дә кәрә-чыга моны тыңлап йөрде. Бу тантаналы хәлләрнең барысы да Кәшфи исән кайту хөрмәтенә иде.

Кәшфи кич буе урамда капкадан-капкага йөрде.

— Сыер — трактор түгел ул. Әле теге елны Мәтәскә Гаптери тракторын да текә ярдан очыртты. И һәм шуның белән сырамга калды. Аның өчен чөнки сыер — була да, бетә дә ул. Ә трактор и һәм дә техника бик кыйммәт әйбер ул...

...Ахиярны военкоматка учетка керергә барган җиреннән үк туп-туры райкомның гомуми бүлегенә җибәрделәр. Бүлек мөдире — тәмәке тарта торган гимнастеркалы хатын-кыз, берничә вак-төяк сорау бирде дә, ярды да салды:

— Связист мени сез? Связист мени? ВКП(б) члены дамы? Белемегез ФЗӨ? Менә нәрсә, иптәш связист... Анкета тутырыгыз. Юк, юк, нинди ул Соликамск ягына җибәрү сезне. Анда үзләренең пермякләре җитәрлек. Шту сез... Хәзер мин сезне беренче янына алып керәм. Хәзер РИК председателенә генә чылтыратыйм әле. Шту сез — Соликамскига...

Һәм ул трубкага үрелде:

— Сеңелем, Фәхриев белән тоташтыр әле. Иптәш Фәхриев! Бер бүлмә кирәк. Ничек кирәк? Очень просто. 8—10 метрлы. Бар бит

синең — Нәдершиннан бушаган? Әйдә, мухлевать итмә әле, пожалуйста. Кадр — синеке. Әйе, туп-туры синеке. Килештек, хәзер үк кереп чыга алсаң, әйбәт булыр иде. Килештек...

Икенче көнне иртәнге сәгать җидедә Ахияр үз гомерендә беренче мәртәбә өстәл янына килеп йомшак урындыкка утырды һәм кабинет почмагындагы озынча биек көзгегә карады. Көзгедә куе кара чәчле, киң җилкәле таза бер начальник күренде. Ул начальникның күкрәгендә орден һәм өч медаль чыңгылдап тавыш биреп алдылар. Начальникның өстәлендә йомры агач трубкалы биек телефон аппараты бар иде. Нәкъ шул секундта ул аппарат җыйнак кына зеңгелдәп алды һәм Ахияр, каушап китеп, трубканы колагына терәде.

— Начальник районного узла связи Гарафиев слушает. Прием...

Фу, чорт! Нинди көлке хәлдә калды бит. Гомуми бүлек мөдире Таҗиева икән. Елмайганы сизелде:

— Как меня слышите? Прием,— дип шаяртты.

Ахияр шунда аңлады: Таҗиева — фронтовичка һәм, һичшиксез, элемтәче икән.

Шулай яңа тыныч тормыш башланды.

## V

Мең тугыз йөз илле бишенче елның 30 мартында партия райкомының киңәйтелгән бюро утырышы булды. Бюрога райондагы барлык подразделениеләрнең (Таҗиева шулай дип доклад ясады) җитәкчеләре чакырылган иде. Монда банк управляющие, сәламәтлек саклау мөдире, заготзерно, крахмал заводы директорлары, юл төзү бүлеге мөдире, райпо председателе, ашханә мөдире, прокурор, судья, медучилище директоры һәм башкалар бар иде.

— Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә: моннан биш көн элек булган Үзәк Комитет һәм Министрлар Советы карары нигезендә авыл хуҗалыгын кадрлар белән тәэмин итү, колхозларның материаль-техник базасын ныгыту мәсьәләләре,— диде беренче секретарь.— Рөхсәт итегез бу мәсьәлә буенча башта миңа сөйләргә. Мин бер сәгать вакыт алырмын,— диде. Һәм колхозлардагы терлек азыклары житештерү, иген уңышы алу, ит-сөт продуктлары житештерү турында диаграммалар, график сызымнар буенча сәгать буе доклад ясады. Йөз гектардан күпме уңыш алу, үзкыйммәт, рентабельлелек мәсьәләләрен утырышлар залындагы иптәшләрдән күбесенең беренче ишетүе иде. Фикер алышуларда Беренче секретарь җай белән сүзне колхозларны җитәкче кадрлар белән беркетү мәсьәләләренә борып җибәрде. Сөйләшү, сораулар, чыгышлар башланды.

— Карагыз инде ул «Яңа юл» колхозын,— диде банк управляющие.— Ул Гыйниятовадан нинди рентабельлек көтә алабыз? Колхозчы бит аннан пәридән курыккан кебек курка хәзер. Тәмам деспотка әйләнгән бит. Ул синңа иген уңышын күтәрү турында уйлап та карамый, аның бөтен максаты — аның алдында кеше калтырап торсын. Ә калтырап торган кеше производствода беркайчан да юньле нәтиҗә бирми. Син аның шомарганын шуннан гына бел: колхоз җыелышында постановлениене чип-чиста буш кәгазьне кулына тотып укый бит ул.

Управляющий шуны сөйләп, урынына утырмакчы гына иде, Беренче аңа реплика ташлады:

— Я, этәч булып кычкырдың, таңын да аттыр инде,— диде.

Управляющий бер секундка аптырабрак торды да, сүзнең мәгънәсен тиз төшенгәненә шатланып, елмайды:

— Ә, иптәш секретарь, мин анда быел җәй буе уполномоченный

булдым. Ул хуҗалык таркалган, беткән. Аны, минемчә, заготскотның ярдәмче хуҗалыгы итәсе, и шуның белән эш бетте.

Беренче мәгънәле, әмма усал елмайды.

— Ә нигә хуҗалыкны бетерергә? Минемчә, Гыйниятованы азат итеп, аның урынына сезне тәкъдим итәргә...

Банк управляющие башта агарынды, аннан битенә кызыл тимгелләр чыкты. Утыра алмыйча торды.

— Нинди тәкъдимнәр булыр,— диде Беренче, бюро члennарына карап.— Ә впрочем, тәкъдимнәр — соңыннан.

Әйе, банк управляющие «Яңа юл» колхозын хәтерли. Беренче тапкыр ул анда июнь аенда барып төшкән иде. Авыл халкы аны «полнаймуч» дип йөртте. Алар белән районда сөйләшкәндә мәсьәлә гел «партбилетны чыгарып салу» тирәсенә барып терәлә. Әйе, управляющийны бер тол хатынга квартирга урнаштырды председатель Сәкинә.

— Зөбәйдә,— диде,— бу иптәш — район вәкиле, әйбәт кара, тегесен-бусын җәлләмә... Мин продукты җибәрермен.

Зөбәйдә, бичара, амбардан, «полнаймуч» өчен алып кайткан юк-бар ризыкка үзеннән дә әллә ниләр өстәде. Һәм Сәкинәнең сүзен закон дип белеп (тегесен-бусын җәлләмә!) — аптырагач, урынны да бергә җәйде. Әмма ятар алдыннан гына управляющий кырт кисте:

— Мин,— диде,— Зөбәйдә, сине аңлыйм, но мин район вәкиле һәм мине тегенди-мондый юлга кертергә маташма.

Зөбәйдә, җиңел сулап, урынны күчерде.

Иртәгесен ул фермасына торып йөгерде, уполномоченныйга бәрәңге кыздырып, аш җылытып, чәй кайнатып калдырды. Сәгать сигезләрдә генә уполномоченный җәйге утарга килде: яхшы йоклаган, яхшы ашаган, ял иткән кешегә охшаган иде. Тегеләй итте, болай итте, савым белән кызыксынды, нидер язгалады.

— Бу сыерың күпме сөт бирә? — дип сорады уполномоченный, зур бер кара сыер янына блокнот белән килеп туктап.

— Бу — бер грамм да бирми.

— Ничек бер грамм да?

— Ә менә шулай. Ул — кысыр.

Уполномоченный өч тонналы йөк машинасы кадәр зурлыктагы үгезгә карап алды. Зөбәйдәгә сорау катыш карады. Зөбәйдә һаман әле, күтәрелеп карамаган көе генә, фляга юа иде.

— Ә бу? — диде уполномоченный.

Зөбәйдә, шалтыратып, фляга капкачын япты:

— Ул — район вәкиле, аңа ярамый,— диде.— Аны әле күптән түгел генә племсовхоздан җибәрделәр.

...Пленумда банк управляющие шуларны хәтерләп куйды.

Сүзне прокурор алды. 25—26 яшьләр, һәйбәт мундирдан, күкрәгендә ромбик.

— Партия райкомы бюросыннан мине райондагы иң артта калган колхозга җибәрүләрен сорыйм,— диде прокурор.

Егет шәһәрнеке иде, бераз шигаеп караучылар булды. Сәламәтлек саклау бүлеге мөдире — затлы күзлекле, ак йөзле интеллигент, илле яшьләр чамасындагы кеше:

— Әгәр партия райкомы шулай кирәк таба икән, мин, коммунист буларак, теләсә кайсы хуҗалыкка барырга әзермен. Авыл хуҗалыгын беләм дип әйтә алмыйм, әмма институт тәмамлап, монда килгәндә мин әле авыруларны да белеп бетерми идем,— диде.

Моның тәкъдимен хупладылар, әмма рәвешенә карaганда бу ак йөзле нечкә кешегә бер дә хуҗалык тапшырырлык сыман түгел иде. Мәсьәләне конкретлаштыра башларга вакыт җиткән иде.

Авыр шыгырдап, урыныннан Ахияр торды.

— Мин барысын да аңладым, иптәш секретарь,— диде ул.— Болай гына, әзерлексез генә чыгарып җибәрмәсләр бит?

— Өч атналык ашыгыч курслар ачыла,— диде Беренче.— Авыл хуҗалыгы институты базасында. Аннан бераз алдынгы колхозда ике ай стажировка узасыз.

— Алайса, «Яңа юл»га мине җибәрегез — туган ягым. Үз авылым Гәр Хутор да шуларга кушыласы икән, дип ишеттем.

Беренче конкрет тәкъдим конкрет рәвештә кабул ителде. Банк управляющие җиңел сулап куйды. Аннан прокурор егет, юл бүлеге мөдире, райфо мөдирен конкрет колхозларга тәкъдим иттеләр.

— Сезне бик почетлы исемегез белән котларга рөхсәт итегез,— диде Беренче.— Партия Үзәк Комитеты авыл хуҗалыгына 30 меңләп кадр җибәрү турында карар кабул итте. Сез — утызмеңчеләр. Рәхмәт сезгә, иптәшләр. Менә коммунистлык шунда күренә дә инде: яхшы атка бар кешенең дә утырасы килә, яман аттан читтәрәк йөрисең. Коммунистлык иң беренче чиратта — иң авыр эшне үз өстеңә алып башкаларга җиңеллек тудыру дигән сүз. Рәхмәт, сезгә, иптәшләр...

Илле бишенче елның көзендә Ахияр стажировканы тәмамлап кайтты. Озак көттермичә райком инструкторы аны «Яңа юл»га алып китте. Арган, йончыган, сугыш имгәтүләреннән әле дә төзәлә алмыйча чак-чак бара торган эреле-ваклы дүрт авыллы ике колхозны берләштереп, исемен «Яңа юл» калдырдылар. Һәм үзеген Колан Кырга күчерделәр. Берләшү җыелышына Гәр Хуторлар да килгән иде. Колхозчылар бу берләшүгә каршы килмәделәр. Колхозның бу көе бара алмаячагын, нәрсә дә булса эшләргә тиешлеген барысы да аңлыйлар иде. Дөрес, Гәр Хуторлар бераз шигәеп калдылар: алар, сугыш вакытында да зур ачлык күрмәгәннәр, хәзер дә хуҗалыклары таза гына. Кәшфи ел саен МТСтан үз колхозларына билгеләнә һәм бөтен басуны бер трактор белән хәл итеп бара икән. Кәшфинең фидакарь хезмәте турында соңгы елда район, республика газеталарында берничә тапкыр язып чыктылар. Ахияр моны күзәтеп бара иде. Җыелыш беткәч, Кәшфи аның белән килеп күреште.

— Өйләндеңме әле, юкмы? Ничә ел күрешмәгәнгә?! — дип сүз башлады ул.— Председатель кешегә өйләнми йөрү килешми. Хатын-кыз белән и һәм дә кызлар белән эш итүе кыен булыр.

Кәшфинең хатыны бик уңган булып чыккан: бер малай, әллә никадәр кыз үстерәләр икән.

— Ничек алай? — дип гаҗәпсенде Ахияр.— Елына бердән дә артык туры килә түгелме соң?

Кәшфи житди рәвештә аңлатып китте:

— Аның өчен, шулай ул, туган: сугыш вакытында илебез и һәм дә җир шары күпме кеше югалтты. Табигать шуны чөнки тигезли.

— Табигать тигезләр инде, ә менә сез ничек өлгерәсез?

— Аның өчен болай, туган: ике тапкыр игезәк бала тапты хатын. И һәм дә кеше рәтеннән өч бала — менә сиңа җиде... Әйдә тусыннар, ашарга икмәк күп. Узган ел бөтен МТСта иң күп икмәк алган кеше мин булдым. Аның өчен йомшак парга күчереп исәпләнгәндә, минем күрсәткеч... Аннан шунысы да бар, картлар әйтә бит әле: ходай иман бирсен дә кибән бирсен, дип. Һәр бала дөньяга үз ризыгы белән туа. Әле менә соңгы кызым — Рәхимә туган көнне генә алыйк. Шул көнне МТСта идем үзем. И һәм кулга премия тоттыралар. Дүрт йөз сум. Кайтсам — кыз туган. Үз бәхете белән. Әле хатын тагын берне алып кайтам, ди.

Балалар бик таза «и һәм дә» бик акыллы булып үсеп киләләр икән.

Ахияр аңа кызыгып карап куйды: үзе гаилә бәхетенә ирешә алмаган кеше бәхетле ата-анага һәрвакыт кызыгып карый.

Ахияр да өйләнгән иде. Элемтә бүлегендә инженер булып эшләүче шәһәр кызы — Сольмага өйләнгән иде. Әйбәт кенә яшиләр һәм бер малай да үстерәләр иде. Әмма райком бюросыннан кайткан көнне гаиләдә бик ямьсез сөйләшү булды.

— Син теләсәң нишлә, мин авылга баручы түгел, нигә мин малаемны бәхетсез итәргә тиеш? — дип Сольма каршы чыкты.

— Суң бит мин дә авылда туып үстем?!

— Син дә, сугыш булмаса, шунда изелеп калган булыр идең инде. Бу сугыш бик күп кешене күтәрде...

Мондый дәрәҗәдәге бәхәсне дәвам итеп торудан файда юк иде. Ахияр курсларга начар кәеф белән китте.

Курсларны тәмамлап кайткач, беренче кичне үк аш янында Ахияр, улы Рамилнең йомшак муеныннан кочаклап, сорады:

— Улым, авылга күчәбезме? — диде.

Малай әтисенең тез арасыннан чыгып китәргә бер талпынды, чыгасы итмәде, әнисенә күтәрелеп карады. Аннан, әнисенең карашы белән очрашкач, акрын гына, башын түбән иеп кенә әйтте:

— Дәү әти белән дәү әниләлгә балам: Шәһәл мәктәбенә укылга келәм,— диде.

Аннан аяк арасыннан шуып чыгып китте, аш янына утырмады.

Ахияр ашның тәмен тапмады: әллә кайнавы җитмәгән, әллә тозы чыкмаган иде.

Хатын-кызны белмәссең... Гадәттә, ирләрдән акыллырак, перспективаны ирләргә караганда тизрәк билгеләүчән булалар хатыннар. Әмма, хатын-кыз кайвакытта шул дәрәҗәдә кирегә эшләп куя — гаҗәпкә каласың. Бер караганда ул ирен уздырып, үзенең өстендәге актык пальтосын салып, каенсеңлесенә бүләк итә ала; икенче караганда шул каенсеңлесенә өч тиенлек трамвай талонын биргәнен күреп иренә бәйләнә һәм ямьсез тавыш чыгара. Ник алай? Сәбәп нәрсәдә? Моны башка кеше түгел, хатын-кыз үзе дә белми.

Әйе, ашның тозы, чыннан да, чыгып җитмәгән икән...

## VI

Кәшфи олы малае белән байтак борчу күрде. Өметләр зур иде, нәселне дәвам итәргә тиешле бердәнбер ир бала шул. Малай я укымады, я армиягә барып, кеше балалары сыман солдат була алмады, я юньле һөнәр өйрәнмәде. Кәшфинең нәселне лаеклы дәвам итәр дигән өмете аңарда иде. Тавис тракторга кызыкмады. Сөйләшү ягына исә гел эредән булды. Ора алмаган олы кусәк күтәрер дигәндәй, Тавис, әтисенең дәрәҗәсенә аркаланып, гел зур эшләр турында сөйләште: менә быел йорт салам («салабыз» түгел), мунча бурыйм, сыерны алыштырам, фәлән-төгән дип кенә сипте. Чынлыкта исә боларны Кәшфи эшли иде.

Малай ат җигеп, төрле эштә йөрде. Күбрәк фермага фураж ташыды. Гәр Хутор бригадасында сарыклар һәм таналар тотыла иде.

Бер кыз белән дә йөрмәде, шулай да бер көнне җилләнеп кайткан җиреннән кинәт кенә өйләнү турында сүз кузгатты. Әти-әнисе аптырап калдылар. Нинди өйләнү? Яшь-яшь көе? Дөнья күрмәгән көе? Әле бит идән тулы бала-чага. Өйнең кайсы почмагына таба атлыйм дисәң дә, үрмәләп йөргән балага сөртенәсең. Әле икесе идәндә оек башы белән гел юеш эз сызып йөриләр...

Әмма Тавис кызган иде. Сүз китте, Тавис каядыр ашыгыч кына барып килде, чулак Абдулларга кереп чыкты ахырысы — бераз өстәп алган иде. Сүз тагы да ямьсезләнде, малай кычкыра ук башлады. Олы кыз Рәсимә дә өйдә иде, абыйсы ятсыз сүзләр сибә башлагач, торып, өйдән үк чыгып китте. Малай тәмам туарылды.

— Сез...,— диде ул исерек күзләре белән әле әтисе, әле әнисенә таба карап,— сез... Үзегез гомер буе... бала үрчетеп (ул ямьсез сүз әйтте), рәхәтләнеп яшисез, ә миңа калгач, рөхсәт юкмы? Демократия шул буламы? Шулмы? Икегез дә путчист сез, белдегезме шуны? Реваншистлар!

Малай дулап чыгып китте, ата-ана телсез калды. Бу нигездә мондый ямьсез тавышның беренче чыгуы иде. Әтөн уртасында Кәшфи белән Асия капка тавышына сискәнеп сикереп тордылар: Тавис шаулый иде. Габделбарый абзый белән Шәмсениса түти почмак якта шыпырт яттылар.

— Сез! — дип кычкырды ул ишегалдыннан ук.— Сез! Менә мин сезне кадаклап куйыйм әле! Сезне кадаклап биклим дә, үзем кыз алып кайтам! Бүген кич үк!

Һәм ул ишеккә килеп, йорт ишеген шап итеп ачты да, куркынып калган ата-анасын күргәч, гөрселдәтеп ишекне япты. Һәм зың-зың итеп ишеккә кадак кага башлады. Чүкеч белән тышкы яктан суккан саен сары чыршы ишек тә, таза ишек яңагы да, озын кадак та сыкрый һәм «зың-зың» итеп елый сыман иде.

Почмак якта Шәмсениса түти берөзлексез догасын укыды.

Тавис исә, ишекне кадаклап бетерүгә, юкка чыкты.

Төн узганчы Тавис шулай әллә ничә гаиләне, әллә ничә кешене дер селкетеп алды.

Кичке тугызда ул инде үзләреннән унбиш чакрым ераклыктагы Өчиле авылында иде. Анда чулак Абдулның туганнан туган кызы — юаш, эшчән укытучы кыз Люция бар. Абдул әйтүе буенча, Тавис моннан бер атна чамасы элек, узышлый гына кергән булып, аларда ат ашатып чыккан һәм кызны шунда күреп ошаткан иде. Кайтты, Абдулга сөйләде. Кәшфиләр бу турыда берни белмиләр иде әле. Чулак Абдул әйтте:

— Кич мәктәптән кайтканын гына саклап тор син аның, атың таза бит, бер чөңгерсәң, кайтып җитәсең, — диде.

Тавис шулай эшләде дә.

Кич иде, мул карлы кышкы җылымса бер кич иде. Капка тирәләре көрәлгән, стена итеп өелгән карга тәрәзәләрдән мул яктылык төшә, тыкрыклар, йорт артлары дөм караңгылыкка чумган. Люция китапдәфтәрләрен кочаклап, шыгыр-шыгыр атлап, өенә кайтып бара. Кайтып җитәргә ике генә өй кала, караңгы тыкрыкта нәрсәдер шыгырдап алды. Атмы, чаналы атмы? Шул арада тыкрыктан:

— Люция! — дигән ипле, әдәпле тавыш ишетелде. Бернидән дә шикләнмичә, кыз шунда кереп китте. Китте... Һәм люцерна түшәлгән чанага ничек барып төшкәнен, таныш булмаган егетнең атка ничек чөңгергәнен сизми дә калды. Урам баганасындагы фонарь көлтәсен үзенә йоткан күк йөзе кинәт кенә артка таба шуа башлады. Кычкырырга тыны буылды, әлегә бер ни дә эшли алмады. Тик колак кына ишетә иде: чана шыгырдый һәм дугага чек-чек итеп, бөжра бәрелә, димәк, ат юыртып бара. Китап-дәфтәрләр чәчелеп калды. Алтынчы класста бүген генә яздырган диктант. Чирек йомгагына бу диктантта алган билгеләр нигез буласы иде. Ә дуга бөҗрасы һаман чек-чек бәрә, тоңкъ-тоңкъ итеп ат эче селкенә, димәк, һаман юырта. Бераздан кыз тын алды, тирән итеп бер сулады да кычкырды:

— Туктат атыңны! Туктат! Син нинди җулик! Туктат, диләр сиңа!

Әмма егет туктатырга җыенмый иде. Ул арада ат үзе акрынайды, як-якта кара стена барлыкка килде. Урман юлына кергәннәр икән.

— Тук-та-а-а-т!

Кыз кычкырып елый башлады. Урман кайтаваз белән җавап бирде.

— А-а-а-т!

Егет атны туктатты. Кызның өстеннән кулын алды. Инде торырга, йөгерергә мөмкин иде. Өчиле урманы авылдан нәкъ ике чакрымда. Ләкин аякларының хәле юк иде. Ул арада егет телгә килде:

— Мин — Тавис. Гәр Хутордан. Абдул абзыйны беләсеңме? Мин — күршеләре. Бер көнне сездә булдым ич мин! Инде таныдыңмы? Таныдың ич инде!

— Җулик син, белдеңме шуны! Надан тәре! Адәм актыгы син! Мин — югары белемле укытучыга, комсомолкага, син наданның ничек кыюлыгы җитте? Бор атыңны хәзер! Бор, дим, бо-о-о-о-р!

Кайтаваз яңгырады:

— О-о-о-р!

Егетнең надан булып күренәсе килми иде. Тәмәкесен кабызды да сөйләп китте:

— Ни бит, Люция, халык бар бит. Хәзер инде сине кайтарып куйсаң да, үзең кайтсаң да — даның чыкты. Кияүгә барып кайткан, дигән данны күтәрәсең киләмени синең? Аннан соң атны ул якка боручы да түгел инде без. Без атны бер генә якка таба куабыз. Барыбер даның чыкты инде синең... Халык әйтә: капка керсә, катын була, ди.

Төн караңгы, урман эче куркыныч, егет таза куллы, Люция ябык кына, кош сөякле генә җыйнак бер кыз иде. Нишләргә? Нишләргә? Кыз ялына башлады:

— Тавис! Зинһар дим, зинһар! — Нәрсә сорый иде ул егеттән, моны үзе дә белмәде.— Зинһа-а-а-р!— Кыз котырынып елый иде. Урман җавап бирде:

— А-а-а-р...

Тагын бөҗра тавышы, тагын тоңкылдап ат эче селкенүе, тагын эчпошыргыч итеп чана шыгырдавы.

...Ике кайнана янына шулай итеп килен төште. Алар кайтканда ишекнең кадагы алынган иде. Өлкәннәр моңа шатланмадылар. Ут яктысында күрделәр: бу — тирә-юньгә матурлыгы белән дан тоткан Люция, Чулак Абдулларга нәсел тиешле кыз иде. Болар, әлбәттә, пар килмәгәннәр, монда нәрсә дә булса булган, бу — ризалык белән эшләнмәгән, шуңа күрә әнә кызның күзләре шешенеп беткән иде. Кыз берни әйтмәде, чәйгә утырмады, аны йокларга каен сеңелләре янына салдылар. Йортта ул көнне каенсеңелләрдән башка берәү дә йокламады. Люция, бичара, төне буе үксеп яшь түкте...

Кемдер урта бүлмәгә утырып, заочно гына никах укыды. Ахырысы, Шәмсениса түти кемгәдер кунакка килгән очраклы бер хатынны өстерәп алып кайткан иде. Теге хатын гарәпчә-татарчаны бергә кушып урды гына. Моңа, әлбәттә, беренче чиратта Шәмсениса түтинең эче пошты. Халтураны тумыштан яратмый иде. Ә «узгынчы абыстай» ура бирде. Әти-әнисеннән намаз, дога рәтен ишетеп үскән Кәшфи дә сизде: бу — чи калдырып сөрүче иде.

— Әлхәмдел-иллаһи колһуаллаһы самадәл-ләм ялиде я әрхәмәр рахимин. Әшһәде ән-лә илаһе илла аллаһе вә лә куәте вә лә фис-самати вә ләм юләде аллаһыммә саллигалә тигез матур торсыннар, инна лиләйһи я аллаһы...

Моның буш сүзләр икәнен Кәшфи белә иде, ләкин, нихәл итәсең, теге хатын һаман тезә бирде.

Габделбарый абзый исә өенә бер керде — биш чыкты. Гомере буе эшне ип белән, җай, план белән алып барырга яраткан карт бераз гына югалып калган иде. Керә-чыга йөргәндә ул ике-өч тапкыр кабатлап:

— Хәерле булсын Хәмидәнең никахы,— диде.

Аның эче поша, йөрәге сикерә иде.

Никах гөненнән соң Тавис урам буйлап киләп сарып йөрде. Ике-өч тапкыр өенә кереп, почмак якта шалтыр-шолтыр килеп, шешә эзләде, тапты, эчте — тагын урамга чыкты. Урам кечкенә, кар баскан, анда

кеше юк иде. Бердәнбер күзгә күренгән нәрсә — урам уртасындагы кое. Тавис шуның янына килде, дөбер-шатыр китереп су алды, ул суны урамга түкте, тагын алды. Нәрсәдер эшлисе килә, әмма тамашачы юк. Аннан ул яшел тавыш белән җырлап җибәрде. Аңа карап, урамга барыбер берәү дә чыкмады...

Матур, акыллы, эшчән кыз баланың кайчан гаилә бәхете тапканы бар соң? Люция шулай торып калды. Колан Кырдагы сигезьеллык мәктәптә тегеннән җыештырып, моннан җыештырып, аңа сәгатьләр таптылар. Шунда квартира алып, ял көнгә Гәр Хуторга кайтып йөрде. Күпмедер вакыттан соң, яратмаган иреннән бала табарга җыена башлады. Кәшфи ашыгыч рәвештә йорт өлгертте. Агач мәсьәләсендә тоткарлык булмады, районның иң алдынгы механизаторы буларак, аңа райпланнан сораганча агач бирделәр, трактор белән ул агачларны үзе тарттырды. Агач белән генә өй салып булмый: шифер, калай, пакля, буяу, пыяла, тимер-томыр, кадак, тагын әллә ниләр кирәк булды. Боларның барысын райпода председатель булып эшләүче, Шәмсениса түти ягыннан туган тиешле Нәбиев хәл итте: Тавис ике көннең берендә ат җигеп районда, склад тирәсендә йөрде. Нәбиев, ни сорасаң, шуны юнәтеште, бер дә аралашмыйча яшәгән туганнар булсалар да, искиткеч зур игътибар күрсәтте.

— Ну, абый җаным,— диде Тавис,— өйне салып бетерсәм, иң түрендә иң кадерле кунак син булачаксың. Иң түрендә, иң кадерлесе...

Килен төшкәнгә сигез ай дигәндә авыл читендә верандалы, урыс капкалы мәһабәт йорт өлгерде. Тавис, авызына тәмәке кыстырган хәлдә, йорт тирәсендә йөгереп йөрде, кибеткә барып кайткалады, моржачыга балчык изде, өй тирәсеннән йомычка җыйды.

— Минем бу йортка кергән расхут инде,— диде ул, эш бетереп, мичкә ягып, осталарны һәм моржачыны сыйлаган көнне кулына стакан тотып.— Моңа кергән расхут инде.— Әтисенә карап алып:— Дөрес, сүзнең дөресе кирәк, эти дә ярдәм итте...

Кәшфи дәшмәде. Бу йортка Кәшфинең саклык кенәгәсендәге нәкъ дүрт мең акчасы кереп китте. Әле бүген «осталарны сыйлыйсы бар» дип тә малай йөз тәңкәне буып алып киткән иде, югыйсә.

— Моңа кергән расхут инде...

Йорт, шулай итеп, «безнеке» түгел, «минеке»нә әйләнде.

Егет кеше читкә китеп эшләп кайтсын, ил-җир күрсен, армиядә булсын икән! Чит җирләрдә тулай торакларда яшәсен, коллективта бераз эшкәртелсен, шомарсын икән!

Тавис, йортка чыккач, бөтенләй үзгәрде. «Мин» көчәйде, шул аңа тынычлык бирмәде. Сигез классы белән югары белемле хатынына акыл өйрәтә башлады.

— Сезнең ул институтыгызда нәрсә бирәләр соң? Менә мин унга алты метрлы йорт салып чыктым. Синең институт акчасы белән аны салып буламы?!

Бәйрәм, ял көннәрендә кичен Тавис авылның китапханәсе дә, клубы да булган йортына килеп, уртага басып, концерт бирә иде. Концерты — төрле халык сүзләрен кыстырып сүгенү, үзеннән яшьрәкләргә бәйләнү. Кәшфи, бичара, үз гомерендә беркемгә бернинди авыр сүз әйтмәде. Әтисе Габделбарый абзый да шулай булды. Чөнки алар — дөнья күргән, коллектив күргән кешеләр. Тавис моны яхшы аңлый. Әмма, ир кеше буласы килә. Һәм ул ир кеше булыр өчен әлеге клубка юнәлә.

— На..., майть! Фәлән иттем мин! Унга алты нарат бүрәнәле өйне кайсыгыз салганы бар!

Һәр ял көнне кичен шулай. Грамматиканы әйбәт белгән яшьләр көләләр: Тавис сүзләрне килеш, заман, родларда дөрес кулланмый, грамоталы кеше алдында сүгенгән саен хур була бара иде.

Малай борчуыннан Кәшфинең тешләре какшады. Хәзер ул еш кына Ташлытауга теш врачына йөри иде. Малай хатыныннан көнләште. Ил-җир күрмәгән ир, гадәттә, хатынын каһәрле торган була. Дөнья, кешеләр күрмәгән ир, гадәттә, хатынына кул күтәрә, үзенең ирлеген шулай раслый. Тавис та шул юлга басмакчы булды. Кыз тугач, бер кыланып алды:

— Бер малай да тапмагач, син миңа нәрсәгә?— дигән булып бер көнне тавыш чыгарып карады. Әнисе кечкә сауган сөтне китергән иде. Әнисе барында Тавис (бераз салып кайткан иде) бик каты кызды:

— Мин хатыннан куркып торучылардан түгел,— диде ул, әнисе каршында тәмәке кабызып.— Мин нәрсә? Унга алты нарат бүрәнәле өй салып монда! Институт нәрсә бирә ул бүгенге катлаулы халыкара обстановкада?

Тавис ишек алды белән веранда арасында ду килеп йөри, керҙ-чыга, әнисе шигәеп, аның җиңенә ябыша:

— Улым, дим, улым! Чү, салгансың икән, ят та йокла, ник алай адәм мәсхәрәсе ясыйсың? Балагыз бар, менә дигән йортыгыз бар!

Тавис аның саен кызды:

— Миңа нәрсә! Чыктым-киттем, пока беләкләрем таза. Йортны кубарам да сатам. Моңа бүген үк, сигез меңне күз дә йоммыйча бирәләр. Чыктым-киттем, шахтага бардым да урнаштым. Институт дигәч тә...

Тавис кызу-кызу гына верандага кереп китә, анда Люция бала карый, үзе ашка токмач кисә. Тавис артыннан әнисе торып йөгерә, бервакыт веранда шыгыр-шогыр килә, верандадан тавыш ишетелә:

— Тавис, дим, Тавис! Улым! Адәм хуры итмә! Тукта дим! Һай, нинди каргышлар гына төште икән безнең нәселгә! Тукта, дим, тукта!

Люция алсу борынлы, йомшак чәчле гүзәлкәен карап, токмач кисә: алсу борын коляска өстенә элгән яшел, сары пластмасса шарларны берөзлексез шудыра, елмая. Әтисен күрми. Ул шуның белән бәхетле... Алсу борынның исеме дә Алсу, кызчык әле берни дә белми, ул туып, дүрт ай торгач, дәү дәү әти белән дәү дәү әнисенең бер атна эчендә бер-бер артлы дөнья куйганнарын да, әтисенең нинди кеше икәнен дә, соңгы бер елда дәү әнисенең чәчләре агарып, муены җыерчыкланганын да, дәү әтисенең берөзлексез теш суыртканын да ул әле белми. Ул әнә шуларны белмәгәнгә күрә елмая һәм яшел, сары пластмасса шарларны берөзлексез шудыра. Үзе көлә: «ыггы, ыггы», ди...

Шудыр, Алсу, шудыр, синең акыллы, бәхетсез әниең барыбер бу йортта калмаячак инде...

## VII

Октябрь урталарында Кәшфине Мәскәүгә механизаторларның бөтенсоюз киңәшмәсенә җибәрделәр. Киңәшмә бик зур һәм абруйлы иде. Кәшфи анда барганчы ике алгы тешен куйдырмакчы булган иде — өлгермәде.

...Башкаладагы җыелыш бик зурдан иде. Килгән кешеләргә искиткеч зур игътибар күрсәттеләр. Кәшфи монда кара куллы тракторчылар гына булыр дип уйлаган иде. Җыелыш барышында, болар алдына чыгып, космонавт та, композитор да, бер академик та сөйләде. Барысы да игенче хезмәтенең изгелеге, Кәшфи һөнәренең мактаулы икәнлеге турында сөйләделәр. Җыелышның беренче көнендә алар хөрмәтенә зур концерт бирелде.

Башкаланы карап, гостиницага җәяү кайттылар. Чалт аяз салкын күктә чекрәеп йолдызлар яна, салкын кырыс җил зур йортлар арасында исәргә үзенә җай тапмыйча, өстән, баш өстеннән бәрә сыман иде. Башкала чиста, урамнар аяк тавышына зыңгылдап тора.

Гостиницага кайтып, соңгы хәбәрләрне тыңлаганда Кәшфи сискәнеп китте. Һава хәлен тапшыручы диктор «Волга — Вятка краенда кинәт суытты, салкынлык төнлә 20 градуска җитәчәк, мондый түбән температура фәлән елдан бирле күзәтелгәне юк иде», дип әллә ниләр әйтеп бетерде. Кәшфинең йөрәге туктады: капка төбенә алып кайтып туктаткан тракторының радиаторыннан суны агызмаган иде ул. Әйе, ул аны карарга өлгерә алмады.

Кәшфинең йокысы качты. Техника харап булды болай булгач, ә син монда алдынгылар исәбеннән утырган бул...

Икенче көнне аларны группаларга бүлеп, халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә алып киттеләр. Кәшфи группасына авыл хуҗалыгы министры урынбасары җитәкчелек итә иде. Группа белән радио, телевидение һәм газета корреспондентлары да йөрде. Арадан берсе Кәшфидән интервью алмакчы иде — Кәшфи үтенечен әйтте дә салды: тракторым харап була, бездә суыткан, диде. Бу сүзне министр ярдәмчесе дә ишетте. Һәм әһәмият бирде.

— Авылыгызда телефон бармы? — диде.

— Авылда юк, потомушто телефон линиясе, төп линия авыл кырыеннан уза,— диде Кәшфи.— Ә колхоз идарәсендә бар. Бездә юк.

— Еракмы?

— Ерак түгел, потомушто төп линия бер өч йөз метрлар булыр,— диде.

Корреспондентлар рәхәтләнеп елмаеп тыңладылар, Кәшфи сабый баладай дулкынлана, ашыга, каушый иде.

— Потомушто, болай ул. Телефон булса, аны хатынга гына әйтәм мин. Минем хатын тракторның рәтен белә. Үз баласыдай карый ул аны. Потомушто, трактор кеше кебек нәзберек ул...

...Кинәт кенә, нәкъ иртәнге 8 дә чылтыраган телефонга Таҗиева сискәнеп куйды. Әле кереп утырган иде генә югыйсә. Беренче телефон ничек булса, көне буе шулай була. Моны телефонлы кабинетта утырган кешеләр генә белә.

— Әйе, тыңлыйм, исәнмесез.

— Мәскәүдән, элемтә министры. Исәнмесез.

— Ә? Кем дисез? Шаярмыйча гына...

— Мәскәүдән. Элемтә министры.

Таҗиева тын ала алмыйча торды. Дөп-дөп йөрәге тибә, трубкада ерак дулкыннар ысылдый иде.

— Сез элемтә бүлеге начальнигымы?

— Әйе, мин элемтә бүлеге начальнигы, Таҗиева. Тыңлыйм сезне.

— Сез армия узган кеше түгелме?

— Әйе, мин элемтә гаскәрләре кече сержанты. Фронтны уздым.

— Иптәш кече сержант! Приказны тыңлагыз. Генерал сөйли. Сезнең районда Гәр Хутор дигән населенный пункт бар. Шул пункттан 375 метр төньяктарак магистраль линия уза. Шул пунктта яшәүче ике орденлы механизатор Габделбарыевның өенә точка куясыз. Срок — 12 сәгать. Кичен үзем тикшерәм. Сораулар бармы?

— Аңлашылды.

— Хушыгыз.

Таҗиева — «Яңа юл» идарәсенә — Ахиярга:

— Саумысез, иптәш Гарәфиев. Әйе, мин Таҗиева. Нәрсә сез анда, понимаете ли, кеше азындырасыз? Беләсезме, сезнең передовигыгыз нәрсә таләп итә анда?

Һәм ул хәлне сөйләп бирде. Ахияр игътибар белән тыңлады. Тыңлап бетергәч, әйтте:

— Ялгышасыз, иптәш Таҗиева, Габделбариев үзе өчен бер энә дә сорый торган кеше түгел. Монда бер-бер хикмәт бардыр. Әмма без бит хәзер приказ үтәргә тиештер?

Районнан килеп төшкән элемтәчеләр бригадасы багана урыннарын күрсәтеп чыкты. Һәм магистраль линия белән Гәр Хутор арасында алты-җиде җирдә ут яктылар. Җир туңын шулай гына җебетеп була иде. Тракторлар бүрәнә тарттырды, берәүләр аны чистартып каезлады, автокран яңа баганаларны казылып яткан чокыр урыннарына җайлады, өч егет тимерчыбыкларны сүтеп, кыр буйлап суздылар.

Кыр тулы ирләр иде, кызык өчен килүчеләр дә булды. Аучы Җәгъфәр хатынына бер казан ит пешерергә кушылды, кладовщик машина белән алар йортыннан әллә ничә әйләнде.

Көзнең кыска көнен караңгы алганда Кәшфи өенең түрендә — тегү машинасы куелган зур өстәлдә — кара телефон аппараты тора, һәм бу аппарат әллә кая тоташкан булуы белән үзенә ниндидер серлелек, курыныч серлелек җыйган иде.

Таҗиева ашыгыч рәвештә район үзәгенә китеп барды. Ахияр исә Кәшфи өендә утырып калды. Телефонисткалар белән әллә ничә тапкыр сөйләшеп тикшерелгән булса да, Таҗиева, кайтып кергәч, Кәшфи өенә чылтыратты. Трубкада Ахияр иде. Шаярышып сөйләшеп алдылар:

— Ало, как меня слышите? Прием.

— Слышу вас. Хорошо. Я — Сокол. Прием.

— Ну, ярый, иптәш Гарәфиев, рәхмәт сезгә. Выручать иттегез.

— Нигә рәхмәт? Кәшфи — безнеке.

— Ярый, хушыгыз. Мин бер-ике сәгать утырам әле.

Таҗиева контрольдә калды. Озак көтте. Телефонистка кызларга да аеруча игътибарлы булырга кушылды. Һәм менә кичке унда Казаннан звонок: Мәскәү!

Таҗиева параллель тоташты һәм тагын йөрәк тибешен ишетә башлады. Мәскәүдән гаҗәеп якын, үз тавыш белән бер кыз дәште:

— Алоэ! Гәр Хутордан Габделбарыев квартирасын, пожалуйста.

Абонент әйтеп бетерелгәнче үк инде шнурны шул каналга тоташтырганнар иде. Таҗиева тын да алмыйча параллельдә утырды. Теге башта да, бу башта да нилэрдер кыдыр-кыдыр килде, теге мөлаем кыз кемгәдер — Кәшфигәдерме, әллә Гәр Хутордагы аның хатыны Асиягамы, дәште:

— Говорите...

Таҗиева һаман тын алмаган иде әле. Линиядә тагын кыдырдау. Тамак кырган тавыш һәм, ниһаять, Кәшфи!

— Алю, алю! Асия, синме?

— Әлү, әлү. Мин, мин, Кәшфи.

— Алю, Асия! Радиаторда су калган минем.

— Мин аны шул көнне үк агыздым.

— Шулай мыни? Ярый хуш. Аның өчен чөнки — трактор ул... Ярый хуш.

— Кончили? — Теге ягымлы тавыштан соң линия тынып калды.

...Кәшфи күргәзмәдән медаль алып кайтты. Бер атна узганда, СССР элемтә министрлыгыннан Таҗиева исеменә рәхмәт кәгазе килеп төште.

...Ахияр Гәр Хуторга соң килде. Уникe өйнең берсендә генә — урманга терәп салынган Тавис өендә генә ут бар иде. Ахияр бернинди шакусызнисез чоланга узды, аннан зур өйнең беренче ягына керде. Люция савыт-саба юып йөри. Тавис күренми иде.

— Сеңлем, нихәл, теге титарай кайда?— диде Ахияр.

Люция, шешенгән күзләрен Ахиярдан яшереп, йортның эчке ягына ишарә ясады. Ахияр түргә узды, ишек янындагы включательне чама белән эзләп тапты. Болын кадәр өйнең түшәменә көндезге яктылык белән озын трубкалар куелган иде. Түрдә — никельле, сыгылмалы зур караватта — Тавис йоклап ята. Ахияр башта аптырабрак калды, кара-

ват башына терәп, зур ястык салынган. Зур ястык астында зур мамык түшәк. Панцир уртадан иңгән. Тавис шулай итеп утырып йоклый икән. Ахияр тупас кына аңа дәште.

— Тавис, тор әле, сөйләшәсе бар,— диде.

Люция керде.

— Ахияр абый, маташмагыз, файдасы юк,— диде.— Нарат яфрак ярырга мөмкин, әмма каен ылыс бирмәячәк. Мин барысын да хәл иттем инде. Отпуск алган көнне үк китәм.

Борылып чыгып китәр алдыннан тагын әйтте:

— Моның белән сөйләштең ни, сөйләшмәдең ни. Безнең авылда андый кешене мунча ташы дип йөриләр: әйткәндә аңламый, сукканда еламый.

Тавис, әлбәттә, йокламый, тыңлап ята иде.

— Тор әле, сөйләшәсе бар.

Тавис күзен ачты. Ахиярны танымый торган булды.

— Тор әле. Чыгыйк әле. Син нәрсә, әллә инде ятып йоклау дигән нәрсәне дә оныттыңмы? Әнә шул утырып йоклау харап итә инде сине. Башыңдагы кан, беләсеңме, кая җыела? Әнә шуңа күрә бөтен эшең дә шул төш белән эшләнә инде синең...

Тавис торды, йокыдан айныган булды, киерелде. Эш буенча председательнең аңа бер дәгъвасы да юк иде. Һәр ходай бирмеш көнне Тавис иртүк атын җигә дә, фермага китә. Эшкә карусыз, бригадир аның теге-бу эшне өзгәнен, каршы килгәнен белми.

Чоландагы эскәмиягә чыгып утыргач, Тавис тәмәке кабызды.

— Юкка килгәнсез,— диде ул Ахиярга.— Хатынга мин хуҗа. Сез анысына председатель түгел.

— Тукта әле...

— Туктыйсы-нитәсе юк. Мин озын сүзле кеше түгел. Мин көненә ике генә тапкыр сөйләшәм: драстуй, досвидания. Минеке шуның белән бетте.— Ул урынынннан сикереп торды, утлы тәмәкесен ачу белән идәнгә ыргытты.

— Нигә ун чакрым җирне бергә кайтканнар алар беркөнне хезмәт укытучысы белән? Урман эчен ник бергә чыгалар алар? Үзегез уйлап карагыз! Ник сөт машинасына утырмаганнар алар, ә? Имеш, машина газы килешми! Тегеннән аерылмас өчен әйткән ул аны. Мин аның йөрәген кисәм әле ул хезмәт укытучысының, йортына ут төртәм мин аның. Керосин сибеп... Мин аның йөрәген кисәм әле... Хиросима ясыйм әле мин аларга.

Ахияр бернигә ирешә алмыйча кайтып китте. Чыгып китәр алдыннан гына йөрәк ачысы белән әйтте:

— Егет кеше ул армияләрдә булып, хәрби хезмәтне күреп кайтсын икән,— диде.

Кәшфиләрнең дә өендә ут яна иде. Малай ике нигезне дә дер селкетеп алган ахры, дип уйлады Ахияр.

Люция шул атнада ук кайтып китте. Колхоз машинасына утырып килгән әнисе әйберләрне төяп бетергәч, бәләкәй Алсуны алдына алып, кабинага кереп утырды, Люция кузовка урнашты. Тавис исерек иде, чоланга сөялеп тәмәке тартты. Машина кузгалыр алдыннан, әби кеше Тависка карап:

— Ишегалдыңа бәбкә үләне үссен иде,— дип нәрсәдер укынды. Моны Тавис та, шофер да аңламадылар. Урамга чыкканда әби кеше искергән зур урыс капкага сеңеп торган сыек гәүдәле берәүне шәйләп алды. Йөзен чытып шоферга борылды.

— Әнә теге юньсез генә харап итте баламны,— диде.— Ирем ягыннан нәсел. Дөнья мәгънәсезе. Юньле булса, гомере буе колхозга кермичә ялгыз хуҗалык булып яшәмәс иде ул. Әле дә керми бит. Әнә шул

юньсез генә харап итте баламны. Әнә, басып тора бит нократ замананнан калган иске капкасына сыланып.

Чулак Абдул, машина узганда, капкасыннан эчкә кереп китте.

— Әйдә ярар инде,— диде әби кеше.— Туасы җан булгандыр.— Аннан бәләкәй Алсуны күкрәгенә кысыбрак утырды. Алсу бәхетле, шат иде: ни әйтсәң дә, машина кабинасында әле беренче баруы бит...

Шофер егет дәшми, тынлый гына. Ул әле яшь, кияүдән аерылып кайтуның кыз бала өчен нинди фаҗига икәнен белми. Әби кеше исә бара-бара да, авыр сулап куя:

— Үз сөягебез үзебездән артмас әле. Тик инде ишетер колакка гына бер дә матур түгел шул. Бигрәк тә рәтсез кешегә тап булды шул. Бигрәк тә бәхетсез бала булды шул. Торып калсалар да ярыйсы иде инде. Тегесе лишнәйрәк кыланды шул...

«Лишнәйрәк»нең бөтен тирәнлеген кодагый үзе генә белә. Кыз белән кияүнең беренче кышлары, беренче айлары иде. Дөньяда бер ямьсез, хәвефле салкын буран чыкты. Буран бәбкә-киштәләрне йолыкты, лапасны, йорт түбәсен алып китмәкче булып котырынды. Кодагый, кызын уйлап, болай да йокысыз ята иде. Шул вакыт капка шыгырдагандай булды. Ялгыз хатын сискәнеп китте: кемдер койма өстеннән кергән сыман дөпелдәп ишек алдына төште. Кодагый ут кабыза алмыйча матавыкланды. Ул арада ишек кактылар.

— Кем ул? Кайсыгыз ул? — диде кодагый, куркудан тамагы чатнаганны җиңә алмыйча.— Кем бар анда?

Салкын буран бер аваз алып килде:

— Бу — мин, әби, курыкма. Тавис мин.

Әби кешенең эченә җылы керде, аягына киез итекләрен киеп, ишекне барып ачты:

— Һай, аллам, Лутсия исән-саудыр бит?— Әби кеше карлы-буранлы кияүгә ялварулы караш ташлады.— Ул-бу булмагандыр бит?

Тавис бүрегеннән-туныннан сырышкан карны какты.

— Юк,— диде ул артык туры карамыйча.— Ташлытаудан кайтышымые. Кибет алдына туктап, таныш-белеш белән тегене-моны сөйләшеп торган арада атым югалды. Үзебезнең якка китмәгән, ул яктан кайткан тракторчыларны очраттым. Берәр тыкрыкка кереп катып калмагае дип куркам. Ат түләсе булса — тагын колхозга. Болай да халыкара хәл катлаулы.

Әбисе, калын сукно шәлен бөркәнеп, фонарь кабызды. Тавис чишенеп диванга ятты.

— Син инде, әби, тышта бик салкын, кырга чыкма. Тыкрык-фәләннәрне генә карап кайт. Батып ятып, тез буыннарын өшетмәсен, дим. Ат түләргә монда... Шундый расхутлы елны, йорт җиткерәсе бар бит. Еллар да тыныч түгел. Әле аның йортын җиткерерсең, ә сугыш башланып куйса. Кара ул Вьетнамда ниләр бара... Мин бераз хәл алыйм, аһ иттем. Мин кешедән куркып яшәүче түгел: бирәчәгем юк, алачагым бар...

Шакмаклы яшел сукно шәлен бөркәнгән әби төнге икедә шакыраеп катып, ут янып торган өенә кайтып керде. Өйалды ишекләре ачык иде. Өенә керде һәм шаккатты: өй асты ачылган. Тавис диванда түгел, идәндә тәгәрәп ята. Кодагый әби, әле аңышып бетермәстән, чыра кабызып, өй астына төшеп китте. Шунда гына аңлады:. нигез балчыгына күмеп асраган ике шешә эчемлеге бар иде. Яз көне бакча сукалаганда, җәй көне печән китерткәндә гел кирәк була торган ике шешә бар иде. Ә хәзер... Нигез актарылган — әйтерсең, күсе йөргән һәм ике шешәнең берсе калмаган. Ярый әле, ак түгел, кызыл гына иде.

...Кодагый-әби иртән мал караганда, Тавис чыгып сызды. Атны тиз тапты. Ул аны авыл читендәге бер йортның лапасына кертеп, ышыкка куйган, ашарына люцерна салган икән. Хуҗаларыннан үтенгән:

— Мин,— дигән,— Гәр Хутордан, күрәсе кешеләрем бар, бер узышлый утын кертермен, атны куеп торыйм,— дигән.

...Килен китеп, бер атналар чамасы вакыт үткәч, авылның юкә чәчәге исенә батып, бал сулап йокыдан торган бер иртәсендә Гәр Хутор халкы «Дружба» пычкысының тавышына сискәнеп уянды. «Дружба» тавышы авылда сабантуйга кадәр, халык утын әзерләгәндә генә ишетелә иде. Берәү дә шикләнмәде: Тавис бу. Чөнки кичә генә ул районнан суд торып кайтты. Кичә бер тапкыр «Дружба» янгырап алган иде инде. Судта мал-мөлкәт, йорт-җирнең яртысын Люция белән Алсуга бүлеп бирергә дип карар чыгарылган иде. Тавис өйдән-өйгә йөреп сөйләде.

— Миңа нәрсә?— диде ул өй саен кереп.— Бүлдем-бирдем, чыктым-киттем. «Дружба»м исән булсын. Пычкымны асам да, Тайшет ягына китәм дә барам. Хатын-кыз шулай ул. Бармагыңны бирсәң, кулыңны тартып алыр. Мин бу йортка күпме расхут тоттым? Аны миннән башка кем белсен? Ашаган белми, тураган белә, ди әнә чулак Абдул. Минем теге чүпрәкбашның туганы. Минем бу йортка тыккан акчамы! Һи-и-и... Осталарны бер кушкачмы? Кирәкнең кыйбаты юк аның.

Бу нотыкны Гәр Хуторның тугыз өендә аерым-аерым тыңладылар. Унынчы өй — Тависның үзенеке, унберенче — әтиләренеке, уникенче — чулак Абдулныкы. Тавис анда бу нотыкны бераз үзгәртеп, ике җөмләсен кыскартып сөйләде. Аннан, пычкысын асып, әти-әни йортына килде. Әтисе эштә иде, туган нигездә ул коры гына сөйләште дә, әнисенә әйтте:

— Давай, кайда, нәрсә турыйсы бар? Пычкы эш сорый. Давай, давай. Ачу килгән чак — кулымда пычак. Кышлык әрдәнә ясап биримме? Анда берәр стакан бырага калмаганмы? Бар карап чык әле. Һи-и-и... Теге хезмәт укытучысынмы? Пөрәген кисәм мин аның шушы пычкы белән. Әйткәние диярсең, бирган булса, ...буду, фәлән итим...

Әнисе кызганды, бер стакан «бырага» бирде. Кәшфидән яшереп кенә, урык-сурык үткән-сүткәнгә, Тависка дип кенә ясаштыргалап тора иде. Тавис җебеде, сүгенде. Әнисе сыер савып йөргән арада пычкысын кабызды да ишек алды буйлап йөрде. Аннан кисәрлек-турарлык әйбер тапмагач, ачу белән җир кисә башлады. Күзен алартып бөкрәя дә, котчыккыч газ биреп, пычкының чылбырын җиргә батыра, якын-тирәгә балчык, бәбкә үләне оча. Әнисе сыер савып чыкканчы шулай кыланды, ишегалдын бозып бетерде.

Ә бүген! Йокыдан торган халык күрде: Тавис ишегалдында быж-быж йөри иде. Күрделәр: пычкысын җилкәсеннән салмаган көе ул чулак Абдуллардан озын баскыч алып чыгып китте. Аннан моторлы пычкының котырынган тавышы ишетелде: пычкы бер явызланып, бер юашланып, йомшап кала иде. Кәшфи дә сискәнеп торды: бу тавыш аңа теш докторының мәкерле, явыз машинасын хәтерләтте. Анда да шулай: нәнием, нәнием, дигән була да доктор, ысылдап торган бер кәкрүшкәне авызыңа тыга. Аннан түз... Эж-ж! Эж-ж!— итеп бәгыреңне телгәли дә, монысы гына җитмәде бугай дип, шалтыр-шолтыр китереп коштабактан тагы да нечкәрәк, тагы да зәһәррәк борау эзли...

Кәшфи уянды, сикереп торды, чыгып йөгерде. Чалбарын урам буйлап йөгергәндә төймәләп бетерде. Яланаякка элгән галошларның берсе өстән ярык икән, урамда төшеп калып үзгәнә үтте. Бер алды Кәшфиң галошны йөгереп барган хуттан кире чигенеп, ике алды. Өч. Аннан, дүртенче тапкырында инде алып тормады.

Ул килеп кергәндә Тавис клуб кадәр яңа йортның бер стенасын кыл уртадан өзеп чыккан иде инде. Кәшфи, йөгереп килеп, улына ябышты, пычкысын тартып алды, сүндерде. Күз яшенә тыгылып, гыжылдап әйтте:

— Нәрсә эшлисең син, улым? Башыңда миең бармы синең?! Аның өчен чөнки... бу йортка минем нәкъ дүрт мең ярым тәңкә...

Аннан чирәмгә лып итеп утырды да күзләрен яшьләндерде. Тавис тыныч кына сигарет кабызды.

— Мин хөкүмәт карарын үтим. Миңа кичә судта әйттеләр. Йорт-җирнең яртысы — теге чүпрәкбашка, диделәр. Син борчылма. Мин ирекле савит гражданы, мин хөкүмәт карарын уважать итәргә тиешме, юкмы? Вәт менә мин шуны үтим. Үз өемне дә кисәргә хокукым булмагач, демократия кайда соң?

Һәм Тавис моторлы пычкысының нечкә тросын «дыр-р-р» итеп тартып җибәрде. Пычкы тагын ишегалдын селкетә башлады. Гәрәбәдәй нарат бүрәнәле өйнең икенче ягына баскыч сөяп, пычкы күтәреп менеп киткән улына Кәшфи инде бер әйбер дә әйтмәде.

Барысы да бүленгән, аерылган, беткән иде инде. Ул, утырган җиреннән торып, билен язып маташканда авыр сулап карап куйды: ун метр озынлыктагы мәһабәт йортны өстәге калай түбә генә тоташтырып тора иде.

— Иманын фәлән итим... Хәзер чулак Абдулдан тимер кайчысы алып чыгам да түбәсен дә кисәм. Аннан Колан Кырга барып теге хезмәт укытучысының йөрәген кисәм. Шуның йөрәген кисмәсәм, дөньяларда да тормыйм... Нигә яшь совет семьясын боза ул? Чыктым-киттем Тайшет якларына. Кеше үтергән өчен чуртым да юк хәзер. Йөрәген кисәм мин аның. Кулы пычкы тота белгән кешегә өтермәдә дә шул эш. Йөрәген кисәм мин аның... Менә эш бетте: уртак малны эт җыймас, дигәннәр...

Кәшфи берсүзсез ишегалды уртасында басып торды.

## VIII

Тавис «Дружба» пычкысы белән йортын кискән көннәрдә Кәшфинең гаиләсе кителә башлады. Олы кызы йорттан инде күптән чыгып киткән, анысы (иң акыллы; иң әдәпле бала) пединститут бетереп, Колан Кырда мәктәптә эшли, ялга гына кайтып йөри иде. Икенче кыз исә трестта штукатур булып эшли һәм байтак акча ала, әти-әнисенә гел ярдәм итеп килә. Анысы кияүне дә тиз тапты — Чүпрәле районыннан чыккан мишәр, Казанда таксист булып эшли, имеш, акчаны күрәп ала. Бүген шуларның туе иде. Таксист кияү кешенең төрлесен күргән, шуңа күрә теге көнне Тависның йорт турап йөрүенә гаҗәпсенмәде, туй барышына бу хәл йогынты ясамады.

Туйның мул узуы өченче кызны әсәртте. Өченче кыз мутрак, үткенрәк иде, туй көнне үк хәл итте: апасы белән җизнәсенә ияреп шәһәргә китәргә. Гәр Хуторда кияү табып булмаячак. Сугыш вакыты мыни— көн тәртибенә тагын кияү мәсьәләсе куелды. Хәзер югары белем алу да хәтәр. Әнә Рәсимә апа ике-өч фәнне укыта ала, аңа тиң егет авылда гына түгел, Колан Кырда да юк, ул күз алдында утырып кала инде. Әнә ул йөгерә-йөгерә туй уздырышып, оештырып йөри, биш ел шәһәрдә студент тормышын кичергән кеше буларак, ул өстәлгә нәрсәне ни вакытта чыгарасын белә... Әмма, аңа ни шатлык? Аңа нәрсәгә бу?

Китәргә! Авылда бер көнгә дә калмаска! Өченче кыз шулай карар кылды. Аның күңеле кузгалды. Җитмәсә, җизни кеше, Чүпрәле мишәре, ишектән кереп-чыгып йөргәндә — көпә-көндез! — ике тапкыр моның калын чәч толымын очраклы рәвештә генә учына алып селекте дә, толым астына кулын тыгып муеныннан сөеп китте. Балдыз шул ярты сәгать эчендә савыт-саба юганда бер аш тәлинкәсе һәм ике хрусталь рюмканы төшереп ватты. Туй кешеләренең бакчага чыгып, хәл алган вакытлары иде, йортта кызлар гына йөри; алар кичке зур табынны

әзерлиләр иде, шуңа күрә савыт-саба ватылганга да, рәтсез Тависның кереп-чыгып әчкәләп, сүз озайтып, болагайланып йөрүенә дә игътибар бирүче булмады. Кичкә зур мәҗлес котелә — вәссәлам! Кичке мәҗлес исә балдызны бөтенләй кешелектән чыгарды: ишегалдындагы таш сарайдан салкын катык алырга дип чыкканда веранда ишеге янында ул кинәт кенә җизни белән очрашты һәм каушап калды. Чүпрәле җизни исә каушап калучылардан түгел икән, чолан ишегенең яңагына үрелде дә нәрсәнедер чыртлатты, һәм шул мизгелдә ишегалдын яктыртып торган лампочка сүнде, балдыз әллә ничек кенә мишәр җизнинең куәтле беләкләре арасына килеп керде, һәм аңына килгәнче, мишәр җизни аның авызын томалап суырып үпте. Аннан, гөлт итеп ут янганда, җизни юк иде инде, һәм өйдән җыр тавышы ишетелде:

> Сандугач җибәргән идем
> Тыңларга сүзегезне...

Балдыз бер мәлгә аңсыз торды: электр яктылыгы аның миен бутады, шул яктылыкта аның өстенә телевизор антеннасы авып төшкән сыман булды, зур урыс капка уптым-илаһи урыныннан кузгалып, верандага таба килде, ә веранда йорттан аерылып, бәрәңге бакчасына таба йөзеп китте. Өй эчендә исә бу хәлләрдән бөтенләй бихәбәр кунаклар гөр килеп җырлыйлар иде:

> Түрегездә сайрап торган,
> Күрмәгән үзегезне.

Урлап, хыянәтчел рәвештә һәм секунд эчендә башкарылган бу эш — мыеклы җизнинең үбүе — балдызны эштән чыгарды. Ул әле кичә генә мондый хәл буласын белми иде. Ул әле кичә генә, бакча башында сыерга эт эчәгесе җыеп йөргәндә, йөрәк тетрәткеч бер хәлгә шаһит булган иде: күкрәге яраланган бер күгәрчен бакча киртәсе буендагы карт әрекмәнгә ышыкланып басып тора. Очып китә алмый. Кызыл кырыйлы мәрҗән күзләре белән мөлдерәтеп карый. Ә каршысында... егерь Минһаҗның бозау кадәр зурлыктагы овчаркасы басып тора. Телен чыгарган. Эче селкенеп тора, еш-еш сулый. Эт күгәрченгә караган, күгәрчен — эткә. Болар инде байтак шулай торганнар булса кирәк, этнең авызыннан селәгәй ага. Күгәрчен дә тыныч түгел, йөрәгенең лепелдәп типкәне беленә — әрекмән дерелди. Кызый каушап калды һәм эт эчәгесен кочаклаган килеш абзарга таба йөгерде. Эт эчәгесен тиз генә утлыкка салды да, күгәрченне алырга дип, бакча башына төште. Йөгереп килде... Ул килгәндә исә озын телле эт тә, күзләре кызыл каймалы күгәрчен дә юк иде инде.

Балдыз, кинәт кенә, үзен шул күгәрчен хәлендә итеп тойды. Ул күзен ачканда янында беркем юк, чоланның шома баганасына арка белән терәлеп тик тора иде.

...Балдыз апа белән җизнигә ияреп үк китте. Җизни — шәһәрдә байтак эләмтәле егет, бөтен сөйләшкәне — «белгән малай», «үзебезнең малай». Ул, балдызны эшкә урнаштырып, тулай торактан урын да алып бирде.

Бераздан алар туган йортка апасы белән бергә кайтып йөри башладылар.

Кайталар — менә дигән итеп киенгәннәр, ялт та йолт китереп өй җыештырып алалар, печән-утын әзерләшәләр, варенье кайнаталар, кер юалар. Өйдә нибары дүрт кыз хәзер, аларның да икесе инде гаҗәп ямьсезләнеп, озынаеп; авызлары зураеп, аяклары торнадай сузылып килгән вакытлары иде — бу инде, бер дә шиксез, тулыланып,

матурланып түгәрәкләнеп китәр алдыннан булган бер халәт һәм инде шулай өч «торна» үстереп галәмгә очырган Кәшфи моның нәрсә белән бетәчәген чамалап йөри иде. Шәһәрдәге ике кыз исә кайттылар да сөйләделәр, кайттылар да сөйләделәр. Бигрәк тә өченчесе, үткенрәге — сөйләде.

— Анда,— диде,— эш бик җиңел, ак халат киеп кнопкага басып кына утырам, көненә җиде сәгать эшлим, көндезге смена гына, ике көн ял итәм, ике йөз таңкәгә хәтле акча алам...

Сыер савучы кызлар моны тыңлап хәйраннар калалар: алар көнтөн эштә, җәй юк, кыш юк, кнопкага алар да баса, әмма кнопкадан тыш әле алар әллә никадәр авыр йөк күтәрә. Кичкә таба бик нык арыйлар, күпме генә эшләсәләр дә, йөз егермедән узмый һәм атнага ике көн ял да эләкми иде. Ләкин юкка гына баш ваталар: Кәшфинең үткен өченче кызы да (кызлар күп булгач, Кәшфи үзе генә түгел, күршеләр дә исемнәрен хәтерләмиләр, чама белән өченче, дүртенче дип номерлап сөйләшәләр) һич тә ак халат киеп кнопкага басмый һәм бер генә сменада эшләми, ике йөз таңкәне әлегә ала алмый иде. Өченче — үткен кыз бик һәйбәтләп кенә мехкомбинатта тире юу цехында өч сменага күчә-күчә эшли, тулай торакка кайтыр алдыннан душта юынып чыга һәм әлегә, өйрәнчек буларак, җитмеш ике таңкәдән дә ары ала алганы юк. Авыр эштән арып, буыннары талып йокыга киткәндә ул, саташып, кайвакытта колхоз басуына кайта һәм төшендә кнопкага гына басып эшләтә торган комбайн белән шикәр чөгендере җыйдыра. Кояшлы көн, имеш, чөгендер тау кадәр өелә, аннан ул комбайнын туктата да шул тау өстенә менә, һәм шунда аның күкрәгенә куәтле беләкле, кара мыеклы үҗәт мишәр җизни төртеп җибәрә дә, ул чөгендер тавы өстенә егыла. Кайвакыт ул чөгендер тавы да булмый, ә ап-ак мамык тавы була, һәм мишәр җизни төртеп җибәргәч, ул, мамык тавына чумып, озак-озак чокырга төшә, ә теге әрсез җизни һаман моның белән. Үзе һаман көлә имеш...

...Менә тагын калын карабодай басулы, кукурузлы саргылт-яшел баллы көз җитте, кышка әзерләнү кебек киеренке, эчке яшерен шатлыклы бер халәт килде. Иген быел бик уңган, көннәр әйбәт тора иде. Кәшфи сентябрь башында үзенең комбайнын паркка кертеп куйды да авыр сулады: идарәнең карары буенча аны иртәгәсе көннән механика мастерскоеның мөдире итеп билгеләгәннәр иде.

Моңсу да, канәгатьле дә һәм канәгатьсез дә бер көз иде бу. Көз әллә ничек кенә шунда кисәк килде, якты зәңгәр күк, сары камыллы кырлар, карачкыл куе яшел кукуруз басулары, анда-санда җир тырмашып дерелдәп эшләп йөргән «Беларусь»лар, салкынга борылырга әзер торган җылы җилләр белән килде. Кәшфи, мастерскоена ияләнә алмыйча, иза чикте. Чыкты да карады тышка, чыкты да карады: кырда булган бөтен техника хәрәкәттә иде, тракторлар, кукуруз комбайннары Кәшфидән башка да йөриләр иде...

Моңсу көннәрдә, болай да күңел үзенә урын тапмыйча йөргәндә, моторлы пычкысын асып, әллә каян гына Тавис кайтып төште. Кайтып төште — йортта тынычлык китте. Кышка дип кыяр-помидор тозлап йөргән көннәр, Кәшфинең дә туганнан бирле дип әйтерлек беренче мәртәбә өенә үз вакытында кайтып кичләрен телевизор карап, газет-журнал укып яши башлаган көннәре иде. Тавис кайтты—тавыш кайтты.

Таккан кулына әллә ниткән бер сәгать. Төшергән аны кул аркасына ук. Гел шуны күрсәтеп йөри. Вакыт сораган кешеләргә юньләп әйтә дә алмый. Сәгатьнең цифрлары юк.

Тависның хикмәтле сәгать тагып фырт йөрүенә чулак Абдул үзенчә хөкем чыгарды.

— Җегет — җилле,— диде ул, Тавис урам уртасыннан сәгатен карый-карый, тәмәке суырып узып барганда, капкасына сөялгән килеш калып. — Җегет — җилле, чикмән — билле, чыбыркы — чуклы, ...лы. Менә шул инде ул...

Тавис кайтты — энисен кыен хәлгә куйды.

Чулак Абдул трактор белән утын китерткән икән, хатыны йөгереп Кәшфиләргә керде.

— Җыеп куйган запасыгыз юкмы, бүген кич үк Колан Кырдан алып кайтып түләр идек,— диде. Кәшфиләрдә гомернең-гомер буена запас була иде, он бурасы эченнән алып берне биреп чыгардылар.

Дөбер-шатыр килеп, трактор узып киткәч, чулак Абдул хатыны Кәшфиләргә кереп елады:

— И ходаем, адәм мәсхәрәләре генә булдым, шешәсенең бөкесе дә рәтле, эчендә кое суы,— диде. — Адәм мәсхәрәләре генә булдым.

Кызмача Тавис, пычкысын кабызып-сүндереп, ишек алдында матавыклана иде. Һаман сүз чыгармак була, этисе-энисе исә сүздән качалар. Чөнки бер эшсез йөргән улына энисе кайткан көннәрдә әйтеп караган иде:

— И, улым, кеше балалары читтә эшләп, күпме акча белән кайталар, синең нинди ярдәмең бар соң атаңа?

Тавис бу сорауга әзер булып чыкты:

— Сезгә акча бирергә мин капиталистмыни? Мин — иреклe гражданин.

Бераздан энисе эшсез йөргән улына эче пошып:

— Ичмаса бәрәңге сабагын чабар идең. Әтинең бик тузды, бик картайды бит,— диде.

Тавис монысына да әзер икән.

— Гел эшләп торырга сез мине трактор дип белдегезмени? Әнә тимер эшләсен,— диде.

Тавистан бөтен әйберне яшерделәр: энисе запаска дигән егерме литрлы шешәне башта печәнлеккә яшереп карады. Печән өйгән булып, өйгән печәнне рәтләгән булып, Тавис аны барыбер тапты.

— Бәт-тәч, монда нәрсә бар соң? — дип ул, сәнәк белән рәхәтләнә-рәхәтләнә шешәгә төртте.— Тукта әле, чабата башы чыкты әле, дигәндәй. Монда нәрсә бар соң? Печән рәтлим дисәң, бер матавык чыга да тора... Бер эш эшлим дисәң, бер нәрсә чыга да тора. Чисти империализм булды бу безнең йорт.

Энисе шешәне икенче тапкыр абзар артына чыгарды. Әле авылда беркем дә йокыдан тормаган иде. Салкынча, кыраулы, бәрәңге сабагы исле бер якты иртә иде. Кая куярга бу афәтне! Буразналарны күмеп, эт эчәгесе катыш бәрәңге сабагы яткан икән, Асия җиңги мәшәкатьле нәрсәне бакча башына өстерәде. Иң түргә меңгереп буразна арасына сузып салды да өстенә бәрәңге сабагы аударды, эт эчәгесен тартып суздьı, шуның өстенә борды. Читкә китеп карап торды, этем дә табарлык түгел иде.

Тавис ул көнне ыгы-зыгы килеп урамда йөрде, аннан бик дәртләнеп кайтты да энисеннән бер генә стакан ачы бал сорады. Асия җиңгинең мич астындагы куышта бер банка ике-өч стакан запасы һәрвакыт була иде, һәм ул, олы запастан игътибарны читкә юнәлтү өчен, монысын аеруча басым ясап, күрсәтеп, болгата-болгата куышлыктан алды.

— Менә, бөтен булганы шушы инде, улым,— диде.

Тавис бер стакан эчте дә авыз тирәсен сөртте.

— Миңа,— диде,— бүльше кирәк түгел, без хәзер чулак Абдулның дуңгызын суябыз.

Асия җиңги авыр сулап алды. Тавис, ашыгыч рәвештә верандадан узышлый, шүрлеккә куелган кайрак, чөйдән бер бәйләм сүс бау алып чыгып китте.

...Кәшфи, мотоциклына утырып, Колан Кырдан кайтканда, чулак Абдуллар тирәсендә ыгы-зыгы иде. Дөнья, тормыш тәҗрибәсе белән Кәшфи сизде: унике йортлык Гәр Хуторның берәр җирендә ыгы-зыгы булса, ул инде, һичшиксез, Кәшфиләр гаиләсенә бер чите белән кагылмый калмый иде. Шуңа күрә Кәшфи тиз генә мотоциклын сүндерде дә, өстен-башын кагып, чулак Абдулларга таба йөгерде.

Кәшфи килгәнче, монда инде бөтен авылның малай-шалае җыелган иде. Метр ярымлы дуңгызны такта капкачны ачып аранга чыгардылар. Аран — трактор кабиналарыннан, иске түбәләрдән бушаган калай-тимер кисәкләре белән уратып алынган иде. Диван кадәр дуңгыз чыкты, кояшка күтәрелеп карамакчы булды, әмма, бичараның табигать биргән инстинкты тартты, ахры, ул, мыркъ-мыркъ килде дә, кояшка битарафлык күрсәтеп, калай стеналарга ышкына-ышкына аран буйлап әйләнә башлады.

Тавис белән чулак Абдул аран эчендә, калай стена буена чүгәләп, тыныч кына тәмәке суыралар, әңгәмә коралар иде.

— Мин инде, ни, Абдул абый. Тукта, дидем, миннән калмасын дидем, барып та карадым. Мин әйтәм, кеше сүзе кеше үтерә бит ничек мин шуны өстемә алып ир булып йөрим, дим. Тегесе сөйләшми дә. Әби генә сөйләште. И, ди, кияү дип әйтсәм дә инде сине, ди, менә болай бит ул, ди. Дөньяны, ди, җил бозар,— кешене сүз бозар. Авыл халкы үзен, ди, күзгедән карый, күршесен лупадан ди. Син аны уйлап кына кара әле, Абдул абый, гап-гади авыл хатыны — лупа дигән сүзне белә, үзен күзгедән карый, күршесен — лупадан, ә инде, ди, укытучыны, ди, микроскоптан карый ди. Менә, билләһи, шулай ди. Лупа, микроскоп дип кенә сөйләшә. Менә, билләһи, шулай ди. Лупа, микроскоп дип кенә сөйләшә. Ә үзенә инде алтмыш яшьләр булыр. Билләһи. Мин тегене сөйләштерәм. Халыкара хәлләргә алып керәм. Чөнки милитаристларның бик котырынган чорында яшибез. Колагыңны зирәк тотмасаңмы? Һи-и-и... Менә шушыннан килде төште чит ил шпионы, алды китте сине. Аннан сиңа җәза, газап, допрос. «Яңа юл» колхозы ничә гектар арпа чәчә? Ничә баш сыер бар? Эштү син! Болар бит барысы да әһәмиятле капиталист өчен. Алар бит дивальвация, инфляция белән башлары әйләнеп... Ул сиңа кука-кула эчеп кенә булмый. Организмны харап итеп...

Диван кадәр дуңгыз әле һаман әйләнә иде.

Тавис торды, тәмәкесен тирескә басты. Багана башына аркылы кадалган озын пычакка карап алды. Тирән итеп сулап алды.

— Я, ярар, Абдул абый. Гомер буе дус яшәдек, син уйлама, ышту мин синең тумачаны хатын итеп алдым да аннан аерып ташладым, дип. Мин бит — ир кеше. И минем үз праваларым бар. Синең белән минем арага су керми. Без бит ирләр. Дуслар булып калыйк...

Бичара дуңгыз һаман бугазын дөңгердәтеп, эфирга тавыш дулкыны чәчә, калай стенага ышкылып әйләнә-тулгана йөри иде. Тавис дуңгыз янына килде, аны тоткан сыман итеп, муенын кашымакчы булды. Әмма дуңгыз алагаемга арт сикертеп чабып китте дә акырып җибәрде һәм аран эчендә бер әйләнә ясады: моны көтмәгән чулак Абдул каушап калды һәм, ялгышып, дуңгызның юл өстенә төште. Дуңгыз исә, муены кашылу рәхәтеннән булса кирәк, үзенең центнерлы гәүдәсенә хут биргән иде һәм юл өстендә очраган какча гәүдәле чулак Абдулны ул тузганак башын өргән кебек кенә мәтәлчек аттырды. Абдулның аяклары күккә күтәрелгәнне күреп, Тавис кычкырып

җибәрде һәм аңа ярдәмгә ашыкты. Ләкин дуңгыз инде темпка кергән иде, икенче әйләнә ясаганда ул, моны теләмәгән көе, калын гәүдәсе белән ялгыш бәрелеп Тависны да очыртты һәм Тавис, сөрлегеп китеп, чулак Абдулның брезент ботинкасының башына ачык авызы белән килеп ябышты. Дуңгыз аның саен кызды. Икеме-өчме тапкыр чулак Абдул белән Тависның өстеннән таптап узды. Ниндидер без мизгелдә Тавис торды һәм стенага сыенды. Чулак Абдул әле һаман тора алмыйча ята иде. Тавис куркынып кычкырды:

— Тор, дим, фәлән итим! Тор дим! Чулак тәре, тор дим! Фин сугышына бармас өчен кулыңны имгәткән чулак дезертир бит син! Тор, дим!

Дуңгыз котырынган, һаман әйләнә иде.

Яңадан куышу, яңадан егылу, аунау китте. Тавис һаман кычкырды:

— Бауны, дим! Бау белән аягын! Танавын боргычла, дим! Ах... фәлән... Чулак тәре!

Гыжылдаган Тавис, яткан җиреннән үрмәләп, дуңгызның арт аягына ябышты һәм байтак вакыт әйләнә буйлап шуышып йөрде. Ул арада чулак Абдул да сүс бауны дуңгызның танавына элдертә алды һәм дуңгыз гөрселдәп тиресле җиргә ауды, тыпырчына башлады. Котчыккыч тавыш, гырлау, сүгенү, тирес, салам, шалтыраган калай, тагын әллә ниткән хәрәкәтләр, авазлар арасында кайсы дуңгыз, кайсы Абдул яки кайсы Тавис икәнен аерып булмаслык бер халәт иде. Хәер, монысы алай ук әһәмиятле дә түгел. Шунда чулак Абдул сикереп торып, баганага кадалган пычакны алды һәм дуңгызга селтәнде. Әмма дуңгыз зур куәт белән алгы санын күтәреп алды да Абдулны бәреп екты, Абдул, пычагын ялтыратып, дуңгыз борынын боргычлап торган Тавис алдыннан чыгып очты. Әллә дуңгыз акырды, әллә Тавис... Тагын бер бәрелеш, һәм монысында инде пычак үзенекен эшләде. Койма буенда карап торган бала-чага читкә сибелде, дөньяны дөңгердәгән тавыш дулкыны басты, аранга кан сиптерә иде.

Кәшфи бу хәлне карап тора алмады, кайтып китте.

Ике-өч сәгатьтән соң, Асия җиңги, эче пошып, Абдулларга килде. Ишегалдын көйгән йон, көйгән кыл исе баскан, хуҗа хатын табада бавыр кыздырган, өстәлдә бер шешә тора иде. Асия җиңги имәнеп китте: өстәл янында утырган Тависның борыны ике күз турысыннан кечкенә мендәр кадәр чүпрәк белән капланган, аннан кан саркып чыккан, маңгае шешкән, ике кулы кан иде. Шулай да кулында стакан. Асия җиңги куркудан кычкырып җибәрде һәм Кәшфине алырга йөгерде. Кәшфи озак көттермәде: мотоциклы белән килде дә, Тависны утыртып, район үзәгенә — больницага чапты.

...Тавис больницада бер атна ятып кайтты. Аның борынын ике җирдән теккәннәр, бите тартылган, ямьсезләнеп калган иде.

Кайткан көнне урамда гел дулады.

— Фәлән итим! Йөрәген кисәм мин аның. Шунда бит бер миллиметр гына калган күзгә. Ни тамаша, шулай ярыймыни. Йөрәген кисәм әле мин аның. Чулак дисәң чулак шул. Чүть мине суймады, дуңгыз урынына.

Шулай дулаганда тыкрыктан чулак Абдул килеп чыкты. Кулында бозау эчерә торган чиләк иде. Тавис болай кинәт очрашуга әзер түгел иде, тәмәкесен ташлап үкчәсе белән басты да кычкырды:

— Исәмме-се-ес, Габдулла абый...

— Ә-ә, кайттың мыни? Син икәнсең әле...

Чулак Абдул туктап торасы итмәде. Аннары Тавис урамнан җырлап узды.

Торги була, торги була
Торги була кызларга;
Торгидан калган кызларны
Кисмәк тә юк тозларга.

Ул көнне Тавис көне буе печәнлек, утын әрдәнәсе тирәсендә йөрде, ләкин нәтиҗәсе чыкмады. Аннан чалгы алып бәрәңге сабагы чабарга чыкты. Сабак бик калын иде, Тавис аны рәттән чапмады: әле бер төшен, әле икенче төшен кыргалап йөрде. Йөри торгач бәхет басты үзен: чалгы борыны «зың» итеп эт эчәгесе астындагы шешәгә барып бәрелде.

Тавис шатлыклы дулады.

— Ну, безнең бу хуҗалыкны да әйтерием инде. Бер эш эшлим дисәң — матавык чыга. Кара инде бу безобразиене, кара инде моны. Юк, булмады, эти дә үз урынында нык тора алмады. Җыен чүпрәкбаш үстереп. Кыз баладан кем игелек күргән? Ватан сакчылары үстерәсе урында...

Шешәнең язмышы ул көнне хәл ителде. Тависның кәеф әйбәт иде. Ул моторлы пычкысын сүтәргә кереште. Үзе гел борын астыннан гына шыңшыды:

Ай-ли, Майтапны,
Башлар күрде байтакны.

Икенче көнне Тавис, моторлы пычкысын чулак Абдулга сатып, авылдан китәргә әзерләнде. Әйтте:

— Сез не думайте, минем анда барысы да бар. Хатын да, квартирам да бар. Минеме? Һи-и-и... Любей урынга бишкуллап алалар.

Капчык, ашау әйберләре инде әзер иде, Тавис нигәдер тагын бер кич кунарга булды. Ул көнне болытлар Гәр Хутор өстенә төшәм-төшәм дип мөлдерәп йөрделәр, шулай да яңгыр яумады. Ял көне иде, Асия җиңги таба ризыгы пешерде, Кәшфи дә, ихтимал, үз гомерендә беренче тапкырдыр, ял көне итеп, эшкә бармады. Кызлар, нигәдер, кайтмый калганнар иде, шуңа күрә йортта ниндидер бер ятимлек, моңсулык хөкем сөрде. Кәшфи, капка төбенә чыгып, әллә ничә тапкыр тыңлап керде: кырдан тракторның тигез гөрелдәгәне ишетелә. Трактор Кәшфидән башка эшли. Аның күңеле тулды. Йортка кереп китте. Ләкин бераздан тагын йөгереп чыкты. Колагына ниндидер сәер тавыш ишетелде. Чыкса — авыл өстеннән җай гына канат сирпеп торналар китеп бара иде. Һай, көзнең шул моңсу көннәре! Торналар, бәгырьләрне өзеп, күк астын моңга күмделәр:

— Тор-рыл-лыйкъ! Торыл-лыйк!

Кәшфи күккә карады. Аның да гомере әнә шул торналар кебек китеп бара сыман тоелды. Менә аны комбайннан алдылар, мастерской хуҗасы иттеләр.

— Синең тәҗрибәң анда кирәк,— диде Ахияр.— Кыр шартларында эшләргә яшьләр дә бетмәгән.

Бу инде син картайдың, туздың, дигән сүз булгандыр. Әйе, дөнья Кәшфине байтак туздырды. Күрәсең, аз гына туктап алырга, капремонт ясарга кирәктер. Подшипникларны тартырга, поршеньнарны юарга, цилиндрларның зазорларын тикшереп чыгарга кирәктер. Ә торналар безнең якны авыр җыр белән калдырып китәләр.

— Тор-рыл-лыйк! Тор-рыл-лыйк!

Шулай моңланып тора иде Кәшфи. Кинәт күк йөзендә гөрселдәгән тавыш ишетелде. Түбән генә очып барган торналар чылбыры кисәк бөгелеп таркалды. Торналар арасында ыгы-зыгы башланды, нәкъ шул мизгелдә бер торна авыр кагылып буталды да, авыл читенә, очын ишен суккан карт каенга таба мәтәлә-кадала төшә башлады. Уникe йортның уникесеннән дә халык чыгып урамга, ындыр артына чабыш-

ты, кычкырыштылар, шауладылар. Бераздан барысы да торна төшкән якка таба йөгерештеләр. Алар арасында Кәшфи дә бар иде. Халык җыелганда карт каеннан читтәрәк, алабута, билчән, тигәнәк баскан чокырда зәңгәр көмеш йоннарын очырып, иләмсез бер җан иясе тыпырчынып ята, озын аякларын, канатларын бәргәли, бөгәрләнә, тартыша иде. Бу — торна икән.

Халык бер сүз дә дәшмәде. Барысы да Кәшфигә карадылар. Кәшфи мондый игътибарга иялэнгән иде. Авыл халкы кыен минутта аңа гомер буе киңәш-табышка килде. Кәшфи әллә ничә срок район советы депутаты булды, райком әгъзасы булды, гел дәрәҗәдә йөрде. Монда да халык аннан җавап көтте кебек, әмма беркем дә берни дә сорамады. Кәшфи, гаҗәпләнеп, як-ягына борылып карады һәм тынсыз калды: кое бурасы янында тәмәке тартып торган Тависның җилкәсендә ау мылтыгы иде.

Торналар тагын бер сызыкка тезелделәр дә юл алдылар. Тик бер генә торна аларга иярмәде: йөрәк өзгеч тавыш белән авыл өстеннән бер әйләнде, биш әйләнде. Авыл кара кайгыга батты. Бераздан болытлар да сирәгәйде, күк аязды. Халык та таралды. Теге ялгыз торна исә, болытлар таралгач, күк гөмбәзенә үк күтәрелде һәм авыл өстендә бөтерелде. Инде аның тавышы бик җете колаклы кешегә генә ишетелә иде.

Иртәгесен иртүк Тавис юлга чыгып китте. Капчыкка салып алып кайткан торнага әнисе күтәрелеп тә карый алмады. Тавис чыгып киткәч тә Кәшфи абзар артына зур чокыр казып торнаны күмде.

Авыр, бик авыр иде аңа...

IX

Дуңгыз итен сатарга чулак Абдул карчыгы белән бергә барды. Шәһәр базарында халык мал таный: гел майдан гына торган ит арасыннан моны тиз искәреп алдылар. Төш вакытында чулак Абдулның куен кесәсенә дүрт йөз сиксән сум акча эһ тә итмичә кереп урнашты. Төштән соңгы поезд белән кайтып та киттеләр. Мондый зур акча Абдулны яшәртеп җибәргән иде, һәм ул ялт кына бер унлыкны чыгарып, шоферлар арасында йөрде. Зур кузовлы йөк машинасының кабинасында урын булмады: шофер янында кызмача иптәше дә бар иде. Унлыкка шул кызыкты, шоферны шул көндерде. Өстән карлы яңгыр явып тора иде, авылга биш-алты чакрым гына калгач, машина батты. Көрәкләр белән казып, агач ботаклары салып, алга-артка биреп карадылар — машина тирәнгәрәк утыра гына барды. Шофер бер өзлексез сүгенде.

— Синең ун тәңкәң аркасында монда. Я, нәрсә катып торасың, казы арт ягын тәгәрмәченең...

Чулак Абдул зур газап белән карлы балчыкны казыды, пычракка батты, юешләнде. Тәгәрмәч выжылдап әйләнгән саен аның битенә башына пычрак сипте. Шофер һаман сүгенде.

— Һи-и-и, фәлән... Ун тәңкә бирәм дигән була бит. Менә нишлим мин ул ун тәңкәң белән синең? Ярарые ул ике унлык булса...

Абдул ике унлыкка риза булгач кына, машина баткан җиреннән чыкты. Кузовка менгәндә Абдулны хатыны танымады: моның кадәр балчыкка моржачының да буялганы юк иде. Хәер, Абдул да хатынын чак таныды: бичара, туңудан зәңгәрләнгән, битендә ак йоннар кабарган иде.

Алар салкын өйләренә кайтып керделәр. Аһ-ваһ итеп мич яктылар, җылынган сыман булып йокыга да яттылар. Әмма икесенә дә бик нык салкын бәргән иде.

Иртәгәсен чәй куярга Абдул үзе торды. Ыңгыр-шыңгыр килеп йөрде, тагын килеп ятты. Өстәл өсте тулы акча — унлыклар, бишлекләр, егерме бишлекләр иде. Тик аларга карап шатланып кына булмады.

Кышның кырык градуслы салкын бер көнендә Абдулның карчыгы дөнья куйды. Кәшфи өй саен кереп, кеше җыеп йөрде, зиратның бер почмагын кардан көрәп ут яктылар, җирнең туңын эреттеләр.

Чулак Абдул салкын өендә ялгыз калды. Асия җиңги, Кәшфи, кызлары кыш буе аны карадылар. Чулак Абдул аларга рәхмәт тә әйтмәде, үз хәленнән зарланмады да. Хәзер аңа үзенең үткән юлы турында бераз гына уйланырга мөмкинлек бар иде.

Чулак Абдул үз гомерендә бер кемгә дә зарар салмады. Ул тынычлап үлә ала иде. Чулак Абдулдан беркем дә файда да күрмәде. Теге вакытта Тавис кына юкка рәнҗетте аны: фин сугышыннан качар өчен кулыңны чулаклатып, диде. Дөрес түгел. Абдулның кулы утызынчы елны ук имгәнгән иде. Урманнан утын алып кайтканда аты таудан дулап китеп, аны йөкле чана астына кысты. Кулы шунда шартлап сынган иде. Ул вакытта узды да китте, ә менә утыз тугызынчы елны комиссия торып йөргәндә хәбәр таралды: Абдул чулак икән, бер кулы мылтык тотарга ярамый икән, диделәр. Шуннан «Абдул» исеме янына аергыч сыйфат өстәлде: «чулак Абдул». Шулай, бер гаепсез яшәп дөньядан китә Абдул. Әмма җир йөзендә аның бер үкенече бар: нәселе калмый. Балалары булмады. Икесе дә сәламәт кебек иде — бала үстерә алмадылар. Чулак Абдул — районда бердәнбер аерым хуҗалык тотучы иде. Ташлы-тау районының статистик мәгълүматларына һәр вакыт цифр мәшәкате өстәгән кеше Чулак Абдул булды. Башка районнарда эш асат: районда күмәкләштерелгән хуҗалыклар саны, процентларда — 100, районда аерым хуҗалыклар саны, процентларда —0. Ташлытауда исә гомернең гомер буе күмәкләшкән хуҗалыкларның саны процентларда 99,99 булып килде. Ит, бәрәңге заданиеләрен аерым хуҗалыклар күбрәк түли иде. Башкалар итне кырык килограмм түләгәндә, чулак Абдул алтмышны түләп килде. Гомере буе бакча сукалату, утын-печән китертү өчен транспорт, ат эзләде — колхоз, әлбәттә, беренче чиратта колхозчыны карый иде. Олыгайгач, чулак Абдул колхоз идарәсенә тегене-моны сорап баргалый башлады. Ахияр гел әйтә килде:

— Абдулла абый, яз гариза, кер колхозга. Беренче утырышта ук кабул итәбез, җыелышка да куеп тормыйбыз.

Абдул сәбәп тапты:

— Мин бит инде картайган, колхозга миннән нинди файда?

— Безгә синнән файда кирәкми. Файдаң тияр вакытта керә белмәгәнсең, колхоз хәзер сиңа терәлеп калмаган.

— Соң, шулай булгач?

— Шулай булгачмы? Үзең өчен кирәк. Минем өчен, кешеләр өчен кирәк. Ничек инде син берүзең ак карга булып яшисең? Менә син миннән өй түбәсен ябу өчен шифер сорыйсың. Йөз табак шифер бирү — колхоз өчен диңгездән бер тамчы. Мин аны бирә алам. Әмма нинди кул белән резолюция салыйм? Колхоз байлыгын ничек итеп читкә чыгарыйм? Син бит — чит кеше. Шул ук вакытта, кеше булараk, минем сиңа ярдәм дә итәсем килә. Караучың юк, түбәгез тузган.

— Ие, ие, йорт тузды.

— Менә алайса, син миңа ярдәм ит. Син хәзер утырып, колхозга алуны сорап гариза яз, ә бер-ике көннән мин синең шифер сораган гаризаңа рәхәтләнеп резолюция салам: «Яңа юл» колхозы члены фәлән фәләневкә йөз табак шифер бирергә» дип язам да, рәхәтләнеп кулымны куям.

Чулак Абдул нәрсәдер уйлагандай итә, уйлап карамакчы булып кайтып китә, әмма гариза язмый.

Бераздан ул утын китертергә трактор сорап килә, Ахияр белән ике арада тагын шундыйрак сүз булып ала. Ахияр аңа тагын шул ук кинәшне бирә, тегесе тагын кайтып китә. Бераздан Ахияр аңа, кызганып, барыбер ярдәм кулы суза. Ара-тирә Кәшфи дә трактор белән ярдәм итә. Ахияр моны күрмәмешкә, ишетмәмешкә салыша. Дөрес, кайбер очракларда колхозчылар кычкырынгалап куялар:

— Аерым хуҗалыкка нигә колхоз техникасын бирәсез?

— Колхозның иң авыр вакытында кайда булган ул? Сугыш вакытында басу түренә кул чанасы белән без тирес чыгарганда чулак Абдул тире иләп акча сугып ятты. Ул вакытта ник безнең белән булмаган ул?

Ахияр барысын да аңлый. Әйе, шулай, нигә хәзер генә идарәгә килә ул? Адәм баласының һәрберсендә күпмедер дәрәҗәдә эгоизм бар. Яхшы кеше кем? Үзендәге әнә шул эгоизмны җиңгән, буйсындыра алган кеше. Чулак Абдул үзендәге эгоизмны җиңә алмаган. Ул — кызганыч кеше. Ул — безнең җәмгыять моралена кадәр күтәрелергә үзендә көч тапмаган. Бәлки ул, гомере буе үзенең шул сыйфатыннан рухи газап кичереп, сыкранып, җәфаланып яшәгәндер?

Ахияр, бала вакытыннан ук, дөньяның көтелмәгән сюрпризларын күп күргән кеше, чулак Абдулны кызганды, идарәдән, парткомнан яшергәләп, гел аңа вак-төяк ярдәм күрсәтеп яшәде.

...Апрельнең каткак, кояшлы бер көне башланганда идарәгә ат атланган Кәшфи килеп туктады. Кәшфинең үз гомерендә, ихтимал, атка беренче атлануыдыр. Ахияр, сәерсенеп, аның каршына чыкты.

— Ни өчен дисәң,— дип сүз башлады Кәшфи, аттан төшеп җитәр-җитмәс,— аның өчен чөнки... бүген төнлә Абдулла абзыйны борып куйдык. Асия белән төне буе шунда утырдык. И һәм дә мин бүген эшкә чыга алмыйм, миңа рөхсәт кирәк...

— Анысы вак мәсьәлә,— диде Ахияр авыр сулап. Үз авылының, болай да кеше саны бик чикләнгән бер авылның, яхшымы-начармы бер кешесе җир куенына керүе әйбәт хәл түгел иде. Кәшфичә әйтсәң, ни өчен дисәң, аның өчен чөнки... авылда бер нигез кимү дигән сүз бу. Гәр Хутор ничә дистә еллар буенча инде унике хуҗалык булып тотынып тора, унөченче хуҗалык Тависныкы иде, ул тиз бетте, әмма, унике бик төпле сан булып озак утырды. Авылның кителә башлавы инде бу.

Кәшфи бүреген салып, маңгай тирен учы белән сөртте.

Төштән соң көн кинәт кенә җылынып китте, көньяктан тыгыз җил исә башлады, каурый болытлар күк гөмбәзенә үк күтәрелделәр дә каядыр киттеләр — чын яз килде. Бозлы суларны актарып, үзенең газигы белән урам гөрләвекләрен вата-җимерә Ахияр килеп туктады. Кәшфи язгы кояшка рәхәтләнеп капкасына сөялеп тора иде, Ахияр килгәнгә балаларча сөенде. Икәүләп койма кырыендагы эскәмиягә утырдылар, эскәмия тактасы җылы бәреп тора иде.

— Нихәл, картаеп буламы? — диде Ахияр.

Кәшфи җанланып китте.

— Була, кордаш, була, — диде ул, алдагы ике көмеш тешен күрсәтеп. — Була. Аның өчен чөнки... балалар ярдәм итә. Менә мин сигез бала үстердем. Илебезгә сигез кадр. Бала — безнең тормышның нәтиҗәсе. Мин үземне, гомер буе эшләгәч, әйбәт кеше чутына кертеп йөри идем. Мин бер генә показательне алганмын. Тагын берсе бар икән адәм баласы өчен. Эш кенә түгел и һәм дә балалар кем булып чыгалар, менә ул да кирәк икән.

— Ну, синең калганнары әйбәт булды инде. Күпчелек дип әйтәм.

— Күпчелек... Күпчелек... Минә сигез балаң — йөз процент дип исәплик. Алар төрлесе төрле хәлдә, белемнәре, эшләгән, укыган урыннары төрлечә. Семья бәхетләре төрлечә. Шуңа күрә мин кеше нормасын уртача алам, аның өчен чөнки... Йомшакка сөрү нормасына күчереп исәплибез бит җирне. Сигез балаң — йөз процент. Бер балаң — 12,5 процентны тәшкил итә. Алабыз Тависны — минус.

— Ну, әйтәм бит инде, шул бер минус синең.

— Юк шул. Ә өченче кызны кая куясың?

— Ник, нәрсә булган? Мехкомбинатта эшли дип үзең сөйләп тордың бит әле кыш көне генә.

— Эшләвен эшли ул. Әйбәт эшли. Премияләр ала.

— Соң, шулай булгач?

— Ә син аның ирсез бала тапканын беләсеңме соң әле?

— Беренче ишетәм. Ну, кыз балада була инде ул. Димәк, кемнедер яраткан, ә тегесе яратмаган — алдаган. Элекке заман түгел бит, яслесе, бакчасы бар.

— Әтисе кем диген.

— Үзе беләдер инде.

Кәшфи авыр сулап куйды.

— Икенче кызның кияве. Җизнәсе. Белдеңме?

Ахияр сызгырып куйды.

— Ой-йой-йой... Ә тегеләр ничек яши соң?

— Ничек яшәсен? Ике бертуган — сөйләшмиләр, йөрешмиләр. Берсе кайтканда икенчесе кайтмый хәзер.

— Юк, кызыңны ачуланма. Яраткандыр. Ярату берни белән дә исәпләшми. Җизнәсеме, кодасымы.

— Ә шулай да, мин аны да унике бөтен уннан биш процент белән чигерәм. Аның өчен чөнки... безне кан-яшь елатты ул.

— Я, синең аннары да байтак кала әле.

— Юк шул, мин нольгә чыгам.

— Нигә алай?

— Аның өчен чөнки... алты бала очырдым. Тагын икесе очарга тора. Бу җирдә кем кала? Нигә берсе дә иген икми? Нигә барысы да шәһәргә китү ягын карый? Мин аларны һиндстан сыерлары дип атыйм.

Ахияр сигарет кабызды.

— Анысы ни тагын?

— Ә миңа миңа Мәскәүдә гостиницада кунганда бер иптәш сөйләде. Ул селекционер, Һиндстанда эшләп кайткан. Сыерны савалар, савалар да, ди, картаеп сөте беткәч, чыгарып җибәрәләр, ди. Дүрт ягың кыйбла. Аның өчен чөнки... сыер итен ашау тыела икән, диннәре буенча. Шуннан сыер нишли? Юл буеннан утлап, акрын гына алга бара. Ни өчен юл буеннан? Аның өчен чөнки... урманда юлбарыстыр, арысландыр бар. Ә бу, знай, атлый бирә юл буйлап. Олы юлга чыга. Чүтки, анда кеше, машина. Кешегә иярәнелгән. Шуларга юанып бара да бара бу. Олы юл кая алып килә? Зур бер шәһәргә. И һәм дә сыер шунда яшәп кала. Чирәмсез, ризыксыз җиргә килеп яши.

Ахияр көлде.

— Минекеләр дә шулай инде,— диде ул.— Әнә кабат китеп, утырып калдылар. Тик малай гына кайтып йөри. Анысы механик булып колхозга төпләнәм дип хыяллана. Но мин әлегә ышанмыйм.

— Минә, минә! Синең икеме! Димәк, 50 процент уңай нәтиҗә бирәсең син! Ә мин — нольдә. Аның өчен чөнки...

Кәшфи сүзен тәмамлый алмады. Зәңгәр күк түбәсеннән йөрәкне селкетеп тарихның, җирнең үзе кебек борынгы, серле тын аваз ишетелде. Ахияр да, Кәшфи дә күккә текәлделәр. Өч җирдән өч өчпочмак булып, көньякка таба торналар оча иде.

Кинәт күңел тулып китте. Ахиярның да, Кәшфинең дә тамак төпләренә нидер утыргандай итте. Күзләргә беренче язгы җил кагылды, һәм күзләр дымланды. Торналар нәкъ Гәр Хутор өстеннән очалар иде. Ачык күккә озак карап торудан күзләр арыды, талчыкты. Хәрәкәт гел бер төрле, тавыш бик тоныкиде. Әмма шул вакыт кырыйдагы сызыкның берсе кителде һәм соры бер нокта сызыктан аерылды. Мондый хәлне, гомумән, үз гомерләрендә бик күп торналар, кыр казлары каршы алган, озатып җибәргән Кәшфинең дә, Ахиярның да беренче күрүе иде. Соры нокта зурайды, аңа канатлар, муен чыкты, ул әйләнә ясый-ясый Гәр Хутор өстенә төшә башлады. Менә бервакыт аның озын нәзек аяклары, тимер кашык кебек башы аермачык күренде, бөтен авыл өстен дерелдәтеп моңлы аваз ишетелде:

— Тор-тор-тор-рыл-лыйк! Тор-рыл-лыйк!

Торна зурайды, зурайды, менә ул авыл читендәге яшен сугудан башы көйгән каен турысында әйләнә башлады. Ә иптәшләре, берни дә булмагандай, көньякка таба юлны дәвам иттеләр, бу торна исә һаман шул урында әйләнде, ул шулкадәр түбән төште, урыннарыннан сикереп торган Кәшфи белән Ахиярга аның һава ярып канат кагуы да ишетелде, хәзер инде аның тавышы да, ничектер кызганыч һәм рәнҗүле булып яңгырады.

— Тор-рыл-лыйк! Торр-рыл-лыйк!

Урам тулы кеше икән, бары да шул якка карыйлар. Көйгән башлы каен турысында байтак әйләнгәч, торна күккә салмак кына күтәрелде һәм бик биеккә менгәч, авыл өстеннән бер әйләнә сызды да, инде күздән югалып килгән өчпочмаклы сызыкка таба юл алды.

— Ата торна бу,— диде Кәшфи, тамагын калтыратып.— Ата торна. Тавышыннан таныйм. Менә нинди тугрылык, агайне. Узган ел нәкъ шушы урында бер торна төшеп үлгән иде. Димәк, ул аның тормыш иптәше булган. Менә бит ничек. Нәкъ шул турыда төшеп үлде ул.

Кәшфи боларны читкә карап әйтте. Чөнки, үз гомерендә беренче тапкыр ялган сөйли иде.

— Я, ярар,— диде Ахияр, сүзне читкә борып.— Әйдә, утыр але машинага. Алдагы дүшәмбедә — нәкъ өч көннән — Сельхозтехникадан киләләр безгә. Әйдә, синең хуҗалыкны карыйк әле...

Алар машина янына килгәндә, күк түбәсеннән ялгыз торна тавышы ишетелеп калды.

Зәңгәр күк җиле ашыга-ашыга Гәр Хутор өстенә язны куа иде.

## X

Саран хатынның чәе кебек сыек болытлар һаман читкә агылдылар. Җиргә, басуга, урманга, болынга бөртек яңгыр төшмәде, машина эзләрендә туфрак тирәнәйде дә тирәнәйде. Кайнар һава күзәнәкләрне киптерде, машина узган саен тузан болыты күтәрелде, ул болыт урамга тартылып үскән тупыл, шомырт яфракларына кунды. Кош-корт кауырыйларына сырышты, форточка җәтмәсе аша өйгә керде, өсте ачык калган ризыкка төшеп, ашаганда тешне чыкырдатты.

Ишелеп уңган игенне җыеп алу өчен менә диган шартлар иде, әмма кешеләрнең холкы бозылды. Моны беренче чиратта Ахияр сизде, үзе үк әллә нишә тапкыр, юкка гына кызып китеп, комбайнерларга җикеренеп ташлады, кырда үзенә урын тапмады.

Быел колхозда эшләү өчен кеше көче җитмәгәнлеге сизелде. Ахияр, үз гомерендә беренче мәртәбә, район оешмаларына, ялынычын белдерде: мөмкин булса, студентлар җибәрегез, диде. Аңа, август аенда студентлар булмас, фәнни-тикшеренү институты хезмәткәрләрен кай-

тарабыз, дип җавап бирделәр. Әмма, председатель алардан баш тартты: тар чалбар киеп, керфек, ирен буяп көшел өстендә көрәк тотып эшләгән яшь хатыннарны колхоз узган елда бер күргән иде. Бер ай эшләп, расчет ясап китеп барганда, буяулы керфекләрнең күбесе бер сум егерме тиен, ике сум ун тиен хезмәт хакы алды. Берничәсе исә, гомумән, колхозга әҗәтле булды: эшләгәне ашаганын каплый алмады. Ахияр вакланып тормады: «әйдә, ярар, чурт с ним» дигән, барысын да гафу итә торган, киң күңелле бөек бер закончалыкка буйсынды да вакланып тормады ул. Колхоз экономикасының язмышын моңа кадәр озын керфекле, бизәнгән матур хатыннар хәл иткәне юк иде әле.

Шулай да колхоздан ник китә бу халык? Ахияр шул сорауга җавап эзли, баш вата. Җитмәсә, нәкъ шул сорауга җавап эзләп, башкаладан килгән корреспондент хатынны районнан аның янына җибәргәннәр. Чалбар кигән, иңенә аппарат аскан, кара күзлек пыялалары чынаяк тәлинкәсе зурлыгында. Сигарет тартучы бу хатын Ахиярдан шул сорауга җавап көтте.

Алар күл буенда, балыкчылар шалашы янында балык шулпасы пешкәнне көтеп сөйләшеп утырдылар. Әллә язып барды теге хатын, әллә тыңлап кына утырды — Ахияр аңа игътибар итмәде. Ут янында тыныч кына әңгәмә барды.

— Менә Кәшфине алыйк. Сугышка бергә чыгып киттек. Гомере буе техника янында булды. Бөтен район буенча беренче урында. Аннан республика буенча беренче урынга чыкты. Өч ордены бар: Ленин ордены, Хезмәт Кызыл байрагы, Почет билгесе. Күпме-күпме медале, грамотасы бар. Сигез бала үстерде. Ник кенә берсе авылда калсын. Ни бары берсе авылда, әмма ул да авыл хуҗалыгы буенча түгел, укытучы. Инде олыгаеп килә.

— Ә сезнең үз балаларыгыз?

— Минеке катлаулы. Без хатын белән аерым яшибез. Хатын авылны яратмады. Сәбәбе дә бар. Балалар шәһәрдә үстеләр. Хәер, мин үзем дә аларны авылга иялэндерергә алай көч куймадым. Шуңа да карамастан, олы улым сельхозда укый. Механизатор-инженер булырга җыена. Менә ничә ел инде җәен миндә тора, колхозда эшли. Үзенә кышлык акча туплый. Миннән бер тиен алмый. Үҗәт. Үз көнемне үзем күрәм, ди. Быел менә автобус йөртә. Терлекчеләрне. Менә аның төпләнүе бар.

Кара күзлекле хатын сигарет кабызды.

— Ә шулай да, яшьләрнең авылдан китүенә төп сәбәп нәрсә?

— Колхоздан ник китәләр? Клуб ачу, аңа пианино алу, танцы оештыру белән генә яшьләрне тотып булмый. Болар — тормышның бизәкләре генә. Яшьләр китүнең сәбәпләре тирәндәрәк. Иң беренчесе — колхозчыны нәкъ шәһәрдәге кебек ике көн ял итә торган итеп көйләргә кирәк. Хәзергә бу мөмкин түгел. Аннан соң ел буена даими эш кирәк. Комбайнер, көтүче кебекләр кышка эшсез калалар. Димәк, кыр эшләре бетүгә нниндидер цехлар ачарга, ниндидер производство көйләп җибәрергә кирәк. Боларын инде күп өлкәләрдә хәл итеп килэләр.

— Әйе, шулай, ләкин алардан да яшьләр китә. Бәлки, яшьләргә, армиядән кайткан, өйләнгәннәренә туп-туры квартир ачкычы тоттырыргадыр?

— Алай эшләп карадык. Кадерен белмиләр. Мин үзем яшьләрнең эш сорап килгәннәренә өмет белән карыйм. Башта ук квартир сорап килгәннәре, гадәттә, төпләнмиләр, бераздан китеп баралар. Казганып, кыенлык белән урнашкан, көйләнгән гаилә төплерәк була. Квартир биргәләп карадык — китәсе кеше барыбер китә.

— Димәк, тагын нидер бар?

— Әйе, бер галим дә әйтмәгән сәбәпләре бар. Бу турыда әле бер журналистның да язганы юк.

Кара күзлек җанланып китте, магнитофонын көйләде, микрофонны алгарак сузды.

— Бу — эфир өчен түгел. Минем өчен генә,— диде.

— Ярый, миңа барыбер. Авылны кешесе-ние белән саклап калу өчен иң әһәмиятле чара — аны яхшы асфальт юл белән шәһәргә тоташтыру. Билләһи, дип әйтәм, авылга асфальт юл керсә, халык китми генә түгел, шәһәр халкы да авылга кайтып йорт сала башлаячак.

— Бу — бик кызык.

— Аннан: һәр авылда кафе, бар яисә ресторан булдырырга кирәк. Әйтик, эссе көнне шәһәр егете паркка кереп агач күләгәсендә пиво эчеп утыра ала. Су керә, пляжда ята. Ә безнекеләр? Кайда, ничек ял итә алалар? Шәһәрдә эш авыррак, әмма, ялы — ял төсле. Авылда, ихтимал эш җиңелрәк, ә ял — ял түгел. Димәк, кешенең яшәү урынын эш кенә билгеләми, бәлки эштән калган вакытын уздыру сыйфаты да билгели.

— Бу — бик, бик кызык.

— Тагын бер мәсьәлә. Авылдан яшьләр ник китә? Без бит инде шул турыда сөйләшәбез. Ә сәбәпләр күп. Менә иң гади мәсьәлә — кышлыкка утын әзерләү мәсьәләсен генә алыйк. Хәзер колхозчы мул итеп, бай итеп яшәргә ярата. Һәрберсендә культура сарае кадәр алты почмаклы йорт. Мунча. Ике-өч бүлмәле. Элек крестьянга кыш чыгар өчен бишалты кубометр утын җитә иде, хәзер кимендә утыз куб утын кирәк. Аны урманда әзерлисе, аннан ташыйсы, кисәсе, ярасы һәм әрдәнәгә өясе бар. Бик таза гаилә өчен бу — кимендә бер айлык авыр эш. Әмма утыз куб утынны сиңа урманнан болай гына бирмиләр әле: башта син урманда ботак яндыру, агач утырту, сирәкләү кебек эштә йөрергә тиешсең. Анысына бер ай. Шулай ук авыр эш. Кул, күкрәк эше.

— Болар минем өчен өр-яңа мәсьәләләр.

— Менә яшьләр өчен дә шулай ул. Яшь егет күреп үсә: утын-печән ди-ди, моның әти-әнисе дөньяны, майны-июньне күрмиләр, кеше күрмиләр, матурлык күрмиләр. Яшь егет исә мондый конвейерга риза түгел. Һәм ул әнә шул мәсьәләләр хәл ителгән җиргә китә. Китте — йортын батарея җылыта, аның өчен түләү — ноль-ноль фәлән тиен... Бюджетта сизелми дә.

— Кызык, бик кызык бу...

— Тагын. Ике егет үсә, күршеләр, дуслар. Икесе дә унынчыны тәмамлыйлар. Армиядә булып кайталар. Кайткач болай: берсенең әтиәнисе пенсионер, йортка кеше кирәк — малайны СПТУга димлиләр, яки колхозда шофер итеп калдыралар. Икенчесенең әти-әни таза, йортта әлегә бер күч егет-кыз бар — анысы шәһәргә китә, шулай ук шофер булып урнаша. Менә берничә айдан болар очрашалар: авылдагы егет майлы комбинезон кигән, тузанга баткан; я ул кирза итек кия дә урам уртасындагы колеяга кереп утырып буксовать иткән машинасының көпчәкләренә чылбыр урап иза чигә. Шәһәрдәге иптәше исә ак күлмәгенең җиңен сызганган, модалы сәгать таккан, ял көне итеп болынга балыкка төшеп бара. Тунеядецмы ул? Юк, менә дигән эшлекле егет, ул бүген просто ял итә. Ә тегеңә мондый ял эләкмәячәк. Ял алса да, ул утын-печән әзерләп җәфаланачак. Шуннан инде бу егет тә уйлап куя: нигә әле болай җыкланырга? Икенче көнне ул минем янга килә:

— Ахияр абый, колхоздан китәм, паспорт алырга справка биргез,— ди. Һәм мин инде шул вакытта көчсез, коралсыз...

— Менә бит, без болар турында бөтенләй уйламыйбыз да...

— Әле шунысы да бар: шәһәрдәге теге егет, бәлки әле вагонда, баракта, тулай торакта яшидер. Әмма, авыл яшьләре алдында ул «өч бүлмәле квартирда торам» дип кенә сиптерә. Анда, ди, газга дүрт ти-

ен түлисең, әзер мунчага керсәң — уналты тиен. Чабынып чыгасың — кружка белән пиво. Анадан яңадан тугандай буласың инде...

— Менә ничек...

— Әнары. Һәр колхозның үзендә больницасы, сельпосы, ательесы, телеграфы, аптекасы, пекарнясы, төрле-төрле парикмахерская, салоннары булырга тиеш. Әнә шунда күпме-күпме кызлар — урта, югары белемле кызлар эшли ала. Ә кызлар күп булган җирдә егетләр кала. Баланс ясала. Калган егетләргә шулай ук мастерскойлар, фотоателье, цехлар, кечке мәктәпләр, консультпунктлар кирәк. Без исә киләчәкне уйлап бетермибез: без быел югары уңыш, мул иген, мул ит, күп сөт алу турында уйлыйбыз да, перспективаны онытабыз. ...Менә сугыштан соңгы елларны гына алыйк. Ни белән шөгыльләндек соң? Авылдан эшче көчләрен читкә озату белән мәшгуль булдык. Алар китте, чөнки перспектива күрмиләр иде. Алар шәһәр читләренә барып, йортлар салып урнаштылар. Анда да авылча итеп яшәргә — бәрәңге бакчасы тотарга, сыер асрарга тырыштылар. Йорт салырга урын булмагач, алар законның үзен эшкә җиктеләр. Участковый милиционер кичтән уза урам башыннан — чүплек, иске чиләк, ләгән ташлаган урын, әрекмән баскан. Иртәгесен шуннан уза — үз күзенә үзе ышанмый — чүплек урынында агач йорт, калай моржаның торбасыннан форточка аркылы урамга төтен чыга, хуҗа хатын мич янында бала имезеп утыра. Закон бар: морҗасыннан төтен чыккан йорттан балалы хатынны куып җибәрә алмыйсың. Ә мужик кулында эш уйный, әнә теге чүплекне койма белән әйләндереп йөри, абзар сыман бер урын ясаган, анда сыеры күшәп тора. Менә шулай итеп колхозлар бушый торды, ә шәһәр тирәсендә «Минутка», «Нахаловка» дигән үзешчән поселоклар үсеп чыкты.

— Ләкин бит заводка, фабрикага да кеше кирәк иде...

— Юк шул. Әлеге мужикларның күбесе заводка кермәде. Ул моңа, беренчедән, мораль әзер түгел иде, икенчедән, аның квалификациясе юк иде, өченчедән, аңа үзенең йортын салып бетерергә, хуҗалыкны торгызырга кирәк иде. Хәзер ул инде көн саен түләүсез эшкә әйтеп йөри торган бригадирдан азат, финагенттан азат, агентларны ул хәзер төшендә дә күрми.

— Ә нәрсә хисабына яши соң ул эшләмичә?

— Эшлимәчә? Шаярмагыз! Ул елларда колхоздан шәһәргә иң отборный эшчеләр китте. Андыйларны эзләп табасы бар әле бүген! Алар шундук эшкә урнаштылар. Ләкин заводка түгел, ә иркенрәк эшкә. Әйтик, төзелешкә (эшкә чыкмый калып, үз хуҗалыгыңны карап алырга була, атна уртасында), алар бер тәүлек дежурда торып өч тәүлек ял итә торган эш эзләделәр һәм таптылар: вахтер, каравылчы, истопник. Балта тота белә — ЖЭКка урнаша. Хатынын да шундыйрак эшкә кертә: буфетта, кибеттә, ашханәдә җыештыручы. Өенә дә кайтып йөри, ашау-эчүгә дә якын. Авылда ипи юк, ә монда ашханәдән кайткан калдык ипи кисәге белән йөзләгән баш үрдәк, тавык асрый, сыер тота ул.

— Димәк, базарга ит чыгара, бу инде начар түгел...

— Начар түгел иде. Әгәр колхозның менә дигән таза куллардан бушап калганын исәпкә алмасаң. Түгел иде... Ләкин, шәһәр тирәләрендәге дүрт аяклы терлекләрне бетерттеләр.

— Әйе, шундый бер хата булды шул.

— Шундый хата. Бүген генә түгел, тагын ун-егерме еллар төзәтеп бетерә алмаслык.

Корреспондент хатын авыр сулады.

— Хәзер боларны кире кайтарып була бит инде, иптәш Гарәфиев.

— Юк, бик күбесен булмый.

— Ни өчен?

— Аның өчен чөнки, дип аңлата әнә безнең алдынгы механизатор

Габделбарыев,— булмый. Ник булмый? Чөнки, сыер асрап, сарык асрап үз хуҗалыгында хезмәт итә торган буынны без югалттык диярлек. Бигрәк тә яшьләр терлек асраудан бизеп бара. Хәзер аларны моңа ияләндерү бик кыен. Чөнки ул — яңа буын. Ул буынга сыер кирәк түгел, аңа кибеттәге шешәле кефир, сөт, банкалы каймак кирәк. Каян килә ул — монысында эше юк аның. Ул буынга сарык кирәк түгел, әмма мотоцикл утыргычына тегәргә сарык тиресе, өстенә кияргә сарык тиресеннән тун кирәк. Боларның каян килгәне аны бөтенләй кызыксындырмый.

— Сез политэкономия буенча белгечкә ошыйсыз.

— Мин генә түгел. Колхоз председателе булып эшләгән бик күпләр шулай уйлый.

— Шәһәр тирәләрендәге бистәләрнең, сез әйткәнчә, «Нахаловка»ларның икенче буыны нишли соң?

— Проблемалар анда да житәрлек. Мин моны беләм, чөнки безнең колхоздан кырык жиде — илле дүртенче елларда киткән кешеләрнең бик күбесе шундый поселокларда. Картлар — беренче пополнение — хәзер пенсиядә. Беренче тыгын йортларын сүтеп, алар соңыннан кирпеч сарайлар салдылар. Мунчалар, душлар, теплицалар булдырдылар. Әмма байлыкка омтылып, теге елларда без күргәнне балалар күрмәсен дип, бер нәрсәне искә алмадылар.

Корреспондент хатын микрофонын Ахиярга якынрак китерде.

— Беренчедән, шәһәр шартларына килеп эләккән бала-чагага эш калмады. Уйлап карагыз: сыер-сарык, дуңгыз асрау бетте. Печән җыясы юк, көтүгә чыгасы, көтү куасы, көтү каршы аласы юк. Кышка печән хәзерләү дигән зур хезмәттән алар читтә. Ул балалар иген, җир, урман, болын, ферма эшен күрмичә үстеләр. Әтиләр тормышны көйләп җибәргәч, «без күргәнне болар күрмәсен», дип аларга мотоцикл, транзистор, магнитофон, японская куртка, океан артыннан килгән джинсы чалбар алып бирделәр. Инде нишләргә? Поселокларда культура сарайлары, стадионнар юк, яшьләрнең исә вакыт күп. Яшьлек энергиясенә «выход» кирәк. Әнә ул «выход» — поселокларда яшьләр арасына хулиганлык үтеп керә. Менә уйлап карагыз: илленче еллар башында без шәһәр тирәсе поселокларына менә дигән эшче кеше бирдек. Менә дигән әнә шул качественный материал, урыныннан күчереп утырткач, нинди җимеш бирде?

— Сез артык гомумиләштерәсез...

— Мин киләчәктә шәһәрне кем туйдырыр дип борчылам. Һәм мин шул борчуыма сезнең дә — журналистлар, язучылар, галимнәрнең дә катнашуын көтәм. Югыйсә, без иләнгән: партия барысын да күрә, барысын да хәл итә. Берәр уңышка ирешсәк, без ул уңышта үз өлешебезне күрергә ашыгабыз. Ә инде авыр мәсьәләгә килеп терәлсәк, партия хәл итәр, дибез. Ләкин бит партия ул — сез, мин, Габделбарыев, безнең сыер савучыбыз Катерина, безнең райком секретаре Байгильдеевләрдән тора. Минемчә, бу мәсьәләдә тынычланып яту — киләчәк буыннар турында кайгыртмау дигән сүз. Менә мин төннәр буе авыл урамындагы йортларны санап ятам: әһә, бу йорт бер-ике елдан бетә. Әһә, бу йортның гомере — күп булса ун ел. Чөнки малай чыгып китте дә шәһәргә урнашты, йортта пенсионер әти-әни генә калды. Монда өченче буын көтелми. Бетәсе хуҗалык нинди? Өченче буын көтелмәгән хуҗалык...

Корреспондент, блокнотын ачып, фломастер белән зур итеп язып куйды: «Өченче буын»...

...Алар «Газик»ка утырып авылга таба кайтканда каршыларына автобус очрады. Ахияр еракган ук таныды: улы Рамил терлекчеләрне кичке савуга алып бара иде.

Әтисе белән очрашуга шатланыпмы, әллә автобус эчендәге кызлар

алдында якланыпмы, Рамил тизлекне арттырып каршыга килде дә, бик кинәт борып, бодай басуына керде һәм егетләрчә кул изәп этисен уздырды. Ике машина да тузан болыты эчендә калды. Әмма этисе тормозын чыкырдатып машинасын туктатты да автобус янына килде. Ахиярның чырае кырыс иде. Тузан болыты томалып читкәрәк акты.

— Ну-ка, чык әле,— диде этисе Рамилгә.— Чык әле.— Корреспондент та, автобус эчендәге кызлар да әсәрештеләр. Ахияр аларның берсенә дә туры карамады.

— Менә хәзер үз кулың белән шул бодайны утыртып, төзәтеп чык,— диде ул. Үзе автобус ишегенә сөялеп калды.

Малай этисенең шаярмаганын тиз аңлады. Һәм берсүзсез эшкә тотынды. Сытылып җиргә сеңгән бодайны торгызу мөмкин түгел иде, әмма ярты сәгать буена Рамил, тезләнеп, берәмтекләп башак төзәтеп йөрде. Баштарак аңа ярдәмгә автобус эчендәге кызлар чыкмакчы булганнар иде, әмма автобус ишегенә сөялгән Ахиярның киң аркасын күргәч, тынып калдылар. Корреспондент хатын да дәшмәде. Рамил исә, мышкылдый-мышкылдый бодай торгызды.

Сүзсез генә аерылышып китеп бардылар.

Шактый юл үткәч, корреспондент хатын әйтә куйды:

— Сез гел шулаймы?

Ахияр елмайды.

— Юк, нигә алай булсын. Әле кичә клубка барганда үземнең ботинкамны киерттем. Пиджагымны бирдем. Кызыкканын белеп йөри идем. Бүген дә шулай барачак ул.

— Ә монда?

— Ә монда — сүз минем пиджак турында бармый. Хәтта, ул таптаткан бер-ике кило икмәк турында да бармый. Монда сүз — икмәккә мөнәсәбәт турында бара. Игенне таптаткан кеше каз бәбкәсен дә сытып уза ала. Ә каз бәбкәсен сыткан шофер кеше дә таптата ала. Мәсьәлә монда зуррак.

— Ә шулай да, улыгыз сезнең авторитет белән бик исәпләшә икән. Без сүз дә әйтмәде бит.

— Анысы үземә дә ошады. Югыйсә, бик гонорлы егет ул. Авыл гармунчысы кебек. Аннан соң шунысы да бар: шәхес буласың килсә, армия хезмәтен уз, дидем мин аңа. Унынчыны бетергәч, әнисен елата-елата армиягә китте. Өч ел хезмәт итеп кайтты. Уку йортын үзе сайлады. Һәрхәлдә, дөнья күрде. Ә егет кеше дөнья күрергә тиеш ул...

Идарә янына алар килеп туктаганда инде көн кичкә авышкан, трактор, автомашина-фәлән шул тирәгә җыелган. Мотоцикллар, җиңел машиналарга утырган агроном, бригадир, ветеринар кебек җаваплы эшчеләр идарәгә таба ашыгалар иде. Әле генә районнан запчастьлар төяп кайткан йөк машинасы янында Ахияр, ят, чит тавыш ишетте: кемдер киеменнән шап-шоп тузан кага һәм сөйләнә иде.

— Мин нишләп анда ятыйм? Мин — демократик илнең ирекле гражданины. Минем моңа тулы хокукым бар. Безнең ил нәрсә өчен кан койды? Егерме миллион корбан биреп. Күпме, күпме милитаристларга, бактериологистларга, путчистларга, экстремистларга каршы көрәш бара хәзер. И мин шул шартларда чит җирләрдә ятыйммы? Халыкара хәлне үзегез беләсез. Мин — бүген монда, иртәгә — тегендә...

Ахияр таныды — Тавис кайткан.

Бөтен иген кыры өстендә тузан болыты йөргән, тән күзәнәкләренә тузан кергән, чәчкән арыш тишелә алмыйча кипкән, колхозда өч йөз гектар бәрәңге көеп утырган бер көнне — җаныңны кая куярга белмәгән бер көнне — колхоз территориясенә Тавис кайтып төшкән.

Ахияр авыр сулап машина ишеген япты. Авыр елмаеп корреспондент хатынга әйтте:

— Әйдәгез, планерканы бергә уздырыйк әле. Анда, кабинеттагы холодильникта «Боржоми» бар минем, әйдәгез.

Ул кашларын җыерып күккә карады.

Күк йөзендә чытлы болыт әсәре юк иде.

## XI

Бу җәй әллә нинди афәтле, мәшәкатьле булды. Сабантуйлар узуга, беркөнне кинәт кенә Кәшфине паралич сукты. Аяк-кул, тел-авыз, күз исән, әмма колаклар дөм томаланган иде. Ахияр килеп җитеп, эшнең нәрсәдә икәненә тиз генә төшенеп, Кәшфине туп-туры шәһәргә алып китте. Һәм республика больницасында калдырып та кайтты.

Бу вакыйга алдыннан гына Кәшфи көтелмәгән, өстәмә бер борчу кичергән иде.

Майның унбише. Авыл көтүе әле чыкмаган, мәшәкатьле, колхоз кырында бик киеренке эш барган бер көндә, Кәшфинең арып-талып мастерскойдан кайтып, диванга ятып гәзит-журнал укырга исәпләгән бер көнендә, елый-елый шешенеп беткән хатыны Асия капка төбендә каршы алды.

— Кәшфи җаным, бакча башында арканлаган җирдән сыер югалды,— диде.— Эзләмәгән җир калмады. Җир йоткандай булды.

Сыер менә-менә бозауларга тиеш иде.

Кәшфи телсез калды.

— Кәшфи җаным... Бүреләр йөри, диләр...

Кәшфи мотоциклын кабызды. Бөтен басуны әйләнеп, елга, чокыр буйларын, урман буйларын карап кайтканда төн уртасы җиткән иде. Арып-талып йокыга ятты. Әмма йокы кермәде. Сыер өчен кайгырудан да түгел, болай, йокы алмады. Кәшфинең саклык кассасында сыерлык кына акчасы бар — ул яктан кайгырасы түгел. Әмма моңарчы Гәр Хутор авылында беркайчан да, беркемнең дә сыеры югалганы юк иде әле. Кәшфи бу хәлнең гадәттән тыш булуына һәм, башка бик күп гадәттән тыш хәлләр кебек, нәкъ болар йортына кагылышлы булуына борчылды. Ул кояш чыкканчы ук торды, тагын мотоциклын кабызды. Иртәнге урманга керде. Урман кош авазларына янгырап тора, салкынча май иртәсен һәр кош үзенчә сәламли иде. Менә гаҗәп! Сыеры югалмаса, Кәшфи урманның шул аһәңен ишетмәгән көе дөньядан ук китәсе булган икән. Иртәнге урман аның башын сафландырып җибәрде. Кайсыдыр куак төбеннән «көр-р, көр-р!» килеп урман тавыгы аваз сала, карт юкә башындагы күке дөнья ямьләндереп гомер саный, ниндидер кош, көмеш торбалардан гына торган бөтен бер оркестр сыман, эфирны калтыратып музыка яңгырата иде. Шулай йөри торгач, Кәшфи тынычланып китте һәм өйгә борылды.

Тыныч күңел белән эшкә китте. Дөнья матур! Табигать гүзәл! Кәшфине механизаторлар көтеп тора иде, дөньяга ул кирәк! Сыер да булдымы бер кайгы! Дөрес, көне буе мастерскойга килгән-киткән кеше Кәшфидән сорашып торды: кая киткән булыр?

...Ә бер көнне иртүк Кәшфиләрнең капкасын Катерина какты. Олыгайган, пенсиягә чыккан Катеринаның кулында бау, ә бауның теге очында бура кадәр «швец» нәселле савым сыер иде.

— Председатель иң тәмле сөтлесен сайлап алырга кушты, сөтсез утыралар икән дип ишеттем, ди. Идарәнең карары булган икән...

Кәшфи шатланды, каушады, йөгерде, Асия гына бауның очын кулына алмыйча торды.

Кәшфи һаман йөгерде, сөйләнде:

— Аның өчен чөнки... Чөнки болай ул. Алдагы базардан Мари ягыннан сыер алып кайтканчы гына. И һәм дә...

Аны Катерина бүлдерде:

— Юк, идарәнең карары булган: бу сыер сезгә бөтенләйгә,— дип китеп тә барды.

Кәшфиләргә килеп, чәйгә утырмыйча китүчеләрдән Катерина тарихта беренче кеше иде. Катерина инде күздән югалгач кына бу хакта Кәшфи белән Асиянең хәтеренә килде. «Швец» исә алай тәкәллефләнеп тормады, озын кытыршы телен чыгарып, Кәшфинең йонлы беләген шоштырдатып ялап алды.

— Өм-м-м,— дип дәшеп тә куйды.

Кәшфи өтәләнде:

— Асия! Асия! Кая, апара ясап бир әле! Кая, ипи алып чык әле! Риза бу, риза бездә калып торырга. Аның өчен чөнки...

Йортка яңадан шатлык кайтты.

Ә бер айдан, сабантуйлар узгач, кояш чыккан бер иртәне Кәшфинең капкасын егерь Минһаҗ какты.

— Кәшфи абый, анда Торна аланы кырыенда бер кара сыер йөри, янында бозавы да бар, чисти зверьгә әйләнгән, якын да җибәрми,— диде.

— Ә? — диде Кәшфи, чалбар каешын эләктерә-эләктерә.— Ә? Нинди кара сыер? Нинди зверь?

— Мин әйтәм, памаему, сезнең «Дучка» ул. Маңгаенда җондызы да бар. Памаему, шул үзе ул...

— Ә? Нинди «Дучка»? Ә?

Нәкъ шул вакытта Кәшфинең яңак төпләре тартылып китте дә нәрсәдер өзелгәндәй итте. Һәм шул минутта егерь Минһаҗ аның каршында авызын кыймылдатып тора башлады. Кыймылдата, әмма бер аваз да чыгармый...

Егерь Минһаҗ бөтен Гәр Хутор халкын урманга Торна аланына алып кереп китте. Асия җиңги генә халык белән керә алмады: Кәшфи авызын ачып тик тора иде. Кемдер нәрсәгәдер утырып каядыр чапты. Каяндыр, нәрсәгә утырыптыр, фельдшер кыз килде. Каян ишетептер, ни арададыр, Ахияр килеп җитте. Кем әмере беләндер, Кәшфи шәһәргә дә чыгып китте.

Ә кешеләр Торна аланына якынлашып килә иде. Озак та үтмәде, күрделәр: алан куенында, карт юкә астындагы куакларга ышыкланып елтыр кара тиреле сыер басып тора, койрыгын болгап, матур шома тәненнән чебен-черки куа. Юкәнең теге ягындагы бушлыкта арт санын кисәк күтәреп, үгез бозауларча иләмсез-җайсыз хәрәкәтләр ясап, ахмак маңгайлы бер мәхлүк сикергәләп йөри. Ул әле күшәп торган әнисе янына килеп арт сикертеп китеп бара, әле юкә артына чыгып ямьсез бер әйләнә ясый да, кычкырмакчы була, әмма, ни сыерча, ни бозауча тоташ аваз бирә алмый, ә өзек-тәтек кенә:

— Өм-мөрт! Өм-мөрт! — килеп куя иде.

Әнисе исә, шомарган, түгәрәкләнгән һәм, Минһаҗ әйткәнчә, тәмам «зверь»гә әйләнгән иде. Кешеләрне ул якын да китермәде: акырды, боргаланды, күзләрен алартып, кызартып, танау тишекләрен киңәйтеп тибенде, сөзәргә килде. Аңардан күрмәкче ак кашкалы кара елтыр малае да арт санын күтәреп, иләмсез хәрәкәт белән сикерә һәм әнисеннән алда кешеләргә һөҗүм итәргә җыена иде. Чак-чак кына сыер мөгезенә аркан ыргыттылар һәм үҗәт, юеш, киң танавын урман печәненә төрткән килеш «Дучка» Гәр Хуторга таба атлады. Ахмак малаеның исә кешеләрне беренче күрүе иде һәм ул мондый шау-шулы, төрле аваз чыгара һәм ике аякта йөри ала торган хикмәтле туганнарын

күрүгә чиксез шатланып, төркемне уза-уза, арт санын сикертеп әле алга, әле артка чаба иде...

Кәшфи бер атнадан кайтты: үзе елмая, үзе дөм чукрак иде. Кайтты, урамны җыеп речь сөйләде:

— Аның өчен чөнки... әлегә иртә, диделәр. Өч айсыз да операция ясамыйлар. И һәм дә...

Һәр чукрак кешегә хас булганча, Кәшфи гадәттән тыш кычкырып, шәрран ярып сөйли иде.

— Ну да ләкин инде мин, эшкә бармыйча ятучы түгел,— диде Кәшфи.— Менә уйлап яттым: нәкъ бер атна йөрдем мин тегендә кабинеттан кабинетка. Колхозга күпмегә төште ул? Беләсезме? Миннән башка ничекләр итеп яши ала ул колхоз? Мастерскойда кем ярдәм күрсәтә ала механизаторга? Белдегезме шуны? Аның өчен чөнки... мин бу колхозның иң галауный врачы. Машиналарга көненә бер обход ясамасам, мин йоклый да алмыйм. Өч айдан операциягә генә барып кайтам да...

Тик аңа операция кирәк булмады.

Август аенда илгә афәт килде: ай буена яңгыр төшмәде, дөньяны эссе тузан басты, күк йөзе агарды, агач яфраклары көеп-саргаеп коелды, бәрәңге сабаклары тузаннан каралып, куырылып калды. Чәчкән арыш тишелмәде, болыннарда, урман аланнарында чикерткә тавышы тынды, кош-корт урман күләгәсенә кереп юк булды. Кешеләр үз эчләренә бикләнделәр — урылган, сугылган икмәкнең шатлыгы да, ничектер, тузан катыш кипкән шатлык булып тоелды.

Нәкъ шул көннәрнең берсендә идарә ягыннан мастерскойга таба бер бензовоз кузгалды. Кәшфи, кайтырга җыенып, мотоциклын җайлап маташа иде. Тузан болытын ишеп килгән бензовоз туктагач та әле күренми торды. Эре коры тузан мастерскойның шифер түбәсенә сыланып ятты. Шул вакытта гына Кәшфи күреп алды: бензовоз ишеген чыкырдатып ачып улы Тавис килеп чыкты һәм, кулындагы күн сумкасын мастерской янындагы иске машина рамына куеп, этисе белән күреште. Бензовоз китеп барды. Баласы бит, Кәшфи дә шатланды. Тависның нәрсә әйткәнен ишетмәгән көе генә сөйләнде:

— Бик корыга китте, улым. Колхозчының бер дә кәефе юк. Бөтен дөнья яна. Бөтенләйгә кайттыңмы? — Ул мотоциклын кабызды.— Әйдә, бик әйбәт булган. Тотынып утыр. Кая, сумкаңны минем алга куйыйк.

Һәм Кәшфи күн сумканы кулына алып мотоциклына атланды. Газ биреп кузгалып китим дигәндә генә, күлмәк сәдәфләрен ычкындырып күкрәгеи җилләтеп торган улына күз салды.— Әйдә, улым, тотынып утыр,— диде ул, әмма күзенә ниндидер чит нәрсә комачаулый, нәрсәдер бу табигатьнең бөтенлеген бозып торган сыман иде. Кинәт Кәшфинең күзләре Тавис күкрәгендәге бер сурәткә төште. Анда куе зәңгәр татуировка белән ялангач кыз рәсеме чигелгән һәм аска «Камера 19 август» дип язылган иде.

— Ә?! — дип кычкырды Кәшфи, куркудан газ биреп. Мотоцикл дөнья җимереп дерелди иде.— Ә?.. Ә?.. Камера?.. Өтермә?..

Нәкъ шул вакыт нәрсәдер Кәшфинең баш артына суккандай булды. Тавис бер читтә тора иде. Кәшфинең башы селкенеп китте һәм... кинәт диңгез шавыдай мәһабәт шау аның колагына килеп керде. Ул ашыгып мотоциклын сүндерде. Дөнья һаман шаулый иде. Менә күптәнге тавыш — Тавис тавышы килеп керде:

— Мин — демократик илнең иркле гражданины. Минем моңа тулы хокукым бар. Безнең ил нәрсә өчен кан койды? Егерме миллион корбан биреп. Күпме-күпме милитаристларга демаркационный линияләр

уздырып, аларның девальвацияләр, инфляцияләр белән мораль яктан череп таркалган стройларын...

Кәшфи авыр сулады да мотоциклын кабызды. Юл буе аның колагы шаулап кайтты.

Шул көннән соң Тавис этисе белән мастерскойга эшкә йөри башлады, ата-ана да тынычланып калды. Тависның чит җир дигәне моннан егерме биш чакрымнар гына ераклыкта булган Шәмәрдән заготзерносы икән һәм ул анда өйләнеп яши, эшли икән.

— Бер унбиш көн сиңа хуҗалыкта булышам да, китеп барам мин,— диде Тавис этисенә.— Анда мине директор дүрт күз белән көтеп тора. Әле монысына да чак-чак рөхсәт итте. Син, ди, иптәш Габделбариев, ди, озак йөрмә, ди, ату, ди, бөтен производство туктала монда. Ә халыкара хәл катлаулы... Сине, ди, партиягә алып, нәчәльник итик без, ди. Мин әлегә риза булмадым...

Бераздан ачыкланды: Тавис заготзернода балта эшендә икән.

Кәшфинең исә бу көннәрдә мастерскойга килгән бөтен механизаторларга сөйләгәне шул булды:

— Ничек яшисез сез, ә? Бөтен тавыш колакка керә дә тора бит. Менә, ичмасам, мин бер ял итеп алдым. Аның өчен чөнки...

Тавис китәргә әзерләнеп йөргән көннәрдә бер кичне тузанлы һава әллә ничек кенә авыраеп китте. Капка-койма буйларындагы тузанлы баганаларга үрмәли-үрмәли мәчеләр тырнак батырдылар, кичке якта өере-өере белән каргалар кычкырышып йөрде, әрәгә генә этләр өргәләп алды. Кәшфи мастерскойдан кайтуга кое суы белән бит-башын юды да, салкын верандага чыгып, диванга ятты: яралы аягы сызлый иде. Асия җиңги дә балтырларының сызлавына түзә алмыйча, мунчага кереп кычыткан төнәтмәсенә аякларын тыгып утырды. Кичке ашны Тавис кына ашады. Күңелсез генә йокыга яттылар. Әмма йоклый алмадылар.

Төн уртасында Кәшфи йортының зур калай түбәсенә «тып» итеп бер нәрсә төште. Верандада яткан Кәшфи моны бөтен тәне белән сизде: кадерле, газиз яңгыр тамчысы иде ул. Кәшфи урыныннан сикереп торды:

— Син, дим, Асия! Син, дим!

Асия да йокламый икән.

— Син, дим! Ишеттеңме? — Ул арада веранда калаена берьюлы ике авыр тамчы бәрелде. Кәшфи яланаяк килеш буяулы салкын идәндә әтәтерләнеп йөрде.

— Син, дим! Бу бит, бу бит... Арыш уҗымына... Бәрәңгеләргә... Кукурузга... Аның өчен чөнки...

Ул арада тигез шау белән калай түбә гөжли башлады. Кәшфи йөгеренде, утны кабызды, аннан тагын сүндерде, ишекне бер ачты, бер япты.

Тышны инде яңгыр исе баскан иде.

Кәшфи аякларына оекбаш киде, майкачан гына баскычка чыкты, чолан түбәсеннән төшкән яңгыр суын учына алды, иснәп карады. Аннан кулын селекте, түзмәде икенче тапкыр учына су җыйды, анысын ялап ук карады, буяу, калай тәме килеп торган балчыклы су иде.

Шулай йөгереп йөргәндә буыннар сызлавы да онытылды. Ут яндырып олы өйгә керделәр, түр тәрәзәне ачтылар. Өй түрендәге акация куакларын шаулатып яңгыр ява иде.

— Асия! Асия, дим! Мин бүген йокламыйм! Кая, запасың юкмы? Син дим...

Асия җиңги шатлык катыш яратып ачуланды:

— Һи-и, кыяфәтсез, картаеп беткән башың белән...

— Юк, дим, юк, бер генә рюмка.

— Ә гастритың нишләр? Авызыңа алмаганга ничә ел инде?

— Гастрит торып торыр әле. Кая, дим, кая?

Асия җиңги өй астына төшеп, бер шешә алып менде. Балчыкка күмеп саклаган икән. Кәшфи шаккатты: мондый этикетка белән чыгармый башлаганнарына биш-алты ел бар иде инде.

— Ну, малай, үзеңә кара, ашказаныңа ябышса, миңа үпкәләмә,— диде Асия җиңги Кәшфи алдына пешкән өч йомырка, бер телем ипи, тоз куеп.— Тавис кермәсен, уянып.

Кәшфи шкафтан чәй чокыры алып килде, аның төбенә бераз салды. Яңадан тәрәзә янына килеп башын тыкты, яңгыр инде түбә почмагындагы торбадан шаулап ага иде. Кәшфи мех жилетын киеп куйды, төймәләде, аннан тагын чиште.

Асия җиңги диванга утырып карап торды: Кәшфи чынаяк чокырын өстәл уртасына куйды да, әйләнә-туглана йөренде. Эчәргә йөрәге житми иде. Шулай да житез хәрәкәт ясап чокырны әйләндерде, аны тиз генә өстәлгә куеп, үзе ишеккә таба йөгерде, кире борылды һәм күзләрен йомып авызын ачты да, киртә өстендәге этәч кебек, жилетын җәеп кагынды, ачык авызына уч төбе белән алты-җиде хәрәкәт ясап һава куды, аннан өстәл янына килеп бер йомырканы кулына алды, аны өстәлгә бәреп ватты да, шунда калдырып, яңадан ишек янына китте һәм жилет канатларын тагын җилфердәтте. Аннан ул диванга килеп утырды һәм тирән итеп сулыш алды.

— Аның өчен врачлар теге вакытта әйткәннәр иде миңа: эчсәң нибары бер рюмка и һәм дә акны гына, дип.

Зур калай түбә һаман шаулый, өй почмагындагы торба астына куелган кисмәкләр тулып, күбекләнеп ташый иде.

## XII

Кәшфи бүген басуда, кемнедер алыштырганмы, әллә түзә алмый чыкканмы, «Беларусь»ка зур арба таккан да дөбер-шатыр килеп басудан подвалга бәрәңге ташый, Ахияр белән ике тапкыр кара-каршы очрашты инде — дөньяда аннан да бәхетле кеше юк, авыз ерык, әлегә исән калган берничә алгы теше белән рәхәтләнеп елмая, шатлыгыннан каушый, тракторны гадәттән тыш тизлек белән чаптыра, арбасын даңгыр-доңгыр китерә иде.

Шимбә көн иде. Кәшфиләрнең егерме биш сотыйлы бәрәңге бакчасында да эш кайнады. Кәшфинең биш кызы, дүрт кияве кайтты. Кәшфи кияүләрдән уңды: таза, эшчән, тауны-тауга бәреп уйнарлык егетләр. Өчесендә машина, әлеге теге гөнаһлы олы кияүдә генә машина юк. Ләкин ул да зарланмый. Сөйләүләренә караганда, мехкомбинат тулай торагында баласы белән бер бүлмәдә торучы яшь, мут балдызны да онытып бетермәгән, акчалата ярдәм дә күрсәтә һәм, гомумән, үзе дә рәхәт яши, диләр. Бажайлар ыһ та итмичә егерме биш сотыйны әйләндереп ташладылар, сары кояш бакча өстендә уйнады: Кәшфиләр бакчасында бер генә сорт — лорх кына утыртыла. Һәм ул ел саен чәйнек кадәр була, каерып салгач, бакчага якты җиз самоварлар таратып ташлагандай була.

Алты кыз уйный-көлә бәрәңге чүплиләр, Рәсимә — баш командующий урынында, кияүләр аңа барысы да апа дип, сеңелләре исә төрлечә, исеме белән дә, апа дип тә, дәү апа, алма апа дип тә дәшәләр. Рә-

сиңәнең эштән бәхет булды. Сеңелләре генә шактый иркендә үстеләр. Рәсимәгә авыр еллар эләкте, кием-салым да такы-токы булды, ул үскәндә йорт җитештерү мәшәкате ничә ел гомерне алды. Беренче кыз булганлыктан, үзеннән соң килгән бөтен пычтыкны карау мәшәкате аңа эләкте, туганнан бирле печән әзерләү, бәрәңге чүпләү аннан башка эшләнмәде. Олы кыз булгач, әнисе аңа гел кырыс булды, Тависка эләккән җылы сүз Рәсимәгә тәтемәде. Өйдә бала-чага эшләгән бөтен шуклык өчен әнисеннән Рәсимәгә эләгә иде. Рәсимә чит кеше гаебе өчен җавап бирергә шулкадәр күнде, бишенче класста укыгандамы икән, бер вакыт шундый хәл булды.

Көзге кичтә, әтисе эштән кайтканда, капка төбендә елап, туңып беткән Рәсимәне күреп алды. Кызның теше-тешкә бәрелә иде.

— Ни булды, кызым? — дип Кәшфи аны кочаклап алды (балалар арасыннан Кәшфи монысын аеруча ярата иде). — Кем кыйнады, балам?

— Ю-у-ук,— дип үксеп үк җылый башлады кызый,— юк, кыйнамады.

— Нәрсә булды соң?

— Минһаҗ абыйларның сыеры көтүдән кайтма-га-а-а-н...

— Соң, кайтмаса?

— Әни тагын мине үтерә инде-е-е...

Кәшфи майлы киеме белән кочаклап, аны өйгә алып керде.

...Өмәгә мехкомбинатта эшләүче мут сеңел генә кайтмаган. Тавис эшкә катнашмый, ул сумкасын капка янындагы эскәмиягә куйган да, Шәмәрдән ягына узучы машина булмасмы дип, басу белән авыл арасында килеп сарып йөри, ара-тирә бакчага кереп кияүләргә акыл өйрәткәләп чыга. Кияүләрнең икесе югары белемле, начальниклар, алары «Волга» белән генә кайта. Тагын икесе шулар кул астында ук эшләүче махсус урта белемле егетләр.

Тавис болар янында яшькә өлкән, ил-җир күргән кеше буларак сөйли.

— Һи-и,— ди ул, теш арасыннан черт итеп бер төкереп алгач,— дөньяны күрдек инде. Бервакыт җәяүләп барып көнендә Иске Кишетне әйләнеп кайттым (Иске Кишет болардан сигез чакрым ераклыкта, әмма кияүләр аны белми). Белдегезме шуны? Хәзер генә ул яшьләр иркәләнде... Халыкара хәл буенча көн саен тегендә, мин эшләгән җирдә, иртән мине тыңлыйлар. Эшкә тотынганчы. Конвейерлар, стартерлар, грейдерларны кабызганчы. Давай, диләр миңа, син күп беләсең, безгә аңлат. Нейтрон бомбасын эшлиләрме тегендә, океан артында, или юкмы? А как же, мин әйтәм, шыпырт кына эшләп яталар аны. Җир астында эшлиләр. Потомушты, космонавтлар күрә аны Америка өстеннән узганда. Хәзер шундый приборлар бар, мин әйтәм, космонавт 300 километр биеклектән шул бинокле белән карап, клеверга кунган бал кортының аягындагы төкне саный ала, дим. Милитаристларга каршы шулай көрәшмәсәң булмый. Алар нәрсәгә кирәк безгә, җыен девальвация, инфляция, демаркация жуликлары... Әнә безнең сверхзвуковой лайнерлар... Сез дә йөргән буласыз инде аспирантуралар яклап, диссертацияләрдә укып. Кулыгыздан бүтән эш килмәгәч. Чулак Абдул әйтәдерие әнә: эш юктан эш тапкан, ыштаныннан бет баккан, дип.

Тавис нотыгын тәмамлый алмады. Күк түбәсендә бөтен тирә-юньне елатырлык моң ишетелде. Барысы да күккә карадылар: җирдә калган кешеләргә моң төшерә-төшерә өстә торналар китеп бара икән. Бөтен халык — колхоз басуындагысы да, бакчалардагысы да — билләрен турайтты, күккә төбәлделәр. Китеп баручы көзге торналарның кычкыруы язгы торналар тавышына караганда да сагышлырак була. Кинәт кенә җирне сагыш басты. Уен-көлке бетте. Ул арада тигез төркемнән бер

торна аерылды да Гәр Хутор өстендә әйләнеп йөри башлады. Авылда, кырда кешеләр кычкырыштылар.

— Теге хатынсыз калган торна!

— Күрдегезме? Теге торна!

— Кайда, кайсы торна?

— Теге хатынсыз калган торна!

— Әнә, әнә, тагын теге каен янына төшә ул!

«Хатынсыз калган торна» исә кыйгач-кыйгач һава ярып, куәтле үткен канатларын сызгыртып, авыл башына түбән үк төште һәм башы корыган ялгыз каен өстендә кычкыра-кычкыра әйләнеп йөрде. Аның канат җиле басудагы, бакчадагы бөтен кешенең битенә бәрелгәндәй булды. Байтак шулай әйләнгәч, ул рәнҗүле бер аваз салды да, көньякка таба күтәрелеп, бераздан юк та булды.

Төштән соң басуда, бакчаларда уен-көлке ишетелмәде. Тавис та сөйләшүеннән туктады, әтисенең мотоциклын чыгарып, шуны кабызды да, Колан Кырга барып кайтам дип, чыгып китте. Китәр алдыннан, бакчадагы кияүләргә мыскыллы караш ташлап, әнисенә әйтте:

— Бу дисседентларны тәмле ашатам дип, тавык-мазар суя күрмә тагын,— диде.— Белгән аларны. Барысы да марихуанистлар, хиббилар алар. Аларга тавык түгел, алабута күмәче дә ашатмас идем әле мин.

Баҗайлар берни ишетми, уйный-көлә бәрәңге кертәләр иде.

Баҗайлар, кызлар бәрәңгене кертеп бетергәч, ду-чат килеп юындылар, ашадылар-эчтеләр һәм кәрзин, кәстрүл алып урманга гөмбәгә кереп киттеләр. Рәсимә, әнисе белән бергә таба ризыгы пешерү өчен, йортта, мич янында матавыкланып калды.

Кичен эштән арып-талып бәхетле Кәшфи дә кайткач, йортка ямь өстәлде. Баҗайлар хатыннары белән дүрт чират мунча чабынып чыктылар. Теге, үз «Волга»лары белән йөри торганнары, холодильникны ачып, аннан тирләгән кара шешәле сыра, «Волга» багажнигын актарып кипкән балык-фәләннәр тотып ук кереп киттеләр.

Йортта бәхет. Мичтә шулпа өстәгән өчпочмак чыжлый, кияүләр, ыгы-зыгы килеп, рюмкалар тезәләр, телевизор шаулап сөйли иде. Тик Тавис кына кайтып җитмәде. Әти-әнисенең моңа эче пошты, әмма апак майкалы, таза беләк-күкрәкле баҗайлар ашап-эчеп утырганда Тавис юклыгын сизмәделәр.

Кәшфи шыпырт кына урамга чыкты. Авыл авыр эштән соң тынып калган, урман артындагы таш юлдан узган йөк машиналарының гына үкереп үргә менгәне ишетелеп ала иде.

Бераздан арган кияүләр, кызлар, веранда, олы як, кече як, кухня якларга таралып йокыга талдылар.

Тик Кәшфи белән Асия генә, өсләренә җылы киемнәр киеп, капка төбендә төн уздырдылар.

...Иртәгесен аларның капкасын егерь Минһаҗ какты. Кәшфиләр болай да йокламый иде инде.

— Анда,— диде Минһаҗ, туры карамыйча гына,— теге каен төбендәге билчәнлектә синең мотоцикл ята. Торна каены янында, дим. Мин янына бармадым, кешесе дә шунда ята төсле.

...Тавис, бичара, олы юлдан күтәрелгәндә торна каенына таба кисәгрәк борылган икән. Башы белән катканакка туры килгән. Гәүдәсе мотоциклыннан дүрт-биш метр ераклыкта ята. Милиция һәм врачлар килмичә кагылмаска булдылар. Ашыгудан барыбер файда юк иде.

Аның гәүдәсен район больницасына алып киттеләр. Организмында байтак алкоголь табылуы турындагы справканы Кәшфи берәүгә дә күрсәтмәде. Больницадан йөк машинасы кузовында алар кайтып төш-

кәндә бажайлар тирән кабер казып, мул итеп ләхет алып куйганнар иде.

— Нигә ашыктыгыз? — диде Кәшфи караңгы, авыр чырай белән.— Бер көн булса да кунсын иде өйдә. Каберне аны күмәсе көнне генә казыйлар. Аның өчен чөнки...

Әмма бажайларның дүшәмбе иртән эш урыннарында буласы бар иде.

## XIII

Көзге эшләр тәмамлануга Кәшфине яңадан мастерской хуҗасы итеп куйдылар. Кәшфи ат җигеп яңадан колхоз үзәгенә йөри башлады. Асия өйдә ялгыз иде.

Узган ел кыш ул җигеп йөргән җирән яшь айгырны, әллә нәрсәсенә генә үҗәтләнеп, ветфельдшер печеп ташлаган. Баштарак, фельдшерның бу планын белеп, Кәшфи сүз катып караган иде, фельдшер аны үзенең галимлеге белән әйләндереп салды:

— Синең тракторыңа мин катышмыйм бит, ник тыгыласың? — диде.— Үз нәселе белән буталгач, нәрсә буласын беләсеңме? Хайван бит ул, синең белән мин түгел,— диде. Җитмәсә, Кәшфинең йөрәген бозып (ат печүчеләр, гомумән, шәфкатьсез, рәхимсезрәк булалар), болай дип калды:

— Син үз семьяңны гына бел. Әнә бит, ни хикмәт буталып беттеләр. Ул бала үскәч, кемгә нәрсә дип эндәшә инде? Җизнәсе — эти. Анасының апасы — үги әни. Фу! Ат печәргә ярамый, имеш. Әнә син үз өеңне кара.

Кәшфи рәнҗеп аңа борылды да сүзсез кайтып китте. Теге явыз исә, нәкъ Тависны күмгән көнне килгән дә, җирәнне хәл итеп тә куйган.

Кәшфигә борчу өстенә борчу булды бу. Кичен эштән кайта, атны капкасына бәйли дә өенә керә. Асия белеп тора: ат илтергә барганда, Кәшфи көн саен үзенең әлегә «больничный»да яткан җирәненә кайнар ризык алып бара. Я була ул кайнар кысыр аш, я кайнар ипи, я төелгән бәрәңге боламыгы. Арбасына шуны утырта да ат абзарына китә, һәр көнне кич Җирән, хәлсез кешнәп, аны каршы ала. Кәшфи җигеп йөри торган яшь ала бия моны аңламый, җиккәндә — аны, ашатасы булганда — Җирәнне, шуңа күрә ул арбадагы ризык исенә борыны кытыкланып ачу белән пошкыра, Кәшфигә ямьсез итеп карап ала.

Шулай атна-унбиш көн «диетада» утыргач, Җирәннең тавышы көрәйде, тиресе матурлана башлады, гайрәт керде үзенә.

Кәшфи дә бераз терелеп китте, хәсрәте җиңеләйгәндәй хис итте. Ничектер, бөтен күңелен шушы Җирәнгә бәйләде, шул терелсә, хәсрәте таралыр сыман тоелды.

Ә бер көнне ул кулына ипи телемнәре салган сумка тотып, ала бияне җитәкләп, ат абзары эченнән коридор буйлап узганда, Җирәннең башыннан сөйим дип тукталган иде, аптырап калды: Җирән аны бөтенләй күрмәде һәм җир-җимерелгәндәй кешнәп алды, ала бия дә җавап бирде. Җирән арата аркылы башын алга суздзы, өске иренен җыерып, кып-кызыл теш казнасын һәм эре сары тешләрен күрсәтеп, борын тишекләрен ямьсез киңәйтеп катып калды һәм авыр тирән итеп мышнады.

Ала бияне бүлмәсенә кerткәч, тагарагына ипи салырга дип Кәшфи килгәндә дә Җирән шул хәлдә тора иде. Кәшфине ул, ахырысы, күрмәде дә, сизмәде дә.

Кәшфи өенә йөгерде. Шатлыгына чик-чама юк иде.

— Кара әле, Асия,— диде ул кабаланып.— Теге көнне фельдшерны салмыш булган дигәннәр иде. Аның өчен чөнки... Җирән кешнәде

бүген, ала бияне күргәч. Менә шатлык! Вәт сиңа шатлык! Кешнәгәч, терелде инде ул! Ызначит харап итмәгәннәр! Син иртәгә солы боткасы пешер әле, яме? Бер чиләк итеп! Геркулестан, яме! Кирәк булса, тагын алып кайтырмын.

Асия җиңги үзе көлә, үзе җылый иде.

Кыш бертөрле генә, тыныч кына узды. Кышлыкка сыер суйганнар иде, Асия җиңги кыш буе ит турагычы әйләндерде: Кәшфинең тешләре коелып бетте. Кияүләре-кызлары бик кыстап караса да, шәһәргә бармады, теш врачына йөрмәде. Асия җиңги кыш буе ялгыз торды, Кәшфи иртән китә, кич кайта иде: ял көне дигәнне дә онытты, ул мастерстерскойга бармаса кышкы ремонт туктап калачак сыман сөйләште. Асия җиңги берүзе зур-зур ике яклы өйдә йөренде, аптырагач, сандыкларын актарып, аннан Кәшфинең гомер буе алган почет грамоталарын, мактау кәгазьләрен, Авыл хуҗалыгы күргәзмәсеннән алган грамоталарын берәм-берәм стенага кнопка белән беркетте, нарат бүрәнәле стена шулай итеп зур стендка әйләнде дә куйды. Асия җиңги моны эшләгәндә аерым бер тәртип саклады: Кәшфинең иң беренче грамотасы сугышка кадәр үк алынган икән. Кәшфи хатынының бу шөгыленә әйбер әйтмәде, көн саен киңәя, зурая барган бу күргәзмә янына кичләрен үзе дә килеп басып тора һәм узган гомерен искә төшерә иде.

Күңеле бик йомшаган вакытларда ул шкаф өстеннән иске патефон ала, (кияүләре-кызлары күпме генә көлмәсен, Кәшфи моны саклады) сандык төбеннән бик кадерле, йөрәккә бик якын ике-өч пластинка чыгара һәм шуларны уйната. Менә алар — әтисе, әнисе исән вакытта Кәшфинең бик кадерле, бер генә малай булып үскән, тракторга укыган еллары. Менә пластинка уртасындагы кәгазь печать. Ногинский завод. Яшьтән таныш, якын сүз бу. Җырлары ни тора: Галия Кайбицкая җырлый. Мансур Мозаффаров музыкасы, Муса Җәлил сүзләре. «Җиләк җыйганда». Кәшфи кеше исемнәреннән һәрвакыт зур мәгънә эзли: Гәр Хуторда Галия, Мозаффар, Җәлил, Муса кебек исемнәр бөтенләй юк. Кешенең исеме аның киләчәк юлын, гомеренең мәгънәсен билгели, дип уйлый иде Кәшфи. Беренче туган балага Асия үзенең сугышта үлгән абыйсы истәлегенә Хәйрулла куймакчы булган иде. Кәшфи теше-тырнагы белән каршы торды ул вакытта: Хәйрулла исемле кешене пластинкага ничек язасың? Әнә бит сәнгатьне, әдәбиятны нинди исемле кешеләр тудыра. Һәм Кәшфи, үзсүзләнеп, малайга Тавис исеме куштырды ул вакытта. Тавис — ниндидер серлелеккә, әчке мәгънәгә ия. Гәр Хуторда гына түгел, бөтен районында башка мондый исем юк. Бу малай берәр хикмәт чыгарыр, дип горурланып йөргән иде Кәшфи...

Пластинкаларның кәгазе инде тузып, майланып беткән. Ләкин Кәшфи аларны барыбер таный. Менә монысы — «Кәләү Гайшә». Аны Фәйзулла Туишев уйный. Ә монысы — Кәшфинең әтисе яраткан «Бригадир җыры». Әтисе, тәрәзә ачып, урамга гел шуны яңгырата иде:

> Әрләнсен лә дошман,
> Шатлансыннар дуслар...

Ә менә монысын кем җырлый икән? Бу — утыз сигезенче елгы пластинка. Бәрхет тавыш, ирләр тавышы. Кәгазе тузган.

> Сандугачлар ояда,
> Оялары пыяла.
> Сандугачлар күк сайрашып
> Торыйк, дуслар, дөньяда.

Кәшфи яшүсмер вакытта бу җырны күп тыңлады. Бу җырдан ул ике нәрсәне аңлый алмады: сандугачның оясы пыяладан була алмый.

Пыяла ояда булгач ул, димәк, тоткынлыкта. Ә тоткынлыкта сандугач сайрамый. Мәгънәсез сүзләр бу. Аннан соң, Кәшфи үз гомерендә сандугачтай сайрашып яши алмады. Ул гел эштә, гел кырда тракторда булды. Яраткан хатыны Асия белән дә сайраша алмады бугай ул. Заманы ул түгел иде. Кәшфи ашыгып эштән кайтты, Асия пешергән токмачлы ашны тирләгәнче ашады, ятты да йоклады, ятты да йоклады. Ярты гомере төнге сменада узды, сайрашырга вакыт калмый иде. Тик Асия гына моннан зарланмады, салмак кына, билгеле бер ритм белән генә, зарланусыз гына ике елга бер тапкыр бала табып торды. Бала тапкан саен юаная, калыная барды, аның саен холкы әйбәтләнә, мөлаемләнә барды. Ул яктан Кәшфи бик тә бәхетле булды. Оялары пыяла, имеш...

Кыш буе эшкә йөрде Кәшфи, кыш буе ремонтчылар янында кайнашты. Трактор астыннан үрмәләп кем чыга дисәң — ул, кара майга баткан кем дисәң — ул. Тик көлгәндә аның тешләре генә элеккеге кебек агарып ялтырамый инде, чөнки алар — юк. Протез куйдырыр өчен үлчәүләр алдырырга дип, шулай да районга барып кайтты бер мәртәбә. Әмма йөрәге урыныннан кузгалып кайтты. Атасыз-анасыз балаларны тәрбияли торган йорт барын ул күптән ишетеп йөри иде, бу юлы тәки шунда кергән. Кергән, сорашкан. Олы яшьтәге тешсез бу абыйны балалар чорнап алган. Шунда Кәшфи алты яшьлек бер малайның йомшак муенына үзенең автол-солидолга бүртеп каткан кулын куйган. Тегесе дә әйбер әйтмәгән.

— Исемең ничек? — дип сораган Кәшфи.

— Фәльгат,— дигән сакау малай, түбән карап. Тәрбияче апа озата чыккач, сөйләгән: Фәргатьнең эти-энисе үз машиналарына утырып Кара диңгезгә киткәннәр икән. Аварияга очрап һәлак булганнар. Бу хәсрәттән дәү әнисе дә китеп барган. Малай дөм ятим калган.

Кәшфи ул көнне кич үзенә урын тапмады. Берөзлексез сөйләнде.

— Исемең ничек? — дип сорыйм. Аның өчен чөнки танышканда шулай кирәк. «Фәльгать», ди бит бу йомшак колак. «Фәльгать», ди. Белдеңме шуны? Ул әйтми бит, ышту «белмим» дип, ул әйтми бит ышту «Тәлгать» или «Рәфкать» дип. Ул бит дөп-дөресен әйтә: «Фәльгать», ди ул, җаныкаем...

Асия җиңги инде барысын да аңлаган иде. Кәшфи, теш куйдырам инде, болай булмый, дигән сыман ыңгыр-шыңгыр килеп йөрде дә яңадан район үзәгенә барып кайтты. Анысында бераз басылыбрак кайтты. Кичке аш вакытында сөйләп утырды.

— Барып кердем. Аңарчы продмагка кереп бер кила печенье алдым. Аның өчен чөнки... бала янына кергәндә и һәм дә олылар янына күчтәнәчсез ярамый. Фәргать бик сөенде. Йөгереп килеп тез башымны кабып уйный. Чү, ди, тәрбиячесе, чү, ди, авызыңа инфекция керә, ди. Тегесе һаман каба. Мин әйтәм, трактористта инфекция була алмый, дим, аның өчен, дим, чөнки керосин барысын да үтерә, дим. И рәхәтләнде Фәргать, и рәхәтләнде. Тәрбиячеләре әйтә, дүкәминтләреңне тутыр, ди, үзең бик заслуженный кеше икәнсең, Минздравка җибәрәбез, ди, бөтен дүкәминтне. Ул тегеләй, килдең дә алдың гына түгел икән. Адәм баласы бит ул. Безнең илдә адәм баласыннан да кадерле ни бар. Шаярма син... Июнь айларына кадәр хәл итәрбез, ди. Анда синең дә имза кирәк икән. Менә мин санаторийда вакытта нишләр инде ул бала? Сиңа анда баргалап йөрергә туры килер...

Март ахырында Кәшфине Львов өлкәсендәге бальнеологик санаторийга җибәрделәр.

— Мин баруын барам,— диде ул Ахиярга.— Әмма ләкин бер шарт белән — сабанга чыкканда мине тракторга утыртасың. Кышын яңадан кайтырмын мастерскойга.

Ахияр риза булган сыман итте, көлде.

Асия җиңги аның кесәсенә егерме унлык санап салды. Колхоз идарәсе биргән ун унлыкны Кәшфи Асиягә кайтарып бирде.

— Аның өчен чөнки... Миңа акча нәрсәгә? Хатын-кыз белән чуалмаган кешегә акча нәрсәгә аңа? Миңа бит син булгач, бу дөньяда бүтән беркем дә кирәкми.— Һәм ул иелеп чемодан тотырып маташкан хатынның артына шаяртып сугып алды һәм читкә атылды. Бер кинода күргәне бар иде: үҗәтләнгән филне ябык кына бер индус этеп карый. Тегесе карап тора. Озын борынын селки. Нигәдер шул фильм искә төште, югыйсә эш күп, бик күп, юл кирәк-ярагын карыйсы бар иде.

Бер «отделение» бала үстергән Асия җиңги йортта шулай ялгыз калды.

Аннан көн санау, сәгать санау китте. Асиянең бөтен баш ватканы шул булды: Бу олы йорт кемнәр өчен соң? Һәм Кәшфи белән Асия үзләре кемнәр өчен? Бу ни бу? Дөньяда нинди үзгәреш булды,ниләр бара, нәрсә эшләнә? Нигә Асия ялгыз бу язгы кояшлы көннәрдә?

Кәшфи, өйдән чыгып китеп, нәкъ егерме алты көн дигәндә, Асия санавынча, алты йөз дә егерме дүрт сәгать узгач, кайтып төште. Рәсимәнең дә ялга кайткан киче иде. Кәшфи апрель баткагын ертып ашлама ташучы трактор чанасына утырып кайтты. Бер кулында чемоданы, икенче кулында агач рәшәткәле әрҗә иде.

— Үл-ләм, җаным, бу нәрсә? — диде Асия җиңги сискәнеп.— Әллә тере инде?

Кәшфинең авыз колакка җиткән иде:

— Бу — белдеңме? Бакча башындагы суга җибәрәбез. Яшәсеннәр, үрчесеннәр. Мондагы суга! Мондагы урман күлләренә!

— Үл-ләм! Бет-тәм! Әллә күсе инде?

Кәшфи аның саен бәхетле була барды.

— Әй-йе! Күсе! Ну ләкин и һәм дә фән теле белән әйткәндә... Аның өчен чөнки... Һәр чәчәкне һәм җәнлекне биологиядә латинча исемләп йөртәләр. И һәм дә боларны да. Болар чөнки ондатра дип атала. Ирле-хатынлы. Бер украинецтан сатып алдым. Бәясе — пүчтәк. Икесе нибары йөз илле таңкә. Менә хәзер үк ит ашатабыз да, иртәгесен күлгә җибәрәбез. Аннан алар үзләре үрмәләп урманга кереп китәләр! Андагы күлләр! Торна бала чыгара торган күлгә барып җитсәләр, болар рәхәткә тиешә инде. Мин хәзер егерь Минһаҗга йөгерәм... Үрчесеннәр! Мин һәрнәрсәнең, һәр файдалы җан иясенең үрчегәнен яратам.

Кәшфине тотып торырлык түгел иде, ул йөгерде. Рәсимә, көтелмәгән бу мәшәкатькә бераз гына ризасызлык белдереп, ит турый башлады. Бераздан Кәшфигә ияреп егерь Минһаҗ да килеп җитте. Минһаҗ, ни арададыр, ондатра үстерү, үрчетү буенча бер китапчык та табып алган һәм аны өй уртасындагы өстәлгә шапылдатып салды.

Аннан әрҗәне саклык белән генә каерып ачтылар. Ондатра дигән елкылдавык тереле ике җәнлек кыю рәвештә өстәлгә чыкты. Һәм ятьмәле тәпиләре белән бит-мыекларын сыпыргалап алдылар да, таш тәлинкәне үткен тырнак очлары белән тырный-тырный, тавыш чыгарып, вак туралган ит кисәкләрен әдәп белән генә, әфсен-төфсен китергән сыман ашый башладылар.

— Болар яшәр,— диде Минһаҗ.— Бирган булса, болар ияләнер. Тик менә китаптан карарга иде.

«Урта полосада ондатра үрчетү» дигән китап өстенә теге елкылдавыкларның берсе менеп үк утырган иде инде: күрәсең, өстәлгә җәелгән клеенканың җансыз салкынын яратмаган.

— Тик менә документы юк,— диде Минһаҗ.— Аңа бит документ кирәк.

— Нинди документ? — Кәшфи гаҗәпләнеп аңа карады.

— Нинди булсын? Товарный чек. Сиңа ничек итеп 150 тәңкәне түләргә хәзер?

Кәшфи буыла-буыла көлә башлады.

— Ышту син, Минһаҗ! Аның өчен чөнки... Миңа акча нәрсәгә? Минем збиркнижкедә күпме акча бар, беләсеңме? Бу авылда миннән дә бай кем бар? Нишләп дәүләт кесәсенә керим мин? И һәм дә акча алыйм?

Бераздан алар бу елкылдавыкларны бакча башындагы вак таллы күлгә җибәрделәр. Тегеләр, саубуллашкандай итеп, кара мәрҗән күзләрен елтыратып, Кәшфигә карап алдылар һәм, тал ботаклары арасындагы бозлы суны чачтыр-почтыр китереп, кереп югалдылар. Кәшфи дә, Минһаҗ да бик бәхетле иде бу минутта. Кайткач, Минһаҗ өйгә кереп тормады, ишегалдыннан гына саубуллашты.

— Рәхмәт инде, туган, сиңа,— диде.— Ярый әле авылда син бар.

— Аның өчен, иптәш, ярамый ул чөнки...

— Тик менә тагын бер мәсьәлә бар.

— Тагын нәрсә? И һәм дә?

— Шушы көннәрдә — бүген-иртәгә торналар киләчәк бит.

Кәшфинең чырае сытылып китте.

— Шулай шул,— Ул күккә карап авыр сулады.

— Миндә бер план бар.

Кәшфи җанланды:

— Нинди план ул, туган?

— Менә болай инде, турысын гына әйткәндә. Үзең беләсең, ничә ел буе инде — елына ике мәртәбә бөтен авыл халкының йөрәге елый. Узганында минем әни карчык, бөтен балаларым елады. Хәер, әйтәм бит, шул вакытта бөтен кеше яшенә тыгылып елый. Моңа чик куярга кирәк.

— Ә ничек итеп?

— Мин үзебезнең общество белән сөйләштем инде. Рөхсәт алдым.

— Нәрсәгә, нинди рөхсәт?

— Теге ялгыз торнаны атам мин. Ул — ата торна. Ул үзенә пар таба алмаячак икән. Теге көтүгә ияреп кенә йөри икән инде ул. Торналар сыңарын югалткач, бүтәнчә таба алмыйлар икән. Менә мин генә ул, хатын үлеп ике атна дигәндә икенче хатынны эһ тә итмичә алып кайттым. Эзләп тә йөрмәдем. Ә аларда булмый икән ул. Тилмереп яшәмәсен. Кешегә дә газап китермәсен, үзенә дә...

Өйгә кергәч, Кәшфи аш янына утырды һәм тәмләп санаторий хәлләрен сөйли башлады. Тик шуны сизделәр: Кәшфигә сөйләшү хәзер көннән-көн авырая бара иде. Санаторийда да аның ике урт теше төшкән икән.

Күңеле йомшап китеп ул урыныннан торды да өстәлнең теге ягында утырган Рәсимә янына чыкты һәм аркасыннан сөйде.

— Тегендә палатадагы иптәшләргә гел сине мактадым, кызым,— диде.— Әйттем: өч телдән укыта ала, үзе чибәр, үзе эшкә булган, дидем. Кызым, чыннан да бик бәхетле син, әти-әниең исән, йортыбыз болын кадәр, байлыгыбыз зур, колхозда минем дәрәҗәм бар, мәктәптә сине яраталар. Шуларны сөйләдем.

Рәсимә әдәп белән генә кашыгын куйды, авыз-иреннәрен кәгазь салфетка белән сөртте дә, тирән итеп, сагыш белән бер сулыш алды:

— И, әти, ни шатлыгы бар соң миңа аларның? — диде.

Кәшфи дә, Асия да аңламыйча аңа карап куйдылар. Рәсимә тагын авыр сулады да:

— Ярар инде, дүрт туй үткәрергә булыштым, тиздән дөнья түгәрәкләнә,— диде.

— Юк, кызым, алай димә. Аның өчен... Аның өчен чөнки... Чөнки... Кәшфи ни әйтергә икәнен үзе дә белми иде. Әйе, бу — беркем дә юата, шатландыра алмый торган бер халәт, һәм моның нинди халәт икәнен утызга якынлашкан кыз бала үзе генә белә иде.

## XIV

Дөньяда кеше ике төрле авырудан врачка кермичә кала алмый: шуның берсе — теш авыруы. Теш врачының ишеге төбендә утырганда кеше дер-дер килә. Теге куркыныч ак машиналар тезелеп киткән кабинеттан җаныңны өшетә торган мәкерле тавыш ишетелә. Юк, монда үз теләгең белән пичек кермәк кирәк? Качарга моннан, хәзер үк поездга утырып кайтып китәргә, аннан беренче очраган трактор арбасына утырып, авыл басуы аша туган колхозыңа кайтырга, баллы куәт исен ишеп-ишеп йөрткән җәйге җилгә күкрәкне ачып киң суларга, үзеңнең туган җиреңнең бөтен каткагын, чокырын, ташын, ызанын тәгәрмәчләр аша сизеп кайтырга, кайтырга да, үз авылыңның чирәмле тыкрыгыннан яланаяк атлап, инешкә төшәргә, шунда бер юынып алырга... Нигә бу ысылдавык машина? Кемгә кирәк бу? Качарга!

Кәшфи коридорда карап утырды: озын, майлы чәч үстергән, баш бармагыннан озын тырнак тырпаеп торган, ямаулы зәңгәр киндер чалбар, тишек ботинка кигән, алтын йөзекле бер егет ишек янындагы урындыкка чүмәшкән. Кәшфи күреп тора — тунеядец бу. Ике кул аркасына татуировка белән язган: «Они, бедные, устали, им нужен отдых». Кәшфи шул вакытта уйлап куйды: ну, кер әле син теге ак машинага. Күрсәтәләр әле, «отдых» биләрләр әле сиңа. Кәшфи аның белән бер рәткә туры килде. Пычрак тырнаклы егетне ысылдап торган ак машина бөгеп салды, тәмам изде. Кәшфи әле уколдан яңагы кабарган көе, берни тоймыйча утыра иде, тегене күзәтте. Вәт, бит, дип уйлады ул, бу эшлексез гидайны ата-анасы кеше итә алмаган. Мәктәп җиңә алмаган. Производствода эшләми бу сыек — күренеп тора, производствода эшләгән кешенең бармагында озын тырнак була алмый. Бу егет — студент та түгел. Студентның чәче андый алама булмый, Рәсимә сөйләве буенча, Кәшфи аны гына белә: студентларга «военка» дигән бөек фән кирә, бу фән андыйларны, күпмедер дәрәҗәдә рәткә салып, стройга бастыра.

Озын тырнак ыңгырашты, кан төкерде, тагын ыңгырашты. Моны әти-әнисе, мәктәп буйсындыра алмаган. Моның белән милиция җәфаланган, ах иткән. Ә менә ак халатлы, үтә күренмәле аксыл-алсу куллы яшь кыз әлеге сыекны бөгеп салды, сыекның маңгаеннан борчак кадәр тир бәреп чыкты. Яшәсен теш врачлары! — дип уйлап куйды Кәшфи һәм Тависны исенә төшерде. Тешләре ягыннан, мәрхүм, әнисенә тарткан, һәрберсе ак, таза ахакъ иде шул. Тавис стоматологның кем икәнен белмичә дөньядан китте. Бәлки, аңа менә бу ак машина астына кереп, «орчык эрләгәнен» бераз гына карап утырырга кирәк булгандыр. Тәрбия өстәлеләдер бу!

Кәшфинең бу юлы врачтан бәхете булмады. Ихтимал, кияүләр сүзен тыңлыйсы булгандыр. Таксист кияү әйтте: бер көн сабыр ит, минем бүген эш көне, минем бер белгән малай бар, больницада завгаром эшли, шуның аркылы үзем доцентка күрсәттерәм, диде. Кәшфи риза булмады.

— Сәламәтлек мәсьәләсенә танышлык катнашырга тиеш түгел,— диде.

Кандидат кияү әйтте:

— Бу атнада ученый советта минем отчет, бик тыгыз вакытым, алдагы атна башында кил, үзем профессорга күрсәтәм,— диде.

Кәшфи каршы килде:

— Теш суырырга профессор кирәк түгел, аңа оста мастер гына кирәк,— диде.

Менә хәзер генә, ак урындыкка кереп, чытырдатып ябышып утыргач кына, уйлап алды: ихтимал, кияүләр сүзен тыңлыйсы булгандыр: врачны күрүгә үк ошатмады Кәшфи. Иң беренче эш итеп аның авызына бармагын тыкты. Бармактан тәмәке исе килә иде. Кырык бишләр чамасындагы врачның башы уртадан ялтырап тора, озын хәлсез чәчләр башны ян-яктан гына әйләндереп алган. Урындык тирәсендә әйләнгәләп йөргәндә куәтле корсагы белән юка, җиңел Кәшфине берөзлексез эткәләп, авыш-тәвеш китерде.

— Һу-у-у, синең монда! — диде ул, корыч орчыгын көйли-көйли.— Монда хәлләр бар. Я, я, нәрсәгә калтырыйсың, мин бит әле бораулап кына карамакчы булам. Әле бик начар чыкса, менә бу икесен суыртып алырга туры килер.— Ул металл таягы белән рәхимсез рәвештә Кәшфинең теш төпләренә сукты, Кәшфинең күз алдыннан миләүшә төсендәге ялкын көлтәсе узды, һәм ул ыңгырашып урындыкка ябышты. Әллә каян, әллә кем сөйли иде, ул моны аңламады.

Кәшфине врач урындыгыннан күтәреп, җитәкләп чыгардылар. Коридорда куркынган Рәсимә басып тора иде. Ул такси алып, әтисен кандидат кияү квартирына алып кайтты да, үзе поездга әзерләнә башлады. Аның иртәгесен дәресләре бар иде. Кәшфи, шулай итеп, «алдагы атна башланганчы» калды. Хәер, бүген җомга, тагын ике генә көн көтәсе иде.

Дүшәмбе көнне кандидат кияү телефоннан белеште: фәлән-фәләневич бүген поликлиникада буламы, әллә кафедрадамы, дип сорады. Ыхым-ыхым килеп, озак сөйләште, елмаюлар, көлүләр, ярым-йорты мәгънәле җөмләләр булды. Шулай да Кәшфине машинасына утыртып каядыр алып китте. Кәшфи өчен кафедра, поликлиника дигән сүзләрнең аермасы юк, ул яңадан ак урындыкка утырасын гына күз алдына китерде. Ак халат кигән ике егет кандидат кияү белән коридорда бик җылы күрештеләр, сигарет кабыздылар.

— Абзыйның кәефе юк соңгы атнада,— диде берсе.— Менә көйләп йөрибез инде. Холостякның холостяк шул, өендә бернинди уют юк.

Ул арада егетләрнең берсе Кәшфине ак ишекле бүлмәгә алып кереп тә китте. Ишек янындагы ак урындыкка утыртты да, башланган әңгәмәне дәвам итәргә дип, бәхетле чырай белән коридорга чыгып китте. Кәшфи кабинетны карады. Берәү дә юк, язу өстәле, телефон, ак машинка.

Ширма артында профессор тавышы.

— Так, так. Ә менә болай иткәч, авыртамы? Юк. Ә менә болай? Яхшы, ярый. Ә болай? Бу тешләр сызламыймы? Ә бу тешләр?

Ысылдаган, выжылдаган тавыштан башка гына дәвалау ысуллары бар икән, дип уйлап алды Кәшфи һәм авылча кызыксынып, сикереп торды да, ширма артына башын тыкты. Тыкты... Һәм телсез калды. Күпмедер секундка теш сызлавы онытылып торды. Тәрәзәгә каршы ак халатлы, таза гәүдәле күзлекле профессор, ә аңа ян белән басканы күзеңнең явын алырлык чибәр, яшь кыз иде. Яшь кыз билгә кадәр чишенгән һәм профессор аның авызын ачтырып, тешләрен карый, әйләндерә, аркасына, җилкәсенә баса, матур күкрәкләренә астан кулын куеп, ниндидер авыру эзли иде.

Кәшфинең баш тыкканын алар күрмәделәр.

Ширма артыннан чыккан профессор кулын юды, озаклап сөлгегә сөртенде, үзе дулкынланып сөйләде.

— Сезнең анда бер генә чокыр бар. Иртәгә шушы сәгатькә килерсез. Металл пломба куярбыз, курыкмагыз, берни дә сизмәссез. Ә, гомумән, тешләрне карап торырга кирәк. Теш начарланса, иң беренче чиратта, ашказаны, аннан йөрәк эштән чыгуы мөмкин. Хатын-кыз өчен тешләрне тикшертеп тору бигрәк тә әһәмиятле. Килеп дөрес эшләгәнсез...

Профессор Кәшфине өстәл янына чакырды, ширма артында теге кыз киенә, шерт-шерт китереп нәрсәләрдер әләктерә, каптыра иде. Өстәл янына утыргач ук Кәшфи, эш тәртибен белгән кыяфәттә, пиджагын салды, күлмәк сәдәфләрен ычкындыра башлады.

Профессор елмайды. Аның кәефе шәп иде.

— Юк, юк, мәшәкатьләнмәгез,— диде ул, Кәшфинең карточкасын карап.— Тракторист? Механизатор! Почетлы профессия. Безне, интеллигенцияне, икмәк, сөт-май белән тәэмин итүче кеше. А как же? Сезгә — безнең бөтен осталык. Так. Менә болай утырыгыз. Аһа. Киңрәк ачыгыз. Так, так. Ничего. Куркыныч берни дә юк. Берсен суыртырбыз. Юк, авыртканын белми калырсыз. Бу — сезнең дошманга әйләнгән. Шуны алдыргач, анадан яңадан туган күк булырсыз. Нигә алай бик каты кырылды? На нервной почве шулай кырыла. Борчу күп күрдегезме? Балалар белән? Все может быть. Ә протез куярга кирәк. Давай без болай килешик: сез иртәгә дә миңа килә аласызмы? Килештек. Димәк, иртәгә үлчәү алабыз. Хуш, туганкай!

Кәшфи чыкканда, ак халатлы теге егетләр кандидат кияүгә нәрсәдер сөйлиләр, көлешәләр иде. Ахрысы, анекдот.

— Юк, сез уйлап карагыз әле. Таныш булмаган чибәр хатын бара. Теге әйтә иптәшенә: вәт, ди, тегеләй-болай иткән булып кына, моны әләктерергә, ди. Шул арада теге хатын — ишетеп бара икән — боларга таба борыла да:

— Тегеләй-болайга гына минем үз ирем дә бар инде,— ди.

Бәхетле көлешү, тәтенгә бәхетле тончыгып, бәхетле юталләү...

Кәшфине шундук киендерделәр һәм әйтә куйдылар:

— Абзыйның кәеф яхшымы? Пациентлар матур кешеләр бүген,— дип мәгънәле елмайдылар.

«Пациент» сүзенең мәгънәсен аңламаса да, бу чибәр егетләргә кушылып, Кәшфи дә елмайды. Егетләр игътибар иттеләр: механизатор абзыйның авызында им өчен бер теш тә күренмәде.

Профессор вәгъдәсендә торды: үлчәүләр алды, протез куярга сроклар билгеләнде.

Ташлытау поездына Кәшфине озатырга биш кыз, дүрт кияү килгән иде.

## XV

Ахияр беренче сүзне райком секретаре Байгильдеевка бирде.

— Хөрмәтле иптәшләр,— диде беренче секретарь бераз гына дулкынланган кыяфәттә,— хөрмәтле дуслар,ерактан кайткан ветераннар, туганнар! Бүген без гаҗәп кызыклы бер тантананың шаһитлары булдык. Ихтимал, республикада мондый тантананың беренчесен сез оештыргансыздыр. Бүген мин президиумда уйлап утырдым. Сезнең культура сараегызга шыплап тулган авыл хезмәт ияләренең шатлыклы чыраена карап утырдым. Илле ел эчендә нинди авыр, мәшәкатьле, данлы юл үткәнсез сез. Гаҗәп бит! Күпме язмыш сездә, күпме тарих! Күргәнсездер, сугыш вакытын, сугыштан соңгы авыр елларны сөйләгәндә,

җыр-декламация белән җанландырып, инсценировкалар күрсәткәндә, күпме кешенең күзендә яшь иде. Бу бит бөтен районның язмышы! Бөтен колхозның тарихы! Мин шуны уйлап утырдым, иптәшләр, мин сезнең коллективта инде унберенче елымны эшлим. Бу якларга килгәндә, монда мине кабул итмәсләр, эшләве, уртак тел табуы авыр булыр дигән идем. Мин бит бөтенләй икенче яктан, Тау ягыннан, озак тора алмас кебек идем. Әмма, мин сезне яраттым. Сезнең колхозны бигрәк тә. Инде сез бүген, хезмәт ветераннары, колхозның җитәкче иптәшләре, алдынгы эшчеләре, бәйрәм табынына җыелдыгыз. Бу өстәл янындагы кешеләрнең күңеле көр булсын, тәннәрендә сихәт артсын, колхозыгыз киләчәктә дә эзмә-эз алга барсын өчен тост тәкъдим итәм, иптәшләр...

Урман итәгендәге инеш буена яңа такта өстәлләр, эскәмияләргә әзерләнгән аш мәҗлесе шулай башланып китте. «П» хәрефе итеп куелган өстәлнең түрендә район кунаклары янында Кәшфи ялгызы утыра иде. Асия җиңги, кияүләр-кызлар кайтыр дип, мәҗлескә килмәде.

Ахиярның хатыны Сольма да бу тантанага кайтмады.

Мәҗлес җанлана төште, колхозның үзешчән сәнгать көчләре чирәмле квадратка чыгып бастылар. Июньнең иң кояшлы, баллы куәт, мәтрүшкә чәчәге, бөтнек үләненең кайнар исе борынга бәрелгән бер сәгате. Колхозның Поник бригадасыннан килгән кунакларның руслар булуын исәпкә алып, концертны ике телдә алып бардылар. Һәркем эчендәгесен сөйләгән, җырлаган сыман иде. Ахияр, зур гәүдәсенә нииндидер җиңеллек биреп, яр буендагы казаннардан кызлар белән бергә ризык ташыды: тәлинкә белән кайнар итне, ак чәчләренең юлын ачып, тыйнак утырган Катерина алдына китерде, аннан йөгереп килеп Байгильдеев каршындагы «Боржоми»ның бөкесен ачты, Кәшфинең рюмкаларын тикшереп чыкты. Кәшфи елмаеп утыра, рюмкасы тулы иде.

— Ва-ва, ывву,— диде ул елмаеп, эченә төртеп күрсәтеп. Ахияр аңлады. Кәшфи шушы көннәрдә генә теш казнасы куйдырырга тиеш, һәм ул бөтен булганын алдырып бетергән, ә инде, «вавва-ывву» дигәне, «ашказанымда гастрит, миңа эчәргә ярамый һәм дә миңа тост әйттереп маташмагыз тагын» дигән сүзе иде.

Катеринаның кызы — шушы авыл мәктәбендә укытучы, бодай саламы кебек калын ике толымлы, зур, тирән зәңгәр су күзле Оля уртага чыгып басты. Зифа буйлы, йомшак бәрхет карашлы бу кыз тыныч кына укытып йөри, фермада агитатор булып эшли, үзенең сылулыгы белән, Рәсимә кебек үк, ялгыз олаеп бара иде.

Су буендагы зирекләргә баян чыңы белән бергә моң бәрелде:.

Бежит река, в тумане тая,
Бежит она, меня маня.
Ах, кавалеров мне вполне хватает,
Но нет любви хорошей у меня.

Кәшфи моңаеп аны тыңлый, үзенең йөрәге ачытып куя: Асия күрсен иде бүгенге матурлыкны. Гомере буе хезмәт кенә итте бит ул! Гомере буе кара майлы комбинезон юды бит ул! Кияүләргә чуртым булыр идеме? Кәшфи күз алдына китерде: Асия белән Фәргать хәзер күмәч белән сөт ашап сөйләшеп утыралардыр. Кичә генә урамнан елап кергәч, Асия аннан сораштырып утырган иде.

— Кай төшеңә суктылар, улым? — дип сорады аннан Асия җиңги, күмәч турап алдына сөт куйганда.

Фәргать эчен тотып елый иде.

— Иат җиреңә типмәгәннәрдер бит? — Асия җиңги куркынып, малайга иелде. Малай башын күтәрде.

— И-й-уукъ,—диде ул яшьләрен сөртеп.— Анда типсәләр, үләсең ис!

...Оля һаман җырлый икән. Кәшфи игътибар итте: Катерина күзләрен кулъяулык белән сөрткәләп утыра иде.

...Быел җәй, әллә ничек кенә шунда, моңлы, сагышлы булды. Кәшфи кызык хәзер: келт иттеме, күзенә яшь килә. Яз көне Ахияр белән төчкерешеп алдылар. Язгы сабанга чыкканда Кәшфигә трактор бирмәделәр.

— Сәламәтлегең шәп түгел, язгы кыраулы төннәрдә төнге сменада ничек эшләрсең? — диде Ахияр.— Шул мастерскойда эшләп ятсаң җитмәгәнмени.

Кәшфи каршы сүз әйтмәде, тамак төбенә яшь тыгылды да идарәдән үпкәләп кайтып китте.

Ә авыл басуына гөрләп ике трактор килеп кергән иртәне Кәшфи бөтенләй нәүмиз калды.

— Аның өчен чөнки...— диде ул, Асиянең алъяпкыч итәгенә күзләрен сөртеп,— и һәм дә яшьләр үсеп житте. Мин олайганмын. Бирсеннәр миңа трактор, бирсеннәр миңа мең гектар җир, әйтсеннәр миңа, иптәш Габделбариев, дисеннәр, мене шушы мең гектарны бер атнада эшкәртеп чык, дисеннәр... Мин төн йокламыйм, көн йокламыйм и һәм дә шуны сөреп чыгам, гөл балчыгы ясыйм.

Ул көнне Кәшфи үзенә урын тапмады.

Мастерскойга узышлый гына кергән Ахияр дә хәлне аңлады. Кәшфигә икенче көнне үк трактор бирделәр. Мастерскойда һәрвакыт аның урынына кала торган яшь егет — егерь Минһаҗ малае бар иде.

...Менә концертның чираттагы номерын әйттеләр. Рәсимә Габделбариева җырлый, диделәр. Күрше колхоз председателенең тостыннан соң ашык-пошык ризык капкалаган вакыт иде. Чирәм уртасына баянист белән Рәсимә чыгып басты. Культура сараеның реквизитыннан — озын, каюлы атлас күлмәк кигән, башына килешле калфак утырткан, буйлы, сагышлы күзле мөлаем бер кыз. Кәшфи тын да ала алмады. Янындагы Байгильдеевка төртте, елмайды.

— Вуву, ыввы...

Байгильдеев — фамилиясеннән үк кем икәнен чамалаган иде — шулай ук елмайды.

— Молодец, абзый, чибәр кыз үстергәнсең,— диде.

— Выввы, вавві...

Рәсимә дә үзенекен җырлады. Ука белән чиккән кызыл саржа жилетлы баянчыга карап ул, бөтен урманны яңгыратып, ачы тавыш белән җырлады.

Өй артында шомыртым лай,
Яннарында кушкаен шул,
Яннарында кушкаен.
Үзенә тиң яр табалмый
Ялгыз яшн башкаем.

Байгильдеев барысын да аңлады. Бу сылу кыз — күзгә чәчәк. Бу укыган, зифа буй үстергән, рухи яктан үзен бай итеп хәзерләгән, хәзер ул, чыннан да, үзенә тиң таба алмый. Ансат кына язалар: имеш, берберецне яратсаң, белем аермасы сизелми дип. Рәсимә, мәсәлән, Лев Толстойны, Бернард Шоуны, Эрнест Хемингуэйны укыган. Ул Штраусның «Зәңгәр Дунаен», Равельның «Болеро»сын ярата. Ә авылның Рәсимә тирәсендә чуалган токарь егет телевизордан хоккей һәм футбол гына карый. Шәһәргә баргач, ул егет иң беренче эш итеп циркка билет ала (егет эшчән, әдәпле, колхозның менә дигән специалисты — егерь Минһаж малае), ә Рәсимәнең, Качалов театрына кереп, Остров-

ский, Чехов яки Гоголь әсәрен карыйсы килә. Бу егет белән менә дигән тормыш корып булыр иде, әмма рухи уртаклылык? Гаилә кору турында ансат кына язган кешеләр әнә шунысын исәпкә алмыйлар. Рәсимә — ялгыз, аның буе-сыны, зифалыгы әрәм була. Әнә сеңелләре ун класс, СПТУ, ГПТУ тәмамладылар да менә дигән егетләргә кияүгә чыктылар. Кайсы кандидат, кайсы цех начальнигы, дөньяны җимертеп яшиләр... Ә бит сеңелләре Глинканы да, Штраусны да белмиләр, мәҗлескә җыелсалар, авыз күтәреп, рәхәтләнеп — җыенысы бергә — шәрран ярып җырлыйлар.

Ишек алдында йөримен,
Карлар яуса көримен...

Ә Рәсимә алай булдыра алмый. Егерь Минһаҗ малае да әйбәт кеше. Тик уртак тел генә табып булмый. Шуның өстенә юаш. Мәктәп коллективындагы тәҗрибәле хатыннар Рәсимәгә әйттеләр:

— Егет кеше артыңнан йөргәндә усал булсын, ир булгач, юаш булсын,— диделәр. Моны алар кат-кат әйттеләр, күрәсең, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып сөйлиләр.

Имеш, яратсаң, уртак тел табып була. Ә Рәсимә әйтә: уртак тел тапсаң, яратып була, ди. Теге, Тавис көнләшкән хезмәт укытучысы да начар егет түгел. Берәр тапкыр озатып та куйды ул Рәсимәне. Эшләр ярыйсы гына бара иде кебек. Ләкин беркөнне хезмәт укытучысы әйтеп куйды:

— Поледельник — иң авыр көн минем, алты сәгать,— диде.

— Ничек? — дип кычкырды Рәсимә үзен-үзе белмичә,— нәрсә дидең?

Егет аның гаҗәпләнүен үзенчә аңлады:

— Ие, ие,— диде ул,— поледельниктә алты сәгать минем. Завуч шулай куйган...

Рәсимә ул көнне кич мендәренә капланып елады. Филолог кызга ул көнне зур җәрәхәт ясалды. Алар бүтән инде очрашмадылар.

\

...Мәҗлес кызды, кичке караңгылык төшкәндә генә учаклар өстеннән алып чәйнекләр китерделәр. Уртага тәңкәле күлмәк, тәңкәле баш киеме кигән бер чибәр кыз чыгып басты.

Байгильдеев борылып Кәшфидән сорады:

— Бу кем кызы була?

Кәшфи, балаларча елмаеп, аңа аңлатты:

— Вуву, ыввы,— диде.

Татар теленә тәрҗемә иткәндә бу «мәктәптә химия укытучысы — крәшен кызы Лиза» дигән мәгънәне бирергә тиеш иде, секретарь «аңладым, рәхмәт» дигән сыман ияк какты.

Крәшен кызы — чибәр генә. Гармунчысы да күрәсең, шулай ук культура сарае хезмәткәре, уртада үзен кыю тотты.

— Колхозыбызның хезмәт ветераннары, кунаклары хөрмәтенә без Лиза Евдокимова белән берлектә бер җыр әзерләдек. Лиза җырлый, ә мин бүгенге көндә кешеләр арасында бик сирәк очрый торган Михаил Вараксин гармунында аның җырлавына ярдәм итәм, русча әйтсәк, «сопровождаю».

Лизаның тавышы көмеш икән. Ул тирән итеп, күкрәк күтәреп сулыш алды да башлап китте.

Биеккәй генә тауның, ай, башларындай,
Салганнар лай, ай, кәнүшнәй ләй...
Бергә чакта, ай, күрешеп калыйк,
Күрешеп булмый, ай, нарушнай лай.

Мәҗлес тулысынча җыр карамагында, шуның тәэсирендә иде, крәшен кызын бер җыр белән генә ычкындырмадылар. Мәҗлес күңеле өчен, алкышлардан соң, ул тагы бер көйгә җырлады. Көенең исемен гармунчы әйтеп тормады.

Биекләй генә тауның башларында
Бибкәй Пауаллары бау ишә.
Безнең крәшен калкын елатмасаң,
Татар беткәнмени сиңа, падиша-а-а...

Гөр-р килеп кул чаптылар, шатландылар, көлештеләр.

...Чыклы, салкынча июнь урманында гармун тавышы тынды. Учакларда очкыннар, кисәүләр уйнады. Көрешүләр, кочаклашу-үбешүләр, вәгъдәләр, планнар ашыгыч ноталарда башкарылды, машиналар газ бирде.

Кәшфи инде гадәти киемнәрен кигән кызы янына килеп басты һәм машина ягына күрсәтте. Ахияр Байгильдеевны озатып йөри иде. Рәсимә аңлады: кунаклар белән төн уздырасы килә әтисенең. Ул арада райком машинасы газ бирде, һәм Ахияр да болар янына килеп басты.

Рәсимә инициативаны үз кулына алды.

— Ахияр абый! Безнең әни тавык тутырып калды, гөбәдия пешерәм, диде. Әти белән мине аласыз да, безгә киттек,— дип Ахияр машинасының ишеген үк ачты. Рамил баранкага тотынган, «Волга» гөрелдәп эшләп утыра, «Маяк»тан концерт бирәләр. Ахияр да тиз риза булды: Кәшфине түргә — рульдәге улы Рамил янына кертеп утыртты да үзе артка чумды.

— Әйдә, улым, Гәр Хуторга таба дуй,— диде.

Инде кошлары уяна башлаган урман артта калды. Машина фаралары үлән өстеннән күтәрелгән урман туфрагын ялый-ялый агачлар арасыннан чыгу юлын эзләделәр.

Тәнне, рухны рәхәтлек хисе, бөтенлек баскан һәм шуның өчен кемгәдер, нәрсәгәдер зур рәхмәт әйтәсе, канәгатьлекне белдерәсе килә иде.

Асия җиңгинең гөлт итеп торган зур тәрәзәләрен ерактан ук күреп алдылар. Ут, хәтта, ишек алды фонаренда да балкып тора иде. Хәер, яктырып та килә икән инде, Гәр Хутор урамында машина эченә чык баскан салкынча тузан исе бәреп керде, авыл читендәге башы корыган каен ботагында чыр-быр килеп карга-чәүкә уянышып ята иде.

Өйгә, чыннан да, гөбәдия исе чыккан икән.

Я инде бу ирләрне. Яктыра башлаган, көн туган бер мизгелдә ашарга-эчәргә утырдылар.

— Був-ву! Бавву! — диде Кәшфи борчылып. Ахияр аңа карады. Асия кайнар шулпа китереп йөри иде, Кәшфигә ярдәм итте:

— Ии, ие, ник ди, Байгильдеевны да чакырмадык, аның, ди, безнең өйдә булганы бар, ди.

— Ә, юк инде,— диде Ахияр,— аның иртүк шәһәргә китәсе бар. Аннары райком секретаре булган җирдә туарылып сөйләшеп булмый.

— Туарылмакчымыни әле син? — диде Асия җиңги.— Туарылып нишләмәкче буласың?

— Ә менә колхозның ветераны, республиканың алдынгы механизаторы Габделбариевны кыздырмакчы булам.

— Гомере буе тырышып эшләгән өченме?

— Юк. Сигез бала үстереп, авыл хуҗалыгына бер кеше дә бирмәгәне өчен ут итәргә кирәк аны. Ачулану гына аз...

— Ывву! Ывву!

— Ие, ие. Үзеңнеке ничек соң, Ахияр дус, ди, Кәшфи. Үзең кемне бирдең соң, гомер буе колхоз өчен чабулап үз урыныңа кемне калдырасың, ди ул безнең Кәшфи...

— Мин бернә калдырырмын кук, Асия. Минә Рамил авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, шушы колхозга кайтам, ди.

— Ву! Ву!

— Кәшфи әйтә, өрлек кадәр гәүдәң белән, ди, йөз ун килолы гәүдәңне өстерәп йөреп, колхозга нибары бер кеше бирәсеңме, ди. Алайса, ди, мине гаеп итмә, минем авырлыгым нибары илле ике кила ди, комбинезоным-нием белән, ди. Әле ди, мине түгел, сине кыйнарга кирәк, ди. Әйдә, шулпа суынганчы утырышыгыз. Кызым! Егетне өйгә чакыр.

— Вы-ва, ув-ва,— дип этәләнде Кәшфи, өстәлдәге ризыкка кулы белән төртеп күрсәтә-күрсәтә. Барысы да аңлаган сыман иттеләр.

Тәрҗемә эшен үз өстенә тагын Асия алды.

— Кәшфи шул инде безнең: ашау вакыты җитсә, кара кайгыларга батам, дип әйтә ул сезгә. Тагын ашарга утырасы бар инде дип көненә өч тапкыр кайгырам, ди ул, тешләре беткәннән бирле.

Капка төбендә туктап калган машина янында гөлдер-гөлдер Рамил белән Рәсимә сөйләшә иде.

Рәсимә егетне кыю гына тотып өйгә алып керде. Укытучы дисәң, укытучы шул, егет белән дә класс җитәкчесе булып сөйләшә.

— Менә син монда утыр, әтиең янына. Әтиеңнең бу ягына. Әтиләрне саклап утырыйк. Алар бүген берсен-берсе кыйнамакчы булалар. Эчми эчкән кешедән барысы да була аның.

Кәшфи киң елмайды.

— Сезнең арада тотып кыйнарлык бер генә кеше бар.— диде Асия җиңги.— Ул — Ахияр. Нинди чибәр хатыны белән тормыш кора алмады бит! — Асия җиңги күз яшьләрен сөртеп алды.— Монда булган бөтен тол хатын, бөтен кыз-кыркынны үзенең тасма теленә каратты да — малаең барында әйтим инде — шул кура җиләгедәй хатынны монда кайтармады бит.

— Үзе кайтмады шул,— диде Ахияр, тәмләп шулпа ашый-ашый.— Миннән эш калмады.

— Калмады, калмады... Үзең гаепле. Гел колхоз, гел колхоз. Гел эш артыннан чаптың. Теге, бичара, шуны күтәрә алмады.

— Юк, аның сәбәпләре булды.

— Һи-и-и... Әйтерием инде сәбәпләрен. Яшьләр бар, яшьләр...

Юк, белеп сөйләми Асия. Хатын-кыз буларак кына сөйли.

Рамил тәлинкәсен ялтыратып куйды, салфетка белән авызын сөртте.

— Рәхмәт, Асия апа, мондый тәмле шулпа ашаганым юк иде әле,— диде.— Мин бакча яктан бер әйләнеп кайтыйм. Кояш чыкканын карап. Только сез этигә әйбер әйтмәгез. Мин аны беләм: шушы колхоз өчен, шушы җир, халык өчен үләргә әзер ул. Без — әни, сеңел, мин — икенче планда. И, по-моему, дөрес эшли. Бөтен кеше дә шулай булсын иде әле: Кәшфи абый и минем әти кебек.

— Минем малай философиядән бишкә биргән быел экзаменын,— диде Ахияр, зур кулын Кәшфинең аркасына салып.

Кәшфи гел авызын ерды. Башта Ахиярның, аннан Рамилнең кулын кысты.

Рамил белән бергә Рәсимә дә чыгып бара иде.

— Әнә син шундый, киң күңелле булганга да кайтмады инде ул Сәлимә. Сиңа кем түзеп торсын... Колхоз дип кенә булмый ул,— дип өстәп куйды Асия.

Ахияр каршы килмәде: дөньяда хатын-кыз белән бәхәскә кереп берәр ирнең ул бәхәстә җиңеп чыкканы бармы соң?

— Ягез, ягез, ашап-эчеп утырыгыз инде,— дип кыстады Асия җиңги.— Шешәсен дә күрсәтер өчен куймаган.

— Мин бер рюмка сухойны эчәрмен кебек. Тик менә йөрәк кенә сизмәсен. Ул сизсә, мине ега да ташлый инде.

— Увыва, увыва,— дип, Кәшфи тәрәзә аша ишегалдына күрсәтте.

— Ни, ди ул, ни ди. Әнә ди, абзарга чыгып кара, быел урман буенда җир сөргәндә поши баласы табып алып кайтканые ул. Шуны үстерә карап. Көзгә урманга җибәрмәкче була. Кояш чыккан ди, тегеңә сөт бирер вакыт җиткән, ди.

Кәшфи шат һәм бәхетле иде.

Кузгалыштылар.

— Чирек сәгать кенә йөреп керегез инде, самовар яңарттым,— диде Асия җиңги.

Башланган «Рислинг» өстәлдә шулай ятим утырып калды. Поши баласын карарга дип, абзарга таба юнәлделәр. Асия җиңги дә верандада таралып йоклап яткан Фәргатьнең өстен рәтләде, бер чебен аның авыз тирәсенә кунып җәфалый икән, тастымал тотып, шактый вакыт шуны ишеккә таба куалап йөрде.

Авыл башында җиңел машиналар тавышы ишетелде. Ирләр әле абзарда, коры такта идәндә басып торган кара ялтыравыклы, ахак күзле, озын торыклы, чиста гәрәбә тояклы, чыгынкы маңгайлы юеш борын янында әйләнгәләп йөриләр, бу мәхлукка якын килергә, муенын сыпырырга тырышалар иде.

Машина тавышлары капка төбенә үк килеп җитте. Асия җиңги йөгереп чыкты. Сыер саварга да вакыт җиткән иде. Ирләр дә капка төбенә чыктылар.

Капка тирәсенә җайлап-җайлап, койма буйлап дүрт машина тезелде. Икесе «Волга», берсе «Жигули», берсе «Москвич». Эчләреннән кызлар-кияүләр коелды. Япон курткаларына төрелеп, йокыга изелгән өч-дүрт пычтык баланы чирәмгә бастырдылар.

— Кара, кара боларны,— диде олы кияү, таксида эшләүчесе. Зәңгәр, яңа «Москвич» шуныкы икән.— Нишләп төн йокламыйсыз? Колхоз бәйрәме кайчан башлана? Без әле бер-ике сәгать йоклап ала алырбызмы?

— Соңга калдыгыз, егетләр,— диде Ахияр,— без әле шуннан таралалмыйбыз.

— Ничек? — диде кандидат кияү,— ничек? Ник сез безгә бит ял көн дип язган идегез?

— Үзгәртергә туры килде,— диде Ахияр, шәһәр кешеләре алдында аклангансыман.— Мероприятиене күчереп арканларга туры килде. Иртәгә район буенча комбайнерлар слеты. Бер группа безнең колхозга килә. Бүген шуңа әзерлек көне.

— Менә сиңа мә,— диде кияүнең иң кечесе.— Менә бензин ягып йөр инде. Мин бит синең шикелле автол, соляр якмыйм,— диде ул Кәшфигә үпкәләүле карап.— Мин АИ-93 ягам. Ун литры ике сум да ноль-ноль тиен аның. Ну кызык иттегез...

— Үл-ләм! Үл-ләм! Бу нинди зат? — Верандадан олыдан кече — икенче кыз тавышы ишетелде.— Кем ямьсезе бу, монда йоклап ята?

Хатын-кыз шунда йөгереште, бераздан Асия җиңгинең үксеп-үксеп елаган тавышы ишетелде.

Кызларның кайсыдыр берсе, аеруча каты кычкыра иде.

— Штубы илтеп биргән булыгыз! Кара син аларны! Әллә нинди килмешәктән туган баланы нигезгә кертергә. Чисти тилергәннәр икәү генә калгач. Аны, сөйләгәннәрие. Ышанмаганыек...

Асия җиңги кычкырып ук елый башлады. Кәшфи йортка таба йөгерде. Ахияр бу мәшәкать, ыгы-зыгыга катнашмыйча гына Рамил янын-

да, үз машиналары тирәсендә торды. Әлеге ыгы-зыгының мәгънәсен аңламый иде ул.

Ул арада теге мут кияү — балдызын бәхетсез иткән үткен кияү — абзар ишеген ачып шау кубарды, дөбер-шатыр килеп юеш борынның муеныннан кочаклады да, абына-сөртенә ишегалдына чыкты. Үзе шау килде.

— Егетләр! Егетләр! Менә безнең бабай молодец! Без кайтышка нинди закуска әзерләп куйган! Бажай! Син шампурларыңны ала кайттыңмы! Давай, кичке якка таба...

Йорттан Кәшфи белән Асия йөгереп чыкты. Кәшфи үзенең җыйнак, җиңел сөякле гәүдәсе белән поши баласын таза кияүдән аерды.

— Ыввував! — дип яман кычкырды ул.

Үткен кияү аны аңламады.

— Ничего, ничего,— диде ул, юеш борынның арт санын сыпыргалап.— Калганын колхоз базарына алып барып сатабыз аның. Нәрсә, килосын биш сумнан эчеңне төртеп тишәме әллә?

Бажайларның иң яше багажниктан бер бәйләм шампур алып маташа иде.

Кайткан кешеләрдән бу ыгы-зыгыга икесе катнашмады. Моның берсе иң төпчек кыз — нәзек торна аяклы, зур авызлы әлегә матурланып җитмәгән төпчек кыз Тәслимә иде, ул янәшәсендә сүзсез торган юка, сыек бер егетнең аркасыннан төрткәләп маташа иде.

— Бар инде, бар инде. Күреш. Әнә монысы — эти. Тешләре төшкән, әлегә сөйләшә алмый. Әнә тегесе — әни. Бар инде! «Исәнме, Кәшфи абый» диген. Мин, диген, әлегә Тәслимәнең танышы, диген. Бар инде, җебеп торма. Ну, безнең танышлык инде, диген... «Исәнме, Кәшфи абый», диген...

Юка, сыек малай, җайсыз гына атлап, Кәшфигә таба китте. Өйдә чырыйлап елаган бала тавышы ишетелде: бу — Фәргать тавышы иде. Шул тавыш барысын да сискәндерде.

Өйгә, үзен-үзе белмәстән, Ахияр атылды. Кинәт кенә айнып киткәндәй, машина яныннан ыргылып өйгә шулай ук Рамил кузгалды. Рәсимә верандадан йөгереп чыгып, шампур белән матавыкланган кияү янына килде һәм үзен-үзе белмәстән, аның төк баскан яңагына киерелеп сукты. Рамил дә ишегалдына йөгереп чыкты һәм Юешборынның муенын кочаклап торган икенче бер кияүне читкә этеп, бакча капкасын ачты да, Юешборынны шунда чыгарып ук җибәрде, бакчаның арт киртәсе юк һәм ул урманга барып тоташа иде.

Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты: зур капкага сөялеп, ишегалдына дүрт кияү, дүрт кыз һәм алар артына Тәслимә белән сыек егет басты, чолан баскычында Кәшфи, Ахияр, Рамил тоташ стена булып бер-берсен кочаклаштылар. Алар артында, әле йокыдан айнып бетмичә елап шешенгән Фәргатьне кочаклап, Асия җиңги тора иде.

Унбер йортлы авылның көтүе чыга икән, урман кырыенда быргы тавышы ишетелде.

— Вы-вы-ы! Вы-вы-ы-ы!

Асия җиңги Фәргатьне җитәкләп, сыер саварга абзарга кереп китте. Сыек егет исә, кыяр-кыймас кына атлап, Кәшфи янына килде дә үзенең сөякчел-таркау кулын сузды:

— Исәнме, Кәшфи абый,— диде.— Мин — әлегә Тәслимәнең танышы. Ну, инде безнең танышлык...

*1982*

Рәшит Әхмәтҗанов

# МӘХӘББӘТНЕҢ ИСӘНЛЕГЕНӘ!

## Тайга чәчәге

Бер нәгъләт, бер рәхмәт укып
Бу болытлы дөньяга,
Тайгадан бара идем мин
Учаклар яга-яга.

Очраштык... Наратлар өши,
Бу һаман алсу, тере...
Куандым, табылган сыман
Җанымның бердәнбере.

Минем йөрәкнең хәлләрен,
Әйтерсең, күптән белә:
«Мин — Сөю! Минем мәңге дә
Сүнәсем юк!»,— дип көлә.

Кузгалгач, кире киләм дә
Яңадан карыйм аңа:
Ал ямьнәр өстәп дөньяга,
Ул чәчәк аткан яңа.

«Яшим мин, күрәм әле, ди,
Күрәм сөйгән ярыңны,
Башыңны җуеп, ярыңны
Эзләп табуларыңны.

Утырачаксың әле, ди,
Кол булып тәхетеңдә.
Минем дә төсем чагылыр
Синең ул бәхетеңдә».

*1966*

Әй түгәрәк икән дөнья, түгәрәк,
Түгәрәкләр йөриләр гел тәгәрәп.

Уела уй: аһ, бары тик бер мәлгә
Шатлыкларны җирдә түгәрәкләргә!

Кулга тотам кайгыларның исәнен,
Ватмак булам аның тик бер кисәген.

Ватылмый... ул дөнья кебек түгәрәк,
Дисәм... кояш күктә йөри тәгәрәп.

*1976*

## Дөньяга таралдык

Кылганнар кадалып эндәште:
«Бар мәллә җаныңда яралар?»
Бар иде... Бар инде яралар,—
Дөньяда яңгырар җыр алар.

Камыллар: «кал инде», диделәр,
Камышлар ымлады киткәндә.
«Анамдыр... кызгана торгандыр...
Тауларны күрәдер җилкәмдә».

Бер талда идек без, таралдык.
Ачтык та авылның капкасын,
Кычкырдык:— Әйдәгез, дөньяны
Безнең дә мәхәббәт якласын!

Әле дә хәтерли торгандыр
Кандызның караңгы урманы —
Аяклар канатып, ерактан
Җанымда китердем мин аны,

Гасырлар төбеннән... көленнән...
Китердем бабамнар Сөюен.
Йолдыздай атылдым түбәннән,
Көтмәдем, әй, кузгал, диюен.

Киләчәк! Күзеңә нур итеп
Күчер син сөюнең яңасын.
И гомер, йолдызга менмәсен,
Син, җирдә ут булып янасың.

Моны бит күптәннән раслады,
Раслады Баулымда батырлар.
Түбәннән девоннан менгәнне,
Айдан да исән-сау кайтырлар.

Дөньяга таралдык, ачтык та
Сөюнең мәңгелек капкасын.
Әйдәгез, кешеләр, дөньяны
Безнең дә мәхәббәт якласын!

●

*Чәчрәр чаткы*
*Төннәр буе*
*Дөрли-дөрли учак янар*
*Тамчы тамар —*
*Ут эченнән*
*Барыбер ул яфрак табар.*

Малай чак шигыреннән

Чәчрәр чаткы, дигән идек,—
Яндык инде, яндык инде;
Гомер буе янып торыр
Учак булып калдык инде.

Тамчы тамар, дигән идек,
Тамды инде, тамды инде.
Аның тапкан яфракларын
Утлар элеп алды инде.

●

Еллар, айлар... көннәр уза тора;
Күктә — кояш, җирдә җан яна.
Яна, яна... Алар яктысында
Җансызлар да, әнә, җанлана.

Яшәү — бәхет! Тик ирнемдә кипте
«Китмә, яшьлек!» дигән бер доѓам.
Җирдә җылы артык булмас әле,—
Мин дә җанны ягып калдырам!

●

Әйткәннәрең булсын туры сүз генә —
Туры сүзеңне төртеп әйт күземә.

Тик ул кипкән чыбык сыман булмасын —
Мине күзләп һәм сагалап тормасын.

Килмәсен ул елан кебек шуышып,—
Елан белән йөрисем юк куышып.

Еланнарның чыкканы бар каршыма,—
Мин аларның баса беләм башына!

*1977*

## Кояш батканда

Тауларым калды, талларым калды,
Тик җил өзгәләп китте шәлләрен.
Ә көнбагышлар кояш артыннан
Йөгерделәр бит... аңлыйм хәлләрен.

Китүчеләрнең гомере хәзер
Таулар артында балкыйдыр инде.
Көннәр буена арыш урдым да
Үлеп арыдым... Калдыр син минем!—

Кояшым, мине калдыр кырларда,
Басуда калдыр мин — тургаеңны.
Кичермәс монда сыңар яфрак та
Таулар артында баюларымны.

●

Кайда ява җәйнең яңгырлары? —
Тауларымның чәче агарган.
Ярты күкне биләп болыт узды,—
Тамчы тамып калды аңардан.

Күренден дә, син дә киттең шулай,
Бер тамчы нур тамды... күзләргә.
Дөнья бакса хәзер шул күзләргә —
Килеп керер сары көзләргә:

Кошлар китәр очып, ә чәчәкләр
Һуштан язып авар... кар явар...
Ә мин тизрәк күзләремне йомдым,
Матурлансын өчен дөньялар.

*1978*

●

Яндым-көйдем, бәргәләндем.
Миңа ташлар бәрелделәр.
Җәрәхәтләр алды тәнем...
Матурлар — бик кадерлеләр.

Җәрәхәтләр эзен тәннән
Көмеш сулар юмас, юмас.
Бәлки инде хәзер җирдә
Миңа охшап беркем тумас?!

●

Ни кирәкнең син барын да табасың.
Син табасың... Минекеләр кая соң?
Күпме танышлыгым бар бит таш белән,
Таш сыннарга җан өрәлми интегәм.

*1979*

## Тал югалды

Кайчан чыгып йөгергән ул
Минем моңсу күңелдән:
Тауларгамы, ярларгамы,
Суларгамы күмелгән?

Минеке ул, Илнеке ул —
Китқәненә карама!

Ничә кабат яфрак япты
Йөрәктәге ярама.

Таң сызыла... Талсыз гына,
Ялгыз гына мин яшим.
Тауларгамы, ярларгамы,
Суларгамы эндәшим?

●

Канатсызлар, имеш, күктә оча,
Канатлылар ята түбәндә...
Мин үзем дә, имеш, җир өстенә
Туган илсез туган бер бәндә...
Уянганчы ничек үлмәгәнмен
Шушы төшне төнлә күргәндә?!

●

Язмышымнан язлар китеп бара.
Мин дә агам Идел суында.
Дулкыннарда батам, тагын калкам,
Тик калкавыч түгел мин монда.

Яшәү — бөек заман! Аны, әнкәй,
Мин аралар өчен карадан —
Баткан җирдән шулай кинәт кенә
Калкып чыгып балкыйм яңадан.

Уйларымда, дисең, ташкын ага,
Ташкын ага... курка башладым.
Туган илгә дигән гомереңне
Ташка бәйләп ташлаганнарын

Төштә күрдем дисең... Юк, борчылма,
Күтәреләм көннәр күгенә.
Һәм кош булып очам... Җыр багышлыйм
Мәхәббәтнең исәнлегенә!

●

Йөзебездә ай нурлары күрдегез дә,
Теләдегез нәкъ шуны ук үзегез дә.
Тагын бер кат текәлебрәк бактыгыз:
Һәм барыбер бер кара тап — миң таптыгыз.

## Балачак

Кырлар буйлап куды безне ачлык...
Качып-посып шунда арыш удык.
Тамак туйгач, офыкларга кадәр
Аллы-гөлле күбәләкләр кудык.

Кошлар исә безне алмадылар
Җылы якка очып киткән чакта.
Кул җылытып калдык җыйнаулашып
Яңгыр астындагы бер учакта.

Камылларны сыйпап узды кояш.
«Без дә монда!» — дидек,— ишетмәде.
Кайтсак, табан бозга ябышканчы
Сугыш бикләп торды ишекләрне...

Өйгә кереп йокыларга талгач,
Ап-ак шикәр күрдем мин төшемдә.
Өлешемне ашамакчы идем
Суга манчып авыл инешендә.

Йокылардан иртән уянганчы,
Ачлык аны миннән ник урлады?!
...Шул иртәдән бирле дүрт ягымнан
Кычкыралар кебек: «Ярлы, ярлы...»

Юк, төшемдә түгел, мин өнемдә,
Бөтен байгурадан бай көнемдә —
Үлемнәрдән качып килермен —
Балачакка шикәр бирермен!

*1980*

## Ак әремнәр кемне әрләсен

Болгар җирләренә барыйм дисәң —
Җитмеш чакрым юлда карурман.
Сак белән Сок сиңа кычкыралар:
«Без генәме әллә аерылган,
Без генәме әллә аерылган...»

Болгар җирләренә җитим дисәң,
Кара урманнарны узасың...
Ярларына аккаеннар үскән
Елгаларга килеп егылганчы
Тарих ташларыдай тузасың.

...Күгәргәннәр ташлар. Тотып карыйм
Бөек Болгар хәрабәләрен.
Авылларын күрәм, шәһәрләрен...
Күз яшьләрем белән юар идем
Тузанланган тәрәзәләрен...

Җимерелгән алар. Таш калканнар —
Ныгытмалар гына кайчакта
Пышылдыйлар төсле: «Бабаларың —
Җылындылар безнең учакта,
Янып үлде безнең кочакта...»

Таш өстендә үскән ак әремнәр
Монда бүген кемне әрләсен!
Тарихымның утлы сүзләреннән,
Замананың нурлы күзләреннән
Эзлик әйдә яшәү мәгънәсен.

*Февраль — 1982*

Юныс Сафиуллин

# МЕНӘ БЕЗ ДӘ ҮСЕП ҖИТТЕК...

КОМЕДИЯ

**КАТНАШАЛАР:**

Хәсән Галимович Гибатуллин — археолог, 28 яшьтә.
Ләйсән — аның хатыны, 23 яшьтә.
Хөсәен Имаевич — археолог, 28 яшьтә.
Зилә Бишевна — Ләйсәннең әнисе, 53 яшьтә.
Алия — күрше хатыны, 46 яшьләрдә.
Физат — аның улы, 18 дә.
Калын тавышлы кеше — ит чабучы, 55 яшьтә.
Әминә — авыл кызы, 17 дә.
Секретарьша кыз
Нечкә тавышлы кеше
Чытлыклы тавыш
Гайрәтле тавыш
Арыган кеше тавышы
} Тавышлары телефоннан гына ишетелә.

Вакыйга безнең көннәрдә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

**Кояшлы иртә. Бер бүлмәле кысан гына фатир. Кая карама — китаплар. Тахтада Хәсән йоклап ята. Янында янып торган торшер. Ләйсән халаттан, Хәсәннең идәндә яткан китапларын җыеп йөри. Телефон шалтырый.**

Ләйсән *(трубканы алып)*. Әйе, бу синме, әни? Ник болай иртүк шалтыратасың?

Зилә тавышы. Ник килмәдегез?

Ләйсән. Хәсәннең бик ашыгыч эше бар иде...

Зила тавышы. Аның гына эше ашыгыч! Аның гына эше эш! Ә хәзер өйдәме ул?

Ләйсән. Өйдәсен өйдә дә...

Зилә тавышы. Көтегез мине, хәзер килеп җитәм.

Ләйсән *(Хәсән янына тахтага утыра)*. Хәсән, тор әле...

Хәсән *(шат көлеп)*. Күктә кояш... *(Ләйсәнне коча.)* Кочагымда Ләйсән! *(Шаян такмаклый.)* Ләйсән диләр, Ләйсән диләр, Ләйсән ире Хәсән диләр!..

---

Әлмәт Татар дәүләт драма театрында 212 мәртәбә сәхнәгә куелды

Л ә й с ә н. Куй әле, Хәсән! Тыңла дим, шаярма! Хәлләр шаяра торган түгел...

Х ә с ә н. Әллә тагын сөекле әниебез киләме? *(Ята башлый.)*

Л ә й с ә н. Килә шул, ә сиңа көлке! Авыр башы миңа төшәчәк.

Х ә с ә н *(торып утыра)*. Соң әйдә, карчык, куып чыгарабыз, куабызмы?..

Л ә й с ә н. Юләрләнмә.

**Хәсән кабат йоклап киткәндәй итә.**

Хәсән, Хәсән дим! Кыланма инде...

**Ишек звоногы шалтырый.**

Х ә с ә н *(башын күтәреп)*. Әллә килеп тә җиттеме?

Л ә й с ә н. Җитте шул. Тизрәк бул!

**Хәсән торып утыра. Тагын звонок.**

Х ә с ә н *(тыңлап)*. Эх, син, үз әниеңне танымыйсың. Бу бит әбкәй түгел, бу чит кеше. Кара әнә, ничек «шикләнеп» кенә шалтырата. *(Кабат йокларга ята.)*

Л ә й с ә н *(ишеккә бара, ача)*. Гафу итегез...

**Калын тавышлы кеше керә.**

К а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Ниһаять, сезне күрү бәхетенә ирештем. Рәхмәт сезгә, рәхмәт, сөйкемлем.

Л ә й с ә н. Сез... гафу итегез... Кем дип белик?

К а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Хөсәен Имаевич үзе өйдәдер бит? Өйдә булмаса да зыян юк, мин аны көтәрмен. Көне-төне көтәргә дә ризамын. Хөсәен Имаевич ничек теләсә, бар да шулай булыр. Минем бик якын дустым бар, замдиректор булып эшли... Хөсәен Имаевич белән уртак танышыбыз икән. Булдыра торган кеше дә инде, чукынган. Киләсе елга ук түгел икән, аннан алдагы елларга һичшиксез директор да булачак. Хуҗа үзе пенсиягә — лаеклы ялга китә...

Л ә й с ә н. Туктагыз, зинһар, сез ялгышасыз... Сезгә кирәк кеше безгә каршы ишектә...

К а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Хөсәен Имаевичмы? Археолог ул. Археолог кем икәнен беләсездер? Карале, сезнең күзләрегез бик матур икән. Хөсәен Имаевичның кеме буласыз?

Л ә й с ә н. Беркеме дә түгел. Барыгыз инде.

К а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Юк, сеңелем, мине ахыргача тыңлап бетерегез. Хөсәен Имаевич миңа бер генә минутка...

Л ә й с ә н. Әйттем бит инде, абзый. Биредә Хөсәен Имаевич түгел, Хәсән Галимович тора.

К а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Археологмы?

Л ә й с ә н. Археолог.

К а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Миңа миңа археолог кирәк тә инде... Хөсәен Имаевичны уятыгызчы.

Л ә й с ә н. Сез миңа ышанмыйсызмы? Хөсәен Имаевич безгә каршы ишектә дим.

К а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Рәхмәт, сеңелем! Алдаламыйсыз икән. Мондый матур күзле кеше алдый алмас. Алайса, ул монда яшәми инде? *(Бүлмә эченә күз йөгертеп.)* Шулайдыр, шулайдыр. Ярый, алайса, рәхмәт! *(Чыга.)*

**Бусагада — Зилә Бишевна.**

Л ә й с ә н. Килдеңме, әни! Әйдә, уз!

З и л ә. Кем бу? Хөсәенгә кереп китте...

Л ә й с ә н. Белмим, әни.

З и л ә. Сездән чыкты түгелме соң?

Л ә й с ә н. Ялгыш кергән ул.

З и л ә. Аста «Волга» тора — аныкыдыр инде?..

Л ә й с ә н. Аныкыдыр...

З и л ә. Беләм мин бу кешене, күргәнем бар. Колхоз базарында ит чаба. *(Хәсәнне күреп.)* Карале син моны, йоклап ята түгелме?

Л ә й с ә н. Йокы тимәгәч. Төне буе укырга туры килде. Эше шундый бит.

З и л ә. Флюс кияүне әйтәм, диссертация яклап йөргән көннәре. Апаң кулына китап тотып утырганын күргәнем юк ди. Укыйм дигәч тә инде... алай ук кыланмаса да буладыр. Гөлфия апаңа Флюсне караштырып йөргәндә, мин әнә шул ягын ошаттым: кешеләр белән аралаша белә. Өч киявем әнә өчесе дә утырды кичәге мәҗлестә. Аларның да эшләре булгандыр, әмма килделәр, үз итеп...

Л ә й с ә н. Ярар инде, әни.

З и л ә. Аның өчен борчылам бит, аның өчен. Кеше сүзен сүз иткәч, өч баҗасы да әнә дөнья җимертеп яшәп яталар... Ә сез биш ел буе кеше почмакларында тилмередегез. Моннан ары да шушы төнтек бүлмәгездә адәм чырае күрми яшәячәксез. Әнә кешеләр...

Л ә й с ә н. Җитте, әни!

З и л ә. Телемә басма! Һич булмаса, әнә Хөсәенгә чыгарга иде. Бусы манараларга табынып, кабер ташлары санап, иләс-миләс килеп йөргәндә, ул доцент булып куйды.

Х ә с ә н. Шаулама инде, әби, уятасың бит.

З и л ә. Күптән вакыт уянырга. Утызга җитеп тә акылга утырмаса, утыздан соң

өмет аз диганнәр. *(Ләйсәнгә.)* Чуртыма кирәкме аның безгә тагын егерме елдан соң академик булуы!.. Куркып әйтмим — үзе дә ишетсен.

Хәсән *(көлә-көлә юрганын кайтарып куя).* Мин аны мең ишеткән инде, әбкәй! Хәерле иртә!

Зилә. Мең дә бер тапкыр да ишет! Аннары да шулай булсаң, миллион да ике тапкырын да ишетерсең!

Хәсән. Әбкәй, ә мин төш күреп ята идем әле. Сине күрдем. Боксер икәнсең, касыгыма шундый иттереп тәрттең, шундук уянып киттем!

Зилә. Әйбәт булган... Ныграк кирәк не әле. Әби хәтле әбиеңне санга да сукмыйча затсызланып ятасың. Аз гына хөрмәт тә юк.

Ләйсән. Хәсән, тор!

Хәсән. Алайса, әбкәй, кругом марш, читкәрәк кара. Безнең монда яшеренеп киенә торган урыннар юк.

**Зилә читкә борыла. Хәсән күлмәгенә сузыла.**

Ләйсән *(күлмәкнең яңарагын күтәреп).* Бусын, бусын!

Хәсән. Ә-ә, житмеш сумлыгын кииммени, карчык? Дөрес әйтәсең бит син, әй! Каяле, бу житмеш сумлык күлмәк янына йөз житмеш сумлык галстук белән жиде йөз сумлык парадный костюмны да китер әле. Ә юк, кирәкмәс, әбкәй хөрматенә без, иң яхшысы, Американың үзеннән кайтарылган биш йөз сумлык джинсыларны киярбез.

Зилә. Шырланмале, кияү. Син миңа шуны әйтсәң ие: ник дип кичә сүземне аяк астына салып таптадың?

Хәсән. Мәжлесне әйтәсеңме, әбкәй? Соң, үз урыныма дусымны жибәргән ием бит инде. Валлаһи Хөсәеннән дә күңеллерәк кеше булмагандыр анда. Мин әле аның өчен сездән рәхмәт көткән идем.

Ләйсән. Хәсән!..

Зилә. Күпме шулай мыскыл итәрсең икән безне, кияү? Биш ел түзәбез бит инде! Биш ел!

Хәсән *(көлә-көлә Ләйсән белән Зиләнең кулларыннан ала).* Ике кешегә биш ел күп түгел инде ул, әбкәй! Менә миңа читенрәк — ун ел түзәм.

Зилә. Соң, кияү, аерылышыйк алайса.

Ләйсән. Әни! Син дә инде юк сүз сөйлисең!

Хәсән. Аерылышабызмыни, әбкәй? Менә рәхмәт. Бир бишне, сау бул!.. *(Шигырь такмаклый.)* Сездән аерылып, туганнар, жайсыз, уңайсыз тору; бу тору, әйтергә мөмкин — кояшсыз-айсыз тору.

Ләйсән. Житте, Хәсән, кыланма. Әни бу юлы дөресен әйтте. Күпме чакырылып та, бер генә мәжлескә дә барганыбыз юк!

Зилә. Кияүләр дә, таныш-белешләр дә, туган-тумачалар да тәмам аптырап бетә. «Ләйсәннең ире бер дә килеп күренгәне юк, якын итми»... диләр.

Хәсән. Әле менә утыз өченче мәжлесегезгә киеп барган башмагымны *(башмагының табан астын күрсәтә)* мәжлесегездән кайткач ук, мастерскойга илтеп биргән идем, шуны бит кичә генә алдым! Шулай булгач...

Ләйсән. Эчертүләреннән курка ул, әни. Көчләп эчертмиләр анда. Бер рюмка тотып куйганнан гына үлмәс идең әле.

Зилә. Эчәр өчен генә җыелалар димени? Анда, жаным, ни житте авыл мужиклары утырмый. Аһ, кемнәр генә юк иде кичә...

Хәсән *(Зилә сүзен «зиләчә» дәвам итә).* Берсеннән-берсе затлы кунаклар. Шунда үзләре белән аралашып, танышып, белешеп китсәң, начар булыр идемени, кияү?!.

Зилә. Шырланмале, кияү! Чыннан да, танышсаң начар булыр идемени соң?

Ләйсән. Танышырга дисең син, әни. Гомердә дә танышмаячак. Әнә, кичә әйтеп жибәрдем: апаның таныш сатучысы көтеп тора, бар, алып кайт кирәк әйберне дидем... Кая-я!.. Ник кайтмый бу дип барып карасам, чират торып ята. Хана Бариевнадан сорыйм, ник бирмәдең инде дим. «Чакырдым — килмәде», ди. Менә бит нинди бу безнең Хәсән.

Зилә. Абау! Харап икән.

Хәсән *(Ләйсән булып әйтеп куя).* Ә Хөсәеннең әнә, әнекәем, бөтен нәрсәне танышлары өенә китереп бирәләр.

Ләйсән. Ник, дөрес түгел мәллә?! Китерәләр шул!

Зилә. Хөсәен белән сөйләшмәгез сез!

Ләйсән. Ә нигә: безнең Хәсәннен аңардан кай төше ким. Икесе дә бер авылда туганнар. Хәтта бер үк көнне. Әниләре бик якын ахирәтләр. Институтка да бергә килгәннәр. Икесе дә археолог.

Зилә. Шулай, берсе хәзер доцент, икенчесе юләр таш жыйган кебек, юк-бар акчасына китап жыеп ята. Жыйган китапларын Рәүф кияү кебек файдалана алса ярар иде дә бит, юк, шушы көнгәчә, хәтта кандидатскиен да яклый алмый... Хез-

мәт хакына утыз сум өстәлер дип курка торгандыр.

Л э й с э н. Өстәлеп ни файда инде. Ул барыбер аны шул китапларына гына тотып бетерер иде... Хөсәеннең әнә...

Х ә с ә н. Ярый, серләрегез бик килешә, серләшә торыгыз, мин тиз генә юынып чыгыйм әле. *(Юыну бүлмәсенә кереп китә.)*

З и л ә. Ант әгәр: тиле бит бу!.. Килеп капкансың икән, кызым. Менә хәзер генә чистый аңладым.

Л э й с ә н. Алай түгел инде ул, әни. Хәсән тулаем фәнгә бирелгән. Халык өчен яшим дип яши.

З и л ә. Кабер ташларын санап, кыйшаеп аварга торган манараларны кемнәр салганын исбатлап йөреп, ул халык өчен яши булып чыга инде, име?.. Я, уйлап кара, чуваш килеп салганмы, урыс килеп салдыртканмы, татар үземе — шуны белүдән халыкка ни файда?

Л ә й с ә н. Фән өчен, ә фән — халык өчен!

З и л ә *(көлә)*. Фәннең кабыргасы йомшак: бүген болай, иртәгә тегеләй... Ә халыкка, матурым, манараларың кирәкми. Табынган кыйбласы да башка аның хәзер.

Л ә й с ә н. Яратам мин аны, әни, ишетәсеңме, яратам. Бик!

З и л ә. И-и, җебегән! Кемгә генә ошагансыңдыр!.. *(Юыну бүлмәсенең ишегенә килә.)* Кияү, моннан соң бездән бер тиен дә ярдәм көтмәгез, аңладыңмы? *(Ишеккә юнәлә.)*

Х ә с ә н *(юыну бүлмәсеннән башын чыгарып)*. Ярар, әбкәй, әмма үзең дә безгә бурыч сорап килмә.

З и л ә *(үзе дә сизмәстән)*. Сантый!

**Юыну бүлмәсе кабат ачыла да сөлгесен кулына тоткан Хәсән чыга.**

Х ә с ә н *(күңелсез елмаеп)*. Син, әбкәй, башка яктан бик хәтәр көчле булсаң да, диалектикадан йомшаграк. Әле кайчан гына безне «кеше почмакларында тилмерәсез бит» дип тиргәп йөри идең. Булыр дия идекме? Менә ике ай инде газлы, ванналы һәм җылы туалеты да булган үз фатирыбызда, дөньяның артына тибеп яшәп ятабыз. Калганы да шулай үз җае белән булыр.

З и л ә. Бер нәрсәгез дә булмас! Бусын да әле шул Хөсәен генә алып бирде, үзенең местком председателе булуыннан файдаланып.

Х ә с ә н. Нәрсә, нәрсә? Хөсәен миңа фатир алып бирде? Ник аны моңарчы әйтмәдегез!

Л ә й с ә н. Әйтерсең сиңа...

Х ә с ә н. Чакыр әле үзен, бар!

Л ә й с ә н. Кирәкми. Хәсән, ишетәсеңме? Аңарда кунак.

Х ә с ә н. Анардан кунакның өзелеп торганы юк лабаса. *(Ишеккә юнәлә, туктый, сәгатенә карый.)* Ә-ә, үзе керер вакыт та килеп җиткән икән.

Х ө с ә е н *(керә)*. Иртәнге обход!.. О-о, Зилә ханым, сез дә биредә икән. Гафу... Хәсән, миндә шундый феномен утыра, күрсәң әгәр!.. Сиңа аны һичшиксез күрергә кирәк. Парадокс. Вот була кешеләр! Гаҗәп! Әйдә, күрсәтәм.

Х ә с ә н. Син, Хөсәен, Хозыр-Ильяска әверелгәнсең икән. Миңа феноменальный яхшылык эшләвең дөресме?

Х ө с ә е н. Һәрвакыттагыча, ахир. Әйдә инде, нәрсә көттерәсең? Әле рәхмәт әйтерсең... күрсәң, күреп туймаслык...

Х ә с ә н. Синең мине — йорт-җирсез мескен сукбайны — фатирлы итүең дөресмени?!

З и л ә. Дөрес булмый ни.

Х ө с ә е н. Я, ташла әле шул мәңге бетмәс квартир мәсьәләләреңне. Ул бит синң гына проблема! Әйдәле, керик миңа! Ну просто кабих!..

Х ә с ә н. Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә. Сөйлә.

Х ө с ә е н. Халык өчен янган кешеләргә ничек булышмыйсың. Чиратың килеп җиткән идеме? Җиткән иде. Хатының да бар. Мин менә ситуациядән файдаландым. Сиңа дип йөреп, бер очтан үземә дә алдым.

Х ә с ә н. Ике бүлмәленеме?

Х ө с ә е н. Шулай, ачуланма инде, шундый бит мин. Телисеңме, сиңа да... Юк икелене генә түгел — дүрт бүлмәлене! Син бераз гына көт. Яме? Булыр... Башта, әйдәле, күр шул Мразь Мразычны. Ничек туйганымны белсәң... Шулай да син бәхетле бит, җен алгыры, бары үзең теләгән кешеләр белән генә аралашасың.

Х ә с ә н. Шулай шул. Сау бул!

Х ө с ә е н. Бөтенләйгә саубуллашкан кебек итеп...

Х ә с ә н. Бөтенләйгә.

Х ө с ә е н. Юк, менә анысы булмый инде. *(Идәндәге китапларга иелә.)* Синсез яши алмыйм мин, Хәсән. Гыйбрәт бит син миңа.

Х ә с ә н. Син дә гыйбрәт. Тимә китапларга, тегеләрен керт башта.

Х ө с ә е н. Кертәм, кертәм. Бер китап бар анда, малай, валлаһи, берни аңлый алмадым. Ну синдә булган баш миндә бул-

са... Беләм бит мин ни өчен куганыңны. Чөнки диссертацияне синнән алдарак яклап аттым. Ялгышымны таныйм. Тик кума гына. Икенчесен инде акыллырак булып, син яклагач кына яклармын. Шулай, ахир, кусаң да синнән калмыйм. Син кая — мин шунда. Юкка гына кушмаганнар бит әниләр безнең исемнәребезне Хәсән белән Хөсәен дип. *(Бәләкәч бер китапның исемен укый.)* Мишель Монтень. «Об искусстве жить достойно». Менә шушылар кебек даһи кеше булачак бит син. Бу фатирны да мин сиңа якынрак булыр өчен алдым. Берга-бергә серләшеп яшәр өчен. Бу Мишельыңны алайса алып торам, яме! *(Чыгып барышлый.)* Кусаң да китмим! Ярый, Зилә Бишевна, сез бездә дә көтелгән кунак! Рәхим итегез!

З и л ә *(аның артыннан)*. Ярар, Хөсәен, ярар.

Л ә й с ә н. Кеше аңарга чын йөрәктән кирә, ә ул шундый тупас итеп сөйләшә!

З и л ә. Хөсәен кебек дусны сиңа эзләргә кирәк әле.

Х ә с ә н. Шулайдыр, шулайдыр.

З и л ә. Я, әйт, жинаять эшләгәнме инде, Хөсәен сезгә квартира хлопатать итеп йөреп?..

Х ә с ә н *(арыган тавыш белән)*. Юк, жинаять түгел.

З и л ә. Шулай булгач, ник аның белән мондый ямьсез итеп сөйләшергә?

Х ә с ә н *(бик күңелсез елмаеп)*. Төпчек кызларын ник шул тикле ярата икән бу әниләр. Әгәр киресенчә — беренче балаларын ныграк яратсалар, ичмаса минут булса да тыныч торып булыр иде.

З и л ә. Инде мине дә куасыңмы?

Х ә с ә н. Куып ни файда, әбкәй. Барыбер безне күрми түзә алмыйсың инде син...

З и л ә. Уйлап кара, кияү. Нишли аласың син безсез? Нишли аласың таныш-белешләрсез? Балакаем, син бит бу дөнья кешесе түгел... Мин сине кызганам...

Х ә с ә н *(шактый җитди)*. Әшнәләрсез нишли аламмы, әбкәй? Әйтимме соң? Әшнәләрсез, мин илгә, дөньяга файда китерә алам, әбкәй.

З и л ә. Балакаем, дөньяга файда китергән кешеләрне академик итәләр. Саташма... Зинһар акылыңа кил. Үзең генә буталып бетүең җитмәгән, кызымның да башын болгатма. Чык кешеләр йөри торган юлга. Акча таптыралар икән дип уйлама. Син аны гомердә дә табалмыйсың. Оят, шунсы оят бигрәк, иң олы апасы да Ләйсәннән яшьрәк күренә. Дүрт кызым арасында иң сылуы, иң чибәре, иң матуры төпчегем Ләйсән иде. Ә хәзер кара!.. Я, ярату, тук тормыш, бәхетле гаилә, ир рәхәте күргән кеше чыраеммы бу?!. Ә гомер үтә! Егерме дүрт була, утыз дүрт тула, илле...

Х ә с ә н *(бик нык арып)*. Ярар, әбкәй, үгетләргә кирәктер, әмма, үтергәнче үк түгелдер... Яле, Ләйсән, чәй булса да эчерт. Юкса мин шул тикле ачыгып уяндым, өч тиенлек алюмин чәнечке белән дә шушы миллион сумлык әбкәйне кабып йотарлыкмын.

З и л ә. Аңлашылды. Чәнчелеп китегез!

Х ә с ә н. Әллә китәсең, әбкәй? Китеп торма инде, барыбер иртәгә үк килеп житәчәксең бит. Ярар, алайса, бар-бар. Кара аны, иртәгә дә бүгенге чакта ук кил. Соңга каласы булма.

З и л ә. Бик кирәгегез бар ие.

Х ә с ә н. Юк, кил-кил, әбкәй! Төпчегең янына булмаса, минем хәлне белергә...

З и л ә. Ә-йә-йәй! Тфү!

Х ә с ә н. Бүген кичкә үк килеп житәчәксең. Бабайга да әйтә күр, утырмага килсен.

Л ә й с ә н *(әнисе артыннан ишекне ябып)*. Нишләвең бу, Хәсән?!.

Х ә с ә н. Минме? Кил әле, бире утыр. *(Ләйсәнне тахтага утырта.)* Димәк, мин яши белеп яшәмим, шулаймы?

Л ә й с ә н. Синме? *(Хәсәнгә сыенып тынып кала.)* Мин сине бик яратам, Хәсән.

Х ә с ә н. «Ярату» сүзен һаман-һаман авызымда әвәләп тормасам да, мин дә шулай, Ләйсән. Яратам сине, бик! Өйләнгәндә әйттем, хәзер әйтәм һәм киләчәктә дә шулай күп сөйләшми генә яратырмын.

Л ә й с ә н. Рәхмәт, Хәсән. Син үпкәләмисеңме?

Х ә с ә н. Сиңа үпкәләгәнем бармыни?

Л ә й с ә н. Чыннан да нинди кеше соң син? Нигә шулай сәер? Икәү генә калганда менә гаҗәеп син. Ярдәм итәсеңме, яки башкасымы... әмма кешеләр арасында... Менә әни белән ничәмә ел буйларына аңлаша алмыйсыз. Начарлык телиме инде ул!

Х ә с ә н. Мин аңардан туя башладым, Ләйсән. Эш шул тикле күп. Кылны кырыкка ярырдай чагымда, әбкәй, эшемне калдырып, юк сүзләре белән җанга тиеп йөри... Шуны да аңламаска, сабыймыни инде.

Л ә й с ә н. Ә Хөсәен?

Х ә с ә н. Хөсәенме? Үзең ничек уйлыйсың? Ошыймы ул сиңа?

Л ә й с ә н. Юк.

Х ә с ә н. О-hо!.. Ни өчен?

Л ә й с ә н. Андый шома кешеләрдән кечкенә чагымда ук курка идем.

Х ә с ә н. Соң, шулай булгач, Ләйсән?

Л ә й с ә н *(бүлеп)*. Юк, Хәсән, син әле мине моңа кадәр аңламый торган булгансың икән... Я әйт, кайчан минем сиңа алар кебек шома кеше бул дип әйткәнем бар? Һаман кабатлап торам лабаса: һәр нәрсәнең чамасы була. Һәр нәрсәнең!..

Х ә с ә н *(үйчан гына такмаклый)*. Әкрен кирәк, иплә кирәк... сазлыкларга батарга... һай...

Л ә й с ә н. Батмыйсың. Хәтта әнә Хөсәен булып Хөсәен дә җинаятьче түгел. Юк!

Х ә с ә н. Әле кешеләргә яхшылык та эшлиме? Барыбыз да Хөсәеннәргә әйләнеп бетсәк, синең кебекләр белән нәрсә булыр иде?

Л ә й с ә н. Элек бит син мондый түгел идең...

Х ә с ә н. Шулайдыр! Ә син башта исеңә төшереп кара... Миңа кияүгә ник чыгуңны хәтерлисеңме?

Л ә й с ә н *(көлемсерәп)*. Әйе шул. Аракы салынган бокалдан су да эчмәгән идең хәтта. Иснәп карадың да, йөзең чытып, кешеләргә сездерми генә бокалны чайкап ташладың. Көлгән идем дә соң шул чакта.

Х ә с ә н. Рәхмәт инде.

Л ә й с ә н. Саф күңелле булганың өчен чыктым мин сиңа. Әмма һәр нәрсәнең дә чик-чамасы була. Чамасы!

Х ә с ә н. Сафлыкның дамы?..

Л ә й с ә н. Пацифистлар кебек син. Алар әнә сугыш булмаска тиеш дигән фикерләре белән шул тикле мавыгып киткәннәр, хәтта туган илләренә дошман бәреп кергән халыкларга да: сугыш начар нәрсә ул, сугышмагыз дип өйрәтеп яталар. Алай булмый бит инде ул.

Х ә с ә н. Ничек була? Әниең әйткәнчә, акча белән данга гына кайтып калырга тиешме әллә бар да? Әгәр шулай булса, без иң мөһимен югалтыр идек.

Л ә й с ә н. Юк-юк, Хәсән! Кирәкми! Мин сине берәүгә дә бирергә теләмим! Ишетәсеңме?

Х ә с ә н. Ә мин сине, Ләйсән!

Л ә й с ә н. Әйдә, юләрем, чәй эчәргә!

Х ә с ә н. Чәй эчәбез бал белән, балачагасыз гына!

Л ә й с ә н. Ә мин үзем бала. Яле, әткәй, күтәреп алып чык мине. *(Хәсәннең кулларында утырган килеш.)* Тагын да югарырак күтәр! *(Хәсән күтәрә төшкәч.)* Тагын да югарырак, тагын да! Көчле дә инде син! Мине йолдызларгача күтәрә аласыңмы?

Х ә с ә н. Белмим, кызым! *(Ләйсәнне төшерә.)*

Л ә й с ә н. Күтәрә аласың... Теләсәңме, теләсәң — күкнең җиденче катына ук менгезә аласың. Мине бәхетле итәчәгеңне мин «бергә булыйк» дип әйткән чагыңда ук сизенгән идем. Әйдә, Хәсән, вакыт бит инде, күтәрел йолдызларга тиклем. Мине дә ал шунда...

Х ә с ә н. Әйдә, Ләйсән. *(Ләйсәнне кабат күтәрә.)* Я, ничегрәк анда, җиденче катта?

Л ә й с ә н. Бергә-бергә меңнек, шаккатсын әле энкәйләр, көнләшсеннәр апайлар!

Х ә с ә н. Әйдә, чәйлик әле! Аннан күз күрер...

**Почмак якка кереп китәләр. Ишектә звонок шалтырый.**

Л ә й с ә н т а в ы ш ы. Хәзер-хәзер! *(Чыга.)* Күктә кояш, җирдә гөлләр... *(Ача.)* Сезгә кем кирәк иде?

Ә м и н ә *(керә)*. Исәнмесез!

Л ә й с ә н. Хөсәен Имаевич безгә каршыда тора.

Ә м и н ә. Кем дисез?

Л ә й с ә н. Хөсәен Имаевич дим. Әнә ишеге...

Ә м и н ә. Юк, миңа Хәсән Галимович Гибатуллин кирәк.

Л ә й с ә н. Нәрсә-нәрсә? Сез кем?

Ә м и н ә. Мин — Әминә.

Л ә й с ә н. Әминә? А-аһ, сезмени әле ул, Хәсәнгә гыйшык хатлары язып торучы?

Ә м и н ә. Юк, соңгы икәве генә гыйшык хаты. Беренчеләрендә без бары археология хакында сөйләштек. Хәсән абый кебек чын археолог булырга телим мин. Ник шулай карыйсыз, апа? Мәктәптә очрашу вакытында без аның белән бик озак сөйләштек. Хатларда да... Ул мине бик яхшы белә.

Л ә й с ә н. Ә минем хатымны алдыгызмы?

Ә м и н ә. Алуын алдым да... Әмма Сез юкка шулай язгансыз. Мин бит Хәсән абыйны егет кеше дип уйлаган идем.

Л ә й с ә н. Ничә яшь соң сиңа?

Ә м и н ә. Унҗиде... Быел унынчыны бетерәм.

Л ә й с ә н. Егетне ирдән аера алмавың бик кызык инде.

Х ә с ә н *(күренә)*. И-и, менә кем килгән икән безгә! Исәнме, Әминә? Ничек килеп җиттең? Кайда урнаштың?

Ә м и н ә. Мин белергә дип кенә килгән идем. Алырсызмы икән?

Х ә с ә н. Алырбыз, Әминә, алырбыз.

Керү имтиханнарын гел бишкә тапшырсаң — алырбыз! Имтиханнарыгыз кайчан бетә әле?.. Ә-һә, димәк, көтәчәкбез.

Әминә. Алайса мин киттем...

Хәсән. Кая?

Әминә. Авылга.

Хәсән. Хәзер үкме? Юк-юк, җибәрмибез. Ләйсән, әйдәле, кунакка чәй эчер. Бик ерактан килгән бит ул. Кунып китсен.

Ләйсән. Кунып?..

Хәсән. Казанны карарга менә җай да чыкты, Әминә... Хыялланган идең. Форсатны ычкындырма.

Әминә. Рәхмәт... *(Китә.)*

Хәсән *(телефон шалтырый)*. Тыңлыйм?

Секретарьша кыз тавышы. Хәсән Галимович, котлыйм сезне!

Хәсән. Нәрсә белән?

Секретарьша кыз тавышы. Кабул итү комиссиясенең председателе итеп Карәм Фаттахыч сайланды. Үзенә ярдәмче итеп сезне сораган.

Хәсән. Рәхмәт инде.

Секретарьша кыз тавышы. Сөенәсезме?

Хәсән. Нишлим икән соң? Андый очракта нишлиләр иде соң башкалар? Өйрәт. Сөенчене беренче генә алуың түгелдер.

Секретарьша кыз тавышы. Кем ничек булдыра инде. Шулай да мин Сезгә не завидую.

Хәсән. Дөрес эшлисең. Хау ду ю ду! Ни дигән сүз була дигән идең әле? Хәзергә саубулып тор инде яме, матурым! *(Трубканы куя.)*

**Телефон кабат шалтырый. Хәсән ала.**

Тавыш. Хәсән Галимович, котлыйбыз!

Хәсән. Ничек котлыйсыз соң?

Тавыш. Чын күңелдән, Хәсән, чын күңелдән!.. Менә тыңла... ишетәсеңме?!.

**Тавышлар көчәя...**

**Пәрдә**

## Икенче күренеш

**Шул ук бүлмә. Вакыт кичкә таба. Имтиханнар башланырга унбиш-егерме көн калган.**

Хәсән *(телефоннан сөйләшә)*. Унсигез көн! Тагын унсигез генә көн калды дим. Менә шунда килерсез! Күрербез шундый да кадерле улыгызны...

Нечкә тавышлы кеше. Димәк, өметләнә алам?!.

Хәсән. Әйттем бит, анысын уйламагыз да! Юк!

Нечкә тавышлы кеше. Ике тәнәнгәме?!. Коры ел бит... Слушай, кайда гына үстең син?.. Инде, алайса, өч! Миннән булсын яхшылык. Я, өч тәнән бал?!.

Хәсән. Тинтәк.

Нечкә тавышлы кеше. Нәрсә дисең, Хәсән Галимович?!.

Хәсән. Тинтәк, дим!

Нечкә тавышлы кеше. Ә-ә, аңлашыла, күптән шулай диләр аны... Теләмисең икән, үзеңә кара. Мин бит әнә синең ашказаның авырта дигәннәреннән чыгып планлаштырдым... Ярар, слушай, болай итик алайса: бөтен уку елы буенча син зимагурны симез сарык ите белән тәэмин итеп торыйм, ә?! По рукам?

Хәсән. По шею! *(Трубканы куя. Телефон янә шалтырый, Хәсән трубканы алмый гына үзалдына сүгенә.)* Хәсис. Сорыкорт. *(Телефон шалтырый.)* Кандала! *(Телефон шалтырый. Хәсән трубканы ала да каты итеп кычкыра.)* Шалтыратма! *(Куя, телефон тагын да тырышыбрак шалтырый. Хәсән аның шнурын розеткадан тартып чыгара.)* Менә бик күп шалтыратсагыз! Звонок?.. *(Аптырап.)* Бу ни дигән сүз инде? Ә-ә. *(Абайлап, ишеккә борыла.)* Керегез!

Калын тавышлы кеше *(керә)*. Хәерле кич, хөрмәтле Хәсән Галимович!

Хәсән. Исәнмесез... Сез кем буласыз?

Калын тавышлы кеше. Роберт Сабитович Сезгә шалтыратмадымыни?

Хәсән. Бүген иртәдән бирле шалтыраталар. Кайсысы Роберт Сабитович булгандыр — белмим. *(Кырку.)* Ни йомыш?

Калын тавышлы кеше. Үтенәм, килегезче бире. Әнә, күрәсезме!..

Хәсән. Нәрсә күрәсезме?

Калын тавышлы кеше. Үтенәм Сездән, килегез тәрәзәгә...

Х ә с ә н. Шуннан?

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Әнә ишеге ачулы «Жигули» тора! *(Түбәнгә кычкыра.)* Игрик! (Х ә с ә н г ә.) Әнә... әнә борылды. Ничек моңсу гына карап тора. Улым, бердәнбер улым. Бик авыр көннәре шул. Юк-юк, Сез күренмәгез, күренмә. Күреп калса, бетте баш. Бер дә үз эшенә тыгылганны яратмый. Ут, су һәм бакыр трубалар аша үткән егет. Шулай да моңсу... Чөнки, әле аның бу кадәр авыр хәсрәткә юлыкканы булмады...

Х ә с ә н. Беттеме?...

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е *(тәрәзәдән түбәнгә)*. Игрик улым, бар-бар... Әнкеңә әйт, барысын да хәзерләсен... Патшаларча!..

**Кузгалып киткән машина тавышы.**

Х ә с ә н. Беләсезме, нәрсә...

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Ашыга ул. Яшьләрнекен үзең беләсең... көтәләр... Өйдән әнә туп-туры аэропортка...

Х ә с ә н. Мине дә тыңлагыз әле...

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Экзаменнарга кайтып өлгерер ансы, өлгерер, аңа чаклы әле унсигез көн бар, тик барыбер... *(Куеныннан зур бер фото чыгара.)* Менә, менә бит ул нинди...

Х ә с ә н. Күрәсем дә килми.

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Анда, приемныйда диюем, кеше башында кеше утыра. Шуның өчен хәзердән үк, бик һайбәтләп карап калуыгыз мөһим.

Х ә с ә н. Чыгып кит!

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Сабыр ит!

Х ә с ә н. Олак хәзер үк, имансыз!

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Чү-чү. Җикеренмә... Кем белән сөйләшкәнеңне бел!

Х ә с ә н. Ах, әле Сез шундый мөһим кешемени?.. Хәзер алайса, мин Сезнең белән сөйләшергә тагын да мөһимрәкләрен чакырам! *(Телефоннан шалтырата.)* Алло, милиция!

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е *(йөрәген тотып)*. Аһ, ух, у-у-у-у.

Х ә с ә н *(борыла)*. Ни булды? Алдашма! *(Шалтыратырга тырыша.)* Нәрсә соң бу?.. Ә-ә. *(Трубканы өстәлдә калдырып шнурны розеткага тоташтыра.)*

Н е ч к ә т а в ы ш л ы к е ш е *(кабат сөйли башлый)*. Син инде, тыңла инде, слуший.

Х ә с ә н. Куй трубканы! Куй!

Н е ч к ә т а в ы ш л ы к е ш е. Син инде, ни инде...

Х ә с ә н *(тагын барып өзә. Чыгарга бара. Калын тавышлыга)*. Хәзер, милиция хәл итәр!

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Уф, у...

Х ә с ә н. Кәмит уйнама монда. *(Карап тора.)* Әллә...

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Әйе, йөрәк... приступ.

Х ә с ә н. Менә инде... *(Су сала.)* Даруыгыз кая?

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Ә, ул, ни... Ашыгу аркасында... Шул улым өчен борчылып... Ох!

Х ә с ә н. Су булса да эчегез.

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Рәхмәт, рәхмәт Сезгә чын күңелдән.

Х ә с ә н. Юк эш белән йөрисез...

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Бала, ай, балалар... Аннары хатын! Нишләргә дә белгән юк. Бит үзем дә бик четрекле тормыш юлы үттем шул мин, братан.

Х ә с ә н. Күптән шаярамы?

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Кем? Минем малаймы?

Х ә с ә н. Йөрәкне әйтәм?

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Ә-ә. Әйе, братан. Үземә дә бик җиңел булмады. Замана, ай, замана... Шулай. Менә соңгарак таба үзе болай ярыйсыланды. Улым да армиядән кайтып төште. Дөрес, ул үзе бер борчу миңа. Хыялый, романтик... Төннәрен бәргәләнеп чыга. Стена аша ишетәм, ах-ух килә... бетерә ул үзен, бетерә!.. Бүлмәсенә керсәң, нәкъ синең бүлмә күк: анда китап, монда китап, тегендә китап... Алып кына китмәсәләр ярар иде малайны... теге йортка...

Х ә с ә н. Ник алсыннар ди?

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Көн тукыйм, төн тукыйм — тыңлау юк. Кабат-кабат әйтеп карыйм: археология ул дим, син уйлаганча үк җиңел кәсеп түгел ул, дим. Аңа кирәкле чыдамлык, сабырлык, түземлек безнең беребездә дә юк ул, дим.

Х ә с ә н. Ә ул?

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Аның үзенеке лә. Янәсе археология — чорыбызның иң мәгънәле фәннәреннән берсе! Ишетәсеңме: мәгъ-нә-ле! Тфү! Юк, бу берничек тә минем башка сыймый...

Х ә с ә н. Хикмәтле эш михнәтле була...

Қ а л ы н т а в ы ш л ы к е ш е. Анысы шулайдыр шулаен, әмма дә менә бу ягы да бар бит әле аның: алмадай сылу хатыныңны, сөйкемле балаңны бер күрергә тилмер, имеш. Өчәр ай буйларына салкын палаткаларда, яңгыр асларында шакраеп

кат һәм каберлекнең мәет сөякләре белән аралашкан шакшы пычракларында чокчынып ят имеш...

Хәсән *(су бирә)*. Тагын азрак эчмисезме?

Калын тавышлы кеше. Нәрсә? Ә-ә... Уза ахры, рәхмәт. Э-эх, дускай, дускай, рәхәтләнеп тынычлыкта гына, тормыш мәшәкатьләреннән бөтенләй-бөтенләй читтә генә, бәхетле иттереп, килгәненең көен китереп, эчеп, ашап, типтереп яшәп ятасы урында — юк! Археолог булалар. *(Авыр сулап.)* Анасы ла, анасы бозды, каһәр суккан нәрсә... Хатын-кыз тинтәк бит, братан. *(Нечкә тавыш белән, хатыны булып.)* Мәңгегә бәхетсез итәсең баланы... Бәлкем аның призваниесе шулдыр. Бәлки, бәлки... Гомумән безнең өйдән тынычлык та, татулык та, бәхет тә качты хәзер. Ашыйм дисәң аш үтми, йоклыйм дисәң — йокы юк.

Хәсән. Кая, рәсемен бирегезче.

Калын тавышлы кеше. Фотосынмы?.. Хәзер, хәзер, иптәш доцент. Менә, менә!

Хәсән *(карый)*. Mhe... Димәк, ул...

Калын тавышлы кеше. Әйе, әйе! Тик... тик син... Сез бушка дип уйламагыз. Ю-ук, яхшылык җирдә ятмый ул. Бер-береңә ярдәм кулы сузмасаң хәзер... Дуслар булсын... Дуслар яшәсен. *(Йөгереп чыгып китә дә, ухылдый-ухылдый, иданнән сөйрәтә-тәгәрәтә олы бер төргәк кертә.)* Менә, братан, рәхәтлән! Син бит хәзер үз кеше. Үз кеше!

Хәсән *(шактый аптырап)*. Сез нәрсә?

Калын тавышлы кеше. Белеше кайда — йомышы шунда, танышы кайда — табышы шунда. *(Күзе идәндә.)* И-и, кара инде бу паркетыгызны... *(Көлә.)* Кирәле дә чыгалы...

Хәсән. Син... Сез!

Калын тавышлы кеше. Бик аңлыйм, аңлыйм, ачуланмаслыкмыни соң... бик ачуланырлык. Син хаклы, хаклы братан. Әй-йе, безнең дуслар мондый төнтек бүлмәдә яшәргә тиеш түгелләр... Ремонтчылар җибәртәм. Иртәгә үк. Юк, бүген үк! *(Телефонга барып тотына.)*

Хәсән *(үзен тыныч тотарга тырышып)*. Мә рәсемеңне!

Калын тавышлы кеше. Кара, кара, әйбәтләп кара, юкса, приемныйда үзең беләсең! *(Шнурны розеткага тоташтыра.)* Куегыз әле трубканы, ишетәсезме! Сезгә әйтәләр бит!..

Хәсән. Ал дим бу сурәтеңне!

Калын тавышлы кеше *(сискәнеп борыла)*. Нәрсә? *(Күзгә-күз карашып торгач)* Әгәр инде... әгәр алай азсынасың икән... рәхим ит — бөтен уку елына симез сарык ите синә... Теленне йотарлык...

Хәсән. Кит аннан!.. *(Капыдт көләргә тотына.)* Симез сарык ите дин. Бөтен уку елына... тел йотарга...

Калын тавышлы кеше *(бергә көлә, бергә кабатлый)*. Бөтен уку елына... Ха-ха. Башкалар базардан бишәр сумга эзләп йөрсеннәр, ә син — ха-ха!..

Хәсән *(көлүдән тuктый)*. Бар, чыгып кит!

Калын тавышлы кеше. Тукта, әйтеп бетермәдем әле. Беләсеңме, нәрсә тагын, мебель табам! Монда бит аның әсәре дә юк.

Хәсән. Ах... сатыйм! *(Төргәкка барып тотына, ә ул кеше кутәрерлек түгел. Калын тавышлыга.)* Тот теге башыннан.

Калын тавышлы кеше. Брат! Братан дим... Ни булды сиңа? Әле генә бик җайлы идең бит. Аңла инде... Өйдә мине асып куюлары бар бит. Йокы юк, ашау юк...

Хәсән. То-о-о-от!! *(Төргәкне этә төшә.)*

Калын тавышлы кеше. Суйдырасың! *(Төргәкне тота, тик кире якка этә.)* Хатын әнә әйтә: туган халкыбызга гомерен дә жәлләми ул безнең малай, ди...

Хәсән *(төргәкне кабат ишек ягына этәрә)*. Этмә — тарт! Үзеңә тарт! Ант итеп әйтәм, хәзер милиция чакыртам.

Калын тавышлы кеше *(тәмам кәефе кырылып)*. Непутевый паразит син! Оберхапуга! Парткомга керәм... Министрның үзенә барам... Белсеннәр кемлегеңне! Судка тартам! Әйе, безнеңише простой кешеләрне типкәләп йөртүчеләрне өйрәтсеннәр азрак! Бик узындылар.

Хәсән *(телефонга юнәлә. Шнурны розеткага тоташтыра)*. Хәзер милиция килеп җитәчәк.

Гайрәтле тавыш *(телефоннан)*. Кайтып җиттеңме, галим кисәге! Бәхетең бар икән. Ярый-ярый! Но кара аны, көн бүген генә түгел! Бер качарсың, ике... И белеп тор: мин сине өеңнән чыгып йөрмәслек итәм! Син әле урамда барганда да артыңа борылып карый торган булырсың!..

Хәсән *(трубкасын ташлый)*. Вәт хулиган!..

**Телефон янә шалтырый.**

Калын тавышлы кеше. Я, Хәсән Галимович, булышыгыз инде. Зинһар, булышыгыз!

Хәсән. Булышыргамы?! *(Кинәт әллә*

*каян килгән көч белән төргәкне күтәрә дә ачык тәрәзәдән урамга ташлый.)* Булдымы?

Калын тавышлы кеше. Нишлисез сез! Нишлисез, әй!

Хәсән *(аның өстенә кила)*. Әйдә, үзеңне дә!

Калын тавышлы кеше. Кирәкми, мин үзем. *(Урамга сикерим дигәндә курткасы белән тәрәзә төбенә эләгеп кала. Бик куркынып.)* О-һо, бу икенче кат икән!

Хәсән *(аңа кире менәргә булыша башлый. Шул вакыт сөйләнә)*. Кандала бит син. Халык җилкәсен кимерүче...

Калын тавышлы кеше *(шулай ук ачусыз гына)*. Ә син — хәерче интеллигент.

Хәсән. Кеше хакын ашыйсың бит син болай!

Калын тавышлы кеше *(зур ачыш ясагандагы сыман тавыш белән)*. Ә сезнең ишеләрне ачтан интектерергә кирәк! У-ух, менә ит чиратында тора башласаң, мине сагынырсың әле, аңларсың!..

Хәсән. Тизрәк маташ, вакытым юк.

Калын тавышлы кеше. Братан. *(Инәлеп карап тора.)*

Хәсән. Ул хакта бетте дидем.

Калын тавышлы кеше. Мин бит үзеңне җәллим. Тәкәббер җан! Сине җәлләп...

Хәсән *(тәмам аптыраган)*. Бар икән күрәселәр. *(Тегене капылт тотып селки.)* Кандала!

**Калын тавышлы усал кыяфәт ясап кизәнә, Хәсән исә аны ычкындыра һәм зур гәүдә аска төшеп китә.**

Хәсән *(борчылып)*. Муенын сындыра инде мөртәт! *(Тәрәзәдән карый. Телефон шалтырый. Алып.)* Тыңлыйм? Ник дәшмисез?

Арыган кеше тавышы. Сезнең кәефегез начар ахры, Хәсән Галимович?

Хәсән. Минем исемемне каян беләсез? Кем сез?

Арыган кеше тавышы. Вакытыгыз бармы хәзер?..

Хәсән. Минем вакытым сезгә нәрсәгә, һәм, гомумән, бу нәрсә дигән сүз?

Арыган кеше тавышы. Мин министерстводан гына шалтырата идем. Безнең монда киңәшмә бара...

Хәсән *(трубканы куя)*. Ну, утырыгыз шунда матур гына киңәшмәгездә. *(Телефон кабат шалтырый.)* Бу тагын сезме? Ничек инде сез,— шундый мәртәбәле киңәшмәләрдә утыра торган кеше — аңлый алмыйсыз! Юк минем вакытым.

Арыган кеше тавышы. Минем дә вакытым юк, Хәсән Галимович. Әйдәгез, иң яхшысы, очрашыйк. Сезне алырга кайчанрак машина җибәрим?

Хәсән. Гафу итегез, әмма мин трубканы куям.

Арыган кеше тавышы. Юк, юк, куймагыз, Хәсән Галимович!

Хәсән. Сез үзегезнең нишләгәнегезне беләсезме?!.

Арыган кеше тавышы. Туктале, минем белән алай сөйләшмә. Кем икәнемне дә белмисең бит.

Хәсән. Кызганычка каршы белдем инде!.. *(Трубканы куя.)*

**Телефон кабат шалтырый.**

Хәсән *(алып)*. Әйе, тыңлыйм!

Нечкә тавышлы кеше. Слуший, син безне рәнҗетмә инде. Үзеңне күреп сөйләшәсе ие... Зинһар! Ну, нәрсә дәшми торасың инде, Хәсән Галимович. Килештекме? Слуший, ялынып сорыйм, рәнҗетмә.

Хәсән. «Слуший», мин синең үзеңнән ялынып үтенәм, өч ай бит инде, өч ай менә сулыш алырга ирек бирмисең! Зинһар, тагын шалтыратма! *(Трубканы куя.)* Әллә акылдан язганнар инде бар да!?.

**Хәсән ачык тәрәзәгә бара. Ләйсән кайтып керә. Кулында чебурашка.**

Ләйсән *(шат)*. Хәсән, карале, бу нәрсә?

Хәсән. Бумы — мин!..

Ләйсән *(көлә)*. Ә кем бирде, беләсеңме?

Хәсән. Әнием инде, тагын кем булсын.

Ләйсән. Юк шул. Мин беләсеңме кемне очраттым!?

Хәсән. Берәр классташ кызыңны.

Ләйсән. Һаман классташ кызларымны очратып тормам бит инде...

Хәсән. Ә, әйе, шулай шул.

Ләйсән. Нина бирде моны миңа. Нина.

Хәсән. Кайсы Нина?

Ләйсән. Квартирада торган идек бит инде! Тегесендә түгел. Без анысында ярты гына ел яшәдек.

Хәсән. Пассаж янындагысындамы?

Ләйсән. Нәкъ үзе. Безне кунакка чакырдылар. *(Ишектә звонок. Ләйсән ачарга бара.)* Хәзер үзләренә яңа фатир биргәннәр. Күрсәң — өч бүлмәле! Светланалары да бик зур кыз булган... *(Ишекне ача.)* Әни! Әйдә уз, әни.

Зилә. Исән-саулар гына торамсыз?

Хәсән. Саумы, әбкәй. *(Телефон шалтырый, Хәсән ала.)* Әйе?

Нечкә тавышлы кеше. Слуший, минем башта бүтән бер план кебек нәрсә туды бит әле, Хәсән Галимович. Әгәр менә болай итсәк, ничек булыр?..

Хәсән *(трубканы куя).* Валлаһи, икебезнең беребез тиздән юләрләр йортына керәчәк.

Зилә. Кызым, ник соң син иреңә бер дә булышмыйсың? Менә бу телефон кырында җавап биреп утыра алыр идең... Хәсән бит хәзер әнә нинди кирәкле кешегә әверелде.

Хәсән *(күңелсез көлеп).* Әйе, шундый да кирәклегә әверелде, хәтта ки ашатмый да башладылар.

Зилә. Кызым, ни карап торасың?! Бердәнбер иренне шулай ач йөртергә рөхсәтем юк. Бар, тизрәк. Бар дим. *(Ләйсән почмак якка кереп китәч.)* Корырак тот, Хәсән кияү. Без хатыннар шуны яратабыз.

Хәсән. Рәхмәт, әбкәй, истә тотармын. *(Китаплар актара. Телефон шалтырый.)* Валлаһи, үтерәләр икән...

Зилә. Борчыла күрмә, Хәсән кияү. Парад белән үзем командовать итәм. *(Нәзакәтле кыланып телефонга килә.)* Алло? Зилә Бишевна тыңлый.

Нечкә тавышлы кеше. Сез кем соң?

Зилә. Хәсән Галимовичның әбкәсе.

Нечкә тавышлы кеше. Миңа әбкәсе кирәкми... Үзе кая?

Зилә. Кирәкмәсә инде... *(Трубканы куя.)*

Хәсән. Молодец, әбкәй.

**Телефон шалтырый. Почмак яктан Ләйсән күренеп ала.**

Ләйсән. Әни, Алия апа керсә, миңа әйтерсез.

**Телефон кабат шалтырый.**

Зилә *(ала).* Тагын сезме? Больше шалтыратмагыз!

Арыган тавыш. Гафу итегез, бу Хәсән Галимовичлар фатирыдыр бит?

Зилә. Сез кем?

Арыган тавыш. Хәсән Галимовичка әйтегез, зинһар: безнең киңәшмә бетте.

Зилә. Нинди киңәшмә?

Арыган тавыш. Ул белә. Кайсысын уңайрак күрер икән: мин министерствода көтеп торыйммы, әллә дә булмаса...

Зилә. Нигә көтәсез аны?..

Арыган тавыш. Ул в курсе... Машина җибәрергәме икән?.. Кай вакытка? Зинһар, мөмкин булса, сорагызчы.

Зилә. Яхшы. *(Трубканы томалап, Хәсәнгә.)* Министерстводан...

Хәсән. Булмагае, шайтанымнан булсын... Куй, әбкәй, трубканы.

Зилә. Яхшы. *(Сак кына куя.)* Кызык икән.

**Алия керә**

Алия. Исәннәрмесез! Аптырап калдыгызмы? Ишегегез ачык калган ич.

Хәсән. Хәерле кич!

Зилә. Исәнме, Алия, саумы, әйдә түрдән уз!

Алия. Рәхмәт. *(Утыра.)*

**Телефон шалтырый. Зилә мөһим кыланып трубканы ала.**

Зилә. Әйе, тыңлыйм сезне!?

Гайрәтле тавыш. Тыңлатырмын мин сиңа! Бир телефонны хәзер үк үзенә. Әгәр ул тагын мине мыскыл итсә, башына кирпеч төшәчәк. Яки мин аны беренче очраган антеннага асып куям!..

Зилә. Туктагыз әле...

Гайрәтле тавыш. Әллә сезгә дә кирәкме?

Зилә. Абау, нинди кеше булды бу? Вәт хулиган! *(Трубканы куя.)*

Алия. Борчыйлармы?

Зилә. Сөйләмә дә инде, Алия. Хәсән кияүгә сабырлык кына бирсен. *(Почмак якка карап.)* Кызым! Ләйсән!

Ләйсән тавышы. Алия апа кердеме әллә? Хәзер-хәзер, Алия апа! *(Күренә.)* Улың кайда, Алия апа?

Алия. Хәзер кайта...

Ләйсән. Ай, хәзер чыгам мин. *(Кабат почмак якка кереп китә.)*

Зилә. Чыннан да, Алия, ул улыңниндирәк инде хәзер? Бер дә күргән юк үзен?

Алия. Безнең үзебезнең дә рәтләп күргән юк аны. Әле тренировка, әле соревнование. Баштарак бокс секциясенә йөрткән идек, аннан хоккейга күчте, футбол да уйнап карады... Инде хәзер әнә штанга күтәрә.

Зилә. Күпкырлы икән...

**Ләйсән чыга.**

Алия. Тырышабыз инде. Зур культуралы, бүгенгедәй киң диапозонлы кеше итәргә исәбебез. Әле соңгы вакытларда чит ил телләрен өйрәнә башлады. Немец белән инглизнекен. Ул аның өйрәтүчеләренә күпме расход түккәнебезне белсәгез... Бернәрсә дә жәл түгел. Кеше генә булсын!

Зилә. Шулай-шулай, балаларны кеше итү бүгенгесе көндә авыр.

Алия. Бик авыр...

Л э й с ә н. Әмма кеше итәргә кирәк, Алия апа, кирәк!

Х ә с ә н. Ләйсән, нәрсәдер яна түгелме соң анда?!.

Л ә й с ә н. Ай, бәрәңгем көя! *(Йөгереп кереп китә.)*

А л и я. Бәрәңге каян аласыз?

З и л ә. Каршыдан гына. Быел бер дә уңмаган.

А л и я. Шулайдыр шул. Безгә болай сайлап кына кертеп бирәләр. Зәйнәп түтигә әйтсәң әнә, шул минуттук...

З и л ә. Зәйнәп — үз кеше. Кыскасы, Алия, дипломсыз ни алга, ни артка?

А л и я. Элек хет алтын медальлене экзаменсыз гына да...

З и л ә. Күбәйде шул, алтынлылары да күбәйде.

А л и я. Кайда да танышлык кирәк.

З и л ә. Бер-береңә ярдәм кулы сузмасаң хәзер...

А л и я. Шулай-шулай, бер-береңне онытырга ярамый.

**Поднос күтәреп, Ләйсән чыга.**

Л ә й с ә н. Әйдәгез әле, рәхим итегез!

Х ә с ә н *(урыныннан торып)*. Мин кухняда ашыйм.

Л ә й с ә н. Ничек инде, Хәсән?..

Х ә с ә н. Хатын-кызлардан авызым ояла. *(Кереп китә. Подносын тоткан Ләйсән дә иярә.)*

З и л ә. Тәмам башы әйләнде Хәсән кияүнең. Тегеннән тарткалыйлар, моннан йолкалар. Әле дә ярый янында Ләйсән бар.

Л ә й с ә н *(чыга)*. Гафу итегез инде, Алия апа, Хәсән...

А л и я. Мин ашарга дип кермәдем.

З и л ә *(Ләйсән муенындагы муенсаны күреп)*. Абау, күрми дә торам. Нинди затлы нәрсә бу синдә?

Л ә й с ә н. Килешәме?

З и л ә. Килешә генәме!..

Л ә й с ә н. Алия апа!..

З и л ә *(Алиягә)*. Каян алган идегез? Әйтәм, Алия апа да, Алия апа дип авыз суын корыта. Чыннан да, Алия, кайдан алган идегез?!.

А л и я. Руфисның сеңлесе инде. Чит илдә булып кайтты бит.

З и л ә. Искиткеч!

**Физат керә. Кулында биш пружиналы эспандер.**

А л и я. А-а, улым кайткан икән, улым!

Ф и з а т. Алдыгызмы?

З и л ә. Нәрсәне?

Ф и з а т. Мамуля, вакытым аз!

А л и я. Тренировкадан арыган өчен ачулана. Бигрәк ярата шул спортны. Спортны яратасың бит, улым?

Ф и з а т. Бик кирәге барые! И, вообще берни дә кирәкми миңа! Ул бит папуля белән сиңа кирәк.

А л и я *(Зиләгә)*. Шаярта. Ләйсән, Ләйсән, күр син... Әнә шуның бишесен дә тарта. Әтисеннән булмый, и миннән дә булмый...

Л ә й с ә н. Яле мин. *(Тарта алмый.)* О!

З и л ә. Каяле-кая? *(Бишесен дә тартып куя.)*

Ф и з а т. О-һо! Браво! Царь-женщина. Ә болай тарта аласыңмы? *(Тартып күрсәтә.)*

Л ә й с ә н. Физат, Хәсән абыеңа да тартып күрсәтерсең, яме.

З и л ә. Молодец, молодец. Спортсменнар университетка бик кирәк.

А л и я. Ул әле музыкант та. Абсолютный слух.

**Хәсән почмак ишеге төбенә килеп карап тора. Бүлмәдәгеләр, Физат белән мавыгып, аны күрмиләр.**

А л и я. Син әле хорга да йөргән идең, улым... яле. Я инде, ялындырма.

Ф и з а т *(бастан — баритонга, баритоннан тенорга күчеп)*. О-о-о, всемо-мо-гущий...

Л ә й с ә н. Ә эстрада?

А л и я. Иң яратканы шул инде. Әгәр университетта нинди дә булса бер ансамбль яки вокаль-инструменталь группа оештырырга җыеналар икән, бер дә борчылмасыннар.

Л ә й с ә н. Имтиханда беренче сорауны ни өчен син археолог булырга телисең дип башлап җибәрәләр ди, Хәсән.

Х ә с ә н. Ләйсән, ә менә Физатка мин беренче сорауны башкачарак итеп бирер идем.

А л и я. Рәхим итегез, Хәсән Галимович, рәхим итегез... Тик, зинһар, бик миһербансыз булмагыз инде.

Х ә с ә н. Физат, инде кергәнсең икән, сорау бирми булмас. Кем син?

Ф и з а т. Минме?

Х ә с ә н. Син, син, менә кем соң син?

Ф и з а т. Белмим.

А л и я. Ничек инде белмисең! Руфис Гатич улы диң, шартлатып әйт.

Х ә с ә н. Белмәү зур гаеп түгелдер... Синең Мисыр төркиләре хакында ишеткәнең бармы? Мамлюклар дип йөртелгәннәр?

Ф и з а т. Шуннан?

Хәсән. Тарих раславына ышансак, алар безнең борынгы бабаларыбыз арасында шактый күренекле урынны алып торалар.

Физат. Мисыр ул нәрсә?

Хәсән. Египет.

Физат. Ник соң алайса Египет кына димисең. Ә Египет нәрсә?

Хәсән. Мисыр.

Физат. Аңлашыллы. Дәвам итегез.

Хәсән. Әнә шул мамлюклар арасында иҗат ителгән бер әкият бар: «Гәләветдин лампасы» дигән...

Физат *(шаяртуын дәвам итә)*. Ә мин татарча укый белмим. Ә нәрсәгә миңа лампа? Электричество бар ич. Электричество яшәсен!

Хәсән. Кызганыч. Әнә шул серле лампа барысын да хәл итә дә инде, Физат. Кесәңне син шул әкияттәге ахмак Гәләветдин кебек төрле ялтыравык ташлар белән тутыргансың, ә инде серле лампага анда урын калмаган. Ә безгә бит серле лампасы булган кешеләр кирәк, Физат Руфисович.

Алия. Хәсән Галимович, зинһар алай димәгез. Ала гына күрегез. Бердәнберебез бит! Әнә анда дача урыны алгансыз. Ике ел инде кысыр ята. Алыгыз Руфис абыегыздан кирәк кадәр средство. Бөтен яклап булышыр!

Хәсән. Бу бит ришвәт санала, Алия ханым. Взятка.

Ләйсән. Син ни сөйлисең, Хәсән!

Хәсән. Кушылма, Ләйсән!

Алия. Түгел, түгел! Нинди взятка ди. Без бит дуслар. Күршеләр. Күрше — кардәшлектән дә өстен. Зинһар ал!

Хәсән. Өстен микән, Алия ханым?

Физат. Ха-ха-ха! *(Хәсәнгә шыпырт.)* Ал, ал! Акчасы күп аның... Теләгән кадәрле ал!

Хәсән *(ишекне барып ача)*. Күршелектән өстенрәк тагын бер нәрсә бар, Алия ханым, ул — кешелек дип атала. Хушыгыз, Алия ханым!

Алия. Куасыңмы?

Хәсән. Кумыйм, хушлашам гына.

Алия. Ярый-ярый, хушлаш. Бик олыладың күрше апаңны. Бик олыладың. Рәхмәтен соңрак ишетерсең.

Физат. Ха-ха! Хәтта минем әнине дә куып чыгарып була икән. Бу миңа ошый. Сез миңа ошыйсыз, Хәсән Галимович! Беләсезме, минем әнине берәүнең дә куып чыгаралганы юк! Әйтегез әле, ә нәрсә ул археология? Сез алтын эзлисезмени? Ну, яхшы алайса, икенче вакытта. Сез миңа керәп йөрергә рөхсәт кенә итегез, о'кеймы?

Хәсән. О'кей! *(Физатны чыгарып җибәрә дә, ишекне ябып куя.)*

Ләйсән *(әрнеп)*. Хәсән! Ник син безне кеше алдында рисвай иттең?!

Хәсән. Базар ачкансыз монда! Әллә мине юләр дип белдегезме, шуны да аңламаска!

Зилә. Юләр шул, томана! Нинди дәрәҗәле кешенең хатынын куып чыгарды бит. Моның өчен дурак булырга кирәк!

Хәсән *(ишекне киереп ача)*. Әби, вон! Эзең дә булмасын бу йортта!

Зилә. Томана, миңгерәү, мокый, ахмак!..

**Бусагада Хөсәен күренә.**

Хөсәен. О-о, Зилә ханым! Сез соң кая болай бик кызу гына?!

Зилә. Ки-ит, кит! *(Чыгып китә.)*

Ләйсән. Әни, тукта инде, әни! *(Артыннан иярә.)*

Хөсәен. Эх, Хәсән, Хәсән! Мена монысы кирәкмәс иде!.. Монысы артык, артык!

Хәсән. Башымны катырып йөрмә!

Хөсәен. Кичке обход! *(Утыра.)*

**Телефон шалтырый, Хәсән алмый. Тагын шалтырый. Хөсәен барып шнурын розеткадан ала.**

Хәсән. Ничәме ай буйларына иртә димәгән, кич димәгән звоноклар. Куркыту, янау, ялыну, ялвару!..

Хөсәен. Күңеленә артык якын аласың...

Хәсән. Реаль эшме соң бу, Хөсәен? Чыннан да мин аларның бөтенесенең балаларын урнаштыра аламмы?

Хөсәен. Ну ярар, диген... Керсә, керә, кермәсә инде, булмады, агайне, дисең, тырыштым дисең...

Хәсән. Бөтен эшләрен ташлап, айлар буена котырышып йөриләр. Юләргә саныйлармы әллә мине. Дүрт ай буе миңа бөтенләй таныш та булмаган әллә кемнәр сәлам бирә. Кемнәрдер мине сыйларга тели...

Хөсәен. Минем баштан үткән нәрсә бу. Ә син аңа игътибар бирәсең. Чепуха! Ну, бая әнә ит чабучыны куып чыгардың... Бу юл белән ни дә булса майтарырмын дип уйлыйсыңмы? Тагын бу күрше хатын Алия! Ну! Бәлки аларның балалары чыннан да археологтыр! Ә хәзер әнә ул итче өенә кайта да синең өстән бөтенләй бул-

маган нәрсәләр уйлап чыгарып, деканатка хат язып җибәрә. Анонимканың нәрсә икәнен беләсең бит инде син!.. Ә тегеләй, мин әйткәнчә, әйберен алып, ярар, брат, тырышып карарбыз дип калган булсаң, хәзер бернинди нервы түкмәс идең. Карама миңа, карама шулай, мин уйлап чыгарган нәрсә түгел — тормыш законы. Башкача булмый, Хәсән. Без кешеләр белән яшибез. Кешеләр катлаулы. Алар белән аралашмый гына яшәп булмый. Без бер-беребезгә менә болай бәйләнгәнбез! *(Бармакларын бармакларга кидертеп тартып куя.)* Карале, серле дустым. Минем анда ике малай бар. Акбаров Фәрит белән Валера Иванов. Син ни инде, аларны ал!

Хәсән. Нәрсә? Син, Хөсәен! Кызык! Итең бармы соң яки маен? Бәлкем дача салып бирерсең?!.

Хөсәен. Юк ла инде, шаяртам гына!

**Ләйсән керә.**

О, Ләйсән, сез тагын да чибәрләнеп киткәнсез димме? Ә-ә, әнә нәрсә. Муенса! *(Билгеле җырның сүзләрен көйләп куя.)* Муенса! Муенса! ... муенса, шаңгап. Бездә алай ук нәфис эшли алмыйлар...

Хәсән. Муенса? Нинди муенса?

Ләйсән. Бәйләнми генә тор әле!

Хәсән. Каян килде бу сиңа?

Ләйсән. Инде мине дә куып чыгарырга телисеңме?

Хәсән. Бар, хәзер үк, каян алдың, шунда илтеп бир!

Ләйсән. Бирмим!

Хәсән. Бирәсең!

Ләйсән. Кычкырма! Мин сиңа кем?

Хәсән. Нинди акмак син! Бир монда!

Ләйсән. Кагылма миңа!

Хәсән. Шулай да бир, Ләйсән!

**Ләйсән, муенсасын салып, Хәсәннең аяк астына ташлый да юыну бүлмәсенә кереп бикләнә. Хәсән иелеп муенсаны ала да озак кына сүзсез тора.**

Хөсәен. Да-а, хәлләр булачак икән.

Хәсән. Нәрсәләр булачак?

Хөсәен. Менә шул дурак әйтте диярсең, булачак...

**Пәрдә.**

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Өченче күренеш.

**Кызу имтихан көннәре. Вакыт кичкә таба. Ләйсән өйдә ялгызы гына. Туктаусыз телефон шалтырый. Ләйсән алмый.**

Зилә *(килеп керә)*. Шул йозагыгызны тәки рәтли алмадыгыз инде. Ир кешесе булган өйгә бер дә килешми, кияү! *(Ләйсәнгә.)* Әллә үзең генәме? Теге кыз да кайтмадымы? Нәрсә дәшмисең? Әле генә Алияне күрдем, Хәсән бу юлы да Физатка начар билге куйдырткан! Нәрсә булды соң сиңа? Үзең гаепле, әйтә килдем. Күптән икенең берен сайларга иде! Синең бәһаң бит монда ноль! Ноль син! Менә нинди хәлгә калдырды сине яраткан Хәсәнең!

**Бер кочак чәчәк күтәргән Әминә йөгереп керә.**

Әминә. Бүген минем иң бәхетле көнем! Ләйсән апа! Ә-ә, Зилә апа да килгән икән! Исәнмесез! Хәсән абый кайтып җитмәдемени? Ләйсән апа, менә бу сезгә! Алыгыз, мәгез инде! Гладиолуслар яратасыз бит. Хәзер мин аларны суга... *(Тиз-тиз почмак якка уза да, ваза алып, юыну бүлмәсенә кереп китә.)*

Зилә. Ничек өзелеп тора. Кичә, беләсеңме, миңа нәрсә әйтте... «Ник ул хәтле Хәсән абыең тирәсендә бөтереләсең, башын әйләндереп куйма тагын...» — дигән идем,— «Нәрсә, мин баш әйләндермәслек кызмыни?» — ди. Хәсәне тагын — авызы колагына җиткән. Ничек түзеп торасыңдыр. Синең урыныңда булсам, бу Хәсәнне бик ныклап өйрәтер идем. Хәзердән үк чара күрмәсәң, тәмам оятсызланачак ул. Ник дәшмисең, әллә телеңне йоттыңмы?.. Уйлашырга кирәк. Хөсәен өйдәме икән? Тукта кереп чыгыйм әле. *(Ишеккә юнәлә.)*

Әминә *(күренә)*. Бишкә бирдем. Тагын икәү генә калды.

Ләйсән. Аларын да бишкәдер инде?..

Әминә. Әлбәттә, иң курыкканым бүген иде...

Ләйсән. Димәк, үтәсең инде?

Әминә. Әйе! *(Җырлап әйләнә.)* Иң бәхетле көнем бүген! Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!.. Әллә нигә бик-бик шатланасы килә. Хәсән абый ник кайтмый икән инде? *(Кулындагы чәчәкне Ләйсәнгә бирергә тырыша.)*

та берни дә аңламыйсың, әллә инде аңлап та башыңны юләргә саласың?

Әминә. Ни булды, Ләйсән апа?

Ләйсән. Бәлкем сиңа булышканнардыр, Әминә. Физат ишеләр бер-бер артлы начар билгеләр алганда, авылдан гына килгән ниндидер бер кыз гел бишлегә бирел барсын имеш. Анда бит бер урынга житмешәр абитуриент. Син үзеңне әллә алардан өстенрәк диеп уйлыйсыңмы? Шулай да гел бишкә?!. Димәк, булышалар?!. Хәсән абыең?!.

Әминә. Физатлар алар матур һөнәр дип кенә килгәннәр. Әгәр Хәсән абыйлар казынып яткан җирләрне барып күрсәләр, белерләр иде ничек матур булганын.

Ләйсән. Нәрсә, син әле теге чакны Хәсән абыеңның казынып яткан җирләренә дә барып йөргән идеңмени?

Әминә. Экскурсия оештырып бардым. Теләгәннәрдән.

Ләйсән. Әминә, акыллым, телисеңме, мин сине бер егет белән таныштырам. Ул да Хәсән абыең кебек археолог. Дөрес, аның яше байтак инде. Әмма Хәсән абыең белән бер яшьтә ул. Аның ике бүлмәле квартиры да бар, өйләнмәгән дә.

Әминә. Ләйсән апа... *(Тотлыга төшеп.)* Шул-лаймыни?.. *(Кинәт ирония белән.)* Ә нигә ул ике генә бүлмәле? Аз ич ул?!.

Ләйсән. Мин сиңа чын күңелдән. Хәсән бит сине ярата, ярата!

Әминә. Әгәр гафу үтенмәсәм икән. Сез дә мине аңлагыз инде, Ләйсән апа: ник кабат әйтергә ди. Ялгышасыз, Хәсән абый Сезне, ярата, Сезне.

Ләйсән *(елап җибәрмәс өчен көлә башлый).* Ярата, ярата... ярата имеш! Ха-ха-ха... Уф, үләм!.. Ха-ха-ха.

**Зилә белән Хөсәен керә.**

Хөсәен. Кичке обход!

Зилә. Күр әле, көлә бит! Дөньясының асты өскә килеп бара, ә ул...

Хөсәен *(почмак якка).* Кичке обход дим бит. Бу тагын ниткән тәртипсезлек!? Хәсән күптән өйдә булырга тиеш иде...

Ләйсән. Аңа хәзер алла да юк, мулла да юк.

Зилә. Ә кем гаепле соң!.. *(Әминәгә.)* Син чыгып тор әле бар! Кеше сөйләшкәнне тыңлап тору — культурасызлык ул. Нәрсә катып торасың, бар дим бит.

Әминә. Кая барырга кушасыз?..

Зилә. Кая теләсәң, шунда! Монда гына акаеп торма.

хакыгыз юк!

Зилә. И, ачуымны китереп торырсың! Болай да ачу килгән чак...

Әминә. Сез Хәсән абыйның кисеп ташлаган тырнагына да тормыйсыз! *(Почмак якка кереп китә.)*

Зилә. Нинди әшәке хәзерге яшьләр!..

Хөсәен. Хәсән йогынтысы!..

Зилә. Хөсәен, син бар нәрсәдән дә хәбәрдар күршебез инде. Күрше генә дә түгел — дустыбыз. Шуңа да бу өй эчендәге хәлләр сиңа яхшы билгеле. Нинди киңәш бирер идең?

Хөсәен. Кеше хәлен кеше белми, үз башыңа төшмәсә.

Зилә. Кызым, сиңа әйтә! Я, күпме көтәргә була? Нигә дәшмисең дим?! Әйдә алайса, җыен, өйгә кайтабыз!

Хөсәен. Шуннан соң ни була?

Зилә. Ни булсын...

Ләйсән. Беркая да китмим. Әйе-әйе. Яратам мин аны. Ярattым, яратам, яратачакмын да!

Хөсәен. Ләйсән әлегә болай сөйләшүгә әзер түгел, минемчә...

Зилә *(Ләйсәннең кулмакләрен алып, берәм-берәм аның үз иңенә үк ташлый башлый).* Үзе кайтканчы хәл итәргә кирәк. Я хәзер минем белән китәсең, я гомергә шул төнтек бүлмәдә саташкан иреңне саклап утырырга каласың!

Хөсәен. Бернәрсә дә аңламыйм. Китеп, ни кырырбыз диеп уйлыйсыз соң сез? Хәсән Ләйсәнне бик нык ярата, шулай булгач, китүләрнең кирәге юк.

Зилә. Яратса, бигрәк тә әйбәт! Ныграк ялынып, тизрәк акылга утырыр! Безгә шул кирәк тә менә.

**Телефон шалтырый.**

Ләйсән. Әллә Хәсән микән?! *(Куанып, телефонга килә башлый.)*

Зилә *(трубканы Ләйсәнгә бирми).* Ишетәсеңме? Әтиең янына кайтабыз. Әнә шулай итеп, Хәсәннән болайракларны да акылга утырталар хәзер. Моңарчы бер-ике китеп торган булсаң, Хәсәнең ефәк кебек булыр иде.

Нечкә тавышлы кеше *(телефоннан).* Слуший! Слуший, күгәрченем минем, кадерлем минем! Нинди генә рәхмәтләр әйтим икән мин сиңа!

Зилә. Әллә котырган инде бу! Җиттеме сезгә — юкмы?

Нечкә тавышлы кеше. Ә-э, бу

Хәсән булмадымыни әле? Әбкәй, чакыр әле Хәсәнне телефонга. Алтын кеше икән бит ул, кәлҗемә баш!..

Зилә. Өйдә юк! *(Трубканы куя.)* Башка чара калмады бит, кызым.

Ләйсән. Уйнамагыз минем белән, китсәм, чынлап китәм.

Зилә. Юк-юк, ниткән китү ди ул. Шулай бит Хөсәен? Андый кешедән бөтенләй китәләр диме. Атлаган саен аунап ятмый бит алар. Почеты көннән-көн арта Хәсәннең. Шулай бит, Хөсәен? Зур кеше булачак диләр бит. Шулай булгач, ниткән китү, бары акылга гына утырту кирәк. Югыйсә, гомер буе үзенчә генә, бездән көлә-көлә генә яшәп ятачак.

Хөсәен. Бөтен Зеленый Бор әһелләрен җыйныйммы соң? Буйдакларны гына.. сайлап кына...

Зилә. Әйдә җыен, Ләйсән.

Ләйсән. Әни, Хәсән кайткач та мин Хәсән белән икәүдән-икәү генә калып сөйләшергә телим.

Зилә. Иң яхшысы сиңа хәзер үк китү. Тик артыңнан сорап килсен. Шунда менә әйтәсең инде кирәк сүзләреңне...

**Ишектә звонок. Ләйсән йөгереп диярлек барып ача.**

Алия *(керә).* Физат юкмы сездә? Хәсән дә кайтмадымы? Менә бит. Юк инде бала. Тәмам суга чумган кебек булды малай. Бөтен таныш-белешләрне аякка бастырдым. Хәсән киткән якка чапканын гына күргәннәр... Бер-бер хәл генә эшләтмәсә ярар иде. Физатыбыз безнең боксер бит ул. Уф, үләм бу бала белән! Чемпион бит, чемпион!..

Хөсәен. Хәсән үзе дә кимен куймас, Алия Гариповна!

Алия. Нәрсә, әллә ул да боксермы?

Хөсәен. Юк ла, шахматны шәп уйный диюем.

**Телефон шалтырый.**

Ләйсән *(ала).* Хәсән, бу синме?! Хәсән, шаярма!..

Гайрәтле тавыш. Хәсәнегезне кисәтегез, минем малайга түбән бәя куйдырткан. Моны болай гына калдырмам!..

**Ишектә звонок. Ләйсән ишек ачарга бармый.**

Зилә. Кызым, нигә ачмыйсың?

Ләйсән. Гарык! Туйдым, туйдым *(Урындыкка утыра.)*

**Хәсән кер[illegible]алгандай, зур булып, марля белән уратылган. Аңа Физат ияргән.**

Физат *(беркемгә дә игътибар итмичә, үзенең сөйләвен белә).* О-о, хоккеймы? Беләсезме нинди көч, нинди җитезлек кирәк. Мин форвард-юношескийда... Гениально. Мин монда — дошман анда... Мин бире — дошман янга... И мин аны бортка резко китереп кысам, сөякләре «шарт». Аннары үзем ыргып алга, алга и го-о-ол!

Хәсән. Молодец, молодец, көч күп синдә.

Физат. Ә Сезнең тагын кан чыкты.

Хәсән *(маңгаен сыпыра).* Шулаймы?.. Һаман онытып җибәрәм, мин хәзер... *(Юыну бүлмәсенә кереп китә.)*

Алия. Улым?..

Физат. Мин түгел, аны — башкалар... Малаена ике куйганнар. Алар, Хәсән абыйга кирәкне бирәбез дип, артыннан киттеләр. Мин бик тиз килеп җиттем дә и сугып-сугып атылдырдым.

Алия. Дурак! Тапкансың тыгылыр җир — ярсыннар ие шунда башың. Ну, шуннан нәрсә диде инде Хәсән абыең? Алам дидеме университетка?

**Телефон шалтырый, берәү дә аңа якын килми.**

Физат *(түзми, ала).* Кем кирәк иде?

Нечкә тавышлы кеше. Хәсән абыең кирәк, слуший.

Физат. Хәзер. *(Юыну бүлмәсенә ишеттерергә кычкыра.)* Хәсән абый. Сезне «Слуший» чакыра!

Хәсән *(чыга).* Кирәкми. Туйдырды мине ул кеше.

Физат *(трубкага).* Син «слуший», яп бугазны, ато анда теш тутырам! *(Трубканы куя.)*

Хәсән. Әминә күренми. Ләйсән, әллә Әминә кайтмадымы әле?

Физат. Кайткан. Әнә чәчәкләре. Бишле алгач, базарга барам дигән иде.

Хәсән. Ә кая соң ул? Котладыгызмы әле аны?

Физат. Кухняда утырадыр. Зилә Бишевна яратмый аны. Килә дә кухняга гел куып кертә.

Хәсән. Әминә!

Ләйсән. Әминә дә Әминә. Әминәдән башка кеше күренми башлады ахры күзеңә!

Физат *(Әминәне кухнядан алып чыга).* Менә ул, әйттем бит, елаган!

Хәсән. Ник балавыз сыктың, кызый?

Әминә. Болай гына, шатлыктан.

Физат. Алдый ул, алдый!

Әминә. Ә синең миндә эшең булмасын.

Физат. Мамуля, күрәсеңме, әйбәт килен булыр иде бу сиңа?!

Алия. Нәрсә-ә-ә?

Телефон шалтырый.

Хәсән. Тыңлыйм?..

Нечкә тавышлы кеше. Слуший, субакы! Нишләтергә сине?! Син бит хәзер иң кадерле кешем! Күгәрченкәем, бу яхшылыгыңны ничек кенә бәхилләтергә соң?!

Хәсән. Нинди яхшылык?

Нечкә тавышлы кеше. Эх, субакы! Ошыйсың син миңа! Алтын зат икәнсең. Я, әйт инде җүнсез, синең өчен күктәге айны да тартып төшерергә ризамын.

Хәсән. Аһ, иблис! Бу әле тагын син икәнсең!

Нечкә тавышлы кеше. Мин, кадерлем, мин! Кругом бишкә генә биреп бара бит малай. Я, әйт инде теләгеңне, субакы! Слуший. Бүген сиңа дүрт тәпән бал китереп ташлыйм, аңладыңмы?..

Хәсән. Житте! Мине сатып алырга җыенасыңмы? Хәзер үк әйт малаеңның исемен, университетта укуны ул колак артын күрә алмаган кебек үк күрә алмаячак!

Нечкә тавышлы кеше. Бетте-бетте, слуший. Юк хәзер сиңа бал! Бармагыңны суыр.

Хәсән көлә-көлә трубканы куя.

Хөсәен. Нәрсә көләсең? Сиңа бар да көлке хәзер...

Хәсән. Дүрт тәпән бал ди бит. Көлмәслекмени. Бигрәк арзанга куя...

Алия. Ә күпме кирәк соң тагы?.. Кешеләрнең дә хәленә керә белергә кирәктер. Төрлечә яши кеше.

Хәсән. Ничек күрми калдык икән бу кешенең малаен?!

Хөсәен. Ә каян беләсең, нәкъ менә шул син үткәрми калдырган Физатлар, Чулпаннар — булачак чын археологлардыр бәлки. Бәлкем син бүген үз кулларың белән булачак Шлиманнарны, Каюм Насыйриларны кире каккансыңдыр!

Хәсән. Мин күрәзәче түгел, Хөсәен. Буласының булган кадәресеннән үк билгеле, дия иде безнең бабай. Әйе, менә шуңа күрә бүген Әминәне котлыйбыз да. Аванс итеп кабул ит, яме, Әминә. Ничек әле: «Җыр язмышы — һәрчак ил язмышы» дигән төшне хәтерлә әле... теге...

Әминә. Бабаларыбызның нәрсә ашаганнарыннан тыш нинди җырлар җырлавын да белсәсе иде бит дигәнемме? Мин аны «Казан утлары»ннан укыган идем.

Зилә. Ачкансыз икән яңалык. Бугаздан җыр чыксын өчен, карынның тук булуы шарт.

Алия. Шулай шул. Ач тамакны бик киерә алмассың.

Әминә. «Тәфтиләү», «Гөлҗамал», «Әллүки», «Кара урман»!.. Алар да тук корсактанмы? Халкыбызның шул искиткеч саф, үзәк өзгеч моң-сагыш белән өретелгән күңел җәүһәрләре арасында, тырт та тырт сикергәләп торган килбәтсез биюләр генә. Моны ничек аңларга? Нигә безнең бию скрипкабызда бары бер генә кыл калган?! Археологларыбыз монысына да җавап бирергә тиеш.

Хәсән. Кураеңны югалтсаң, сыбызгыга калырсың... Әзер җавабы юк. Ансы бәлкем син ачачак өлкә булыр, Әминә. Алынырсыңмы?

Әминә. Алынырмын.

Хөсәен. Авырлыклардан курыкмыйча?

Әминә. Чебеш тавык булганчы, тилгән күп тапкыр килә... *(Урындык артына элгән күлмәген, тахта артындагы чемоданын алып почмак якка кереп китә.)*

Хөсәен. Дуслык элек-электән кешеләр күңелендәге иң бөек тойгыларның берсе булган.

Хәсән. Ә-ә, менә ни өчен син мине үз урыныңа тәкъдим иткән булгансың: «Хәсән талантлы кеше, аны күптән киңрәк файдаланасы булган» дип. «Дуслык» файдасына димәк...

Ләйсән. Кит зинһар, рәхмәт әйтәсе урында, кешедән көлеп торасың.

Хәсән. Рәхмәт, Хөсәен, шунда бергә гафу да ит: теге Фәрит белән Валеркаларга булыша алмадым.

Зилә. Дөресен әйт, кияү, юри батырдым диң.

Хөсәен. Бу — аңлашылмаучанлык. Мине белмисең икән әле. Башы тишелгәнче эшләп йөрергә бар кеше дә синең кебек юләр түгел. Азрак ял итәргә теләдем, бары шул. Югыйсә, местком председателе кем? Хөсәен! Комиссиядә кем? Анда да Хөсәен. Фигаро здесь, Фигаро там дигәндәй, таптылар бер юләр. Кемдер ат урынына эшли, ә алар кеше утында кул җылыта. Ә инде бу Фәрит белән Валерка-

ларга килгәндә, алар өчен борчылма син, киләсе елга ук кирә алар. Физат та кирә, кирә!

Физат. Әни, әйдә!

Алия. Йомырка тавыкны өйрәтми!

Физат. Ну кал алайса! *(Чыга.)*

Алия. Тукта, улым, тукта! *(Артыннан чыга.)*

Хөсәен. Инде китапларыңны кертеп бирми булмас.

Зилә. Мин дә күтәрешеп чыгармын.

**Алар чыгып китүгә, Әминә күренә.**

Әминә *(кулында чемодан).* Рәхмәт сезгә, хушыгыз!

Хәсән. Син кая болай, төнгә каршы?..

Ләйсән. Тотма аны, Хәсән. Безнең икәүдән-икәү генә сөйләшәсе сүзебез бар. Бик кирәк икән, син аны чакыртып та китерә аласың...

Әминә. Сау булыгыз! Бөтенесе өчен дә рәхмәт сезгә! *(Йөгереп чыгып китә.)*

Ләйсән. Гаҗәпләнмә. Минем түземем бетте. Артык болай яши алмыйм.

Хәсән *(моңсу гына).* Мин ал да булыр идем, мин гөл дә булыр идем. Чәчәк атып, алларыңда гел көлеп торыр идем дә, әмма үзең ук бик яхшы күреп торасың...

Ләйсән. Хәсән! Ялынып сорыйм. Физатны гына үткәр инде шул конкурсларыннан. Башка мин сине борчымам.

Хәсән. Әкият!

Ләйсән. Әниләр алдында мин — ноль! Туганнар алдында мин — ноль! Хәзер инде әнә күршеләр алдында да мин нольмы!

Хәсән. Тынычлан, Ләйсәнем, тынычлан. Ялгышма!

Ләйсән. Син, Хәсән, һаман китабыңны укырсың да, китабыңны укырсың инде. Бар да шушылай барган көе барачак ул. Ә мин нишләрмен, мин? Минем дә кешеләрчә яшисем килә! Минем дә гомерем бер генә!

Хәсән. Моңарчы без бәхетле идекме, Ләйсән?

Ләйсән. Бәхетле идек, чөнки әле мин киләчәгебезгә ышана идем. Баксаң, ул киләчәк юк икән. Мин әйтмим, синең кебекләр бардыр ул, сез чыннан да кирәкледер дә. Ә миңа нишләргә? Тумас борын картаергамы?

Хәсән. Тормышның төрле чагы була, авыры да, җиңеле дә...

Ләйсән. Ә нигә гел авыры гына тия соң аның безгә?

Хәсән. Нәрсәне авырлык дип санысың син? Әллә ул «шома» Хөсәенгә яшәве ансатмы?

Ләйсән. Ансат!

Хәсән. Алия белән әниләреңә җиңел дип беләсеңме?

Ләйсән. Җиңел, мең тапкыр җиңел! Хәсән, мин синнән китәм.

Хәсән. Бөтенләйгәме?

Ләйсән. Бөтенләйгә. *(Жыена башлый.)*

Хәсән. Ә син беләсеңме шуны: хыянәтчеләрне беркайчан да гафу итмиләр.

Ләйсән. Курыкма, синнән гафу сорап килгән кеше булмас.

Хәсән. Әгәр килә калсаң?..

Ләйсән. Тыныч бул!

Хәсән. Ләйсән, бу берничә ай безнең өчен аерата болгавыр булды... Мин үземне бик тә гаепле саныйм.

Ләйсән. Шуннан ни файда: аккан сулар кире кайтамы?

Хәсән. Миңа синсез авыр булачак... бик.

Ләйсән. Ә миңа синең белән... бик!

Хәсән. Гомер барыбызга да санаулы бирелгән, шулаймы?

Ләйсән. Бер генә мизгелен дә әрәмшәрәм итәргә ярамый!

Хәсән. Әйе-әйе, комарланып, онытылып, тормыш мәшәкатьләреннән читләшеп, төрле юллар белән юаныч эзләп, акыл миңгерәүләнгәнче, зиһен томаланганчы, бәхетле итеп яшәргә...

Ләйсән. Анысы минем үз эшем.

Хәсән. Аңлашыла. Машина... мебель... төрле озынлыктагы юбкалар? *(Пауза.)* Ә бер акыл иясенең әйтүенә караганда, болар гына әле кешенең гасырлар буе тәрбияләнгән рухи дөньясын канәгатьләндерерлек түгелләр... Янәсе, комфорт коллыгының богаулары башка коллык богауларына караганда ныграк кыса. Ныграк микән? Кемгә нәрсә бит!.. Менә... менә...

Ләйсән. Юлымда торма, философ!

Хәсән. Кая бармакчысың?

Ләйсән. Каямы? Әйтимме?

Хәсән. Кирәкми, аңлашылды!

Ләйсән. Менә аңлашылмады шул, әйтимме?

Хәсән. Кирәкми, кирәкми. Беләм.

Ләйсән. Белмисең шул, белсәң, әйт кая?

Хәсән. Каен башына — каймак ашарга.

Ләйсән. Юк, монастырьга. Ләйсәнне анда кемнәрдер көтеп торалар икән дип уйлама. Беркемем дә юк минем. Син генә,

бары син генә. Сине генә яратам. Башка чара калмаганга гына китүем. Җан тынычлыгы эзләп китәм. Ярый хуш, сау бул.

Хәсән *(күбрәк үз-үзенә, гаять уйчан)*. Ир кешегә иң авыр вакытта, иң кирәк чагында хатын-кызның ярдәм иткәне булдымы икән? Юктыр, мөгаен. Чөнки алар тышкы бизәклеләрдән саф тойгылы һәм чын омтылышлары булганнарны аера белмиләр. Аларның күңел күзләре дөммә-дөм сукыр!.. *(Тын гына.)* Ә бәлкем, шайтан алгыры, алар аны күрергә дә теләми торганнардыр, ә?! *(Гел каядыр ераккa караган хәлдә.)* Бүгенге көннәр минем өчен иң авыр көннәр. Чөнки бу бернично көн бөтен киләчәгемне бер максатка турылый... Син тынычлык эзләп китәм дисең. Ә барыбер житәчәк бит ул көн, һәм мин куйган максатыма ирешәчәкмен.

**Нәкъ шул мәлдә ишек ачылып, бусагада кулларына кочак-кочак китап күтәргән Зилә Бишевна белән Хөсәен күренәләр.**

Зилә. Кызым, сиңа ни булды? Күзләреңдә мөлдерәмә яшь?

Ләйсән. Китәм әни, туйдым.

Зилә. Әйдә-әйдә, бик шәп. Мондый чүп-чар базында яшәп яталар диме, шушындый заманда...

Ләйсән. Уф, тизрәк саф һавага чыгасым килә. Әйдә, китапларын ташла да, китик. *(Китапларны алып, Хәсән аягы астына сала.)* Рәхим ит! Ирештең теләгеңә, яшә инә шуларга күмелеп! И туйган идем, и туйган идем шулар тузаныннан. Квартирадан квартирага күчкәндә, шуларны ташый-ташый жаннарыбыз чыгып бетә иде. Кая гына күченсәк тә, түр башына иң беренче алар кереп урнашкан буладыр иде. Уф, китик, әни. Китик!

Зилә. Елама кызым, елама.

Хөсәен. Хәсән, я, нәрсә катып калдың. Китә бит, китә! Соңыннан үкенә-үкенә чабып йөргәнче, менә хәзер туктат та кал үзен.

Хәсән. Татарга тылмач кирәкми.

Зилә. Кирәк булыр әле. Ничек кенә кирәк булыр. И, кызым, рәхмәт әле сиңа. Мине дә коткардың бит. Моннан ары миңа да бу караңгы базга килеп йөрисе булмас.

Ләйсән *(бүлмә белән саубуллаша)*. Хуш инде, якты өметләремне сүндереп бетергән бүлмә. Башка мин бу китаплар каберлегенә үз иркем белән аяк басмам.

Хөсәен. Зилә Бишевна, сезнең телефон номерыгыз ничек әле?

Зилә. Син беләсең түгелме соң, Хөсәен.

Хөсәен. Мин беләм дә бит, Хәсән белми әнә. 2-73-79! Хәсән, онытканчы язып куй!

Хәсән. Минем адресны да онытмассыз дип ышанам. Татарстан урамы, йорт номеры 13, фатирныкы 137.

**Пәрдә.**

## Дүртенче күренеш

**Имтиханнар беткән. Шул ук бүлмә. Бүлмәдә Физат ялгызы гына.**

Физат *(телефоннан сөйләшә)*. Бетер диләр, дуңгыз! Күпме әйтергә мөмкин?! Тагын бер шалтыратсаң, мин сине стенага башың белән — шалт! Мин Хәсән Галимовнч кына булмам! Каратэ хакында ишеткәнең бармы? Ишетсәң — кач тизрәк! *(Трубканы куя. Өстәл тирәсендә мәтәлчек атып, күнегүләр эшли башлый.)* Бер, ике, өч... *(Кабат шалтыраталар.)* Неужели тагын син?! *(Трубканы алып кычкыра.)* Җимерәм башыңны!

Ләйсән тавышы. Физат, ни булды сиңа? Нишлисең анда?

Физат. Миңа берни дә булмады, ә вот Сезгә ни булды, Ләйсән апа? Нигә Сез туктаусыз шалтыратасыз да и үзегез дәшмисез? Хәсән абый бит барыбер әйтә, что сез шалтыратасыз!.

Ләйсән тавышы. Тагын нилар сөйли Хәсән абыең?

Физат. Газап итмәгез Сез аны.

Ләйсән тавышы. Туктале, әни!..

Зилә тавышы. Каяле — кая? Физат, акыллым, газапланамыни Хәсән абыең? Бикме? Менә яшәп карасын әле безсез

генә, ие, университетта экзаменнар алган булып. Ансат кына яшәмәкче ие.

Физат. Ә экзаменнар бетте-китте инде. Хәсән абыйны кругом мактадылар!

**Тынлык. Зилә белән Лэйсәннең трубка өчен тарткалашканнары ишетелә.**

Ләйсән тавышы. Әни, җитте!

Зилә тавышы. Үзе килер, дүрт аяклап үрмәләр!

Физат. Килер — көт! *(Трубканы куя.)*

**Хәсән белән Хөсәен керәләр.**

Хөсәен. Син тыңлап бетер!.. Менә мин ни өчен өйләнми дисең, ә? Яраткан кешемне таба алмаганга. Табалмыйм, юк ул. Фикердәшем булырдай кешене таба алмыйм. Әле Ләйсәнне күрдем әнә. Үкереп-үкереп елый. Нигә кайтмыйсың, кайт дим, юк ди, кайтмыйм ди. Горур хатын.

**Телефон шалтырый.**

Физат *(алып)*. Кем бу?

Гайрәтле тавыш. Бир әле трубканы үзенә! Шунда белер кемлегемне!

Физат. Мин сезне таныдым. Малаегыз өчле алды. Мин булсам берле куяр идем!

Гайрәтле тавыш. Бир дим трубканы!

Физат. Кулында бит инде трубка. Сиңа бары җитми носовой платок!

Гайрәтле тавыш. Бир үзенә трубканы, мальчишка!

Физат. Бирәм, тик авызыңны яп. Тешләрең коелмасын!

Хәсән. Чү, чү, Физат! Чамалап! *(Физаттан трубканы ала.)* Беттеме?

Гайрәтле тавыш. Нинди көчек ул анда? Кемгә өйрәнеп белеп өрсен. Мин фил! Нәрсә көләсең? Җитмәдемени әле, хатының да китте бит инде!..

Хәсән. Бар әле өз, Физат. *(Трубканы куя.)*

Физат. Нәрсәне, муенынмы?

Хәсән. Розеткадан ал дим, шнурны.

Физат. Кирәкми, Хәсән абый. Торсын, бәлкем теге шалтыратыр.

Хәсән. Ә-ә, Әминәме?

Хөсәен. Син, Физат дус, кунып ятасың ахры монда.

Физат. Телохранитель мин. Саклыйм Хәсән абыйны.

**Ишектә звонок. Физат ача.**

Алия *(керә)*. Кайтасыңмы—юкмы син өйгә, наконец. Мин сиңа ничә тапкыр әйттем. Режимнарын бозылып бетте...

Физат. Мамуля, бар әле, бар. Мин кечкенә бала түгел. Үзем беләм!

Алия. Менә хәзер әтиең...

Физат. Мамуля, алдашырга ярамый. Әти — командировкада.

Алия. Хәсән Галимович, Сез күрәсезме! Бу Сезнең йогынтыгыз! Балада Сез ата-анага шундый нәфрәт уяттыгыз! Бу — зур җинаять! Мин моны болай гына калдырмыйм! Хөсәен, Сез шаһит булырсыз.

Физат. Мамуля, не мешай олы кешеләргә яшәргә! Иди — бар.

**Алияне озатып чыгара. Телефон шалтырый.**

Хәсән *(ала)*. Кем бу? Ник дәшмисең?

Физат *(шыпырт кына)*. Тагын Ләйсән апа бу!

Хәсән *(бармагын иренenә куя)*. Беләм.

Физат. Син аны кайтарт. Ул бит ничего. Мин если әгәр олырак булсам, үзем аны өйләнер идем.

Ләйсән тавышы *(бары җыры гына)*.

Күзләрдән соң язлар килми,—
Алда салкын, ак кышлар.
Китәсез дә мени, китәсез дә мени.
Китәсез дә мени, аккошлар?

**Җыр өзелә. Трубканы куялар. Ишектә звонок.**

Хөсәен. Уһу, тагын кемдер килде. Монысы да шаһит итеп чакырмасын — чыгып торырга кирәк.

Хәсән. Хуш! *(Хөсәенне озата чыга.)*

**Телефон шалтырый.**

Физат *(алып)*. Убью!

Әминә тавышы. Котырдыңмы әллә?

Физат. Котырырсың. Экзамен вон кайчан бетеп китте, ә алар һаман җан кыйный. Син авылдан шалтыратасың, да?

Әминә тавышы. Әйе, авылдан.

Физат. Син мине ник алай?.. Мыскыл итү булып чыга бу. Мин сөйләшә белмим, да? Ә син мине давай, зинһар төзәт.

Әминә тавышы. Бөкерене кабер төзәтә.

Физат. Юк, төзәтмә, өйрәт!

Әминә тавышы. Үзең өйрән.

Физат. Юк, син өйрәт. Мин шунда тиз өйрәнәм. О'кеймы?

Әминә тавышы. Акаймый. Карале, мин ялгыш җыям ахры бу номерны. Хәсән абый урынына гел сезгә эләгәм.

Физат. Нигә ялгыш, дөрес номер бу. Син чоли белмисең. Мин хәзер Хәсән абыйга уң кул. Телохранитель. Мин бөтен кешене тәртиптә тотам.

Әминә тавышы. Мактанмасана.

Физат. Институтка кералмады дисең ведь, да? Керәм мин, киләсе елгук. Без бергә укырбыз. Киноны да бергә карарбыз. Әйдә, теләсәң, bездә тор син.

Әминә тавышы. Ие, хәзер, көтеп тор. Акылың алтын икән.

Физат. Ник?

Әминә тавышы. Икенче курста укыган башым белән, первокурсниклар арасында буталып йөримме соң?

Физат. Ә кем сине саклар?

Әминә тавышы. Син.

Физат. Конечно.

Әминә. Физат, Ләйсән апа Хәсән абыйга һаман кайтмадымы? Мине бик борчый бу. Ни әйтсәң дә мин сәбәпче булдым кебек.

Физат. Булыр, кайтарырмын.

Әминә тавышы. Җитди кеше түгел инде син, әйеме?

Физат. Җитди кеше кем ул?

Әминә тавышы. Ышанып булмый сиңа.

Физат. Миңа? Вон анда Зилә Бишевна килде. И, димәк, Ләйсән апа да монда була. Бүген үк. Син тагы шалтырат, әйтәм, ни булды.

Әминә тавышы. Карале, Физат, Хәсән абыйның «Курганы, идолы, монеты» дигән китабы булырга тиеш.

Физат. Бар ул. Автор: Федоров-Давыдов. Нечкә генә, да? Но үзе белә-ә, юан китаптан да күп. Молодец автор.

Әминә тавышы. Миңа бик кирәк ие ул...

Физат. Ярый — ышан. Булыр. Хәзер почтага китәм.

Әминә тавышы. Ашыкма. Чак кына соңрак тагын шалтыратам мин, яме.

Физат. Зур рәхмәт.

Әминә тавышы. Үзеңә рәхмәт *(Трубканы куя.)*

Хәсән белән Зилә Бишевна керә.

Зилә. Әйе, менә шул. Кызымның әйберләрен бүлешергә дип килдем!

Хәсән. Алыгыз әйдә, Зилә ханым. Күңелегезгә ни ошаса, шуны алыгыз. Тик китапларга гына тимәгез. Машина белән килдегезме? Төяшимме?

Физат. Мин тоже!..

Зилә. Шаяртам гына ла... Ай-йай син, ә! Хатыныңны шулай җиңел генә биреп җибәрәсеңме?

Хәсән. Җибәрәсе калмаган инде, киткән.

Зилә. Китә, әлбәттә, көрәшмәгәч.

Физат. Хәсән абый көрәшеп йөрми — вакыт юк.

Хәсән. Физат!..

Физат. Булды, булды: татарга тылмач кирәкми... *(Киштәсеннән Әминә сораган китапны эзли башлый.)*

Зилә. Кайчан килеп аласың? Әллә инде китереп куйыйммы?

Хәсән. Нәрсә ул?

Зилә. Хатыныңны! И, аңламаган булып торырсың!..

Хәсән. Ә-ә, минем бит әле хатын да бар. *(Бүлмә эчен игътибар белән караган булып.)* Әй-йе-е...

Зилә. Син нәрсә?..

Хәсән. Ни бит, бу чүплек базы бик караңгы икән. Әйбәтрәк җиргә илтеп куеп булмыймы соң аны?

Зилә. Әй, кияү-кияү, ачу саклау синең ише затлы кешегә бер дә килешми инде...

Хәсән. Мин нәрсә, минем шушы, Ләйсән әйтмешли, «китаплар каберлегем» дөньяның иң мәһабәт сарайларына тиң булып күренә дә бит... Ләйсәнгә генә менә, алай түгел...

Зилә. Күренер, күренер. Ул чаклы инде, теге, күпкә түзгәнне тагы азга гына түзәр диюем. Шулай бит, кияү. Ир бул. Син бит инде хәзер малай-шалай гына түгел, ә дәрәҗәле кешеләр белән аралаша торган өметле кеше. Андыйларның хатыннары ирләреннән узып, бернәрсә дә эшләмәс.

Хәсән. О-о, менә без дә үсеп җиттек...

Физат. Моңсу гына менә... *(Эзләгән китабын табып, телефон кырына килә.)* Хәсән абый!

Хәсән. Нәрсә, Физат?

Физат. Әминәгә әйттем: бу китапны авылга салам, әйеме?

Хәсән. Әминәгәме? Аңа булса, ярый.

Зилә. Хәсән, алай булса хатыныңа шалтыратыйк инде, яме. Кияү, син мине тыңлыйсыңмы? Хәзер үк, яме, шалтыратыйм. Килсен, сөйләшерсез. *(Ишеккә юнәлә, туктап кала.)* Кара, моннан гына да

шалтыратып була лабаса. Каяле, Физат. Хәсән абыең каршы түгел бугай...

Ф и з а т. Зилә Бишевна, гафу, мин звонок көтәм. Пожалуйста, әнә дустыгыз Хөсәен Имаевич якында гына. Кереп шалтыратыгыз.

З и л ә. Ярар, алайса, шунда керим. Хәсән, син өйдә буласыңдыр бит?

Х ә с ә н. Өйдә.

З и л ә. И, кияү!.. *(Куанып чыгып китә.)*

Х ә с ә н. Инде нишләдик икән, Физат?

Ф и з а т. Ләйсән апаны алып килсә, да?..

Х ә с ә н *(көлемсерәп)*. Да.

Ф и з а т. Рәхмәт әйтергә кирәк. Тагы да шулай китеп торсын, экзамен вакытында. *(Хәсән көлә.)* Но җиңел генә не сдавайся. Минем әтине күрсәң. Әнинең җанын ала. Җаным, җаным гына — әни этигә. *(Телефон шалтырый.)*

Ф и з а т. Бусы миңа — Әминә! *(Трубканы ала.)*

**Нәкъ шул чакта ишектә дә шалтыраталар.**

Х ә с ә н. Ә бусы кем? Ләйсән апаң мәлләә?

Ф и з а т *(баш кага)*. Әнисе только шалтырата, ә ул уже монда.

Х ә с ә н. Алайса ялындырыйм әле. Акылга утырсын. *(Ишекне ача.)*

Ф и з а т. Әминә, бу синме?

Ә м и н ә т а в ы ш ы. Ә бу синме соң?

Ф и з а т. Әминә, барысын да син кушканча эшләдем.

Ә м и н ә т а в ы ш ы. Шулаймы? Менә рәхмәт.

Ф и з а т. Китапны прямо хәзер салам. Ләйсән апа әнә ишек төбендә.

Ә м и н ә т а в ы ш ы. Ишек төбендә? Соң алайса нишләп торасың син анда, чык аннан. Калдыр икесен генә.

Ф и з а т. Ә син тагын шалтыратасыңмы?

Ә м и н ә т а в ы ш ы. Әлбәттә. Хәзер үк чыгып кит, яме.

Ф и з а т. Ярый. *(Трубканы куя.)*

**Ләйсән белән Хәсән керәләр.**

Ф и з а т. О-о, Ләйсән апа кайткан икән. Бездән сәлам!

Л ә й с ә н. Исәнме, Физат!

Ф и з а т. Бик шөкер. Алла ярдәм бирсен.

Х ә с ә н. Син кая барасың әле, Физат?

Ф и з а т. Ә менә. *(Китапны күрсәтә.)* Әминә сорый. Ни әйтсәң дә булачак кәләш. Тыңламый ярамас. Юкса вот Ләйсән апа кебек булыр. Киттем әле почта ябылганчы.

Х ә с ә н. Шулаймы? Бар-бар.

**Физат китә.**

Л ә й с ә н. Син, Хәсән, «кер» дип тә әйтмисең, «кермә» дә димисең?

Х ә с ә н. Димим шул.

Л ә й с ә н. Хәсән.

Х ә с ә н. Нәрсә?

Л ә й с ә н. Мин кире кайттым бит.

Х ә с ә н. Соң, тор кайтсаң...

Л ә й с ә н. Ник болай сөйләшәсең? Алайса кире китәм?

Х ә с ә н. Алайса кит.

Л ә й с ә н. Сау бул! *(Ишеккә бара.)*

Х ә с ә н. Хуш. Әби анда Хөсәен янында утырадыр. Сине ул никтер монда алып киләм дигән иде. Бар, юкка шалтыратып утырмасын, азапланып.

Л ә й с ә н. Әйтер сүзең шул гына идеме?

Х ә с ә н. Минекесе шул гына иде.

Л ә й с ә н. Тагын бер кат сау бул, Хәсән!

Х ә с ә н. Тагын бер кат хуш, Ләйсән!

Л ә й с ә н. Нигә кал дип әйтмисең инде син миңа?

Х ә с ә н. Шушы «китаплар каберлеге»ндәме? Караңгы чүплек базындамы? Син югында бит монда берни дә үзгәрмәде. Менә бары бу почмакка тузанлы китаплар гына тагы өстәлә төште. Калганы бар да элеккечә. Менә күчим әле өч бүлмәле алтын сарайга. Шунда әниең белән икегезне кунакка чакырырмын. Уйлашырбыз...

Л ә й с ә н. Мин бик куп уйландым, Хәсән, бик күп. Әле кичә генә син кайчандыр миңа бүләк иткән китапны укып чыктым. Хәтерлисеңдер бит: Плутарх дигән антик язучының Епонина исемле бер хатын хакында язган әсәре ул.

Х ә с ә н. Хәтерлим, император аның ире Сабинийны зиндан базына яптыра.

Л ә й с ә н. Әйе, шул ирнең хатыны үзе теләп сөекле ире белән тугыз ел гомерен зинданда үткәрә. Инде ирен, ниһаять, император үтерткәч, хатыны да ире белән бергә үлемгә бара. Үләр алдыннан императорга ул болай ди: «О, Цезарь! Мин ирем белән караңгы баз-зинданда да бик бәхетле яшәдем, андый бәхеткә син хәтта якты кояш һәм нурга чумган империяңдә дә ия була алмагансың!» — ди. Гаҗәп бит бу, әйеме? Тугыз ел буе базда яшәп, кеше үзен иң бәхетлегә санаган.

Хәсән. Мине чак кына булса да сагындыңмы соң?

Ләйсән (*сүзсез генә Хәсәнгә якынлаша һәм капылт талпынып кочагына керә*). Яратканым, яратачагым! Ничек кенә сагындым әле!

Хәсән. Ләйсән! Җанкисәгем!

Ләйсән. Син хаклы булгансың, син мең тапкыр хаклы. Хәсән, безнең бит балабыз була!

Хәсән (*бик дулкынланып*). Ничек — була?

Ләйсән. Тиздән табам!

Хәсән. Ялган түгелме?

Ләйсән. Билләһи! Биш ел буе зарыгып көткән балабыз. Әни әйтә: «төшертик», ди. Мин юк дидем. Дөрес әйткәнмен бит, әйеме, Хәсән?

Хәсән. Дөрес, Ләйсән, дөрес!

**Кабат бер-берсенә сарылалар. Ишектә Хөсәен белән Зилә күренә.**

Зилә. Абау! Бу ни дигән сүз инде тагы?

Ләйсән. Ир белән хатын арасына кермә дигән сүз була бу.

Зилә. Китәм-китәм. Сезнеке дөрес, сезнеке. Киттем. (*Чыга башлый.*)

Хәсән. Ә безнең баланы кем карар?

Зилә. Нәрсә?

Ләйсән. Оныгыңны кем карар, ди?

Зилә. Ә-ә, әйе-әйе, исемен ничек кушарбыз икән?

Ләйсән (*Хәсәнгә*). Исем ди әни...

Хәсән. Уйлап кил, әбкәй, шунда берике исем, бабай белән бергәләп. Без дә монда уйлашырбыз.

Зилә. И кияү, акыллы да баш инде син. Валлаһи, уңдым кияүдән. Ярый, сау булып торыгыз. (*Китә.*)

Хөсәен. Ә мин?

Хәсән. Нәрсә син?

Хөсәен. Исем эзләшимме соң?

Ләйсән. Кирәкми-кирәкми, үзебез табып, үзебез кушабыз үз малаебызга. Без аны биш ел көттек.

Хәсән. Ишеттеңме, күрше. Тукта, нишләп йөрисең әле син монда тиктомалга?

Хөсәен. Кичке обход.

Хәсән. Бүтән берниндни дә обходлар булмаячак.

Ләйсән. Ие, синең дә юлыңа ак җәймә! Комачаулап йөрмә безгә башка.

Хөсәен. Шулаймы?! Кара, шулай икән шул.

**Пәрдә.**

# Укучының күңел дәфтәренә

**Индонезия мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Зур агачның йомычкасы күп.*
*Телсез кеше төшен сөйли алмый.*
*Үрнәккә — ияру, ә йоланы утәу кирәк.*
*Мачтаны җилкән аудара.*
*Пычрак коеда чиста су булмый.*
*Мәче булып утырса да юлбарыстай сикерә.*

Изаил Зарипов

# ДУСЛАР ТУГРЫЛЫГЫ

Себерлеләрнең Татарстан нефтьчеләреннән шактый алга атлауларына, ярышта беренчелеккә ирешәчәкләренә һичкем шикләнми иде. 1977 елның беренче яртысында Нижневартовск бораулаучылары искиткеч уңышларга ирештеләр. Тизләтелгән яңа ысулга таянып, алар атаклы Ромашкино катламнарын үзләштергән ярышташларына караганда ике тапкыр зуррак күрсәткечләр бирде. Самотлорның планнан тыш җитештерелгән нефте генә дә Татарстандагы уртакул бер предприятиенең ел буе чыгарган ягулыгы кадәр булды. Хезмәт нәтиҗәләрен раслаучы саннар теләсә кемне сокландырырлык иде. Өстәвенә, күрсәткечләр, бөтен шартын җиренә җиткереп, бик әйбәт итеп тиешле формасына китерелде. Чөнки соңгы сүзне әйтергә җыенганда материалларның ничек формалаштырылуына да игътибар ителә.

Татарстан кунаклары килеп төшкәндә, себерлеләр үзләрен җиңүчеләр дип үк хис итәләр, эш рәсми төстә бер җыелып алуга гына терәлеп калган кебек иде.

Менә алар, социалистик ярыш нәтиҗәләренә йомгак ясау өчен түгәрәк өстәл тирәсенә утырыштылар, һәм шунда бар нәрсә дә... кирегә тәгәри башлады. Татарстан нефтьчеләре үзләре дә моны һич көтмәгәннәр иде, киресенчә, алар Себердәге фидакарь дусларын котларга әзерләнделәр. «Хыянәтче» — себерлеләрнең үз арасыннан чыкты. Иң элек шәһәрнең санитария врачы Елена Давыдовна Книсс:

— Безнең «Нижневартовскнефтегаз» оешмасына керүче предприятиеләрдә һәм алар карамагындагы мәйданнарда санитариянең элементар кагыйдәләре бозыла,— дип әйтеп салды.

Хуҗалар аптырашып бер-берсенә карангаларга тотындылар. Бу карашларда: «Дәлилләрең кайда?» дигән кебегрәк сорау да бар иде. Елена Давыдовна үз сүзләрен раслардык шактый мисал китергәч кенә, аның белән килештеләр. Нефтьчеләр шапшаклыкның гына ярыш нәтиҗәләрен әллә ни үзгәртә алмаячагына нык ышаналар иде. Әмма врачның сүзен тагын берәү куәтләде. Монысы шәһәрне янгыннан саклау оешмасыннан икән. Ул:

— Нефтьчеләребез янгынчыларның хәрбиләштерелгән часте тарафыннан куелган ике таләпне үтәмәделәр,— дип кырт кисте.

Бу дәгъва да, хата тиз арада төзәтеләчәк, дигән вәгъдә биргәч, шактый шома гына узачак иде әле. Шул чак халык депутатларының шәһәр Советы башкарма комитеты председателе урынбасары Виктор Дмитриевич Филатов сүз сорады. Ул әйбәт кенә башлап алып китте дә шәһәрне матурлау, уңайлыландыруда нефтьчеләр өстенә төшкән бурычның үтәлеп җитмәгәнен, яман якларын санарга тотынды. Янәсе, юллар, ишегаллары, тротуарлар ташландык хәлдә калган.

Бәхәсләшә торгач, шәһәр буйлап йөреп кайтырга булдылар. Кайбер урамнардан үткәндә, хуҗалар Татарстаннан килгән кунакларның күзенә туры карарга кыймыйлар иде. Хәзер инде җиңүченең кем икәнен раслар өчен иплэп кенә сөйләшергә, агын

акка, карасын карага аерып күрсәтергә кирәк булып чыкты. Сүз Обь елгасының чисталыгын саклау мәсьәләсенә барып терәлгәч, аның, Идел белән чагыштырганда, шактый нык пычратылганлыгы фаш ителгәч, Себер нефтьчеләре үзләре үк ярыш нәтиҗәләре буенча беренче урын дәгъвалаудан туктадылар.

Илебезнең нефтьне иң күп бирә торган бу ике регионында үзара социалистик ярыш килешүләре төзү кайчан ничек, кем тәкъдиме аркасында башланып киткәндер — хәзер анысын ачыклавы кыен. «Җәлилнефть» идарәсендә, бу адымны беренче без ясадык, дигәннәр иде. Нижневартовскида да, Мегионскида да әлеге күркәм башлангычны үзләренә беркетеп куймакчы булалар. Хикмәт анда түгел. Бу ярышта җиңеп чыккан өчен бераүгә дә һичнинди бүләк-фәлән бирелми. Әмма һәр ике якта да беренче булу теләге көчәйгәннән-көчәя бара. Хәзер инде хезмәт ярышы, әле генә сурәтләнгән вакыйгадагыча, «Татнефть» һәм «Нижневартовскнефтегаз» кебек зур берләшмәләр эшчәнлегенә үк үтеп керде.

Берсендә миңа «Җәлилнефть» белән «Нижневартовскнефть» идарәләре арасында ярыш нәтиҗәләрен йомгаклау комиссиясенә катнашырга туры килде. Бу юлы себерлеләр Татарстанга килгән иде. Кунакларны ерак юлдан соң азрак сыйлап, ял иттереп алдык та аларга үзебезнең хуҗалыктагы байлыкны күрсәтә башладык, эштә ирешелгән уңышларыбыз турында, бигрәк тә отышлы ысулларыбыз хакында сөйләдек, тупланган тәҗрибәбез, серләребез белән уртаклаштык.

Себер егетләрен ул вакытта Самотлор өчен мөһим мәсьәләгә әйләнеп баручы четерекле нәрсәләр — нефтьне тозлардан, судан арындыру аеруча кызыксындырды. Ромашкинода тәҗрибә җитәрлек, чөнки анда инде бу проблема күптән кузгалган һәм хәл ителгән иде. Себер делегациясе члены, нефтьне чистарту һәм озатып тору бүлеге начальнигы Геннадий Иванович Шаболкин иң алдан җәлилчеләрнең тоз һәм судан арындырып кына калмыйча нефтьнең тиешле стабильлеген дә тәэмин итә торган комплекслы җайланмалары белән танышырга теләк белдерде. Аның барыннан да бигрәк нефтьне эмульсиядән торба эчендә чистарту алымы белән ныклап танышасы килде. Бу ысул аңа күптән тынгылык бирми, әмма җайланманың үзен күрергә туры килгәне юк икән.

Татарстан нефтьчеләре бу кыю адымны беренче башлап «Җәлилнефть» промыселларында ясадылар. Зур экономик эффект бирүче бу яңа ысулны тормышка ашыру белән техник фәннәр докторы профессор Валентин Петрович Тронов җитәкчелегендәге Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект институты галимнәре шөгыльләнде. Профессорның бу өлкәдәге фәнни хезмәтләре себерлеләргә дә яхшы таныш, тик ачышның эштә практик ярдәмен үз күзләрең белән күреп тору — китапка язганнарны уку гына түгел инде.

«Җәлилнефть» идарәсенең галимнәр уйлап тапкан яңалыкны беренче башлап тормышка ашыруы да мактауга лаек. Чөнки кайберәүләр бу ысулның уңай нәтиҗә бирүенә башта ышанмадылар. Алар ачышның артык дәрәҗәдә гади булуына сәерсенеп карады: нефтьне эмульсиядән арындыру өчен моңарчы бик катлаулы җайланмалардан файдаланалар иде, хәзер шуны гап-гади торба алмаштыра, янәсе.

Геннадий Иванович Шаболкин яңа ысулның Түбәндә ни кадәр эффект бирәчәген уйлап, сөенеп бетә алмады. Ә нефтьне комплекслап эшкәртү җайланмасында ул резервуардагы ягулыкны үлчәү өчен куелган приборга игътибар итте. Механиканың элементар законына көйләнгән шул приборны үз кулы белән тотып карыйсы килде аның. Моның өчен исә аңа биек резервуар өстенә менәргә кирәк булды. Җил исеп тора иде. Кирегә үгетләүчеләр дә табылды:

— Кара аны, өстә шактый салкын,— диделәр.

— Мин бит — Себер егете,— диде ул.— Мондый салкыннарны гына күргән бар.

Югарыдан, үлчәү приборы белән танышып төшкәч, егет, ни өчендер, беренче сүзләренә төзәтү кертергә кирәк тапты.

— Дөресен генә әйткәндә, мин — Татарстан кешесе бит,— дип куйды.

Самотлор кешеләрен автоматика яки телемеханика системасы белән шаккатыру — кыен нәрсә. Чөнки анда промыселлардагы җиһазлар техниканың иң яңа казанышлары белән баетылып кына тора. Идарә итүнең автоматлаштырылган системасы да беренче башлап Самотлорда җайга салынды. Моннан егерме еллар элек нефть

бирә башлаган Ромашкино промыселларында исә андый автоматик механизмнар юк иде әле. Татарстан нефтьчеләре Себер ятмаларын үзләштерүчеләргә бу мәсьәләдә көнләшеп карадылар.

Хәтеремдә: «Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры Валерий Исаакович Грайфер белән бергә Казаннан Бөгелмәгә кайтып барабыз. Төн иде инде. Самолеттан факеллар тезмәсе күренә. Якында гына Миңлебай газ эшкәртү заводы булса да, без бораулаучылар ачкан һәр чыганакны вакытында үзләштереп өлгерә алмый азапландык. Мин үзем дә сизмәстән:

— Самотлорда ул газны кая куеп бетерерләр инде? — дип сорадым.— Анда бит әле газ эшкәртү заводлары бөтенләй юк...

Валерий Исааковичның Самотлордан кайтып кына төшкән көннәре икән.

— И-их! — дип уфтанды ул.— Анда бит бөтенләй башка шартлар! Әгәр бездә Ромашкино җире кебек тагын бер чыганак табылса, без аның байлыгын шундый матур итеп үзләштерер идек ки, газны әрәмгә яндыручы бер генә факел да кабынмас иде!..

Чыннан да, Ромашкино чыганагына автомеханик механизмнар аз-азлап, акрынлап кына керә барды. Эшчеләр дә белемнәрен хезмәттән аерылмыйча гына күтәрделәр. Яңа техниканы өйрәнергә алынучылар арасында «Җәлилнефть» кешеләре дә бар иде.

Хәзер генә Себердән килгән Геннадий Иванович Шаболкин җәлилчеләр кулындагы автоматик җайланмаларның һич «холыксызланмыйча» җай гына эшләп ятуына сокланып та, көнләшеп тә карый. Ул операторларга, гап-гади эшчеләргә төрле сораулар бирә башлады. Җаваплар гел төп-төгәл. Өченче разрядлы бер оператор үз карамагындагы приборның җитешсезлекләрен һәм алардан котылу юлларын да санап чыкты хәтта. Шаболкин иптәшләрен дә операторны тыңларга чакырды. Соңыннан әйтте:

— Безнең Самотлорда техника мондагыга караганда әйбәтрәк, яңарак, җайлырак, әлбәттә,— диде.— Тик без аның кадерен белеп җиткермибез. Эшчеләрнең квалификациясен күтәрмәсәк, безгә бернинди автоматлар да ярдәм итмәячәк. Җәлилчеләр безне бу мәсьәләдә нык оттылар.

Себергә кайткач та Г. Шаболкин нефтьче кадрларның әзерлеген күтәрү турында зур сүз кузгаткан. Җәлилдә күргәннәрен шәһәр газетасына да язып чыккан.

«Җәлилнефть»кә килүләренең икенче көннәрендә себерлеләр скважиналарның җир асты җайланмаларын ремонтлау объектлары белән танышып йөрделәр. Алар ремонт эшләренең торышы, ничек оештырылуы белән нык кызыксыналар.

Хәзер Самотлорда да нефтьне чыгару катлаулана, механикалаштырылган авыр ысулга күчү бара. Татарстанда исә бу өлкәдә дә бай тәҗрибә тупланган. Килүчеләр арасыннан скважиналарның җир асты ремонты цех начальнигы Николай Федорович Любимов нәкъ әнә шул тәҗрибәдән мөмкин кадәр күбрәк өйрәнеп китәргә тиеш иде. Николай Любимов, әле студент чагында ук, Җәлил поселогында практика үткән икән. Дөрес, егет ул елларда Самотлорда эшләячәген дә, Себер нефтенең язмышы шушы җир асты ремонтының нинди дәрәҗәдә алып барылышына бәйләнеп калачагын да уйлап тормаган. Бу килүендә исә Любимов цехның бөтен структурасын күздән кичереп чыгарга теләде. Ул хезмәтнең ничек оештырылуын да, мораль һәм материал кызыксындыру чараларын да, хәтта эшчеләрнең кайда ничек туклануларын да — барысын да белергә тырышты. Вакыты тар иде аның. Мин ихтыярсыздан аны күзәтергә тотындым: бер көн эчендә боларның бөтенесен тикшереп чыгарга ничек өлгерер соң ул? Күзәтәм, карыйм. Любимов, кечкенә генә яңалык сизеп алса да, сораулар яудырырга тотына. Кемнән нинди җавап ишеткәнен куен дәфтәренә терки бара. Җәлил поселогындагы цех җитәкчесе Владимир Винокуровның кабинетында сөйләшкәндә, ремонтчы бригадалардагы ял көннәрен күчмә графикка көйләнүен ишетеп алды ул. Яңа сораулар яудырырга тотынды. Җаваплардан тагын да әһәмиятлерәк тәҗрибәле яклар ачыла иде.

Любимов, торбалар саклана торган урынга җиткәнче, эшнең оештырылуы һәм агышы белән бик канәгать булып йөрде. Кинәт ул:

— Нигә соң бу торбаларны аркылы-торкылы саласыз? — дип, беренче тапкыр чыраен сытты.— Бөгелеп бетәчәкләр бит! Яхшы хуҗа бервакытта да болай яткырмас иде.

Мастер Әмир Кадыйров бригадасында аны куркынычсызлык техникасы чараларының тиешле дәрәҗәдә куелмавы борчуга салды. Самотлордагы контрольнең ничек җайга салынуын аңлатып бирде.

Бу очрашуда да кунакларның һәркайсы эш урынындагы үз вазифасына караган мәсьәләләр белән танышып йөрде. «Нижневартовск» идарәсе начальнигының урынбасары Ванцет Солтанов, әйтик, җәлилчеләрнең җитәкчелек системасындагы отышлы алымнарына игътибар итте; промком председателе урынбасары К. Ногинов исә социалистик ярыш күрсәткечләренең ни дәрәҗәдә яктыртылып баруын тикшерде. «Самотлор» ял итү базасы директоры Валентина Глазырина Җәлилдәге дәвалану учреждениеләреннән чыгып тормады, аны мондагы гаҗәеп шартлар сокландырган иде. Ахырда ул:

— Көнләшүемнән үләм инде! — дип, күңелендәгене ачыктан-ачык әйтеп салырга мәҗбүр булды.

Делегация җитәкчесе Ванцет Солтанов аны тынычландырырга ашыкты:

— Сез «Самотлор»да да шундый ук җиһазлар булдырырга тырышыгыз! — диде.

— И-и, бездә кайдан табасың аны? Бинасы да андый түгел бит безнең! Врачлары да юк...

Бу көннәрдән соң нибары ярты еллап вакыт үткәндер, профкомның киңәйтелгән бер утырышында врач Тамара Ивановна Гориславская сүз сорады. Көн тәртибендә медицинага кагылышлы сораулар юк иде. Шунлыктан барысы да врачка сәерсенебрәк карап алдылар. Аның сүзе әллә ни озын да түгел икән.

— Иптәшләр! Без ял базасын өр-яңа баштан ремонтлап чыктык,— диде.— Менә диган җиһазлар кайтарттык, квалификацияле белгечләр чакырып китердек, дәваланырга теләгән эшчеләрегезне генә күргән юк. Нигә җибәрмисез?

«Самотлор» базасында профилактик дәвалауны ял көннәрендә үткәрәләр. Бу яңалык нефтьчеләрне, эштән һич аермыйча, стенокардия, йөрәк һәм кан тамыры чирләре, гипертония һәм башка бик күп җитди авырулардан саклап кала башлады.

Җиһазлар һәм врачлар мәсьәләсе хәл ителгәч, ял базасын киңәйтергә, аның бер бүлекчәсен шәһәр эчендә дә булдырырга мөмкин иде. Кадрлар алтын бәясендә йөртелгәндә, кешеләрнең сәламәтлеген саклау эшендә берниндн киртә дә тормаска тиеш, дип карадылар.

Бусы инде — җәлилчеләрне дә мавыктырырлык тәҗрибә. Кадрларны саклау өчен анда да әллә нинди чаралар уйлап чыгаралар. Себерлеләр, Җәлилдәге нефтьчеләрнең ике катлы коттеджларын күреп, сокланып туя алмады. Бөтен уңайлыклары булган андый коттеджлар беренче булып хезмәт ветераннарына бирелде. Акрынлап бик җыйнак, заманча бизәлгән ике катлы йортлардан аерым шәһәрчек барлыкка килде. Хезмәт кешесенә күрсәтелгән игътибарның, кайгыртучанлыкның бик күркәм үрнәге иде бу. Самотлорда исә торак мәсьәләсен хәл итү шактый кыен әле. Җәлилчеләр үрнәгендә, үз көчләре белән йортлар салырга ашыксалар, кадрларны Себердә саклап калдыру, мөгаен, уңай якка чишелер иде.

Ярыш нәтиҗәләрен чыгарырга килгәч, себерлеләр Җәлил поселогының чисталыгына, җыйнаклыгына югары бәя бирделәр. Шунда яшәүчеләрнең үзләрендә яңа йортларны кадерләп саклау, чисталык өчен көрәшү гадәте тәрбияләнгән булуны сизү аларны бигрәк тә шатландырды. Поселок урамнарына автомашиналар, хәтта мотоцикллар белән кереп йөрү дә тыелган. Транспорт өчен читтә махсус тукталыш мәйданы ясалган. Берсендә, әлеге тәртипне бозып, поселок Советы председателе «Москвич»ы белән урам аша уза. Автоинспекция вәкиле машинаның номерын язып кала. Кешеләр председательгә нинди җәзалар бирелүен белмиләр белүен, әмма шул көннән бирле ул да, «Москвич»ын тиешле урында калдырып, урам буйлап җәяү генә үтә.

Кунаклар Җәлил поселогындагы культура һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү учреждениеләре белән дә бик теләп таныштылар. Күпсанлы үзешчән сәнгать түгәрәкләре, спорт секцияләре, герой шагыйрь Муса Җәлил музее, нефтьчеләрнең хезмәт даны бүлмәсе — болар барысы да яшьләрне заман рухына җавап бирерлек итеп тәрбияләү өчен оештырылганнар.

Тикшерү-танышулар ахырына якынлаша иде инде. «Җәлилнефть» идарәсе началь-

нигы Шәфәгать Тәхәветдинов янына җыелып, үткән елда ирешелгәннәргә нәтиҗә чыгарырга һәм алдагысына яңа килешү төзергә генә калды. Себерлеләр арасында иң тынгысыз күренгән Николай Любимов начальникка да мең төрле сорау өзерләп өлгергән: үзгәртеп корулар нәрсәдән башланды? Оештыру чараларыннан иң әһәмиятлесе кайсы булып чыкты? Җир асты ремонтын башкаручы цех ничек ныгытылды? Болар барысы да нинди нәтиҗәләргә китерде? Нинди ялгышлар булды? Кыскасы, тавык чүпләп бетермәслек күп һәм җитди сораулар иде алар. Әмма Шәфәгать Фәхразович һәр җавапны өздереп әйтте дә бирде:

— Җир асты ремонтын башкаручы цехның эшен тамырдан үзгәртергә кирәк булды, чөнки мондагы җитешсезлекләр аркасында без тәүлек саен тонна ярым ягулыкны әрәм итә идек. Цехка зур ярдәм күрсәтелде, хәзер безнең бу коллективка һичнинди дәгъвабыз да юк! — диде.

Башка сораулар бирүче табылмады. Инде барысы да ачык иде. Ярыш нәтиҗәләрен генә йомгаклап куярга кирәк. Сүз саннар белән исәпләп күрсәтүчеләргә күчкәч, җәлилчеләрнең кайбер процентлары шактый югары икәнлеге беленде. Аларның йөзендә җиңүчеләрдә генә була торган горурлык нурлары балкый иде. Ярышташларның күп өлкәдә алда икәнлеген күрү себерлеләрнең дә кәефен күтәргән. Алар инде үзләренең җиңелүләрен аңлап торалар кебек. Әмма мин, бу коллективларның икесенә дә бертигез мөнәсәбәттәге нейтраль кеше буларак, түзеп кала алмадым, исләренә төшердем:

— Ленин исемендәге «Нижневартовскнефть» идарәсе 1979 елдагы уңышлары өчен КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының, ВЦСПСның һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы белән бүләкләнде бит,— дидем.— Бу бүләк ВДНХның Бөтенсоюз Мактау тактасына да теркәлде!..

Кунаклар, тыйнаклык саклау йөзеннән, үзләренең бу җиңүләрен телгә алмый торганнар икән. Безнең нефтьчеләр исләреннән чыгарып җибәргәннәр. Минем әйтеп куюым бик урынлы булды. Җәлилчеләр, ир-егетләргә хас киң күңеллелек белән:

— Беренчелек даны «Нижневартовскнефть»кә бирелсен! — дигән сүзне үзләре үк әйтте.

Үз якларына кайткач, Себер нефтьчеләре Җәлилдә күргәннәрен шәһәр газетасына да язып-язып чыктылар. Николай Любимов мәкаләсе «Ремонтчыларның мөмкинлеге» дип атала иде. Анда ул, үзе өчен яңалык санаган һәр тарафка тукталып, җәлилчеләрнең җир асты ремонтында ирешкән уңышларын тасвирлады. Мәкалә азагында исә бу бай тәҗрибәнең кайбер якларын «Нижневартовскнефть» идарәсендә дә үзләштерә башлаулары хәбәр ителгән иде.

Идарәдә, ярыш нәтиҗәләрен истә тотып, чыннан да, җитди эшләр башланып китте. Үзгәрешләрнең күбесе җир асты ремонтын алып баручылар коллективында иде. Хезмәтне фәнни оештыру лабораториясе тәкъдиме буенча ремонтчылар бригадасында көнлек эшне фотога төшерделәр. Фотосурәтләрне анализлау ремонт эшләрендәге саксызлыкны, әрәм-шәрәм, техника һәм вакытны җилгә очырулар фаш ителде, алардан тизрәк котылу юлларын эзли башладылар. Цех начальниклары, зур белгечләр, бүлекләрнең һәм производствога хезмәт күрсәтү базасының җитәкчеләре катнашында киңәшмә үткәрелде.

Җир асты ремонтчыларының эшен яхшырту өчен комплекслы чаралар уздыру планы төзелде. Бу яңалык башка коллективларның хезмәтенә дә бәйле иде. Шунлыктан ремонт бригадаларының атналык эшен планлаштырганда, ярдәмче коллективларның да, техник хезмәт күрсәтүче белгечләрнең дә катнашы күздә тотылды.

Атналык эшне алдан планлаштырып кую бригадаларның вакытны әрәм-шәрәм итүеннән коткарды. Әле шуңа өстәп, көндәлек «оператив»калар да оештырылды, боларында һәр бригаданың тәүлек эчендә башкарыла торган бурычы ачыклана, аларга кирәкле техника билгеләнә иде. Нәтиҗәдә ремонтлауның срогы кыскарды, сыйфаты яхшырды.

«Нижневартовскнефть» идарәсе җир асты ремонтчыларына игътибарны арттырганнан-арттыра барды. Техниканың да әйбәте иң элек аларга бирелә иде, өр-яңа ике автобус та аларга бүлеп куелды, Октябрь бәйрәме алдыннан өлгертелгән егерме биш квартирага да алар кереп урнашты. Монда себерлеләр җәлилчеләрдән дә арттырып җибәрә алды бугай.

Үзара ярышып эшләүче дус бу коллективлар бишьеллыкны һәр икесе үзләренчә башлап җибәрде. Планны үтәү өчен аларга үз шартларына гына хас кыенлыкларны җиңәргә туры килә иде. Әмма еллар узган арада мәшәкатьләр уртаклаша да барды. Әйтик, җәлилчеләр унынчы бишьеллыкта торбаларны коррозиядән саклауда зур адым ясадылар, махсус җайланма ярдәмендә торба эчен тутыгудан коткара торган эләә белән каплау ысулын үзләштерделәр. Самотлорда башта моның кирәге юк иде әле. Үткән җәйдә анда да торбаларның тутыгуы нәтиҗәсендә аварияләр булгалады. «Җәлилнефть» тәҗрибәсен искә төшерергә туры килде.

Җәлилчеләргә дә Себер нефтьчеләреннән өйрәнер нәрсәләр шактый. Анда, нефть җыю урыннарында блоклы корылмалар салып, югары күрсәткечләргә ирештеләр. Әмма шул ук вакытта бу корылмаларның җитешсезлекләре дә ачылды. Татарстанда бу ысулны үзләштерә башлагач, Себердәге хаталар искә алынды.

Себерлеләрнең төркемләп бораулавы да Татарстанда файдаланырлык отышлы алым булып чыкты. Алар Җәлилгә килгәндә, Әмир Кадыйров бригадасы бер төркемдәге өченче скважинаны бораулый иде. Самотлор кешеләре аңа файдалы киңәшләр бирделәр, чөнки алар өчен скважиналарны төркем-төркем бораулау — гадәти күренеш.

Моңа кадәр Самотлорда ягулыкны мул нефтьле скважиналардан бик җиңел суырталар иде. Вакыт узган саен, эш катлаулана бара, элек үз куәте белән бәркелеп торучы нефтьне хәзер башка юллар белән кысып чыгарырга туры килә. Ике меңнән артык скважинага механик ярдәм таләп ителә. Аларның һәрберсенә җир асты ремонты ясаучылар кирәк.

Бу проблема унынчы бишьеллыкның соңгы елында ук көн тәртибенә килеп басты. «Нижневартовскнефть» идарәсе илгә сиксән алты миллион тонна нефть бирергә тиеш иде. Җир асты ремонтчыларына мең ярымлап ремонт үткәрер, өч йөз егерме скважинаны механик ысулга күчерер өчен кимендә егерме бригада кирәк. Каян алырга соң ул көчне? Идарәдә нибары сигез бригада бар. Ярдәмгә Татарстан нефтьчеләре килде. Алар Татарстанда бригада-бригада булып оештылар да экспедицион вахта методы белән эшләргә керештеләр. Әлмәт, Азнакай, Баулы, Лениногорск, Алабуга, Актүбә ремонтчылары ике атна Самотлорда эшлиләр дә ике атнага өйләренә, ял итәргә кайтып китәләр.

Ел башында шундый алты бригада оештырылды. Аларның күбесе Себергә тиз ияләнде. Эш искиткеч кыен иде. Бригада кайчак самолеттан төшеп тә өлгерми, ремонтланырга тиешле скважинага ашыга. Эш сәгатен санаулар бетте. Нефтьчеләрнең өйләре-гаиләләрендә дә тынычсызлык артты. Нинди генә нык булсалар да, адәм баласының көч-куәте дә, чыдамлылыгы да чамасыз түгел бит. Себерлеләр, көннәрнең берендә аларның кул селтәве, кирегә тырный башлаулары да мөмкин, дип, шикләнеп тә йөргәннәр иде. Әмма безнең очып йөрүче бригадалар торган саен яхшырак нәтиҗәләргә ирештеләр. Ярты еллап вакыт узгандырмы-юктырмы, Әлмәт һәм Лениногорскида оештырылган Александр Белов белән Өлфәт Минхәеров бригадалары Себер чыганакларын беренче башлап үзләштергән ветераннардан да калышмый башладылар. Өченче кварталда исә Минхәеров бригадасы «Нижневартовскнефтегаз» берләшмәләрендә иң яхшы бригада дип танылды.

Тагын ярты ел үткәч, Себер нефтьчеләре яңадан Җәлил поселогына килделәр. Бу сәфәр идарәнең мастерлар Советы тәкъдиме белән оештырылган иде. Мастерлар Җәлилдә күргән яңа, отышлы алымнарны, Самотлорга кайткач, башкаларга да сөйләп аңлатырга, эштә файдаланырлык дәрәҗәдә төшендерергә тиеш булдылар. Күргән яңалыкларын һәркем кайту белән үк аерым отчет итеп теркәргә һәм шуның белән юлга чыгуын акларга мәҗбүр ителде. Ул хәтта командировкада өйрәнеп кайткан отышлы ысулның Себердәге бер конкрет коллективта файдалануын да күзәтергә һәм бу хакта мастерлар Советына яки идарәгә җиткерергә тиеш.

Социалистик ярышның иң күркәм максатын алдынгы тәҗрибәдә мөмкин кадәр тизрәк таратуда күрсәк, бу коллективлар арасындагы мөнәсәбәттә без аның киң колачлап тормышка ашуын расләй алабыз. КПССның XXVI съезды карарларында социалистик ярышның нәкъ әнә шул практик ягына аерым басым ясалды. «...Алдынгы тәҗрибәнең үз вакытында гомумиләштерелүен һәм планлы рәвештә таратылуын тәэмин итәргә,— диелә ул карарларда.— Хуҗалыкларда алдынгы тәҗрибә гел тупланып тора

һәм аны предприятиеләрнең, оешмаларның уртак хәзинәсенә әйләндерә барырга кирәк...»

Себер нефтьчеләренең мастерлар командировкасына куйган таләпләре — бу карарны тормышка ашыру юлында бик матур үрнәк. Җәлилчеләр янына килгән мастерлар нинди хәзинә алып киттеләр соң? Советның председателе Валентин Иванович Григорьев скважинага кирәкле сальникларны әзерләгәндә материалны механик ысул белән кисүне бик ошатты. Цехта бу җайланманы күргәч, үзләрендә аны кулдан кисеп азаплану аңа хәтта көлке тоела башлады.

— Кара инде, ә?! — диде ул, иптәшләренә мөрәҗәгать итеп.— Бездә бит бу эшнең күләме дә артыграк, димәк, механикалаштырудан файданы да күбрәк алырга мөмкин.

Бер ай да үтмәде, җәлилчеләр җайланмасы Нижневартовскида да эшли башлады, сальникларны тизрәк тә, җиңелрәк тә ясарга тотындылар.

Өлкән инженер Г. А. Кононенко да, өлкән мастер Ю. И. Соловьев та, нефть әзерләү цехының резервуарлар паркы начальнигы А. С. Комиссаров та үз эшләрендә Җәлилдә күргәннәреннән файдаланалар.

Биредә без Җәлил һәм Нижневартовск нефтьчеләренең ике сәфәренә генә тукталдык әле. Алар арасында уңай тәҗрибә уртаклашу өзлексез дәвам итә. Социалистик ярышның ярты еллык нәтиҗәсен чыгару-йомгаклау өчен генә дә алар бер-берсенә егермешәр тапкыр баралар. һәр сәфәр исә яңа ачышларга — димәк, производствода яңа отышларга китерә.

Нижневартовск нефтьчеләре унынчы бишьеллыкта планнан тыш унөч миллион тонна ягулык бирделәр. Бу «Җәлилнефть» идарәсенең ел буе житештергән нефтеннән күбрәк. Тик себерлеләр ярышташларын зур саннар белән шаккаттырырга теләмиләр. Киресенчә, алар Татарстанда инде хәл ителгән кыенлыкларны җиңү ысулларын тирәннәнрәк өйрәнү ягында торалар. Татарстан нефтьчеләре исә унберенче бишьеллык куйган зур планнарны уңышлы үтәүдә Самотлор егетләре үрнәген алда тотып эшлиләр.

Безнең карашыбызча, Себер нефтьчеләренең хезмәт ысулында Татарстан өчен әһәмиятле яклар шактый күп. Әйтик, нефтьне җыю, әзерләү, озату циклы өчен салынган комплекслы туплау пунктларын эре блоклы төзелешкә нигезләү зур игътибарга лаек. Төркемләнгән скважиналарны ремонтлау, тоз утыруга каршы көрәш чаралары, хезмәтне автоматлаштыру һәм механикалаштыру һәм башка бик күп яңалыклар Татарстандагы нефть предприятиеләре өчен матур үрнәк була ала. Ашыгыч рәвештә генә санап үтелгән әнә шул фактлар Себер нефтьчеләрен чагыштырмача кыска вакыт эчендә илебезнең нефть индустриясе флагманына әйләндерде дә инде.

Үткән елның октябрь аенда «Нижневартовскнефть» коллективы оештырылганга ун ел тулды. Монда чыгарылган нефтьнең күләмен күрсәтүче саннар үзләренең зурлыгы белән теләсә кемне сокландыра алырлык. Беренче елда Самотлор чыганакларыннан ун миллион тонна нефть алынган иде. Бишенче елда инде монда ел саен йөз миллион тонна ягулык җитештерелә башлады. Унынчы бишьеллыкта «Нижневартовскнефть» дүрт йөз миллион тонна чамасы кара алтын бирде.

«Җәлилнефть» идарәсе исә бишьеллыкта аны нибары алтмыш өч миллион тонна гына җитештерә алды. Аерма зур бит. Мондый коллективларның үзара ярышуы акланамы соң? Себерлеләр «көчсез көрәшче» белән ярышудан туймасalармы? Җәлилчеләрне Себер байлыгы куркытмасмы? Ун ел элек башланып киткән бу ярыш хәзер мәгънәсез бер формализмга әйләнеп калмаганмы?

Һич юк! Себерлеләр Татарстандагы дусларына зур хөрмәт белән карыйлар, аларны үзләренең остазларыннан саныйлар. Алар зур-зур җиңүләргә җәлилчеләр ярдәмендә генә ирешүләрен тирәннән аңлыйлар.

«Җәлилнефть»тә себерлеләрнең байлыгына көнләшеп карау юкмы соң? Бу кадәр күп нефть җитештерә торган идарә белән ярышып торуның ни кызыгы бар, дип, дуслык элемтәләрен өзәргә чамаламыйлармы? «Нижневартовскнефть» идарәсенең үсеш темплары, чыннан да, искиткеч бит! Алар ун ел эчендә Бөтенсоюз социалистик ярышында егерме мәртәбә беренчелекне алдылар. Кайбер елларда алар җиңүче исеменә квартал саен ирешә килделәр. КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының, ВЦСПСның һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы аларга биш мәртәбә тапшырылды. Бу тантаналар вакытында Себер нефтьчеләре ор-

деннар һәм медальләр белән бүләкләнә торды. А. Суздальцев, Н. Сливин кебек иң яхшы операторларына Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Ә «Җәлилнефть» идарәсе кайбер кварталларда үзенең «Татнефть» берләшмәсе эчендә генә дә бүләкле урыннардан колак каккалады.

Бер карагана, мондый тигезсезлек коллективларны бер-берсеннән читләштерә кебек иде. Әмма алар һаман да иң тугры дуслар булып кала бирәләр. Алар өчен коры саннар түгел, хезмәткә мөнәсәбәт, тырышлык, йөкләмәләрне үтәүдә намуслылык мөһим.

Бу идарәнең ярыш килешүендә бер-береңә ярдәм итү, тәҗрибә уртаклашуның дәрәҗәсе аерым бер пункт булып тора. Кем кемгә күбрәк ярдәм итә алган! Кайсы коллективның уңай тәҗрибәсе уртак кулланышка күчкән?

Монда хәтта ил күләмендә зур масштабта алып барыла торган социалистик ярыш өчен дә үрнәк булырлык күркәм сыйфат бар. Саннардан, продукция җитештерүнең гомуми күләменнән чыгып кына нәтиҗә ясау авыр түгел ул. Шул ук ярыш ялкынын кешеләрдә, коллективларда матур гадәтләр тәрбияләүгә дә юнәлтү бер дә зарарлы булмас иде, безнеңчә. Коллективларның үзара тулысынча аңлашып, көчсезләрнең көчлерәккә таянып, куәтлерәгенең ярдәмгә омтылып хезмәт итүен оештыру кешеләрдә эшкә иҗади караш тәрбияләячәк.

Социалистик ярыш килешүе төзегәндә коллективлар бер-берсе алдында вәгъдә бирәләр, йөкләмәләр алалар. Ярышка нәтиҗә ясаганда инде шул вәгъдәгә кемнең тугрырак калуын, алдан бирелгән сүзне кемнең җиренә җиткеребрәк үтәвен тикшерергә кирәк. Җәлилчеләр, бу яктан караганда, һәрвакыт оталар. Алар себерлеләргә ихлас күңелдән ярдәм итәргә әзер, уңай тәҗрибәләрен бик теләп уртаклашалар.

«Нижневартовскнефть» идарәсендә дә моны тирәннән аңлыйлар һәм һич тә бурычлы булып каласылары килми. Алда әйтеп үткән идек инде: нефтьне судан һәм тозлардан чистарту ысулларына алар Җәлилдән өйрәнеп кайттылар. Ә хәзер себерлеләр нефте чисталык ягыннан иң яхшы сыйфатларга ия. КПССның XXVI съезды ачылу хөрмәтенә алар җитештергән нефтьнең туксан алты проценты иң шәп сыйфат белән тапшырылды. Монда инде нефтьчеләрнең теләсә кайсы коллективын көнләштерерлек тәҗрибә туплана. Геннадий Иванович Шаболкин миңа шатланып әйтеп өлгерде инде:

— Иң элек, әлбәттә, җәлилче дуслар белән уртаклашачакбыз,— диде.

Шикләнергә туры да килми. Хезмәттәге дуслыкны бары тик шундый мөнәсәбәтләр генә ныгыта ала.

# ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

# БЕР ХИКӘЯ ПОЭТИКАСЫ

Әмирхан Еникиның хикәяләү алымы бик үзенчәлекле: язучы нинди дә булса үзәк геройны тотып ала да, аның тормышындагы үзгәрешләргә игътибар итә-итә, матур әдәбиятка хас әдәби алымнар белән үз күңелендәге йөгәнсез дәртне тыштан яшерә-яшерә, тын гына, моң гына көйли. Прозасының шагыйрәнә үз ритмы бар. Нинди генә темага мөрәҗәгать итсә дә, әсәрләрендә бер төрле эчке мәгънә яңгырый. Бу — гүяки, дөреслек белән ялганның, матурлык белән ямьсезлекнең, картлык белән яшьлекнең беркайчан да тәңгәл килмәвен ассоцияциялүү, шуны тәэсирле итеп хикәяләү. Сугыш темасына багышлап язылган «Ялгыз каз» хикәясендә дә бу мәгънә эчке бер җеп булып сузыла.

Хикәядәге ялгыз ана каз — корыган, яндырылган җирдә тереклекнең сакланып калуын күрсәткән символик образ. Берничә әсәрдә (тагын «Мәк чәчәге»нең дә фикере шуңа якын) бертөрле идеяне ачарга нәрсә мәҗбүр иткән соң язучыны? Ә. Еники үзе бу сорауга түбәндәгечә җавап бирә: «...Утлы җәһәннәмнән соң яңадан тыныч тормыш алып кергән солдатлар тирәсенә адашкан хайваннар — этләр, колыннар, кәҗә, кош-кортлар ияләшә иде. Шулай бер авылга кергәч, безнең ротага да ялгыз ана каз килеп ияләште. Әсәрдә уйлап чыгарган бернәрсә дә юк. Вакыйгалар да, персонажлар да минем үз күзәтүләремнән чыгып тасвирланган».

Ялгыз казның төп образ булуы хикәянең кыйммәтен һич тә киметми. Чөнки каз әсәрдә кеше кебек уйлый, моңлана, шатлана. Әсәрдәге башка персонажларның һәм авторның да уй-тойгылары нигездә шул казга бәйләп яисә аның аша бирелә. Бу — кешеләштергән образ.

Әсәр болай башланып китә: «Немецлардан азат ителгән бер авылда бер каз күрдек. Гаҗәпләнмәгез, тере каз иде. Башы соры, муены белән түше ак, канатлары янә соры — безнеңчә ала каз була. Җитмәсә үзе ана каз икән. Әгәр безнең солдатлар Калинин урманнарында тәвә кошын очратсалар бу кадәр гаҗәпләнмәсләр иде»...

Язучы риторик эндәш («Гаҗәпләнмәгез, тере каз иде») белән укучыга мөрәҗәгать итеп, анда гаҗәпләнү тойгысын тагын да көчәйтү өчен, гипербола да (тәвә кошы) куллана. «Җитмәсә ана каз икән». Бусы инде аның буын үрчетүче, нәсел калдыручы, димәк, тереклекне дәвам итүче булуын ассызыклау. Күп нокталар куеп һәм «икән» ярдәмче фигыле белән ритмлы сузылган бу җөмләгә тагын эмоциональ төсмер дә өстәлә.

«Рәсәй казы немец илбасарларының ач аппетитларын котырткан майлы калҗа булды. Әйтерсең, казлар өстенә үләт явы килде»... Әйе, автор «үләт явы», ди,— үлем генә түгел, фашизм тереклекне әнә нинди газаплы юл белән буган. Укучы күз алдына тетрәндергеч трагик картина килеп баса. Көчле антитезага корылган фраза котырынган фашистларның Рәсәйдәге майлы калҗага ташлануларын күрсәткән үтергеч сатира да булып яңгырый. Үләт бөтен «Рәсәй» җиренә килә. Татар теле калыпларына салынып әйтелгән бу сүз — фашизмның бар халыклар байлыгын корытучы булуына ишарә.

«Бердәнбер ала каз безнең солдатларда зур кызыксыну тудырды. Һәркем аз гына булса да тукталып, аңа сокланып карый торган иде. Олырак яшьтәге солдатлар исә, аның тирәсенә җыелып, тыныч тормыш турындагы истәлекләрен бер-берсенә сөйләргә яраталар иде». Бер-бер артлы килгән бу җөмләләрдә «дә» һәм «иде» ярдәмче фигыле кулланып, язучы вакыйганың үткән булуына ярымманусулык белән

ишарә ясый. Ләкин солдатларга шул кадәр иялә шкән каз — «соңра ул кинәт безне ташлады, безне онытты, китте бездән». Ташлашу, оныту,— укучы бу сүзләрне моң, кайгы сибүче сүз буларак кабул итәргә өйрәнгән һәм язучы бу мәгънәгә кат-кат басым ясый. «Ничек булды соң бу?» — риторик сорау белән мәрәҗәгать итеп, автор укучыны тагын кызыксыну катыш гаҗәпләндергән вакыйгалар эченә алып кереп китә.

Вакыйгалар әсәр башында тыныч кына хикәяләнә, барлык җан иясенең дә үз пары, семьясы барлыгы күрсәтелә һәм шунда «Йортта бары ала каз гына кала» — дигән үзәк өзгеч фраза килеп керә. Ялгызы калган каз, көне буе нишләргә белмичә «нәрсәдер көткәндәй, озак кына каранып тора». Фигыль составында «дәй» кушымчасы кертеп каз ялгызлыгы укучы йөрәгә тоярлык итеп ассызымлана һәм җөмләгә музыкаль аһәң өстәлә. Автор кайбер сүзләргә фонетик үзгәреш тә кертеп (чөкердәшеп — чүкердәшеп) җөмләне җанландырып җибәрә.

Хикәядә йорт хайваннары төрле күзлектән чыгып, төрле максатны белдерү өчен сурәтләнә. Әтәч горурлыгы «кып-кызыл мәһабәт әтәч» дип, комик пландарак күрсәтелә. Җөмләдә музыкальлек саклансын өчен, җан ияләре эпитетлар белән дә күрсәтелә (ак кәҗә, кызыл әтәч, ала каз).

Бичара казның ялгызлыктан эче пошу бер дә гаҗәп түгел. Чөнки тирә-якта туй бара — табигать туе. Әнә «җир өсте көннән-көн үсә, куера барган яшь үлән белән түшәлде һәм кояшка карап йөзләрен ачкан хуш исле нәфис чәчәкләр белән бизәлде. Ул чәчәкләргә билен буган, аякларына сары итекләр кигән **яшь кияүләр** төсле, **үттан чая** бал кортлары килеп кундылар... Ак, сары, кызыл-чуар купшы күбәләкләр, туй вакытында яшь килен тирәсендә **куштанланып** йөргән кызлар шикелле, бал корты белән кавышкан чәчәк әйләнәсендә уйнаклап-талпынып очалар. **Сылу** сыерчыклар, **назлы** сандугачлар, **иркә** кәккүкләр, туйга чакырылган **җырчылар** кебек, су буендагы куе тирәлекләрдә туктаусыз сайрап торалар. **Җитез** сабан тургайлары, такмаклап биюче егетләр сыман, нурлы һавадан төшмичә, сайрый-сайрый, сызгыра-сызгыра җилпенәләр».

Әсәрдәге тасвирларның һәркайсы гаҗәеп күркәм поэзия, һәркайсы — җыйнак, төгәлләнгән бер шигырь. Язучы оста чагыштырулар, гади һәм катлаулы эпитетлар (дәртле кояш кытыклап уянды, табигать тирләп көлеп күзен ачты) кулланып, оста рәссам буларак, тереклек белән табигатьнең үсүен һәм яшәрүен бөтен бер сурәт итеп күз алдына китерә. Бу **сүз сурәтләр** бер-берсен үзара тулыландыралар, шагыйрәнә ритм белән, матур, бәхетле тормышның башлануын күрсәтәләр.

«Үзләренең гаиләсе ишле булуларына шатланып, Машаның карт кәҗәсе дә: «тапкач баланың шундыен табарга кирәк!» дигәндәй, горурлы мактану белән дөньяга карый, тик масаеп сакалын гына сыйпап куймый».

Шул рәвешчә укучы күз алдына туып, яшәреп килүче яңа тормыш килеп баса. Мелодиянең борылышы кебек, менә шул матурлыкны, тулы тормышны ала казның ялгызлыгы алмаштыра.

Башкаларның бәхетле яшәүләрен, үзенең шундый аяныч хәлен сизгән казның эче пошмыймы соң? Укучы күңелен сыкратып, үзәк өзгеч җөмлә яңадан кабатлана. Риторик сорау бу аянычлыкны тагын да көчәйтә төшә. Автор «һичшиксез эче пошадыр, йөрәге яна торгандыр» дип, халык иҗатында еш очрый торган эпитетлар куллана, раслау алмашлыгы белән фикерен куәтләп, икенче төрле уйламаслык итеп тә куя. «Шуңа аның эче поша. Ул ялгызлыктан аптырап сөйләнә, дәртсез тавыш белән, муенын җыерып, мескен булып сөйләнә». Югары стиль алымы — эпифора кулланып язылган бу җөмлә укучыны ялгыз казның «эчке дөньясы»на алып керә һәм образ тагын да җанландырыла.

Авылга сугышчылар килеп керүен, урамнарның җанланып китүен ялгыз каз менә болайрак күзәтә: «Ләкин никадәр сак һәм житди каранмасын, бу солдатлар кырык беренче елның җәендә авылга кинәт» «хальц, вальц, һау, һау» дип ямьсез, ят тавышлар белән кычкырып шаулап килеп кергән, муеннарына элгән кара саплы автоматларыннан тиктомалга уңга-сулга пуля сиптергән, кызарып бүртенгән чырайлы, акайган күзле солдатларга һич тә охшамыйлар иде».

Язучы бер тын ала да, шул тын эчендә төрле сурәтләү чараларына басым ясап, фашист солдатының хәрәкәте, портреты аша, үтергеч сатира белән фашизмга хас булган бөтен сыйфатларны тасвирлап бирә. Каз да «йөрәк төбендә тынычлык тоя,

гүя ул кемнең кем булуын сизенә иде». Игътибар итик: йөрәгендә түгел, ә «йөрәк төбендә» — димәк, нык, ышанычлы тынычлык. Тоя, сизенә — ике төрле фигыль формасы бер-берсенә синоним булып киләләр.

Повар Иван әсәргә икенчел дәрәҗә образ булып (беренчел дәрәҗәдәге — Маша) килеп керә. «Менә ул — киң, таза гәүдәле, янып торган шома битле — ак калпак, ак алъяпкычтан җитез атлап килеп керде». Менә ул — бу сүз-тезмә казның алдан ук бу кешене көткәнен белдерә. Иван аңа, үз итеп, «Исәнме, иркәм»,— дип эндәшә.

«Повар, кулларын бутап, казның муеныннан эләктерергә тырыша, ләкин аның муены елан җитезлеге белән боргалана, бер озыная, бер кыскара, поварның әле бер ботыннан, әле икенче ботыннан эләктереп, борып ала». Сөйләмне җанландыру өчен җөмләдә борып ала («тешләп ала» түгел) фигыле кулланыла. Каздагы мимик хәрәкәтләр аеруча үзенчәлекле чагыштыру белән (елан җитезлегендәге муен) оста итеп тасвирлана һәм «каз салмак кына ава-түнә атлап, сүзсез генә кайта» дип, күз алдына җанлы картина бастырыла.

Ләкин көннәрдән бер көнне каз поварга иярмәде. «Повар аны чакырып карады, бераз үпкәләп, шелтәләп тә алды, ләкин каз аның сүзләренә һич колак салмады; ул ни өчендер тын һәм уйчан иде». Менә шул җөмлә ярдәмендә, казның моңлануы аша күтелмәгән вакыйгага ишарә ясала, укучыны кызыксындырган каз тормышында яңа үзгәрешләр башлана.

Казның юклыгына аптыраган солдатлар да «Иван, озын муенлы ярдәмчең кайда?» — дип сорыйлар. Казның Иваннан аерылуына сәбәп тавык астында чыккан бәпкәләр икән. Укучыда эмоциональ тәэсир кузгату өчен тавык образы комик планда килеп керә («берәүнең «кор-кор» диюе ишетелде»). «Бу күренештән ала каз тәмам таңга калды. Ул бәпкәләренә карап бөтен барлыгы белән йотылган, һич айный алмаслык булып сихерләнгән иде. Бичараның йөрәгендә бу могҗизалы күренештән нинди хисләр уянды икән? Ничек итеп, нинди тавыш, нинди хәрәкәт белән ул аны белгертә алсын! Әгәр каз кеше кебек булса иде, һичшиксез, бу минутта аның ике күзеннән сөенеч яшьләре мөлдерәп агып киткән булыр иде».

Язучы фигыльләрнең берсеннән-берсе матуррак синонимик төрләренә, риторик сорауларга, эндәшләргә мөрәҗәгать итеп, укучыда тирән тойгы уята. Аның күзаллавы белән ана казның уйлары бергә үрелә һәм, җанлы образ булып, укучы күз алдына килеп баса. Ә сюжет төенләнешен каз үзе чишеп җибәрә, ул, булдыксыз ана кулыннан бәпкәләрне тартып алып, су буена китә.

«...Машаның чакыруын колагына да элми икән, бары тик су эченнән сап-сары булып күренгән сыңар тәпиен генә селтәп куя». Биредә инде казның горурлыгы югары дәрәҗәдә күрсәтелгән. «Табигатьнең кечкенә бер хатасы төзәлгән кебек булды». Язучы өнә шулай фикерне төгәлләп тә куя.

Ә менә хикәянең соңгы өлеше: «Аяк тавышлары тына, урам янә көмеш нурлы тынлыкка чума, һәм каз тавышлары үтеп китүчене азат ителгән авылда яңадан туып килгән тормышның җанлы сулышы, куанычлы авазы кебек озатып кала».

Бер-берсен тулыландырып килгән һәм бер-берсенә эмоциональ төсмер биргән төрле сурәтләү чаралары тулы бер музыкаль яңгырашка ия булып, әсәрне йомгаклап куялар. Шул рәвешле Әмирхан Еники прозасы, гомумән дә, шигъри әсәргә, музыкаль әсәргә якыная төсле. Бу сыйфат аның бүтән хикәяләрендә тагын да үстерелә, көчәйтелә.

Әлфинур ЗИННӘТУЛЛИНА.

# ФАНТАСТИКАГА ЧЫНЛЫК КИРӘК

Казанда күп тапкырлар шундый хәлгә шаһит булганым бар: берәр танышы белән бик матур гына татарча сөйләшеп торган абзый яки апа аның баласына эндәшкәндә кинәт русчага күчә. Соңгы вакытта мондый «Драстуй»ларга, өлкәннәрне аптырашта калдырып, «Исәнмесез» дип җавап кайтаручы балалар арта башлады.

Фантастик әсәрләр белән очрашканда минем үземнең дә чамалау-сиземләү әлеге абзыйныкы кебегрәк була иде. Үзем инде укып торам, ә үзем, бу артык иркә, артык «шәһәрчә» жанрның татарча сөйләшә белүенә шикләнеп, «Юктыр ла, тәрҗемәдер лә!» дип уйлыйм. Мондый халәттән мине Адлер Тимергалинның дәвамлы һәм актив иҗаты чыгарды.

Фатих Әмирхан, Шамил Усманов, Гадел Кутуй, Атилла Расих... Бу исемнәр татар фәнни фантастикасын үстерүдә күпмедер дәрәҗәдә тарихи эзлеклелек һәм дәвамчанлык турында сүз алып барырга мөмкинлек бирә. Әмма әлеге жанр бездә бар дип авыз тутырып әйтү өчен әдәбиятка Адлер Тимергалин килү кирәк булган, күрәсең.

Гадәти романнар һәм повестьлар арасында кысрыкланган, «Без дә бар!» дигән авазлары ишетелер-ишетелмәс кенә яңгыраган берничә фантастик «бәләкәчләр»гә, «чандыр-ябык» булсалар да, мөстәкыйль китаплар кушыла торды. Һәм менә әдәбиятыбыз тарихында истәлекле көн: укучы кулына тулысынча фантастик әсәрләрдән торган калын (күләме 21,5 табак) китап [1] керде.

Инде сан бизмәнен читкә куеп, авторның күп еллык иҗатының сайланмасы булган бу китапны сыйфат бизмәненә салып карыйк.

«Җинаятьче», «Хәерле юл», «Әфсен түгел...», «Кабул булсын теләгең» — үзенчәлекле композицияле бу әсәрләрне әдипнең татар әдәбиятында повесть һәм хикәя жанрларын үстерүгә берникадәр өлеш кертүе дип бәяләргә була. Шулай да А. Тимергалин алып килгән яңалыклар күбесенчә әдәбиятның ул сайлаган тармагы белән бәйле. Гомумән, башлангыч хәлендәге татар фәнни фантастикасы кысаларында гына тикшергәндә, А. Тимергалин иҗаты ачышлар тезмәсе булып тоелыр иде. Ул тәкъдим иткән яңа темалар гына да бихисап. Ул татар укучыларын космос темасы орбитасына алып чыккан беренче язучы булды. Шул нисбәттән, әсәрләрдә очраган фантастик образлылык аеруча игътибарны җәлеп итә. Космик корабль экранында якынаеп килүче икенче бер корабльнең чагылышын, мәсәлән, язучы менә болай сурәтли: «... төртке йолдызлар арасында күзгә бәрелеп торган озынча җисем, киптергеч кәгазендәге кара тамчысы кебек, тагы җәелә, зурая башлады». («Адашкан йолдыз»). «Җинаятьче» хикәясе персонажы Җир хакында «нәгъләт төшкән шарик» дию белән, зәңгәр планетабыз миллиардлаган күк җисемнәренең берсе, аларның дә үтә бәләкәе булып күз алдына килә...

Адлер Тимергалин фәнни фантастиканың татарча терминологиясен булдыруга шулай ук зур көч салды. Ул әсәрләрен техницизмнар белән тутырудан качарга, терминнарны мөмкин кадәр гадирәк һәм татарчарак итәргә омтыла («диаметр» сүзе урынына да ул, мәсәлән, «аркылысы» дигән сүзне куллана).

Милли фәнни фантастика. Бу сүзтезмә колакка ничек кенә сәер тоелмасын, аны әйтер вакыт җиткәндер инде. Раслау төсендә булмаса, сорау төсендә. Бөтен барлыгы белән киләчәккә, интернациональ як өстенлек итәчәк чорга төбәлгән фантастика милли була аламы соң? Була алган тәкъдирдә, миллилек ничек чагылырга тиеш? Адлер Тимергалинның Ассони, Гамсун, Глюк, Уилки, Понтекорво кебек персонажлар белән тулы повестьлар һәм хикәяләрен укыганда мин әнә шул хакта да уйландым. Бәлки Орнит Довер («Ерак планетада») һәм аның шуңа охшаш исемле иптәшләренән «Бәла космоста да аяк астында гына йөри», «Хәрәкәттә бәрәкәт» кебек гыйбарәләр әйттерүдәдер? Юк, саф татарча сөйләшү генә геройларның милләтен үзгәртә алмаган кебек, әсәрне дә милли итә алмас.

Вакыйга буржуаз илләрдә барган әсәрләр дә күп. Аларның барысына да дип

---

[1] Адлер Тимергалин. Кайтыр юллар. Татарстан китап нәшрияты. 1981.

әйтерлек актуальлек, фаш итү мотивлары хас. Әдәби эшләнешләре дә (кайберләрен исәпкә алмаганда) әйбәт. Арада «Хәерле юл», «Уян, сөеклем», «Кабул булсын теләгең», «Рибб Локсның үлеме» кебек сокландыргыч үрнәкләр дә бар. Әмма чит-ят җирләрдән, ниһаять, үзебезнең Казанга («Рәшад эффекты»), нарат сагызы исе аңкып торган борынгы Болгарга («Әфсен түгел...») әйләнеп кайткач, сулышлар иркенәеп киткәндәй була. Монда инде безнең күңелгә яфрак кыштырдавына кадәр якын һәм кызык! Күрәсең, әдипләр дә, күпчелек укучылары кебек, «гомер»ләренең төп өлешен туган җирләрендә «үткәреп», чит тарафларга «барып кына кайткаларга» тиешләр...

А. Тимергалин иҗатын чын-чынлап аңлау һәм бәяләү өчен аны, әлбәттә, дөнья һәм совет фәнни-фантастикасының бүгенге казанышлары фонында карарга кирәк.

И. Ефремовның «Андромеда томанлыгы» романында Галәмнең аерым мәдәниятләре Бөек Боҗрага тоташкан кебек, аерым фантастлар да бергәләшеп үз дөньяларын төзеделәр. Һәркайсының анда үз белемнәре, үз планеталары бар (берсенең планетасы күгендә, әйтик, яшел болытлар йөзеп йөрсә, икенчесендә алар шәмәхә булыр), һәркайсы акыл ияләренең үз вариантын өстәргә омтылыр (спрут, океан, агач, үлән...). Әмма Галәм бер. Терминнар да уртак («бластер», «һуманоид»...). Язучылар бер-берсеннән асылда иҗат манералары белән генә аерылалар. Кемдер фаразны яки мавыктыргыч сюжетны үз итсә, икенче берәүләр хискә, драматизмга яки психологизмга өстенлек бирү ягында. Аларның гармониясенә иң талантлылар гына ирешә.

Әйе, фәнни-фантастикада яңалык ачу гаять авыр эшкә әйләнеп бара. Аерым галимнәрнең ачыш-фаразларын файдалану исәбенә генә көн итүче фантастлар да аз түгел. Эрудиция, аналитик акыл белән бер мичәүгә җигелгән көчле фантазия, фәнни фараз-гөман белән сюжетны оста йөгәнләү сәләте А. Тимергалинга үз идеяләрен дә тәкъдим итә торган **иҗади** фантастлар сафында атларга мөмкинлек бирә дисәк тә ялгышмабыз кебек. «Адашкан йолдыз», «Ерак планетада», «Хәерле юл» повестьларында, «Өчлек, җиделек, туз» хикәясендә һәм бу китапка кермәгән кайбер әсәрләрендә фәннең төрле тармаклары, Галәм төзелешенә кагылышлы кызыклы фикерләр әйтсә, күп кенә башка хикәяләрендә ул мәдәниятләр үсеше, аларның бер-берсенә йогынты ясау мөмкинлеге турында уйлана.

Соңгы теманың нинди киң, катлаулы, хәтта четрекле булуын аңлау өчен, каршылыклы берничә фикерне карап китү дә җитә. «Адашкан йолдыз», «Баскыннар» әсәрләрендә башка планеталар язмышына йогынты ясаудан тыелып калырга кирәклеге алга сөрелсә («...читтән ярдәм алу исәбенә аякка баскан мәдәният үз көчләренә үзе ышана торган, тәвәккәл һәм көчле булып җитлегә алмый), «Әфсен түгел» хикәясе персонажы исә «Космик тугандашлыкны мин тигезлек дип кенә түгел, яшь мәдәниятләргә ярдәм дип тә аңлыйм»,— дигән нәтиҗәгә килә. Ә инде «Кайтыр юллар» хикәясендә «катышмау» теориясенең эзе дә калмый. Үзләрен мәңгелек йокыга дучар итеп, шушы халәтләреннән ләззәт-тәм тапкан җан ияләре белән очрашкан Җир вәкилләренең уй-теләкләре бер генә була: кире кайтып, бу дөньяны дер селкетергә! Болар бар да гаять табигый булган эзләну чылбырының буыннары.

Әмма китапта сагаерга мәҗбүр итә торган очрашу да тасвирланган. Авторның соңгы әсәрләреннән берсе булган «Адашкан йолдыз» повестенда (кызганычка каршы, әсәрләрнең язылу вакыты күрсәтелмәгән) өч космонавт Кояш системасы чикләренә килеп чыккан билгесез җисем белән очрашу өчен юлга җыена. Әлеге җисемнең «Кояш» һәм «Ватан» космик корабльләре югалуга сәбәпче булу ихтималы да күздә тотыла.

«Фикер ачык, төгәл һәм хикмәтле афоризм кебек кыска булганны ярата торган» Нур Сэлим (Космик Үзәк директоры) очышның максатын кайта-кайта аңлата. Шулай да мин үзем аны һич кенә дә ачык итеп күз алдына китерә алмадым. «Җир мондый югалтуларга чик куярга тиеш. Кояш системасында билгесез көчләр калмаска тиеш. Сезнең экспедициянең максаты әнә шул» — «...төп максат шул: әгәр фаразыбыз дөрес булып, ишек төбебездә читтән килгән гакыл ияләре очрата калсак, без алар белән элемтә урнаштырырга, үзара аңлашырга тиешбез». — «Безнең төп бурыч — элемтә урнаштыру. Контакт». Әнә шундый «конкрет» инструктаж алган экипаж исәнимин генә тиешле районга килеп җитә. Җисем — билгесез космик корабль — «Тур-

гай»га (Җир корабленә) үзе якыная башлый. һәм... контакт урнаштырырга тиешле «Тургай» читкә ыргыла. Объект тагын якыная. Шуннан менә ни була. «Капитан психоаналитикка күз төшергән иде, тегесе, керфеген генә кагып, атом-төш бомбаларын әзерләргә рөхсәт бирде... Объект егерме километр гына калгач, команда буенча, мин уң яктагы батареядан залп бирдем. Реактив бомбалар, артларыннан кайнар тасмалар сузып, «Дзета»га таба омтылды. Алар аны үзләре эзләп табачак, шартлаячак һәм... Кояш системасына әллә каян килеп чыккан затлар монда кем хуҗа икәнлеген күрәчәкләр».

Бәхеткә каршы, «Дзета» үзен саклау чарасын таба, һәм... контакт урнаштырыла.

Повестьны укымаган кеше бу вакыйга, кешелеккә мондый саксыз адымнар ясалмасын өчен, кисәтү төсендә китерелә икән, дип аңларга мөмкин. Әмма геройлар — уңай, һәм автор аларны гаепләвен берни белән дә сиздерми.

Сүз сәнгати дөреслек турында гына бармый. Бүтән планета вәкилләре белән очрашу теләсә кайсы мизгелдә булырга мөмкин. Кешелек гомумән моңа алдан ук әзер булырга тиеш. «Космос әчкерлелекне яратмый, аны кулга-кул тотышып, пакъ йөрәк белән генә яулап була». — «Бер генә мәдәният тә башкалар хакына — хәтта югарырак торучы затлар хакына да үзен корбан итә алмый. Тегеләрә ягында шанлы тарих, гыйлем һәм тәҗрибә булса, болары шундый ук шанлы киләчәккә өмет баглый...» — фикер концентрациясе һәм төгәллеге белән кагыйдәгә якын торган мондый гыйбарәләр Адлер Тимергалин әсәрләрендә аз түгел. Алар нәкъ менә әлеге максатка хезмәт итәләр.

Фантастика «геройлары» түгел, чып-чын роботларыбыз ерак планеталарның туфрагын учына алган бу чорда фантастик жанр дигәнебез безнең күз алдында «ярым фантастика»га әйләнеп бара икән ләбаса! Асылда бу — безнең иртәгәсе көн күлмәген киеп каравыбыз: «бу җирен төзәтәсе, җиңен кыскартасы булыр...»

Димәк, фәнни-фантастик әсәрләрнең чынлык иллюзиясе арта. Хәер, элек-электән бу жанрны, әйтик, әкиятләрдән аерып торган бер билге нәкъ шул иде бит инде. «Сәнгатьтә фантастик башлангычның чиге һәм кагыйдәләре бар. Ул реаль як белән шулкадәр нык берләшергә тиеш ки, сез аңа тәмам ышанып бетә язарга тиеш». Фәнни фантастиканың танылган осталары Достоевскийның бу шартын җиренә җиткереп үтиләр. 1938 елда Америка радиосы Герберт Уэллсның «Дөньялар сугышы» дигән романы буенча эшләнгән радиоинсценировка тапшыра. Аны тыңлаган алты миллион кешенең бер миллионга якыны, марсианнарның Җирне яулап алуы турында репортаж тапшырыла икән дип уйлап, паникага төшә. Шундый ук тапшыру барганда меңнәрчә эквадорлы (монысы илленче еллар башында була) йорт-җирләрен ташлап кача.

А. Тимергалинның «Адашкан йолдыз» повестен укып чыккач, уйга калдым. Яңа техник һәм фәлсәфи идеяләр, сокландыргыч фаразлар бар. Драматик ситуация, мавыктыргыч сюжет. Эчтәлеге буенча әсәр тетрәндерергә тиеш. Ә ул мавыктырып та җиткерә алмый. Ара-тирә психологик чынлык югала башлый. Менә космонавтлар үз корабльләрен суырып алган «Дзета» корпусына аяк бастылар. Я дуслык, я дошманлык илчесе ул. һәрхәлдә, ят дөнья вәкилләре белән тарихта беренче очрашу көтелә. Космонавт бу минутта нәрсә хакында уйларга, ни кичерергә мөмкин? Менә повесть героеның уйлары: «һәр тарафта йолдызлар, йолдызлар... Алар һәммәсе бала чактан ук таныш, һәммәсе күңелгә якын. Әнә Өлкәр йолдызлыгы. Аны юкка гына Иләк йолдыз дип атамаганнар шул...» Мизгелнең чын бәһасен күрсәтәсе, киеренкелек өстисе урында автор үзе үк тормоз педаленә баса!

«Тәмам караңгыланып җиткән күк йөзендә бихисап йолдызлар чекрәешеп яна. Тик алар Җир күгендәге йолдызларга бер дә охшамаганнар, урыннарын алмашып, буталып беткәннәр. Тимер Казыкны да, Җидегәннәрнең чүмечләрен дә табып булмый... Күк гөмбәзен кап урталай ярып үткән Киек Каз юлы гына: «Таныйсызмы? Бу мин бит! Сез үз Галактикагызда. Моннан башка галактикалар да күп Галәмдә. Сез әле өегездән артык ерак түгел» дигән сыман, вак кына җемелдәп, күңелдә өмет уята иде». — Чын космик лирика тулы бу мини шедевр үзе генә дә кайбер повестьларны алыштыра ала. Авторга бер генә теләк телисе килә: һәрвакыт үз таланты югарылыгында иҗат итсен иде ул!

**Рәфикъ ЮНЫСОВ.**

# ТАБИГАТЬ ИСЕМЕННӘН

Урман шавы, чишмә чылтыравы, кошлар җыры аша Табигать безнең белән аңлашу юлын эзлидер кебек. Әнә шулай, адәм баласына тереклек, хәрәкәт, мәхәббәт дигән мәңгелек төшенчәләрнең тирән асылы ачыла башлый... Табигать кешенең рухын ныгыта, күңелен нечкәртә. Миһербанлы әниебез кебек, ул безне яшел бишегендә тибрәтеп үстерә, бага, тәрбияли. Менә шуңа күрә аны күз карасыдай саклау, төрле кыерсытулардан яклау безнең изге бурычыбыз гына түгел, намус эшебез дә. Билгеле булганча, тормышыбызның тизләтелгән хәрәкәте, фәнни-техник революция нәтиҗәләре табигать дөньясында уңай һәм тискәре үзгәрешләр килеп чыгуына сәбәпче булды. Бу үзгәрешләр, үз чиратында, әйләнә-тирә мохитне саклау дигән проблеманы бөтен җитдилеге белән безнең алдыбызга китереп бастырдылар. Табигатьнең борчулы авазы язучыларыбыз иҗатына да хәвефле тон өстәде.

Бер мәсьәләнең берничә чишелеше булган кебек, әдәбиятыбызда табигатьне саклау темасына ике төрле юлдан килү күзгә ташлана. Гомәр Бәширов, Марс Шабаев, Нәби Дәүли, Габдулла Шәрәфи, Әхсән Баянов, Габделхәй Сабитов, Фаил Шәфигуллин әсәрләрендә дә бу тема кешенең туган җиренә, туган табигатькә мөнәсәбәтендә, аның иминлеген яклап аваз салуында чагылыш таба. Гарәфи Хәсәнов, Мәрди Рафиков, Касыйм Тәхау, Аяз Хәсәнов кебек «саф табигать язучылары»ның әсәрләрендә исә табигать сурәте бераз үзгәрәк яссылыкта ачыла. Аларның әсәрләре беренче карашка натуралист язмаларын да хәтерләтәләр. Анда табигатьнең теге яки бу күренеше игътибар үзәгенә алына һәм тәфсилләп хикәяләнә. Үсемлекләр, кошлар, хайваннар дөньясын тасвирлау аша укучыда табигатькә мәхәббәт хисе, ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү кебек игелекле максат белән иҗат итәләр әлеге авторлар.

Әйтергә кирәк, Гарәфи Хәсәнов әсәрләре арада аерым урын алып тора. Татар балалар әдәбиятын үстерүгә сизелерлек өлеш керткән бу тыйнак әдип ярты гасырга якын инде бер үк темага — табигать темасына тугрылыгын саклап килә. Аның хикәя һәм повестьларын бер дә икеләнмичә «Табигатьнең сайланма әсәрләре» дип атарга мөмкин булыр иде. Аларны балалар гына түгел, өлкәннәр дә көтеп алалар, яратып укыйлар. Чөнки ул табигать дөньясының игътибарыбыздан читтәрәк торган өлешен мавыктыргыч итеп сурәтли, геройлар язмышына үзенең йөрәк җылысын куша.

Узган ел дөнья күргән «Җир — ул уртак йортыбыз» исемле китабында Гарәфи Хәсәновның ярты гасырга якын чор эчендә иҗат ителгән хикәя һәм повестьлары тупланган. «Яр башында болан» дигән хикәядән башлап «Җирем-суым» диеп исемләнгән өч китаплы повестька кадәр язучы табигать гүзәллеген җете буяулар белән сурәтләп, күз алдыбызга китереп бастыра. Әсәрләрнең китапка урнашу тәртибе дә кызыклы һәм көтелмәгән янәшәлеккә нигезләнгән. Әдәбиятыбыз аксакалы Гомәр ага Бәширов бу китапта кереш мәкаләсендә билгеләп үткәнчә, «җанлы табигать һәм аның җансызы — бер-берсен тулыландырып, берсе икенчесендә яшәргә тиеш». Табигатьтә буйсынучылар һәм буйсындыручылар юк! Бары дус, тату һәм бердәм тереклек кенә яши. Бу — яшәешнең төп формуласы булырга тиеш! Шушы фикер язучының барлык әсәрләрен бер ноктага туплый.

Гарәфи Хәсәнов үз геройларының — үсемлекләр, кошлар, бөҗәкләр, җәнлекләрнең гаҗәеп тормышын эчке бер җылылык белән сурәтли. Без һәрдаим язучының үткен күзен һәм йомшак күңелен тоеп торабыз. Ул дөньяны самими һәм садә итеп күрергә гадәтләнгән, табигатьтәге бар тереклекне якын фикердәше һәм кардәше итеп таный. Табигатьне җәберләүчеләргә кискен нәфрәт хисен белдерә, тәртипсез малайның корбаны булган чуар тараканнар фаҗигасен ул сөекле кешесен югалткандай авыр кичерә («Чуар таракан фаҗигасе» исемле хикәя). Вәхшилек белән бер тамырдан шыткан золым аның бәгырен үткен пычактай телгәли. «Тимәгез аңа, рәнҗетмәгез!» дип әрнеп кычкыра кебек язучының җаны! Җан авазы укучыны да битараф калдырмый, аны да уйландыра, кылган гамәлләренә күңел күзе белән карарга чакыра...

Көндәлек тормышыбыз катлаулы вакыйгаларга, мөнәсәбәтләргә бай булган кебек, табигать тә алардан мәхрүм түгел. Алыйк «Куркак куян һәм усал селәүсен» хикәясен генә. Үзен зәзрлекләп килгән селәүсеннең үткен тырнагыннан качып, киң күңелле боланнар янына элдертә кылый! Тупас көч оттыра, усал селәүсен боланнар мөгезеннән көч-хәл белән генә котыла... Куянның зирәклеге укучыда соклану тудыра. хикәяне бер сулыштан укырлык итә. Яшәешнең нигезе игелектә, бер-береңә ярдәм кулы сузуда, явызлыкка үз вакытында киртә куюда дигән фикер үткәрә язучы.

Табигатьнең йөз аклыгын, намусын һәм хокукларын яклауны үзенә бурыч итеп алган язучы иҗаты туган ягыбыз гүзәллегенә мәдхия буларак кабул ителә. Җыйнак парчалардан үрелгән «Уникe матур» повесте тулаем ел фасыллары турында сөйләүгә корылса да, ил-көнебезнең чибәрлеген, табигатебезнең байлыгын сурәтләве белән күңелебезгә тирән уелып кала. Әкият чалымнары да кереп киткән бу әсәрендә язучы табигатьтә барган үзгәреш-яңарышларның асылын аңларга, үсемлекләр, кошлар, бөҗәкләр, җәнлекләр өчен гомуми булган уртак сыйфатларны ачарга омтыла, ел фасыллары алышынуының тәртипле агышын күзәтеп, бу илаһи халәткә чын күңелennән соклана.

Өч китаптан торган «Җирем-суым» повестенда да табигать темасы тамырга үстерелә. Агулы елан, гөберле бака, йомран, керәшә, ләтчә, шәүләгән, абага чәчәге, нарат, ромашка, имән, зирек, бүдәнә һәм табигатьнең башка төр җан ияләре тормышыннан алып язылган җыйнак хикәяләрдә Гарәфи Хәсәнов фәнни дөреслеккә һәм төгәллеккә ирешү принцибын беренче урынга куя. Шуңа күрә, табигатьнең беренчел «мини энциклопедиясе»н хәтерләткән бу әсәр танып-белү офыгыбызны чиксез киңәйтә, күңел хәзинәбезгә рухи байлык өсти. Гаҗәеп серләр, искитәрлек могҗизалар иленә сәяхәт «кече кардәшләребез»гә ихтирамыбызны арттыра. Ихтирам итмәслек тә түгел шул алар! Баксаң, кошлар арасында да «телләр», «диалект»лар бар икән. Мәсәлән, шәһәрдә яшәүче карганарның авылдагы ишләре белән «сөйләшкәндә» кыенлык кичерүен, аларга тылмач булып, авыл белән шәһәр арасында очып йөргән каргалар хезмәт итүен беләидекме әле без? Әнә ничек гармониягә омтыла икән табигать. Кеше кулы, кеше сизгерлеге җитешмәгән җирдә дә ул үзе эшли, күпсанлы эшсөярләренә куша.

Гарәфи Хәсәнов табигатьнең «җанлы китабын» тирәнтен аңлап «укый», үзенчәлекләрен яхшы белеп иҗат итә. Җанлы һәм җансыз табигать күренешләрен сизгер йөрәгә аша үткәреп, дәвамлы күзәтү-тикшеренүләре белән чагыштырып төшерә ул хис-тойгыларын ак кәгазь битенә. Шуңа аның әсәрләре җанлы, табигый агышлы. Ул — нәфасәт дөньясы таләпләренә бик сизгер язучы. Аңа фактик материал һәм әдәби материал дигән шактый четерекле мәсьәләне чишәргә туры килгән. Фактик материалга гына нигезләү язучыны натурализм чикләнгәнлегенә китерер иде. Әсәрләре белән тәүге тапкыр танышканда, чыннан да, натуралист язмалары түгелме соң бу дигән шөбһәле уйларга бирелергә дә мөмкин. Икенче тапкыр, җентекләп укысаң үзеңнең ялгышуыңны аңлыйсың. Дулкынландыргыч хикәяләр, сәнгать әсәрләре икән ләбаса... Табигатьнең җанын ачкан, холык-фигылен сурәтләгән, аның үзенчәлекле образын тудырган хикәяләр икән. Язучы әдәби материалның тамырын фактик материал туфрагыннан аермыйча, катлаулы теманы уңышлы хәл итә, тойгыларыбызны уятырлык әдәби картиналар тудыра.

Гарәфи Хәсәнов әсәрләре бай тел белән язылган. Сүзләрнең саллысы, фикергә тәңгәл килердәйләре генә сайланган. Балаларга атап язуын истә тотып, «кыскалыкта — осталык» дигән принциптан тайпылмый яза. Кыскасы, теле йөгерек, ташлар арасыннан чөлтерәп аккан салкын чишмә кебек уйнак. Көянтәдәй сыгылмалы, көйле һәм шул ук вакытта купшы бизәклардән, төче тәгъбирләрдән, ялган пафостан азат. Кошларның «сөйләшү-аңлашулары» бу әсәрләрнең табигый яңгырашын көчәйтә, стилен җанландыра. Мәкаль һәм әйтемнәрне, канатлы сүзләрне, җырларны үз урынында белеп файдалану да фикернең үткенлеген тирәнәйтә, сүзнең үтемлелегенә куәт бирә. Яшәеш матурлыгын уртак йортыбыз — җир язмышының иминлеген кайгырту белән сугарылган бу игелекле иҗат укучыны да тирән уйландыра, аны тереклек язмышына битараф калдырмый.

Әхмәт СӘХӘПОВ.

# ТАКТАШ ХАТЛАРЫ

*Журналга тәкъдим ителә торган бу хатларны күпләр, хәтта шагыйрьнең иҗатын һәм тормышын өйрәнүче галимнәр дә югалган дип исәплиләр иде. Ләкин шагыйрь кулъязмаларын югалтып та, яндырып та, гильотинада кистереп тә булмый, күрәсең. Алар, төрле чикләрне үтеп, барыбер әдәбиятка кайталар. Такташ хатларының да язмышы шундый. 80 еллык юбилеен бәйрәм иткән көннәрдә Такташның үнбер хаты яңадан Казанга әйләнеп кайтты. Аларны шагыйрьнең олы улы Рафаэль Такташ Татарстан Дәүләт музееның әдәбият бүлегенә тапшырды. «Әнинең соңгы ире үлгәннән соң, аның язу өстәле тартмасыннан табылды», — диде ул.*

*Музейга алынган хатлар 1929 елны Такташның беренче хатыны Гөлчәһрә Хәмзинага язылганнар. 1926 елның 8 маенда язылган бер хат кына шул елларда Мәскәүдә яшәүче Мәхмүд Максудка җибәрелгән. Хатны Гөлчәһрә Хәмзина тапшырырга тиеш булган, күрәсең. Нинди дә сәбәпләр аркасында ул тапшырылмый кала.*

*Журналга тәкъдим ителә торган хатлар — шагыйрьнең шәхси хатлары. Ләкин алардагы фикерләр, хисләр шәхси мәнфәгатьләр белән чикләнми. Хатларның күбесендә шул елларда әдәбиятта барган көрәш рухы чагыла. Аларда Такташның әсәрләрендә күтәрелгән әхлак мәсьәләләре, хатын-кыз һәм аның җәмгыятьтәге урыны һ. б. проблемалар күелә. Хатлар шагыйрь тормышының катлаулы чорында — мораль һәм материаль яктан иң авыр көннәрендә язылган. Аларда авыр, каршылыклы хисләр, тирән кичерешләр теркәлгән. Хатлардан укучы күз алдына ышанучан һәм бераз шикләнүчән, «бик якын җылылык хисләре белән янучы», тормыш ваклыкларыннан интегүче нечкә күңелле шагыйрь образы килеп баса. Такташ үзенең эчке кичерешләрендә дә, бөтен иҗатындагы кебек үк, олы җанлы һәм кешелекле шәхес булып кала.*

*Хатлар — шагыйрьнең интим хисләрен саклаучы документлар. Ләкин, безнең уебызча, вакыт үтү белән олы шәхесләрнең интим хисләре дә, күен дәфтәренә генә язылган фикерләре дә иҗтимагый яңгыраш ала.*

*Шагыйрь хатлары... Шагыйрь мәхәббәте. Ул аның иҗаты кебек үк олы һәм саф. Хатларның бүгенге яшьләр өчен тәрбияви әһәмияте дә зур.*

*Хатларны матбугатта чыгару Такташның иҗатын туплау һәм өйрәнү өлкәсендә, шагыйрьнең фәнни биографиясен эшләү юлында бер адым булыр.*

*Озак еллар өй шартларында, өстәл тартмасында саклану нәтиҗәсендә хатлар нык таушалган, урыны-урыны белән танымаслык хәлгә килгән. Аларны хәзерге орфографиягә күчереп, басылырлык хәлгә китерү өчен күп көч куярга туры килде. Кайбер хатларның даталары аларның эчтәлегеннән чыгып куелды. Кайбер искәрмәләр азакта бирелә. Кыскартылган урыннар күп нокта белән билгеләнде.*

**Дания БАҺАВЕТДИНОВА**
**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ**

Тимербай абый [1] һәм Мәхмүд әкә! [2]

Сезгә дуслык сәламе җибәрәм. Без монда Иделнең бозы китүне, беренче пароходларны көтеп, урамнарда ара-тирә җәйге кыска күлмәкләр кигән кызларны караштыргалап, дөнья көтәбез.

Мәскәү миңа һәрвакыт авыр тәэсир итә. Бу юлы да Мәскәүдән кайту белән, исключительно Мәскәүнең начар тәэсиреннән генә, берәр атна авырып яттым. Хәзер бер төрле хис итәм. 17 майларга колхозларга китәм. Хатның яртысына җитеп килгәндә генә Мәскәүдә «Яңалиф» белән язылмаган хатларны укымыйсыз дигән нәрсә искә килде. Мин әле рәтле яза белмәгәнгә, зинһар, бу хатымны гына укыгыз. Киләчәк хатларымны, әлбәттә, яңа хәреф белән язармын.

Сезгә тиешле хикәяләремне төзәтеп ятам. Егерменче майларга алырсыз. Ә сездән хәзер бер үтенечем бар. Пожалуйста, миңа тиешле акчаның калган 20 сумын майның беренче яртысына кертегез. Гөлчәһрәгә [3] доверенность җибәрәм. Ул алыр. Булмаса, безработный кешенең акча ягы беләсез ничек булырга тиешле.

Зинһар, унбишеннән калдырмый бирегез.

Казанда хәбәрләр күп, кунакка килегез.

Сезгә дуслык сәламе белән, күңелегез булсын өчен фамилиямне яңа хәреф белән куям.

Такташ. 8, V, 1926.

Сөеклем Галя!

Сиңа озын бер хат һәм рәсемемне җибәргән идем, алгансыңмы-юкмы, белмим. Чөнки озын хатымны иске адресың белән җибәргән идем. Хәнифә[4] хатларыңны китерсә дә, адресыңны оныткан иде. Бәлки ул хатны алмагансыңдыр. Ул тәэсирле генә хат иде. Үзебез исәннәр. Рафаэль дә, әни дә — һәммәбез дә синнән озын бер хат язып җибәрүеңне көтәбез.

Исәнлегең ничек?

Акча ягың?

Минем бик әйбәт түгел.

Сиңа шигыремне җибәрәм,[5] карарсың.

Гафу ит, озын язарга вакытым юк. Чөнки бу хатны сәгать 4 тә редакциядә генә язам. Баш бик арган.

Я, сау бул, Галя.

Такташ. 19, II, 1928.

Галя!

Сиңа 15 сум акча җибәрдем. Үзебез бер төрле торабыз. Бала исән. Үземнең настроение бик начар. Ялгызлык, юксыну, әллә нәрсә. Торасың, эшлисең — әллә нәрсә. Әә бит дөньяга яшәр өчен килгәнбез — ә яшәвебез әллә нинди юлсызлык, кызыксызлык белән бара. Аерылып торуның да чиге булыр микән? Соңгы вакытларда эшләгән дә юк... Эшләргә дәрт тә юк. Сине сагынам. Тыныч, пошлый, әллә нинди әчулы-авыру сагыну белән сагынам. Соңгы көннәрдә бигрәк ялгыз. Кемне дә күрәсе килми. Сөйләшәсе, шулай ук үземне үзем дә күрәсем килми. Әллә нәрсә йөрәктә. Сау калам.

Такташ. 4, I, 1929.

Сөеклем!

Сиңа хат язарга утырдым.

Авыр үпкә, авыртулы якынлык хисләре белән язылган хатларың мине борчыйлар. Мин сиңа язган хатларымда әллә ышандырырлык итеп язмаганмынмы, әллә син үзең шулай иманыңны минем сүзләргә югалттыңмы? Ни булса да, бала турында язган сүзләремә дә, үз турымда язган сүзләргә дә ышанмыйсың төсле. Рафуш[6] әллә кайчан терелде инде. Терелде генә түгел, шаярып, дөнья җимереп үсә. Син Аны өзелеп сагынсаң да, аның син исендә юк. Йөри, шаяра, уйный.

Бүген дә менә ике хатыңны алдым. Алар берсеннән-берсе уздырырга теләп, мине тиргиләр. Ниндидер ышанусыз хисләр белән тулы ул хатлар.

Мин телем белән алдасам да, каләмем минем алдарга өйрәнмәгән. Мин алдап, бер юл шигырь дә язганым юк. Менә шул мәңге алдаусыз каләмем белән сиңа язам. Рафушның исәнлегенә дә, минем сиңа булган алдаусыз якынлык хисләремә дә ышан. Биш ел синең белән үткән сансыз минутлар, мине сиңа өзелмәслек бәйләгән. Аларны син дә, мин дә өзәлмәбездер...

Бит минем дә сиңа ышанмаска бик күп сәбәпләрем бар. Ләкин мин аларга карамый, сиңа ышанам. Синең алдавыңны әйтергә курыкмавыңны белеп ышанам...

Казан син киткәнче ничек булса, шулай. 18 ендә минем «Югалган матурлык» куела. Менә шул нәрсә йөрәкне бик дулкынлата. Нәрсә булып чыгар? Нишләрләр? Әә впрочем, барыбер. Мин ул нәрсәне курыкмый яздым. Аңар булган тәнкыйтьне дә шулай бодрый, куркусыз каршы алам. 13 гыйнварда Габдрахман Сәгъди[8] хәсрәтлә-

ренең минем хакта доклады булды. Ләкин докладын куркып ясады, буталды. Гомәр Гали, Кутуйлар бик нык тәнкыйть иттеләр. Кыскасы, бик нык төште. Доклады вакытында зал гел көлеп барды... Ул бик нык җиңелде.

Башка язар хәбәрләр юк бугай. Син киткәннән алып әле серьезный эшли башлаганым юк. Эшкә һаман кайтып булмый. Йөрәктә ниндидер яшерен дулкынлану. Впрочем, таныш дулкынлану. Эшләр, язар алдыннан булган хисләрнең уянулары алар.

Синең хакта һаман уйлыйм. Әллә ниләр уйлыйм. Син бит үзең дә күп вакытта кара уйлар уйларга повод бирәсең. Әмма, Галя, мин әле сине бер вакытта да җиңә алганым юк. Бер генә минутка да бөтенләең белән үземнеке итә алганым юк... Ә сине бәлки миңа үземнеке итәргә дә кирәк түгелдер, хакым да юктыр. Ә кайчакларда «син минеке генә» дигәнгә шулай ышанасы килә. Юк, Галя, мин сиңа бәлки бүгенге уйлар чуалуы белән яза торганмындыр... бәлки? Мин сиңа һаман бер генә минутка да, аңлыйсыңмы, биш елда бер генә минутка да ышана алганым юк, син үзең дә ышандырырга теләгәнең юк бугай. Шуның өчен дә башка килгән кара уйларны куарга, ул турыда уйламаска, бөтенләй, бөтенләй уйламаска да, шуның белән тынычланырга уйлыйм. Ә син миңа ышанырга тиешле идең. Әйе, мин сине ышандыра алырлык якынлык хисләре күрсәтәм. Чынлап җылаганда күз яшьләре ихтыярсыз чыгалар. Син саф хисләремнең чынлап агуларын, саф килеш синең юлларыңа түгелүләрен күп күрдең. Ә син ул хисләрне миңа күргәзгәнең бармы? Алар бәлки миңа хыянәтсез булсаң да, булмаганнардыр. Миндә инде кызык бер нәрсә башланды. Син китү белән хыялымда эшләнгән синең рәсемең урыныңны ала. Ул рәсем синең үз тәсеңнән күп матур. Аңлыйсыңмы, минем хыялымда яшәгән Галя, ул — усал түгел. Ул мин теләгән минутларда мине ярата, чәчләремнән сөя. Ул хрусталь кебек саф. Тормыштагы Галя кебек юк нәрсәләр өчен ачуланмый да, тиргәми дә. Ташлап та китми. һаман минем хыялымда елмая. Матур, хыянәтсез, йөрәкне дулкынлатып елмая ул. Син ташласаң да, ул ташламас. Син башкаларга алмаштырсаң да, ул алмаштырмас. Чөнки ул рәсемне мин үземнең хыял көчем белән тудырдым. Чөнки ул Галя минем иҗат кулымның һәрбер хәрәкәтенә буйсына. Ул Галя бары минеке генә. Аны беркем дә күрми дә, беркем дә белми дә. Үлгәндә дә ул минем белән үләчәк «Югалган матурлык»[8] та мин аның шәүләсен генә бирдем...

Сау бул...

һади. 16, I, 1929.

Галя!

Мин синең ирония белән тулы хатыңны алдым. Настроение авыррак бер вакытта туры килгәнгәме, дөресен язам. Ертып ташлыйсым килде. Син, гомумән, әллә нәрсә. Ә впрочем, барсы да к черту.

«Югалган матурлык» уйналды. Казанның «политический грамотный» кешеләре контрреволюция таптылар[9]. Бүген гәзиттә шундый рецензия дә чыкты. Ләкин бу идиотизм да беренчелек белән танылган «сәяси сакаллар» тарафыннан гына. Культурный, акны карадан аера ала белгән, дөрестән дә сәяси аңлы кешеләр тарафыннан яхшы каршы алынды. Тик уйнаудагы начарлыклар гына пьесаның матур якларын караңгыладылар. Байкина үзенең уены белән бер нәрсәгә ярамады. Пьесага 10 февральдә дискуссия булачак. Сүгәнәсе Дон Кихотлар сүгенерләр. Үземдә, йөрәктә булган бөтен нәрсәләрне... дә әйтергә җыенам...

Бар да к черту. Мин үземнең бөтен йөрәк каннарымны иҗадыма бирдем. Омтылышларымның яктылыгы исеменә генә, киләчәктә тагын да көчемне шатлана-шатлана шул юлга бирүем намына гына минем әсәрләремә бераз уважение кирәк иде. Минем бу сүзләр массага каратылмый. Масса мине аңлый. Бирергә теләгән нәрсәм аларның йөрәгенә керә. Аларның минем җырларымны тәкърарлап йөрүләре генә дә миндә ул омтылышларны саклап килә.

Синең элек язган хатың артык авыр уйлар, миңа ышанмау хисләре белән тулган иде. Мин җавап та биреп тормадым. Теләсәң ышан, теләмәсәң ышанма, Галя. Минем

бөтә сине алдау уйларыннан башка да хаос. Ә мин — йөрәктән сөйли торган кеше. Минем тормышымда хатын-кыз мәсьәләсе артык зур урын ала алмый.

Синең үзеңә дә ышанмыйм мин. Бел, ышанмыйм. Син үзең бу мәсьәләдә миннән күбрәк алдарга тырышасың бугай. Син үзеңнең самолюбияңне саклау өчен генә мине башка хатын-кызлардан сакларга тырышасың бугай.

Дөрес бу, Галя.

Син үзең дә синең миңа никадәр кыйммәт булуыңны беләсең. Аны мин һәр адымымда күргәзеп килдем.

Уйлар караңгы, гел, к черту, к черту, к черту дигән сүзне генә тәкрар итә. Әйе, барсы, барсы к черту.

Бу хат кичә язылган иде. Настроение авыр вакытта. Болай, кайвакытта шундый уйлар булуны сиңа белдерү өчен генә бу хатны җибәрәм, Галям.

Бүген сиңа бер генә нәрсә җибәрергә уйласам да, кулымда бер тиен акчам юк. Таба да алмадым. Татар театрыннан ала алганым юк. Габидулла[10] барып төшкәч, сиңа бер нәрсә дә җибәрә алмавым авыр тәэсир итәр. Син, сөеклем, бик бала табигатьлерәк. Белсә идең, ничек авыр. Ачуланма, үпкәләмә, бәгърем. Хәл шулай, сиңа кыйммәтле булса, йөрәгемне кисеп җибәрергә аямас идем. Кичер, Галям.

Сиңа акча — 15 сум — жалуния исәбенә алып җибәргән идем. Бүгенме, иртәгәме — алырсың. Калганын Габидулла сөйләр. Хат яз. Көтәм.

Сагындым инде. Бик сагындым үзеңне. Ә беләсең, ничек авыр.

Сине үбеп Һади. 7, II, 1929.

Сөеклем Галя!

Мин синең кая икәнеңне белмим. Бәлки син больницададыр инде. Белсә идең миңа никадәр авыр. Йөрәгем ни кадәр өзелә, сөеклем. Ләкин син мине тыңламыйсың. Син үзеңчә итәсең. Хатым авыр минутларыңа туры килүдән куркып артык уйлыйм үзеңне. Ләкин ни булса да бел, һәр минутта, һәр секундта шулай йөрәгемне өзәсең. Сине сагынам. Ялгызлыгымны уйлаган саен сине сагынам. Ә мин бит бик ялгыз хәзер. Их, Галя, бар да труслар. Мин үземнең идеямда дөрес, Галя. Бүгенге миңа каршы булган бунт — куркаклар бунты. Алар мине пессимизмда гаеплиләр, ләкин алар үзләре куркаклар. Алар бу проблеманың дөрес икәнен беләләр дә, принциплар беләнме, яки хәл итәргә куркуданмы, күтәрмиләр, күтәрергә куркалар.

Киләчәктә бу мәсьәлә хәл ителәчәк. Ләкин хәзер, хәзер минем пьесамдагы Галиянең нагрузкасы булмаган хатын-кызлар да шундый хәлдә. Ә балалары, я үзләре аксыйлар. Бүгенге хатын-кызга бирелгән сәяси ирек, ирләр белән бертигез булу хокукы белән, хатын-кызның био-физиологический яклары карышалар. Мин хатын-кыз ана гына булырга тиеш димим. Шулай ук мин аны (ана булуны. Ред. искәрмәсе) икенче планга да куярга теләмим.

Ләкин аны хәл итәргә кирәк. Миңа каршы чыгучылар югарыдагы принциплар өстенә үзләренең надanлыклары, Дон-Кихотлыклары белән дә бик нык аксыйлар. Казанда пьеса турында дискуссия булып үтте. Сүгүчеләргә каршы миңа да туры сүзләр әйтергә туры килде. Хәзер бөтен Казанда, газит битләрендә, шунда сөйләнгән сүзләремне күпертеп, контрреволюция табып, шау килеп йөриләр. Ә мин нәрсә дигән идем: «Сез сухой оптимистлар, һәрбер ташланган лозунгы гамәлгә ашты инде дип йөрүчеләр. Лозунг — эшләнгән эш түгел, эшләнүгә тиешле эш дигән сүз ул. Безнең бик күп лозунгларыбыз әле йолдызлар өстендә очып йөриләр. Ә сез, алар гамәлгә ашты инде дип, авызларыгызны күбекләндерәсез. Хатын-кыз мең еллар буенча ана гына булып килде, ун ел эчендә ул ана да, җәмәгать эшчесе дә булып җитеште дип әйтү — наданлык...» — дидем. Шуннан контрреволюция чыгардылар. Соң, дөрес түгелме болар?.. Мин үземне бүгенге идеалларга бөтен йөрәк каннарым белән тоташкан коммунист итеп саныйм. Язган нәрсәмне йөрәк каны белән язам...

Язучы социальный заказны газитләрдән, кемнәрнеңдер кушуы буенча алмыйча, турыдан-туры массадан, үзеннән алырга, үзе эшләп, үзенчә язарга тиеш. Моның өчен

гакыл яшенә җиткән булырга, бүгенге идеалларны үз иткән булырга тиеш. Мин үземне шулай уйлыйм. Шулай язарга тырышам...

Җитәр, ардым. Сине дә арытканмындыр. Моннан элек җибәрелгән хатларыма җавап алганым юк. Әллә укуы авыр булган, авыр сүзләр язган идем бугай, кичер. Синнән җылы сүзләр, шатлыклы хәбәрләр көтәм. Бел, синең исәнлегең — минем бердән бер юанычым. Рафаэль сау. Һәммәбез исәннәр. Үзең хат язмасаң, кемнәндер яздыр.

Көтәм. Сау бул, сөеклем Галя.

Һади. 10, II, 1929.

Галя!

Хатыңны алдым. Алты хатка каршы. Син тизрәк кайт инде. Мин Шелангада[11] дача алдым. Бик матур җир. Өч айлап Иделдә су кереп, ял итеп бик тыныч гомер уздырырга мөмкин. Без — әби[12], бала белән 19-20 майда дачага чыгарбыз. Син озакка калма. Мөмкин кадәр тизрәк кайтырга тырыш. Инде агачлар яфрак яралар. Бөтен җир гаҗәп матур. Ике зачетыңның берсен күзгә калдырып булса да кайт.

Без монда бер төрле яшибез. Минем кәеф һаман рәтләнеп беткәне юк. Бераз салкын тидердем. Баш бик авырта. Матур сүзләр язарга күңел бармый. Әллә нәрсә булды күңелгә.

Теге вакыттагыдан соң гаилә тормышы, бигрәк тә синең белән тормыш, матур тормыш төзүгә бөтенләй дәрт бетте. Аңлыйсыңмы? Бөтенләй, бөтен нәрсә безразлично булып китте. Икебез өчен дә күңелле бер нәрсә тудыруга яки эшләүгә ышаныч та сүнде, дәрт тә бетте.

Әллә ни булды да — рухан да, тән белән дә, сине бары миңа гына, үземне сиңа гына бәйләнгән дип уйлый идем. Шул нәрсә дәрт бирә иде. Синең яратуыңны, битемдә синең җылы сулышларыңны сизү көч кертә иде. Икебезнең дә әйләнәбезне матурлауга дәрт уята иде.

Ә хәзер...

Ул сулышларыңның башкаларга тагын да матуррак, тагын да көчлерәк бирелүен сизгәч, мин синнән киттем. Сиңа гына бирелеп килгән хисләремне никадәр югары хисләр булуын исәпләми, кем теләсә, шуңар бирдем. Бәясез рәвештә җилләргә тараттым. Күкрәгемдә калганнарына да салкын боз кебек салкын кырау төште. Мин сиңа хәзер ничек карыйм? — Белмим, Галя. Ләкин борынгы җылылык, синең өчен дә нинди дә бер шатлык тудыруга омтылу бетте. Йөрәкне газаплый торган давыллы көнләү хисләре дә салкын кан белән уйлауга, яки бөтенләй уйламауга әйләнде.

Бу — рухымдагы соңгы ачык бер җимерелү.

Бала исән. Ләкин гел урамда йөрүе сәбәпле, сирәк күрәм.

Һади Такташ. 15, V, 1929. Сыркыдыга бармассың инде?!.

Дустым Галя!

Күрәшемдә, ялгыз минутларымда син генә мине аңлыйсың дигән уй юата. Тик ул уй да тотынып әйбер, юатыр хисләр булмаганнан гына. Мин — революция художнигы. Мин бүгенге миллионнарның йөрәк тибүен ачыграк ишетәм. Миңа каршы кешеләр — үзләренең булулары белән революция әдәбиятына бәхетсезлек китергән кешеләр... Ул кызыл, җансыз, алдаулы хамелеоннарны, яки тупас, талантсыз иҗат итүче типларны еллар күмәр. Минем алдаусыз хисләрем һаман, һаман шулай калыр. Менә шуның өчен бөтен тупас бәйләнүләрне күтәрергә тырышам. Киләсе югары еллар мине яклар.

Казандагы бүгенге минем эш мәйданым талантсыз кешеләр белән тулы. Алар бөтен пычраклыклары белән минем юлыма киртә салырга телиләр. Минем әдәби гомеремне Есенин дарына илтеп терәргә телиләр. Ләкин алар минем революция шагыйре булуымны оныттылар. Алар минем әдәби гомеремнең соңгы сулышлары бик зур каршылык көче бәрабәренә генә бирелачәкләрен аңламыйлар.

Мин киләчәкнең һәм бүгенгенең йөрәгенә үземнең иң җылы хисләрем белән тоташкан. Миллионнарның йөрәкләренә каным белән сызып язган җырларымны

алар кулы берninди могҗиза белән дә юа алачак түгел. Минем рәсемемне миллионнар үзләре тудырды. Алар миңа үзләренең иң җылы хисләре белән шагыйрьлек исемен теләп, үз теләкләре белән бирделәр. Аларга җинаять итүем генә ул рәсемемне дә, ул исемемне дә таплар. Ә мин миллионнарга бер вакытта да, бер хисем белән дә, бер җырым белән дә алар алдында җинаять ясамам.

Алар мине үзләре тудырган, үзләре йөрәкләрендә сакларлар. Чөнки мин алдаусыз аларның хисләрен җырлыйм. Алар минем тормышымдагы бүгенге күренешләрне якыннан күрсәләр, минем йөрәгем аркылы әйтелми үтелгән хисләремне белсәләр, мин бүген болай яшәмәс идем.

Бүген хатыңны алдым. Һәр сүзеңнән йөрәккә җылылык эзләдем. Ә беләсең, син хатыным булмасаң, бәлки мине артыграк яратыр идең...

Рафаэль исән. Хатыңда син аны үз яныңа алдыру турында язасың. Мин хәзер бу мәсьәләне синеңчә хәл итә алмыйм. Үзең каникулга кайткач, бергәләп хәл итеп, үзең белән алып китәрсең. Кыскасы, минем Казанда калу-калмау да бала мәсьәләсе белән бәйләнгән. Әгәр бала синең янга күчсә, мин үзем дә ул вакытта Казаннан китү ягын карармын. Ләкин син бала белән укый алырсыңмы? Бу хакта бик нык уйла. Хискә бирелми уйла. Бит син аның белән бер ай ял иткәндә булдың. Эшләгән вакытыңда аны карау җиңел булмас. Шулай ук бу елгы Казандагы минем материальный ягым да бик әйбәт түгел. «Татиздат»ка 26 сум, бүлмә өчен 150 сум, вексель белән 75 сум, Татар театрына 100 сум, димәк, алты йөз сумнар бурычлы мин. Алты айлык жалуниям дигән сүз. Бу нәрсәләр барсы да жалуниямнән тотылып барылачак. Ә Казанда яшәү хәзерге көндә бик авыр. Майның кадагы 2 сум 40 тиен, утын да алырга кирәк. Башка кирәкләр дә күп. Менә шул нәрсәләрдән чыгып, Казанда бу ел ничек кышны уздыру турында уйлаганда, мин аптырап торам. Ә нинди атмосферада яшәвемне дә моңар китереп кушсаң, кошмар килеп чыга. Бу ел — минем иң авыр ел. Каникулга кадәр бала минем янда булыр. Мин ничек тә аны начар хәлдә яшәтмәм. Син кайгырма.

Хәнифә мәсьәләсе начар. Казанда хәзерге көндә бер төрле дә хәл итеп булмас тоела. Аны эшкә җибәрергә кирәк булыр. Бу ел әдәбиятта да зур көрәш алда тора. Бу көрәш, билгеле, минем Казанда калуны да сорый. Бу ел гына түгел, күп елларга калуны сорый. Ләкин алда күелган зур нәрсәләр язылу мәсьәләсе, берәр елга Казаннан китүемә дә зарар итмәс. Нишләргә белмим. Синең дә бу ел иң авыр елың. Бу ел мөмкин кадәр сине авыр эшләрдән азат итүне куярга иде. Ләкин... эш шулай. Үпкәләмә, ачуланма. Бу елгы минем эшсез йөрүем бер яктан әдәби эшем өчен кирәк булса, икенчедән, бит миннән генә бу нәрсә килеп чыкмады.

Посылкаңны җибәрәм. Онытканн нәрсәләрем булса, язарсың. Хатыңны көтәм. Сине сагынам. Беләсең, әллә ничек, авыр хисләр белән, бик якын җылылык хисләре белән сагынам. Бу ел сине юксыну, сине кирәксенү, алдаусыз газаплы. Бу ел, минемчә, хәзергә кадәр без хәл итә алмаган бик күп нәрсәләр хәл ителәчәк. Син бу ел мәктәпне бетерәсең. Ә, беләсең, мин синең бу елыңны ашкынып, шатланып көткәнем кебек, бетерүең якынайган саен, курку хисләре дә көчәя барды. Бу курку ирләрдә үзләренең хатыннарының үсә, күтәрелә баруын күрү белән уяна торган курку. Бит без, ирләр, үзебезгә иптәш булган хатыннардан нәрсә белән дә югарырак булуны, өстенрәк булуны телибез. Шушы өстенлек ике арада тигезләнә башлагач, бездә курку уяна. Бу — тарихи психология. Чөнки хәзергә кадәр хатыннарның ирләргә кызыгуларының төбендә, бер яктан ирләрнең тән белән көчле (физический) булуларына кызыгу торса, икенче яктан ирләрнең тормышта да яши алырлык көчле булуларына кызыгалар иде. Менә шул тигезлек хатын ягына авыраю белән, тарихи рольне алмаштыра һәм иптәшлек нигезенә корылып китмәсә, фаҗига тудыра. Бездә нишләр? Белмим. Ләкин без аерылырбыз төсле. Сау бул, сагындыручы Галя.

Такташ. 12. X. 1929.

Гөлчәһрә!

...Син гомумән хатларыңны сирәгәйттең. Язган хатларың да ниндидер жуткий настроение бирә.

Бездә рухани яктан бер-беребездән ерагаю дигән нәрсә дә резкий черталар белән күзгә күренә башлады.

Нәрсә диергә дә, ничек аңларга да белмим. Казанга ишетелгән хәбәрләргә караганда, синең мәсьәлә бик спорный мәсьәлә булып тора, диләр. Белмим, ничек бетәр. Ләкин ни булса да артык тынычсызланам. Мондый кабәхәт сәяси гаепләр ташларлык материаллар бирүең эчемне пошыра. Тизрәк үтсен һәм очы күренсен иде...

Комиссиядә синең мәсьәләң каралып бетмәгән булса һәм минем партиясез булуым синең суллыгыңа — левичылыкка бәйләнүгә сәбәп итеп алынса, син комиссиягә минем 23 нче елда ук солтангалиевчыларга каршы «Фахиш Казан» [13] дигән нәрсәмне язуымны белдер. Ул шигырь солтангалиевчы уңнар тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, ЦКга да кертелгән иде. Шул ук «Эшче» [14] дә Ханәф Наумның [15] мәкаләсе бар иде. Мине солтангалиевчыларның эзәрлекләүләре турында материаллар бирә алам. (Әгәр кирәк булса, хат яз.)

Инде хат язмавыңа киләм. Ни өчен язмыйсың? Әллә... «связьны өзәргә булдыңмы»?

Әллә минем белән эчке тормышыңны бүлешергә теләмәүдәнме?

Аларны ачык язарга кирәк.

Мин хәтта партиядә калу(ыңа)-калмавыңа сәбәп булам икән, аерылырга да хәзер.

Ләкин минем сәяси хаталарым бик күп зур партиецларның хаталарыннан кимрәк. Мин аларның күбесеннән выдержанныерак коммунист булып барам. Творчествода выдержанностьлыкны алып бару бик зур көч сорый (онытма). Кайчан каникул булыр?

Миңа бик авыр. Матди ягым да бик начар. Килгәч, документлар белән күрсәтермен. Хәзер тынычсызларга теләмим. Бер-ике шигырь яздым. Тагын язам. Рафаэль исән. Авырганы юк.

Тагын. Ник хат язмыйсың?

Сәламәтлегеңне дә белмим. Башың-йөрәгең аркылы нинди уйлар үтүне дә белмим. Ә беләсем бик килә. Бит ни булса да, безнең бик күп нәрсәләр бергә бәйләнгән.

Измайлов кебек типларның сиңа каршы чыгуларының сәбәпләрен ничек аңларга? Бит Измайлов синең хакта бер дә алай начар караштa түгел иде...

Заһид [16] нәрсә дип чыкты?

Башта томан, җавап табалмыйм.

Тиз генә хат яз.

Нәһар шул көннәрдә Мәскәүгә барырга җыена. Ул сиңа хат язган иде. Җавап бирерсеңме — белмим.

Иртәгә вексель түләп аласым бар. Бүген 8 сум жалуния алдым. Синең акча ягың ничек? Ичмаса акча ягың гына ничек? Бик күп язасы нәрсәләр булса да, кайткач сөйләшергә калдырам. Хәнифәне кире педтехникумга урнаштырдым [17]. Тик стипендия бирми маташалар.

Бик тиз хат яз.

Ичмаса исәнлегеңне белдер.

Сау бул.

Ачу килә.

Һади. 15. XII. 1929.

Гөлчәһрә!

Каләм алып тагын да язарга утырдым. Нәрсә язарга? Бер вакытны син миңа: «По измене сообщу», — дип язган идең. Син аны эшләмәдең. Шулай эшләгәндә син дөрестән дә үзеңнең бик матур ягыңны ачкан булыр идең... Без, ирләр, хатыннары-

бызның икенче ирләргә булган мөнәсәбәтендәге серләрне инстинкт белән бик тиз сизәбез...

Балабыз исән. Ул минем нинди содержаниедә хат язуымны белми, янымда уйнап утыра.

Такташ. 20, XII, 1929.

Гөлчәһрә!

Мин сиңа ике озын хат язып җибәрдем. Бәлки синең рухыңның төшкән вакытында ул хатларны җибәрмәү яхшырак булган булыр иде. Бәлки, бу мәсьәләне син каникулга кайткан вакытта күтәрү яхшырак булган булыр иде. Ләкин һәр очраган кешенең синең хакта... сөйләп һәм бөтен уйларымны чуалтып, синең алар телен әңадан-яңа хәбәрләр бирүең мине... хат язарга мәҗбүр итте.

Мин бу соңгы хатым белән сине ачыктан-ачык сөйләшергә чакырырга телим. ...Мин синең ирең булып саналып килдем. Бит, бер нәрсәнең дөрес булуына ышанган вакытта гына гакыллы бер карарга килергә мөмкин. Шөбһә-шик дәрәҗәле кешеләрнең дә аякларын бәйли. Бер төрле адым атларга комачаулый. Мин сине биш ел яраттым. Биш ел иң якын иптәшең булуым исеменә, синнән ачык булуыңны, мине томанлы, газаплы шөбһәләрдән коткаруыңны сорыйм.

Син әгәр бу хатны нинди хисләр белән язуымны белсә идең, син бер нәрсәне дә миннән яшермәс идең.

Бу хатны сиңа көнләүче ирең түгел — иптәшең, синең белән бер бүлмәдә торган, вакыты белән сиңа үзенең тормышын бирергә әзер булган иптәшең яза. Синең йөрәгеңдә хәзергә кадәр уянмаган батырлыгыңны уятырга теләп язам. Һәм мин синең ачык рәвештә барсына да җавап бирергә курыкмассың дип ышанам. Син хәзер ачык сөйләүдән бер нәрсә дә югалтмыйсың. Киресенчә, син минем өчен иң зур яхшылык эшләгән булырсың. Ачык сөйләүнең беренче минуты гына авыр булыр. Ә соңыннан мин бер төрле карарга килә алырмын. Бәлки безнең гаиләнең корылышын, аерылып торуларны күзгә алып, сине гафу итәрмен. Синең белән тормышымны дәвам иттерергә көчем җитәр. Бит мин консерватор түгел. Инде аерылырга дип карар итсәм дә, син ирегеңне чикләүче иреңнән генә котылырсың. Ант итәм, сиңа авыр булырлык бер генә эш тә, бер генә хәрәкәт тә ясамам.

Мин бу хатны күз яшьләрем белән синдә ачыклык, искренность уяту өчен язам.

Хәзергә кадәр сиңа бу хакта ачык булырга бер нәрсә комачаулап килде. Син мине кызганып, газапларга теләмәс өчен, ачык булырга куркып килдең. Шул хисләр белән булган булса бел: миңа бу килеш авыррак. Бер адым атлый алмыйм, бер эшемне эшли алмыйм.

Мин сине көчле, кешеңең гаебен күзенә ачык әйтә ала торган бер кеше дип беләм. Тик сине үзенең гаебен ачык әйтә ала торган кеше итеп күргәнем юк. Син моны да эшли алырсың.

Мин синең мине яратмавыңны, икенче кешеләргә миннән күбрәк хисләреңне бирүеңне белеп килдем. Нәрсә ялганларга. Бит бер вакытта да миңа ярату хисләреңне биреп килмәдең.

Сине миңа бәйли торган ул хисләр булмагач, мине кызгану, бергә ир-хатын булып торуга гадәтләнү хисләре генә дөресен әйтергә сиңа комачаулый алмас.

Тормышыбызның шулай баруы синең өчен дә матурлык хәзерләми. Син университетны бетергәндә бу мәсьәләдә тагын да ачыграк була аласың. Син әле икенче гаилә төзеп тә бәхетле була алырсың. Ә минем турыда уйлама. Минем бу мәсьәләне хәл итүгә салкын канлылыгым җитә.

Без бу мәсьәләне икебез ике якта булган хәлдә хәл итәргә тиешлебез...

Барысын да ачык яз. Неужели син дөресен яза алмыйсың. Һәр җөмләң, һәрбер сүзеңне мин җанландырырга тырышырмын. Һәр сүзеңнән мин дөресме, дөрес түгелмелеген сорармын.

Мин бөтен барлыгым, бөтен хисләрем, бөтен кешелегем белән дөрес җавап бирүеңне сорыйм.

Син бу нәрсәне мине тынычландыру өчен, миңа бер карарга килүгә мөмкинлек бирү өчен эшләргә тиешлесең. Бел, мин тыныч каршылармын.

Мин ялган җавап көтмим.

Мин җавапның ялган булуын теләмим.

Неужели син, минем шушы саф йөрәгемнән сораган нәрсә(гә) дөрес җавап бирмәссең?

**Һади. (XII, 1929.)**

### ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Тимербай абый — Мәскәүдә СССР халыклары үзәк нәшрияты хезмәткәре.

[2] Мәхмүд әкә — татар совет язучысы Мәхмүд Максуд (1900—1962). Хат язылган вакытта шул ук нәшриятта эшләгән.

[3] Гөлчәһрә — Һади Такташның хатыны Гөлчәһрә Хафиз кызы Хәмзина (1908—1957). 1926—1930 елларда Мәскәү университетының юридик факультетында укый. Шагыйрь аңа 1925 елда өйләнә. 1930 елның март-апрель айларында аерылышалар.

[4] Хәнифә — шагыйрьнең бертуган сеңелесе Хәнифә Такташева (1908 елда туган). Бүгенге көндә Казанда яши.

[5] «Болай... гади җыр гына» шигыренең бер варианты. Ул беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан»ның 1928 елгы 19 февраль санында басылган.

[6] Рафуш — шагыйрьнең улы Рафаэль (1926 елда туган), бүгенге көндә Ташкент шәһәрендә яши, сәнгать фәннәре докторы.

[7] Әдәбият тарихчысы Габдрахман Сәгъди.

[8] «Югалган матурлык» — Һ. Такташның шул исемдәге драмасы.

[9] Вульгар социологизм позициясендә торган бер төркем тәнкыйтьчеләр Такташ драмасына каты тәнкыйть уты яудыралар. Шунлыктан ул бик тиз арада сәхнәдән төшерелә.

[10] Габидулла — шагыйрьнең бертуган энесе Габидулла Такташев (1903—1943). Ул бу вакытта Мәскәүдәге Н. К. Крупская исемендәге Коммунистик тәрбия академиясендә укый.

[11] Шеланга — Идел буендагы пристань һәм авыл. Югары Ослан районына карый.

[12] Әби — шагыйрь, улы Рафаэльне тәрбияләп тору өчен, йортында бер рус карчыгы тоткан.

[13] Сүз шагыйрьнең «Казан» исемле шигыре хакында бара. Ул беренче мәртәбә 1924 елның 10 апрелендә «Эшче» газетасында басылган.

[14] «Эшче» — 1918 елның 20 сентябреннән Казанда чыга башлаган большевистик юнәлештәге газета. 1918 елның октябрендә Мәскәүгә күчерелеп, 1932 елга хәтле шунда чыгып килгән.

[15] Ханәф Наум — матбугат тирәсендә чуалган вульгар тәнкыйтьче.

[16] Заһид — Һ. Такташның якын дусты Заһид Мостафин, Мәскәү университеты студенты.

[17] Шагыйрь семьясына дошман кешеләрнең уйдырма хатлары нигезендә Хәнифә Такташева 1929 елның сентябрендә, «дворян кызы» дип, педтехникумнан чыгарыла. Һ. Такташ мәсьәләне ачыклап, сеңелесен кире педтехникумга урнаштыра.

## Укучының күңел дәфтәренә

### Испан мәкальләре һәм әйтемнәре

*Әре балык зур суда йөзә.*
*Биксез ишекне ачарга изгеләр дә кызыга.*
*Кояш яктырткан чакта шәм яндыру кирәкми.*
*Чәнечке чәчсәң, энә урырсың.*
*Кайгырып тавык булгәнче, куанып ипи бүлеш.*
*Төн — бизәкле, көн — ап-ак.*
*Тырнаша белмәгән мәче яхшы дус була алмый.*

## Таныштыру сүзе

*Татар культурасына бөтен бер гаиләләре белән хезмәт иткән кешеләр мәгълүм безгә. Шундыйларның берсе — Газиз Айдарский, Сара Садыйкова, Әлфия Айдарскаялар гаиләсе.*

*Газиз Айдарский — талантлы актер һәм режиссер — бик кыска гына гомерендә (ул 34 яшендә туберкулездан үлә) татар театры үсешенә шактый зур өлеш керткән шәхес. Муса Җәлил 1933 елны аның иҗатына бик югары бәя бирә. Газиз Айдарскийның гомер юлдашы Сара ханым Садыйкова, җырчы буларак, Татар музыкаль театры һәм опера театры тарихында шулай ук якты эз калдыра (Галиябану, Алтынчәч образларын әйтү генә дә җитә!). Сәхнәдән киткәч, Сара ханымның сәнгатьтә икенче тормышы — композиторлык эшчәнлеге башлана. Аның халык моңнарына таянып язган дистәләрчә җырын халык үз җыры, үз моңы итеп кабул итте һәм яратып җырлый. Бу гаиләнең өченче кешесе Әлфия Айдарская — Газиз Айдарский белән Сара Садыйкованың кызы — Ленинград хореография училищесын тәмамлап, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры сәхнәсендә 22 ел буена солист була.*

*Әлфия Айдарская хәзер татар халкының балет сәнгате хакында китап яза. Белеп, яратып яза. Шул китаптан бер бүлек журнал укучыларына тәкъдим ителә.*

**Гариф АХУНОВ**

# ХЫЯЛ КАНАТЛАРЫНДА

## Балерина хезмәте турында уйлану...



Балерина. Биюче кыз. Романтик күтәренкелек бар бу сүзләрдә. Моңлы бер музыка, күңелләрне канатландыра торган дәртле көй ишетәм мин аларда. Бию сәнгате музыкадан башка була алмый. Гомумән, музыкадан башка сәнгать юк. «Музыка бары тик мәхәббәттән генә калыша, ә бит мәхәббәт үзе ук — моң»,— ди даһи Пушкин.

Балет, бию сәнгатенең югары формасы буларак, безнең чынбарлыгыбызның хореографик образлардагы тойгылы чагылышы ул, әмма кеше характерының барлык якларының да түгел, билгеле бер якларының чагылышы. Классик биюнең табигате ярыйсы ук шартлы, әмма ул искиткеч гүзәл! Күңел матурлыгын, күңел тибранешләрен, хис-тойгыларны классик бию ысулы белән, гәүдәнең сыгылмалылыгы белән, хәтта сүз белән әйтүгә караганда да күбрәк әйтеп бирергә була. Әлбәттә, буй-сының шуңа яраклы булса, һәм син табигать биргән шул гүзәл гәүдәңне камиль рәвештә биюгә куша белсәң!

Балерина классик биюнең нигезләрен һәм кануннарын яхшы белергә, аларны сакларга, башкару культурасының тиешле югарылыгына, техник төгәллеккә ирешергә тиеш. Бию сәнгатенә өйрәтүче уку йортлары арасында безнең илдә А. Я. Ваганова исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Ленинград академик хореография училищесы аерылып тора. Миңа шушы училищега керү бәхете эләкте. Ә биергә тәпи баскан көнемнән башлап өйрәндем дисәм, укучылар моны тыйнаксызлык дип санамас, шәт. Бәләкәй чагымда мин Казанда, әби белән бабайларда яшәдем. Без торган ишегалдында скрипкачы карт бар иде. Көнгә бер мәртәбә ул скрипкасын алып чыга да, үзе ясаган агач эскәмиягә утырып, сыздырып җибәрә. Шуны ишетүгә, мин баскычтан ава-түнә йөгереп аска төшәм, бабай мине күрүгә скрипкасын кызурак уйный башлыйм, мин тыпыр-тыпыр килеп биим, ишегалдына халык җыела, кул чабып тора, мин биим дә биим, биим дә биим...

Мин азрак үсә төшкәч, мәктәптә укый башлагач, әни белән Башкортстанга бардык. Ял итәргә. Әнине бер дә көтмәгәндә, ял иткән җиреннән, кайсыдыр бер калага концерт бригадасы белән чыгарга чакырдылар. Китте минем әни, калдым мин Уфада ялгызым! Дәресрәге — ул мине үзенең күп санлы дусларыннан берсендә калдырды, әмма мин, алардан рөхсәт-мазар сорап тормастан, Уфа урамына чыгып киттем. Туйганчы, күңелем булганчы йөрдем урамда: йортлар, кибетләр карадым, плакатлар, афишалар укыдым. Берәү дә миңа шелтә ясамады. Йөри торгач, зур бер йорт янындагы белдерүләр тактасына килеп туктадым. Анда язылган: 12 яшьтән дә олы булмаган башкорт һәм татар балалары Ленинград балет мәктәбенә кабул ителә, диелгән. Ленинград! Минем бу кала хакында мәктәптә, укытучыларымнан ишеткәнем бар иде. Безгә аны революция белән, Ленин бабай белән бәйләп өйрәтәләр иде. Минем Ленинградка барасым, балет мәктәбенә керәсем килде. Димәк, шушы зур йортка керергә, кемнәндер белешергә кирәк. Тышкы зур, бик тә авыр ишеген ачып, эчкә уздым, биек баскыч буйлап икенче катка күтәрелдем. Бик иркен, бик якты залдагы өстәл янында бер апа утырып тора, аның янына бер абый баскан, алар икәүләп, минем кебек бер кыз белән сөйләшәләр. Соңыннан мин ул абыйның атаклы башкарт биючесе һәм балетмейстеры Фәйзи ага Гаскәров икәнен белдем.

Өстемне чишендергәч, үземнең ярым-ялангач булуымнан куырылып килеп, мин аларга таба йөгереп киттем.

Абый дигәнем, мине башымнан аягыма кадәрле күздән үткәргәннән соң, кулларымны алга суздырды, аягымны алмаш-тилмәш күтәрттерде, баскан урынымда сикертте, йөгертте, чүгәләттерде, кул-аякларымны тотып-тотып карады, тагын нәрсәләрдер эшләттерде. Минем шул хәрәкәтләремне йөзләгән бала бер читтә карап торды. Аннары мине пианино янына китереп, аңа артым белән бастырдылар. Пианинода нинди нота алынса, шуны әйтергә кушылды. Аннары озынрак бер мелодиянең нинди ноталардан торганын әйттерделәр. Ритм аңлавымны тикшерделәр. Мин алар күрсәткән ритмны төп-төгәл шакып күрсәттем. Болар миңа кыен булмады, чөнки җырчы әнием белән бергәләп без аларны өйрәнгән идек... Аннары безне медицина тикшерүенә китерделәр. Бәхетем бар икән, медицина минем балет мәктәбендә укырга теләвемә каршы килмәде. Ниһаять, без өч йөз баладан 12 бала балет мәктәбенә уздык. Әни гастрольдән кайтуга, аның дусты, мин яшәп калган апа, минем «балерина» булуымны әйтте. Әни, гадәте буенча, ахылдады, ухылдады, кулларын чапты, ниндидер ымлыклар әйтте, шулай да минем теләгемә каршы килмәде. Шулай итеп, без аның белән аерылдык: мин — Ленинградка, ул Мәскәүгә — Дәүләт консерваториясе каршысындагы татар опера студиясенә китте.

Ленинград. Росси урамы. Хореография училищесы. Булачак балеринаның авыр да, романтик та хезмәте шушында башлана. Укуның беренче көннәреннән үк безне төрле юнәлешләрдә укыталар, тәрбиялиләр: физик чыныктыру. Үзеңдә кешелекле матур сыйфатларны туплау. Классик биюнең нигезләрен үзләштерү, гомуми һәм музыкаль белем алу, актерлык осталыгына, сәнгатьлелеккә өйрәнү. Дөньяны танып-белү, дөньяга карашыңны үстерү. Француз телен, теоретик белемне, тарихи-көнкүреш һәм характерлы биюләр, көнбатыш Европа биюләре үрнәкләре башкару... Булачак артистлар училище сәхнәсендә дә, С. М. Киров исемендәге атаклы театр сәхнәсендә дә халыкка күренәләр.

Киров театры сәхнәсендә биюне без, үсмерләр, ашкынып көтә идек. Ул хыя-

лыбыз да тормышка ашты. «Йокыга талган гүзәл», «Корсар», «Дон-Кихот» кебек спектакльләр хореография училищесы укучыларыннан башка узмады. Балетларда гына да түгел, бу театрның сәхнәсенә мин ун яшемдә чакта «Салтан патша турында әкият» операсында чыктым. Тиенне биедем ул чакта. Унөч яшендә исә мәктәп театры сәхнәсендә Ц. Пуниның «Наяда һәм балыкчы» балетында классик адажионы беренче мәртәбә биедем. Ә бит аны классикадан минем беренче укытучым Наталья Александровна Камкова биегән булган, аннары ул Алла Яковлевна Шелестка күчкән. Менә шул номер, хәтта «Шелест» дип иseме язылган костюм да миңа эләкте! Минем партнерым өлкән класслар укучысы Һашим Мостаев булды. Мин чиксез дулкынландым, чөнки залда минем өзелеп яраткан балеринам Татьяна Михайловна Вечеслова утыра иде. Мин барлык эшләгән эшемне, барлык гамәлемне аңар охшатырга тырыша идем. Аның күзләре соры, зур иде, керфекләре кап-кара, сөрмәле иде. Мин керфекләремнең дә аныкы төсле булуын бик теләдем. Ләкин Татьяна Михайловна кемгәдер охшарга тырышуның зарарлы икәнен аңлатты миңа. Сәнгатьтә үз юлыңны табарга кирәк, диде. Тормыш тәҗрибәсе туплый төшкәч, үзем дә аңладым: нинди зур талантлар, нинди көчле педагоглар эшләгән икән безнең белән! Алар бездә зәвык, корычтай дисциплина, үз-үзебезгә таләпчәнлек хисе тәрбияләделәр. Ә бит бию — барыннан элек дисциплина, төгәллек, рәхимсез төгәллек!

Әмма теләсә кайсы мәктәп — ул әле юлның башы гына. Калганы — синнән. Әйе, синнән, синең үзең сайлаган язмышыңа мөнәсәбәттән. Синең ихтыярыңнан, тир түгүеңнән. Мәктәп сине 32 «фуэте» ясарга, сине канатландырырдай сикереш-очышка өйрәтә. Балеринаның алдагы тормышы — тоташы белән үзеңне чикләү. Һәр нәрсәдә, һәр кайда! Иҗат гомерең күпме, шул чаклы чикләү. Сине тәмам хәлдән тайдыра торган физик арыганлык белән көрәшү. Балет актерының тормышын медицина ике генә һөнәр иясенең тормышы белән тиңли: шахтер һәм такелажник тормышы. Бию профессоры Агриппина Яковлевна Ваганова шуңа өстәп әйтә: «Балерина хезмәте ат хезмәте»,— ди. Мин бу сүзләрнең хаклыгына тулысынча ышандым. Көн саен баскыч буенда һәм зал уртасында мәҗбүри шөгыль, янында аерылмас юлдашың — сөлге. Хәрәкәтләрнең матурлыгына, җиңеллегенә, гүзәллегенә ирешкәнче җитмеш җиде кат тир түгәсең.

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында минем беренче зур ролем — «Жизель» балетындагы Мирта партиясе. Аны балетмейстер Леонид Алексеевич Жуков куйды. Ул РСФСРның атказанган артисты, ССР Союзы Зур театрының элекке биючесе, күренекле рус балеринасы Екатерина Гельцерның партнеры, зур сәнгать культурасына ия кеше, тәҗрибәле оста иде. Беренче партиямне башкарып чыгу бик авыр булды миңа. Мирта образы җиңеллек, җилдәй җитезлек, шул ук вакытта рухи көч тә таләп итә иде. Аяк бармаклары канап чыга, идәндә бармак очларында йөгерергә, «йөзеп» китәргә тиешле син һәм ул йөгерү-йөзүләрнең иге-чиге юк. Һәрбер «па»ны бик күп мәртәбәләр кабатларга, чыкканчы кабатларга кирәк. Шул чакта гына син иҗат канәгатьлеге табасың. Рәхәт талчыгу шул чакта гына килә. Бу — үзеңнән өстен чыгу, үзеңне җиңә алу...

Безнең театрда бер үк кичне «Жизель» белән бергә Веберның «Розаны күрү» — дөнья классикасында романтик балет үрнәкләре куелды. Мирта икенче пәрдәдә люктан — «җир астыннан» чыгарга тиеш. Бүгенгедәй хәтеремдә, сәхнә астында, чыгар минутларымны көтеп, калтырап утырам. Салкын, караңгы. Спектакльне алып баручы режиссер Кальбин, минем «җир өстенә» чыгуымны бик тиз эшләр өчен, яныма йөгереп килде. Каберне гәүдәләндергән караңгы сәхнәгә килеп чыгуым булды, прожектордан ут көлтәсе йөземә китереп бәрде. Мин аяк очларымда алга таба, сәхнә алдына таба «йөзеп» киттем. Оркестрда скрипкалар искиткеч гүзәл моң сибәләр. Жизель каберенә күрсәтеп һәм биргә ник чыгуымны тамашачыларга аңлатып, вариацияләр ясарга керештем... Бүгенге көн күзлегеннән караганда, мин, әлбәттә, сәер күренгәнмендер: тәнем Идел буе кояшында кызынып каралганга, балетмейстер миңа традицион балет трикосы кияргә рөхсәт итмәде. Тәнем кап-кара диярлек, кардай ак хитоннан, җилкәләремә таралып төшкән кап-кара чәчтән, каймакка төшкән чебен төсле булгаймындыр. Дөнья хореографиясендә дан алган атаклы шедеврга кагылу җаваплылыгыннан булса кирәк, дулкынлануым, каушавым шул хәтле дә көчле иде

ки, йөрәгем, менә-менә сикереп чыгам дигәндәй, дөпелдәп тибә иде. Сәхнәдә мин төш күргәндәй йөрдем. Ә соңыннан, башны артка чөеп, финалдагы позага баскач, бер генә мәлгә пауза булып алды, аннары, бердәм алкышлар яңгырап китте. «Китте» дигәнем биредә бәлки бигүк төгәл сүз дә түгелдер, чөнки ул алкышлар артык озак булып тоелды миңа. Ниһаять, төш күрүдән туктадым, ниһаять, класста чакта интеккәннәремнең нәтиҗәсез калмавын аңладым. Тамашачы мине үз итте!

Теләсә кайсы сәнгатьтәге кебек, балеринаның да уңышка ирешү, танылу юлы катлаулы, авыр. Бию күнекмәләре генә җитми, үзлегеңнән күп укырга, сәнгатьнең башка төрләре белән яхшы таныш булырга кирәк. Ул сине рухи баета, тирәнәйтә.

Нәҗип Җиһановның «Зөһрә» балетына аеруча тукталасы килә. Мин анда — Җамал ролендә. Милли репертуардагы беренче зур һәм җитди эшем. Үзем бик яшь әле, үсмер генә диярлек. Ә «Зөһрә» миңа Прокофьевның «Золушка»сын хәтерләтә. Икесе дә — романтик рухтагы әкиятләр.

Әгәр айга бик озак карап торсаң, анда көянтә-чиләк күтәргән кызны күрергә була, диләр. Әнә шул инде ул Зөһрә кыз. Борынгы татар легендасында явыз үги ана үзенең чибәр үги кызы Зөһрәне төпсез кисмәккә су ташырга мәҗбүр итә. Ә аның ямьсез, холыксыз үз кызы Җамал Зөһрәнең чибәрлегеннән бик тә көнләшә, аны үчекли, мыскыллый. Җир өстендә инде тәмам яшәрлеге калмагач, Зөһрә ялынып-ялварып Айдан үтенә, ал мине үзеңә, ди. Зөһрә-гүзәлгә Айның нуры сузыла, ул аңа зур тылсымлы шарф бүләк итә. Җамал Зөһрәдән шарфны тартып ала да, аны үзе җилкәсенә салып, гүзәл кызга әйләнә. Баһадир егет Якуб, элгәрәк Зөһрәгә күз атып йөргән егет, Җамалдагы матурлыкны күреп, аның ягына авыша. Җамал белән Якубның туйлары шаулаган чакта Айның нуры төшеп, Җамал җилкәсеннән шарфны тартып ала, менә шунда ялган ачыла, Җамал тагын котсыз, ямьсез, усал кыз булып кала. Якуб биредән качып китә, Җамал ямьсезлеге һәм усаллыгы белән тагын ялгызы торып кала.

Спектакльне сәхнәгә Башкортстанның танылган балетмейстеры Фәйзи Гаскәров куйды. Мине Ленинградка балет мәктәбенә илткән Фәйзи ага Гаскәров! Мавыгып эшләдек. Балерина өчен партнерның нинди булуы бик тә мөһим. Якубны башкарган артистның көчле ышанычлы кулларында мин үземне тыныч сиздем. Моңлылыгы һәм хис тудыруы ягыннан икенче пәрдәдәге романсны без рәхәтләнеп башкардык, оныт ылып биедек. Минем уемча, ул романс спектакльнең бизәге иде. Бу чын мәгънәсендә мәхәббәт дуэты, җиңел, өрфия, бәхетле һәм сөенечле дуэт булды. «Хореографик романс музыка романсына бик тәңгәл килгән» диде белгечләр. Атаклы романс минем иң яратып башкарган номерым булып калды, соңыннан концерт репертуарыма да күчте.

Бераз соңрак безнең театрда балетмейстер Л. А. Жуков тарафыннан Асафьевның «Бакчасарай фонтаны» куелды.

Александр Сергеевич Пушкин поэмасын укыган кешеләр яхшы белә: Гәрәй хан, канлы сугышларының берсеннән, поляк княжнасы Марияны әсир итеп алып кайта. Гәрәй аның гүзәллегеннән акылын җуяр дәрәҗәгә җитеп йөри. Әмма аның сөекле хатыны, грузин кызы Зарема иренең аны башка берәү белән алыштырганын аңлый. Көнчелектән, дәртенең ташып торуыннан һәм күңел төшүеннән нишләргә белмичә, ул Мариягә ялына, кайтар миңа иремне, ди. Моңлы-хәсрәтле Мария аңардан ни таләп иткәнне аңларлык хәлдә түгел. Зарема әйтә: «Кавказда туган кеше мин, кулда хәнҗәр тота беләм». Җәза бик зур булып чыга: Мария үтерелгән көнне Зареманы суга батыралар... Гәрәй хан янә дә талау-кыру сугышларына чыгып китә. Мария истәлегенә ул мәрмәр һәйкәл сала — «Мәхәббәт фонтаны, хәсрәт фонтаны». Соңыннан аны килер буыннар «Күз яшьләре фонтаны» дип атыйлар.

Бу спектакльдә мин үземне тиз генә тапмадым. Башта Мария роле бирелгән иде, репетицияләр вакытында миңа Зарема күбрәк туры килә булып чыкты. Зарема партиясендә мине дулкынландырган нәрсә аның мыскылланган, кимсетелгән горурлыгы түгел, аның мәхәббәттәге көнчелеге түгел, ялкынланып, кабынып, саф бер ярату белән ярата белүе иде. Беренче спектакльләрдән соң балетмейстер Л. А. Жуков миңа болай диде:

— Син, әлбәттә, Пушкинның «мәхәббәт йолдызы, гаремның чибәре» дигән юлларын аклады. Ләкин әле моңардан да зурракка ирешәчәгеңә ышанам. — Аның сүзләрендә минем ролемнән канәгать булып җитмәү ишарәсе бар иде. Марияне йокы бүлмәсендә бию теле белән аңлашу сүлпәнрәк, көчсезрәк чыккан булса кирәк. Кончелек кебек зур һәм катлаулы хисне бирү өчен мин әле яшь идем шул, балеттагы осталыгым да җитмәгәндер, күрәсең. Мин әле Гәрәйгә булган мәхәббәт хисләрен дә аңлап бетерми идем... Ә Зарема — минем сәхнәдәге бәхетем ул. Тугыз ел буена биедем мин бу балетта.

Дөньяның атаклы балеринасы, балет сәнгатенең йолдызы Уланованың Казандагы гастрольләре вакытында өч спектакльдә дә аның белән бергә бию бәхете эләкте миңа. Галина Сергеевнаның гаять тәэсирле, рухи бай һәм чын сәнгате чиксез-чамасыз дулкынландырды, каушау-тетрәү минутлары кичертте. Партнерының бер «сүзенә» яшен тизлегендә җавап бирү җәһәтеннән ул таң калдыра сине. Мария белән Зареманың сәхнәдәге диалогы вакытында миңа никтер шулай тоела башлый: мин аның аркасына ханҗәр кадау түгел, аңа карата саксыз бер хәрәкәт тә ясый алмамдыр кебек... Аның нәфислеге, шигърилеге, рухи байлыгы безне, Казан биючеләрен, әсир итте. Аның сафлыгы, иҗади әдәплелеге безгә электр тогы сыман йогынты ясады. Әгәр спектакльләрдә мин үземне тиешенчә тота алганмын икән, моңа бары тик аның гаять тыйнаклыгын аңлау, кешеләргә карата изге күңелле булуын белү генә ярдәм итте диярга кирәк.

Зарема партиясе техник яктан да, актерлык осталыгы ягыннан да катлаулы. Героиня Гәрәйгә булган хисләрен монологларда белдерергә тиеш. Хисне дуэт биюендә белдерүгә караганда монологта, ягъни япа-ялгызың биегәндә белдерү авыррак. Балет спектаклендә монологның нинди хикмәтләре бар соң? Монолог драмада бик озакка сузыла ала, биюдә — санаулы минутлар гына. Бию киеренкелекне бирүгә кадәр үсеп җитә алмый икән, син аны эчке киеренкелек белән алыштырасың...

Һәрбер иҗаттагы кебек үк, балет сәнгатендә дә илһамлана алу бик мөһим. Ләкин бит ул илһам дигәннәре,— рәхмәт яугыры! — гел-гел килеп тормый. Аны чакыра белергә дә кирәк. Ни рәвешле? Ничек итеп? Мавыга белү, эшкә бөтен сәләтеңне бирү, чынлык, ихласлык — болар барысы илһамлануга китерәләр. Танылган совет балеринасы Т. М. Вечеслова сүзләре искә төшә: «Образга приказ буенча керә алырга кирәк». Монда, әлбәттә, югары профессионализмнан башка берни дә эшләп булмый. Шул ук вакытта актерның характеры, шәхес булып тәрбияләнүе эшкә бик-бик зур ярдәм итә. Ә характерны үзеңдә бик яшьли тәрбияли башларга кирәк.

Үзем комсомолда тәрбияләнеп үскәнгә, «Аккош күле» балетындагы Одетта-Одиллия ролен мин комсомолның XI съездына багышладым. Спектакльдә партнерым тәҗрибәле биюче Бари Әхтәмов булды. Соңыннан миңа аның белән эстрадада да байтак биергә туры килде. Шопен вальсларында биедек. Ул оста биюче, бик тә ягымлы һәм игътибарлы булуы белән күңелне җәлеп итә иде. Күп төрле акробатик трюкларга да мине ул алып килде. Иҗатым классика кануннары буенча үскәнлектән, мин баштарак биюдә төрле трюкларны кабул итми идем, азактан күрәм: алар биючедән кыюлык, осталык, профессионализм таләп итәләр икән — өйрәндем, кыюландым. «Аккош күле» балеты — классик балет мәктәбенең иң югары казанышы. Техник биеклекнең иң сирәк очрый торган жанрына — романтиклыкка, хыяллана белүгә кем генә, кайсы гына балерина омтылмый икән?! Үземне бәхетле саныйм — мине биегәндә уйчанлана, хыяллана белергә, аяк-кул хәрәкәтләре белән сагышлы моңны аңлатырга шул романтика өйрәтте.

Безнең театрда героик темага да спектакльләр куелды. Шуларның берсе — «Лауренсия» балеты. Авторы А. Крейн аны испан классигы Лопе-де Веганың «Фуэнте-Овехуне» әсәренә нигезләнеп язган. «Лауренсия»не чын мәгънәсендә бию бәйрәме диярга була. Спектакль бик якты, бәйрәмчә куелган иде. Балет безнең биючеләребезне кайнар темпераментлы, ярсулы, виртуоз биюләре белән җәлеп итте. Лауренсия ролен балерина Н. Юлтыева искиткеч оста башкарды. Биредә аның бию мөмкинлекләре генә түгел, актерлык мөмкинлекләре дә ахырынача ачыла алды. Эчке киеренкелек белән тыенкы сабырлыкны да куша алды ул нәкъ шунда. Аяусыз нәфрәт, протест, бунт, азатлыкны тою Лауренсия—Юлтыеваның камил башкарган

сикереш-очышларында гәүдәләнде. Боларның бөтенесе таң калырдай осталык белән башкарылды.

Бу балетта мин алданган бәхетсез кыз, Лауренсиянең дусты Хасинта ролен башкардым. Мине чөеп-чөеп җибәргәннәрен, идәнгә екмас өчен тотып калганнарын, кулдан-кулга ыргытканнарын хәтерлим. Биюнең иң кыены, иң авырлыгы шунда иде ки, мин үзем биегәнне, үзем кулдан ыргытылганны күрсәтмәскә, үземнең ярдәмчесез икәнемне, боларның барысы минем ихтыярдан тыш эшләнгәнне, үземнең язмыш корбаны булуым трагизмын тамашачыга ышандырырга тиеш идем.

Ә. Ц. Пунинның «Эсмеральда» балетында (бездә аны Одесса балетмейстеры Н. Трегуб куйды.) мин капма-каршы булган ике рольдә чыктым. Гудула һәм Флер-де-Лис. Гудула партиясендә бию аз, әмма драматик киеренкелек күп. Минем бу ролемне тамашачы да, театр коллективы да хуплады.

Балет сәнгатендә реалистик юнәлешне раслаган чорда «драматик балет» дигән агым да булып алды. Бу агым биюнең үзен икенче планга кысрыклый иде: балерина күп хәрәкәтләнә, аз бии. Хәзер исә биюнең образлы көче яңадан сәхнәгә кайтты, ул үзен кабат раслады. Төзелеше ягыннан классик, яңгырашы ягыннан бүгенге көн спектакльләрендә заманның иң катлаулы темалары балетта яңартылган классик бию ярдәмендә гамәлгә аша.

Заманның катлаулы проблемаларын Кара Караевның «Күкрәүле юл» («Тропою грома») балеты да бик мәгънәле ачты. Безнең сәхнәдә ул уңыш белән барды. Мица аңарда классик бию белән негр биюләренең бергә кушылуы бигрәк ошады. Хезмәтче өч кыз аны төрле вариацияләрдә биеделәр, аларның берсен мин башкардым.

Безнең Казан каласына илебезнең иң атаклы балериналары, күренекле балет артистлары гастрольгә килделәр. СССР төзелүгә 60 ел тулган елны моны искә төшерү бигрәк тә күңелле. Классик биюне яратучы Казан тамашачылары Г. Уланова. Н. Дудинская, А. Шелест, С. Каплан, Юрий һәм Леонид Ждановларга, С. Головкина, Ленинградның характерлы биюләр остасы Н. Федоровага, тагын башка бик күп беренче класслы артистларга ашкынып кул чаптылар. Бу сәнгать осталарының һәр чыгышы театр тормышында да, шәһәребездә дә чын бәйрәмгә әйләнә иде. Әлеге очрашулар, иҗади багланышлар безнең театрның балет труппасына тулаем да, һәр артистка аерым-аерым да йогынты ясады. Алар безне осталык серләренә баеттылар, таләпчәнлеккә өйрәттеләр.

Биредә мин Ленинградның опера һәм балет академик Киче театры солисты Рөстәм Садыйковны искә алмый китә алмыйм. Ул — Ленинград хореографик училищесын тәмамлаган егет. Классик биюне дә, характерлы биюләрне дә бердәй тигез осталык белән башкара. Темперамент, виртуозлык, ягымлылык, лирик җылылык — менә аның иҗатына хас сыйфатлар. Аның бию культурасы соклангыч. Ул безнең театрда ирләр партияләрендәге барлык әйдәп баручы рольләрне уйнады. Аның биюендә героик башлангыч өстенлек итә. Ә тормышта ул үзе гаять күңелле, юморга бай, тиз аралашучан. «Аккош күле», «Кыз һәм хулиган», «Кылычлар белән бию» балетларындагы биюләре, безнең калабыздагы гастрольләре вакытында башкарган рольләре әле дә күз алдымда тора.

Икенче бер биючебез Рөстәм Сафин — сирәк очрый торган «самородок» талант. Махсус хореографик белеме булмауга да карамастан, ул эчке бер сиземләве белән образның асылына төшенә. Бию дуэтларында ул — менә дигән партнер. Аның белән бию рәхәт һәм җайлы. Мин аның көчле кулларын белә, ул кулларга ышана идем. Сафинның зур партияләреннән «Эсмеральда»дагы шагыйрь Гренгуар, Ф. Яруллин балетындагы Шүрәле образы бик истә калган.

«Йокыга талган гүзәл», «Баядерка», «Таш чәчәк», «Шәһрезадә», «Дон Кихот», «Кызыл мәк», «Мысыр төннәре», «Тау хикәяте», «Шүрәле», «Зөһрә», «Джоконда», «Жизель», «Аккош күле», «Пер-Гюнт», «Күкрәүле юл», «Лауренсия», «Шопениана», «Эсмеральда», «Фатих», «Алтын тарак», «Доктор Айболит», «Бакчасарай фонтаны», «Раймонда» һәм тагын башка күп кенә спектакльләр, татар профессиональ балет сәнгатенең кырык елдан артып киткән гомерендә сәхнәбезне бизәделәр. Һәрбер спектакльгә бер үк вакытта авыр да, мавыктыргыч та көч куелган. Казан тамашачыларына билгеле булган артистлар Н. Юлтыева һәм Г. Калашникова, А. Гацулина һәм Б. Әхтә-

мов, Рөстәм һәм Ревдар Садыйковлар, С. Хәйруллин һәм Р. Сафин, И. Круглов, А. Нарыков һәм тагын башка бик күпләрнең хезмәте салынган.

Ә театрда озак еллар буена бик яхшы иҗади атмосфера булуы исә — талантлы балетмейстерлар Л. Жуков, К. Боярский, И. Смирнов, Ф. Гаскәров, Г. Таһировлар тырышлыгы нәтиҗәсе. Театрда озак еллар эшләү дәверендә безгә, артистларга, бик күп ярдәм иткән кешеләрдән тагын танылган дирижер Х. Фазлуллин, театрның баш дирижеры И. Шерман булдылар. Ә бит дирижер кулын тою, оркестр белән бәйләнешне тою, бөтен залның сулышын берьюлы тою — иҗат коллективы өчен бик мөһим нәрсә ул.

Республиканың халык артистлары турында, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры турында кулга тотарлык китапларыбыз күренә башлады. Балет сәнгатебезнең совет власте елларында үсү, алга китүен күрсәткән китапларыбыз да булыр дип өмет итәбез. Моны яза алырдай каләм осталары, белгечләр бар бездә.

...Барлык сәнгатьләрдән дә балет сәнгате иң нәфисе, күңелләрдә бәйрәм тойгысы уята торганыдыр, мөгаен. Ләкин җиңеллеккә, виртуозлыкка, нәфислеккә ирешү, тамашачыда бәйрәм тойгысы калдырырлык итеп бию өчен, кабат әйтәм, җитмеш җиде кат тир түгәргә кирәк. Классик биюнең билгеле бер биеклегенә ирешкән сурәттә генә тамашачы балет сәнгатенең гүзәллеген сизә ала. Әмма балет биючесенең сәхнә гомере исә бик тә кыска. Килә бер көн, сәхнәдән китәргә кирәк. Балачактан өзелеп яраткан сәнгатең белән саубуллашу көне җитә! Үз вакытында китә белгән балеринадан да бәхетле кеше юк. Балеринада балет сәнгатенең сүнгәнен тамашачы сизмәскә тиеш. Театрда егерме ел эшләгәннән соң китү-китмәү мәсьәләсен хәл итүне балерина үз намусы алдына куя. Сәнгатьне күпме көчле яратса, бу авыр, кыен, ачы язмышны балерина шулкадәр тизрәк хәл итә. Ветераннарга алмашка яшьләр килә. Ветераннар — педагоглар булып, классик мирасны яшь буынга тапшыручылар булып калалар.

Хәзер миннән: «Әгәр үсмер чагың булса, нинди һөнәр сайлар идең?» — дип сорасалар, «Балет артисты булуны берни белән дә алыштырмыйм»,— дип җавап бирер идем.

Бүген балет сәнгатенә килгән, сәхнәгә аяк баскан яшьләргә теләгем: бер генә хыялыгыз сүнмәсен, сәхнә канатлары сезне гел югарыга, гел биеккә алып менсен. Зур сәнгатькә ирешү юлында тайпылышсыз булыгыз. Тыйнаклык бизи кешене, тырышлык бизи, үзең сайлаган язмышка турылыклы булу бизи. Сезгә карап, кешеләр соклансын: «Нинди гүзәллек, нинди гармония, нинди могҗиза!» — дисеннәр.

**Әлфия АЙДАРСКАЯ**

## Укучының күңел дәфтәренә

**Итальян мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Зур кичереш аз сүзле була.*
*Куркакның дошманы көчле.*
*Түземнең азагы — уңыш.*
*Артык тәвәккәл кеше берни дә эшли алмый.*
*Түбәдән егылып төшүгә караганда, тәрәзәдән сикерү артык.*
*Нинди матур читлек тә кошны үзе ашатмый.*

# ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*XVIII йөзнең икенче яртысында оештырылган академик экспедицияләр турында*

Тарихка тирәнрәк үтеп кергән саен, тарихи чынбарлыкның объектив сурәтләрен тергезергә ярдәм итәрдәй басма һәм кульязма чыганаклар азрак табыла. Шунлыктан, сакланып калган язмалар безнең өчен аерата кадерле һәм кыйммәтле. Аларны җентекләп, бөртекләп өйрәнергә кирәк. Бу татар халкы тарихын өйрәнүгә дә тулысынча кагыла. Төрле сәбәпләр аркасында халкыбыз тарихы буенча XVII—XVIII йөзләргә караган язма чыганаклар бармак белән санарлык кына калган, X—XVI йөзләр турында инде әйтеп тә торасы юк. Шуңа күрә андый һәр хезмәтне профессиональ тарихчылар гына түгел, киң катлау укучылар да һәрвакыт алкышлап каршылый. Танылган тарихчылар С. Х. Алишев, Ш. Ф. Мөхәммәдъяров, М. А. Госманов һ. б. хезмәтләре бигрәк тә кызыксыну уята.

Бирегә сүз Россия Фәннәр академиясе оештырган экспедицияләр материаллары турында барачак. Алар XVIII йөзнең 60 нчы елларында ясала. Бу экспедицияләрдән И. И. Лепехинның, П. С. Палласның, И. П. Фалькның, Н. П. Рычковның, И. Г. Георгиның «көндәлекләр» яки «журналлар» дип аталып йөртелә торган язмалары саклапып кала.

Илне экономик, политик һәм культура ягыннан үстерү максатларыннан чыгып, нәкъ менә шул чорда бөтендөнья фәненә яңа принциплар — гакыл һәм тәҗрибәне фәнни танып-белүнең нигезе дип игълан итү, экспериментлар белән мавыгу һәм мәгърифәтчелек идеяләре үтеп керә. Шуңа бәйле рәвештә тикшеренүчеләрнең дөньяга карашы, кызыксыну офыклары киңәя. Алар төрле халыкларның реаль тормышына һаман ешрак мөрәҗәгать итәләр.

Идел буе халыкларын өйрәнү белән кызыксыну да 1724 елда Россия Фәннәр академиясе ачылганнан соң планлы төс ала: Академия күп санлы экспедицияләр оештыра, материаль культура әсбаплары җыйнала, халыкларның көнкүреше, дөнья күтү рәвешләре, телләре өйрәнелә (мәсәлән, 1787 елда «Барлык телләрнең һәм халыкларның чагыштырмалы сүзлеге» басылып чыга, бу сүзлеккә Россиядә яшәүче 200 халыктан 270 сүз теркәлә).

Бу чыганаклар зур фәнни һәм танып-белү әһәмиятенә ия.

Кайбер экспедицияләрнең оештыру тарихына да тукталыйк.

1769 елның 3 июнендә астрономия өчен әһәмиятле вакыйга көтелә. Венера планетасы Кояш боҗрасын кисеп үтәргә тиеш була (мондый күренеш шактый сирәк күзәтелә, соңрак ул 1877 елның 9 декабрендә һәм 1882 елның 6 декабрендә була, киләчәктә 2004 һәм 2012 елларда көтелә). Шуны күзәтү өчен Академия 6 астрономик экспедиция әзерли. Алар илнең төрле төбәкләренә — Төньякка, Якутиягә, Оренбург губернасының көньягына җибәрелә. Болар белән бергә 5 географик экспедиция әзерләнә, тикшеренү төбәкләренә карап, аларга «Оренбург» һәм «Астрахань» отрядлары дигән исемнәр бирелә. Отрядлар 1768 елның җәендә юлга чыга. Аларны биология, минералогия, химия, медицина, этнографияне яхшы белүче галимнәр җитәкли. Отряд җитәкчеләре язып барган көндәлекләр соңыннан бастырып чыгарыла.

Татар халкы тарихын өйрәнү өчен, алар язып калдырганнардан без нинди мәгълүматлар таба алабыз соң?

Оренбург ягына юл тоткан өч отрядның җитәкчеләре И. И. Лепехин, И. П. Фальк һәм П. С. Паллас була. Иван Иванович Лепехин (1740—1802) медицина, химия, ботаника белән шөгыльләнә. Ул — Идел буе халыклары тормышын, культура һәм көнкүрешен, дөнья күтү рәвешен иң тәфсилләп язган галим[1].

И. И. Лепехин отряды Санкт-Петербургтан 1768 елның 8 июнендә кузгалып, ике атнадан Мәскәүгә һәм август урталарында Сура елгасы үзәненә килеп җитә. Беречне татар авыллары — Маклюковка, Мәчеле, Красная шул вакытта искә алына. Красная авылында экспедициячеләр абыз белән очрашалар. Ул аларга сырхаулаган авылдашларын ничегрәк дәвалавын сөйли. Галим, авыруларны дәвалаганда, имгә ярый торган даруларны бик кызыксынып тасвирлый. Алатырь, Сембер шәһәрләрен узганнан соң ул Чирмешән елгасы үзәнендәге татар, мордва, чуваш авылларын сурәтләп үтә, бигрәк тә халыкның көнкүрешенә киң туктала. Әдәбиятта беренчеләрдән булып, бу төбәк крестьяннары бик уңышлы файдалана торган татар сабаны турында җентекләп яза, халыклар көнкүрешендә бик күп үзенчәлекләр күреп ала. Мәсәлән, татарларның ихаталарында кышкы ызба белән бергә җәйге ызба да бар. Һәркайсында сәке, җыйнак итеп чыгарылган мич булу (бу мич тәфсилләп сурәтләнә) — татар өенең үзенчәлеге. Бу төбәк халкы тәрәзә пыяласы урынына карындык, җәен яки кырпы тиресе куя. Автор каралты-кураны тасвирлап үтә, авылларның ничек идарә ителүенә: десятниклар, сотниклар, старосталар эшенә туктала. Бу төбәк халкының төп шөгыле игенчелек була. Казан губернасының көньяк өязләрендә җирләр гаҗәп уңдырышлы — ашлап торасы да юк: бары тик басуда калган саламны гына язын яндыралар һәм, игеннәрне урып-җыйгач, кырга көтү кертәләр. Өч басулы игенчелек системасы өстенлек итә. Чәчү мәйданының төп өлешен арыш алып тора, сирәк кенә борчак басулары очрый, ә ясмыкны татар крестьяннары гына чәчә. Лепехин урак уру, игенне саклау, сугу (өч ысул белән сугалар: көлтәдә килеш чабагач белән, көлтәләрне чишеп һәм атлардан таптатып), көлтәләрне киптерү (ул Урта Идел крестьяннары гына куя торган әвеннәрне сурәтли) хакында зур кызыксыну белән һәм эшне белеп яза. Крестьяннарның яшелчә бакчалары да бар. Алар анда чөгендер, кәбестә, кишер һәм кыяр гына үстерәләр. Халык мал асрый, умарта тота, төрле һөнәрләр белә. Мәсәлән, сарык йоныннан кием өчен тула басалар, ап-ак, нәфис киндер сугалар, чана табаннары бөгәләр һәм җир эшкәртү кораллары ясыйлар.

Лепехин, нигездә шәхси күзәтүләренә таянып, чувашларның, мордваларның һәм татарларның этнографиясен бәйнә-бәйнә тасвирлый. Мөлкәт-хәлләренә карап, крестьяннарның катлауларга аерылган булуын һәм, әлбәттә, моның көнкүрештә дә чагылуын күздән ычкындырмый. Әйтик, татар крестьяннарының көн дә кия торган һәм кешелеккә генә кия торган киемнәрен сурәтләгәндә, «ярлылар» һәм «байлар» киргән киемнәрнең нинди тукымадан тегелүен (баерак татарлар ефәк киергә тырыша, ярлыраклары «китайка»га да риза), кайсыларының бакыр, ә кайсыларының көмеш бизәнү әйберләре тагуын ачыклап үтә.

Галимне мөселман дине, аның атрибутлары, дин шарт итеп куйган йолалар һәм гореф-гадәтләр дә кызыксындыра. Ул дин әһелләренең тормыш рәвешен, составын, хокукларын әйтеп үтә, мәчетләрнең эчке бизәлешен сурәтли. Өйләнешү, бала туу, мәет озату кебек вакыйгаларга бәйле йолаларны бәйнә-бәйнә язып үтә. Галимнең үткен күзе татар халкында калым түләү йоласы булуны да күреп алган. Ярлылар арасында калым 20—30 сум тирәсендә тирбәлсә, байларда ул 100—200 сумга, ә кайвакыт 300 сумга да җитә. Шулай итеп, өйләнү экономик алыш-биреш ясауга әверелә (ул заманнарда арыш онының поты — 12-13 тиен, бодай онынык ы — 30-32 тиен, ә солы ярмасыныкы 9-10 тиен була. Әгәр кияүнең атасы яки кияү үзе кәләш өчен калымны шунда ук түли алса, никах укылуга ук кәләш өенә китә, юк икән — калым түләнеп беткәнче (кайчакта бу берничә елга да сузылырга мөмкин), кәләш әтисе өендә калып тора. Көндәлекнең авторы татар халкының белем дәрәҗәсенә дә туктала: «Язу танысын өчен, динне өйрәнсен өчен, улын мәдрәсәгә бирмәү ата кешегә гафу ителмәслек гөнаһ санала».

[1] И. И. Лепехин. Доктор һәм Фәннәр академиясе адъюнкты Иван Лепехинның 1768 һәм 1769 елларда Россия дәүләтенең төрле провинцияләрендә сәяхәт көндәлекләре. СПб., 1771.

Чирмешән елгасы үзәненнән соң Лепехин сәяхәте Казан губернасының көньяк өязләрендә дәвам итә. Шул ук вакытта, 1768 елның көзендә ул үзенең ярдәмчесе Николай Озерецковскийны (соңыннан ул күренекле галим, академик була) Казанга җибәрә. Озерецковский шәһре Болгар харәбәләрен карап чыгарга һәм күргәннәрен язып куярга җай таба. Бу язмалар да И. И. Лепехин көндәлегенә кертелә. Ул чорда Болгарда 44 корылманың калдыгы сакланып калган, араларында 7 сарай, 4 манара һәм 2 багана элекке «төс-кыяфәтләрен» югалтып өлгермәгән була. Көндәлектә бу борынгы корылма калдыклары берәмлекләп санала һәм тасвирлана. Болгар һәм әрмән этнографиясе истәлекләренә тасвирлама да бик кызыклы. Лепехин беренче булып шәһре Болгарда табылган кабер ташларындагы (47 се болгар һәм 3 есе әрмән телендә язылган таш) язуларның тәрҗемәсен бастыра. Бу язулар 1721 елда Болгарга Петр I килгәч җыйналган була. Аларны татар ахуны Кадыйрмәмәт Сүнчәләев, тәрҗемәче Йосыф Ишбулатов һәм әрмән Иван Васильев тәрҗемә итә.

1768—1769 еллар кышын Лепехин экспедициясе кешеләре, җыелган материалларны системага салып, Сембердә үткәрәләр. 1769 ел язында тагын кузгалгач, аларның юлы Иделнең түбән агымына һәм Урал буена таба китә. Отряд барысы 4 ел юлда була. Н. И. Лепехин рус булмаган халыкларны объектив рәвештә, теләктәшлек күрсәтеп тасвирлый, аларның чыдам, хезмәт сөючән, зирәк кешеләр булуын искәрә. Гади хезмәт халкының авыр хәлен дә, байларның «кеше җилкәсендә һәм өлгергән игенне бүтәннәр кулы белән урып яшәвен» дә, ә «ярлыларның елдан-ел бөлгенлеккә төшә баруын» да, әлбәттә, сизми калмый. Христиан дине миссионерлары һәм мөселман фанатиклары ясалма рәвештә кабызган дини ызгышның да күңелсез нәтиҗәләре Лепехинга көн кебек ачык. Ул керәшен татарлары белән чукынмаган татарлар арасында «зур низаг» бар, аларның бер-берсен «җене сөйми» һәм «бер-берләренә этлек кенә эшләп торалар» диген күзәтү ясый. Ихтимал, Лепехин татар авылларындагы төрле-төрле тарихи һәм әдәби кулъязмалар белән дә танышкандыр. Үз язмаларында ул, әйтик, шәһре Болгарны Аксак Тимер яулап алу турында сөйли торган, үзенә мәгълүм татар язма истәлегенә ишарә ясый.

Оренбург экспедициясендә иң зурысы дип исәпләнгән икенче отрядның җитәкчесе Петр Симон Паллас (1741—1811) була. Ул, Берлинда туып үскән табигать галиме, 1769 елда Фәннәр академиясе чакыруы белән Россиягә күчеп килә. Сәяхәт башында аларның юллары бер тирәдән — Казан губернасының Казан өязе, Чирмешән елгасы үзәненнән үтә. Аннары Паллас, 1768 елның августында Касыйм шәһәренә керәп үтә дә биредә ханлык чорыннан калган күп кенә корылмаларга — Ока елгасы аръягыннан таш чыгартып салынган ак мәчеткә, мавзолейга, кабер ташларына игътибар итә), көнчыгышка, Себергә китеп, 1770 елны — Тобольскига, 1771 елны — Красноярскига, 1772 елны Саян тауларына барып җитә. Ул, экспедициядә барлыгы 6 ел булып, иң авыр маршрутны йөреп чыга [1].

Чирмешән буйларында ул Усман авылына кагылышлы кызыклы бер фактны китерә. Бу авылны тагын Надыйр дип тә атап йөртәләр икән. Имештер, бернича ел элек кенә үлгән старшина Надыйр Уразмәтовка бәйле рәвештә куела бу исем. Бу кеше 1756 елда Оренбург тау конторасыннан шушы тирәләрдә табигый асфальт җыйнап, аннан нефть ясарга рөхсәт ала. Шул максат белән ул Камышлы елгасының өске агымында — бер завод, Сургут елгасы буенча икенче завод сала башлый, ләкин вакытсыз үлеме аның бу эшен бүлдерә.

1768 елның декабрендә Паллас та, калын кар каплаган булса да, борынгы шәһре Болгар харәбәләрен карый һәм бар күргәннәрен язып куя. Ул Болгар кабер ташларындагы язулардан (Паллас аларның барысы 49 ди) Петр I боерыгы белән күчермә алынган, шулардан 22 язу һиҗринең 623 нче елы белән тамгаланган (бу якынча 1225 елга туры килә), калганнары 619 нчы елдан алып 742 нче елга кадәрге чорга карый (якынча 1221—1341 еллар) дип хәбәр итә.

1769 елның язында экспедиция Оренбург ягына юнәлә. Без көндәлектә Оренбург тирәсендәге Сәгыйть (Каргалы) бистәсе, аның урнашуы һәм каралтыларының тасвирламаларын табабыз. Паллас таш нигезгә салынган, 2-3 ак өе булган йортлар

---

[1] П. С. Паллас. Россия империясенең төрле провинцияләре буйлап сәяхәт. СПб. 1786—1788

саны өч йөзгә җитә дип яза. Монда яшәүче кешеләр Казан татарларыннан чыкканнар һәм тел белән дә, гадәт ягыннан да алардан аерылып тормыйлар. Ярыйсы гына бай яшиләр, асылда, сәүдә белән шөгыльләнәләр, шуңа күрә, дип билгеләп үтә Паллас, аларның «көязлек һәм зиннәт өчен яраклы вак-төякләре», төрле бизәнү әйберләре булуы гаҗәп түгел.

1769—1770 елларның кышын Паллас отряды Уфада үткәрә. Шәһәр тирәләрендә ул үзе «Уфа татарлары» дип атаган татарларның тормышын күзәтә. Биредә шәп табыш белән сәүдә итеп ятучы Казан татарларын ул Уфа татарларыннан аерып карый. Уфа татарлары — «гаять тырыш игенчеләр һәм фәкыйрь яшәмиләр». Монда туфрак бик уңдырышлы, сөрелмәгән җирләр дә байтак. Паллас өч басулы иген игү системасын сурәтли һәм биредә бодай чәчүлекләре күбрәк, дип әйтеп үтә. Буш җирләр күп булганга күрә кешеләр яңа урыннарга еш күченә.

Автор татар крестьяннарының терлек асрауларына кагылышлы бер кызыклы фактны искәргән: кышын мал-туар авыл янындагы махсус араннарда асрала, җәй көне, терлекне көтүгә чыгаргач, бу араннарда киндер чәчелә. Җирле халык даладагы һәм чирәм җирләрне генә сабан белән сөрә, ә болай гадәти сөрү коралы — сука. Паллас Уфа татарларының, рус крестьяннарыннан аермалы буларак, келтәләрне гадәти эвендә түгел, ә бәлки ут ягылган чокырлар өстенә чатыр кебек кадап тезелгән колгаларга түшәп киптерүләрен билгеләп үтә. Татар крестьяннарының өй эчен, кием-салымын сурәтләгәндә, Паллас Казан, Идел буе татарларыныкыннан биредәге кием-салым кайбер детальләре белән аерылып торганын әйтә. Мәсәлән, хатын-кызлар киемә калын киндердән тегелә, итәк очлары, чит-читләре чигелә.

1773 елда Паллас экспедициясе Кама буе, Урта һәм Түбән Идел буен (Сарапул аша) үтеп, башкалага әйләнеп кайта. Галим елга буйларында төрле борынгы корылмалар, иске торак урыны калдыклары (шул исәптән Иске Казан урыны) очравын теркәп үтә. 22—25 апрельләрдә галим зур татар алпавыты Тәфкилевнеке булган Икәшүр, Мордва һәм Тирсә авыллары аша үтә. Алпавыт Тәфкилев үзе Тирсә авылында (анда ул чагында йөз хуҗалык исәпләнә) бүрәнәдән салынган бик шәп йортта яши торган була [1]. Бу авылларда ул игътибарга алган бөтен нәрсә — игенне, келтәләрне саклау рәвеше дә, утынны сакчыл тоту да, сөрү җирләренең бүленеше дә, терлек асрау, йорт-җир тоту үзенчәлекләре дә, Паллас фикеренчә, «яхшы хуҗалык итү үрнәге була ала, мактауга лаек һәм күзне куандыра». Шунысы кызыклы: бу сүзләр нәкъ менә 1773—1775 еллардагы Крестьяннар сугышы башланыр алдыннан әйтелгән. Баш күтәргән Тәфкилев крестьяннары Тирсә авылындагы алпавыт утарын туздырып ташлыйлар, ә Йосыф Тәфкилевнең үзен җәзалап үтерәләр. Палласның Тәфкилев белән бик күрешәсе килә, ләкин тегесе үзенең Агыйдел буендагы утарына киткән була — алпавыт сабан туен шунда бәйрәм итәргә яраткан. Тирсә авылыннан 28 чакрымдагы Барҗы авылында Тәфкилевнең дүрт мичле бакыр эретү миче була. Бакыр рудасы җитмәү сәбәпле биредә гадәттә бер генә мич эшләтелә (тирә-юньдәге рудниклар инде бушап калган була, Паллас заводтан 23 чакрымдагы Кузаково диген удмурт авылы янындагы бакыр базын үзе дә барып карый). Ләкин рудникларның барысы да өметсез булмый әле. Мәсәлән, Бөгелмәгә барышлый галим Чатыр тау янындагы бакыр руднигына керә. Бу рудниктан елга ун мең пот руда чыгарыла, 100 пот рудадан 2 пот бакыр алына торган була.

Аннары Паллас Җаек елгасына таба, көньяк далаларга юл тота, ә 1774 елда ул Царицын, Тамбов һәм Мәскәү аша Петербургка кайта.

Экспедиция составында танылган галим, Россия Фәннәр академиясенең беренче член-корреспонденты Петр Иванович Рычковның улы, Фәннәр академиясе адъюнкты Николай Петрович Рычков та (1746—1784) була. 1769—1770 елларда ул Сембер — Зәй — Алабуга — Минзәлә — Оренбург — Уфа — Казан маршруты белән мәстәкыйль сәяхәт ясый [2]. Аның сәяхәт журналында татар халкы турында да кызыклы белешмәләр бар. Барлык тикшеренүчеләр кебек үк, ул да Казан губернасының көньяк өлеш-

---

[1] П. С. Паллас аны генерал-майор дип олылый. Мәгълүм булганча, элекке генерал-майор Котлымөхәммәд Мамеш углы (Алексей Иванович) Тәфкилев инде вафат була, димәк, алпавыт аның улы — секунд-майор Йосыф Котлымөхәммәд (Осип Алексеевич) углы гына була ала.

[2] Н. П. Рычков. Капитан Рычковның Россия дәүләтенең төрле провинцияләре буйлап 1769 һәм 1770 елларда ясаган сәяхәте журналы яки көндәлек язмалары. СПб, 1770.

ләрендә җирнең уңдырышлы булуын билгеләп үтә. Монда игенчеләр күп яши, икмәк уңа, шуңа күрә аның бәясе дә башка районнардагыдан арзанрак була. Борынгы болгар авыллары урынында табылган һәм сәяхәт вакытында үзе дә күргән җир эшкәртү коралларына карап, Рычков «монда яшәгән кешеләр игенчеләр булган» һәм бу кораллар «игенчеләр арасында әле дә кулланылышта йөри торган кораллардан берни белән дә аерылмый» дигән нәтиҗә ясый. Шулай да, бу төбәктә яшәүчеләрнең бик тырышуларына да, хезмәт сөюләренә һәм соңгы елларда уңыш әйбәт булуга да карамастан, игенчеләр ярлылыктан чыга алмый. Рычковка бик күп татар авылларына керергә туры килә. Ул балаларны мәктәпләрдә укырга-язарга һәм «кече яшьтән кеше белергә тиешле шөгыльләргә өйрәтүне «хаклы рәвештә макталырга тиешле тәрбия йолалары» дип саный. Биләрдән Зәйгә кадәр араны Рычков 1769 елның май аенда, язгы кыр эшләре тәгәлләнгән бер чорда үтә. Зәй елгасы буендагы Чишмә авылында ул татарларның шушы уңайдан уздырылган бәйрәмнәрен карый. Бөтен халык авыл янындагы тау битенә җыйнала, корбан чалына, мулла дога укый, аннары шунда ук барысы да утырып ашый. Тантанада катнашучылар кунакны бәйрәмнәренә чакыруны үзләре өчен дан дип саныйлар. Алабуга янындарак Кама елгасын кичеп чыккач, автор бу тирәләрнең бик урманлы, туфрагы кызыл балчыклы икәнен, шуңа күрә иген игү һәм мал асрау өчен бик үк кулай булмавын билгеләп үтә. Халык сөрүлек җиргә генә түгел, мал-туарны көтүдә йөртердәй болыннарга да мохтаҗлык кичерә. Алабуга кешеләре җитештерә торган төп продукт — суган, алар суган белән хәтта ерак шәһәрләрне дә тәэмин итеп торалар. Аннары, Каманың сулъяк ярына кабат чыгып, Рычков сәяхәтен Ык һәм Минзәлә елгалары буйлап дәвам итә, юлында аңа күбесенчә татар авыллары очрый. Бу як кешеләре алабугалылардан хәллерәк яшәгәнен, күп итеп мал-туар асраганын, умарта тотканын күрә ул. Сәяхәтчене төрле халыкларның, бигрәк тә мариларның һәм удмуртларның йолалары кызыксындыра. Үз көндәлегендә аларның мәҗүси ырымнарын, культурасын һәм көнкүрешен бәйнәбәйнә язып куя. Моннан тыш, Рычков типтәрләрнең социаль-хокук хәленә игътибар итә һәм аларның илнең көньяк районнарыннан тоз ташуларын тасвирлап үтә. Типтәрләрдән 1200 хуҗалык бүлеп алынган, һәр хуҗалык (йорт) ел саен казнага 600 пот тоз алып кайтып тапшырырга тиеш. Моның өчен алар тозның һәр потына 6-7 тиен исәбеннән акча җыялар. «Тоз алырга, алдан килешеп, җиде кешенең берсе китә, калган алтысы аңа ничек тә булса ярдәм итә яки аның белән бергә бара» икән. Өстәвенә типтәрләрдән 200-400 ләп кеше ел саен шәһәр төзү эшләрендә эшләү өчен Оренбургка җибәрелә.

Өченче экспедиция — Оренбург отрядының җитәкчесе Иоганн-Петр Фальк (1727—1774) дигән галим. Ул Швециядә туып үсә, ботаника докторы һәм Петербургтагы ботаник бакча директоры була. Үз юл язмаларын ул үзе эшкәртми диярлек. Моңа Фалькның экспедиция вакытында сәламәтлеге какшап китү сәбәп була. Аны «эшләгән эшем бернигә дә ярамас, Фәннәр академиясен оятка калдырырмын» дигән бәйләнчек фикер эзәрлекли. Психикасы сау булмаса да, Фальк үзенең экспедиция эшләрен 1774 елга кадәр алып бара. 1774 елның мартында авыруы аны һәлакәткә этәрә — Фальк Казанда атылып үлә. Ул Казанда күмелә дә. Ә 1770 елны Фальк экспедициясенә ярдәмгә Иоганн-Готлиб Георги җибәрелә, соңыннан Фальк көндәлекләрен шул эшкәртеп бастыра[1].

Фальк отрядының маршруты нигездә Түбән Идел буе һәм Урал аша үтә. Хәер, экспедиция ахырында ул Урта Идел буенда да булып китә. Шуңа күрә ул туплаган материалларда татар халкы турында мәгълүматлар бик күп түгел. Анда Казан шәһәрендәге татар бистәләренә, андагы каралтыларга, кешеләрнең шөгыленә карата характеристика бик кызыклы. Шәһәр кешесе дип йөртелгән татарларның күпчелеге шәһәрдә түгел, ә шәһәр читендәге авылларда яши. Аларның төп кәсебе — сәүдә, бакчачылык, һөнәрчелек. Ул заманда Иске татар бистәсендә 162 хуҗалык һәм агач мәчетләр урынына төзелгән ике таш мәчет, Яңа бистәдә 172 хуҗалык һәм шулай ук ике мәчет була. «Казандагы рус һәм татар байларының тире, сабын кайнату завод-

---

[1] Академик Фальк сәяхәте язмалары. Император Фәннәр академиясе президенты үз тәкъдиме белән бастырып чыгара торган гыйльми сәяхәтләрнең Тулы җыелмасы. 6 нчы том. СПб, 1824.

ларында җитештерелгән сәхтиян, йомшак күн һәм сабын һәркайда үтемле товар булып исәпләнә»,— дип яза Фальк. Ул Оренбургта да була һәм Сәгыйть бистәсенә сугылып үтә. Аның мәгълүматлары буенча, анда салым түләп торучы 2160 кеше яшәгән, шулардан утызы — бохаралы булган. «Бистә татарлары, дип яза галим, гади, аек һәм пакъ тормыш алып бара». Ул аларның йорт җиһазын, төрле бизәнү әйберләрен, келәмнәр, көмеш һәм фарфор савыт-саба ясатуын сурәтли.

И. П. Фальк юл язмалары материалларын эшкәрткән И. Г. Георги үзе дә XVIII йөздә Россиядә яшәгән халыкларның этнографиясе буенча зур күләмле хезмәт авторы[1]. Бу китап күп еллык гыйльми экспедицияләргә һәм сәяхәтләргә йомгак ясый, һәм аны зур кызыксыну белән көтеп алалар (аның XVIII йөз ахырына кадәр үк рус телендә өч басмасы чыгуны әйтү дә җитә). Бу басманың икенче китабы «Татар кабиләсе халыклары турында» дип атала, анда Казан һәм Оренбург татарларына киң урын бирелгән. Сүз башында Георги татар халкы тарихына күз ташлый, аның күп санлы һәм Россиянең төрле губерналарына гаять таралып урнашкан булуын билгеләп үтә. 1779 елда Казан, Уфа, Пенза, Сембер һәм Пермь губерналарында ул ир-ат җенесеннән булган 51044 татар һәм шулай ук 6686 керәшен татары яшәвен әйтеп үтә. Шәһәрләр турында язганда исә Казан һәм Оренбургтагы татар бистәләрен дә игътибардан читтә калдырмый, аларның ничек барлыкка килүен, шулай ук халкының кәсеп-шөгылен тасвирлый. Георги төрле халыкларның холык фигылен дә аңлатырга тырышып карый. Билгеле булганча, бу эшкә соңрак тотынган һәм мәгълүматы зуррак булган белгечләрнең дә мондый омтылышлары уңышлы тәгәлләнгән дип әйтеп булмый. Һәм, гомумән, халыкларга гомуми характеристика бирү мөмкинлеге үзе үк бәхәсле нәрсә, ләкин, шулай да, бу басмада татар халкына бирелгән характеристика шактый кызыклы: «алар шөһрәт сөючән, горур, акыл ягыннан артык аерылып тормыйлар, ялкау түгелләр, әмма ял итәргә дә яраталар, һәртөрле һөнәрне булдыралар, тәрбияләре һәм диннәре буенча... чиста, аек, сабыр һәм мәрхәмәтле». Георги да татарча кулъязмалар, аерым алганда һәр авылда да диярлек булган авыл тарихлары белән таныша. Галим үз хезмәтендә татар кешеләренең төрле шөгыльләрен, укый-яза белергә омтылуларын, алардагы буйсыну һәм идарә тәртибен, каралтыларын һәм өй эчләренең бизәлешен, диннәрен һәм гадәтләрен, ашаган ризыкларын бик тәфсилләп сурәтли.

Югарыда телгә алынган бу сәяхәтче галимнәрнең XVIII йөздәге хезмәтләре фәндә тирән эз калдыра. Алар гаять зур территорияне биләгән империядә гомер кичерүче төрле халыкларның тормышына һәм көнкүрешенә игътибар иткән беренче кешеләр була. Бу тәҗрибә гаять уңышлы булып чыга, чөнки әлеге галимнәрнең хезмәтләре һәм сәяхәт журналлары бүгенге көнгә кадәр фәнни әһәмиятен югалтмаган. Тикшеренүчеләр хәзер дә бу авторларга зур ышаныч белән таяналар.

Фәннәр академиясе галимнәренең хезмәтләре соңгырак елларда бу мәсьәләне тагын да тирәнрәк өйрәнүләр өчен җирлек хәзерли һәм бу эшне 1804 елда ачылган, XIX йөздә Идел буе һәм Урал буе халыкларын өйрәнү үзәгенә әверелгән Казан университеты дәвам итте һәм итә.

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,**
СССР Фәннәр академиясенең СССР тарихы институты аспиранты.

[1] И. Г. Георги. Россия дәүләтендә яшәгән барлык халыкларның тормыш йолаларын, диннәрен, гадәтләрен, торакларын, киемнәрен һәм башка үзенчәлекләрен тасвирлау. СПб. 1—3 кисәкләр. 1776—1777.

## Афзал Нигъмәтулин

*Вятка елгасы буенда урман хуҗалыгы техникумы белән данлыклы Лубьян поселогы бар. Мин шунда 1957 елда тугьанмын. Миңа бер яшь тулганда әти-әниләрем Мамадыш районының Түбән Шәндер авылына күчеп килгән. Сигезенче класстан соң Арча педагогия училищесын тәмамладым. Хәзер Казан дәүләт педагогия институтының бишенче курс студенты.*

*Шигъриятка мәхәббәтем кечкенәдән үк килә. Минем бәхеткә, Шәүкәт абый Галиевнең шифалы шигырьләре безнең балачакка да туры килде. Үземнең шигырьләремдә барыбызны да борчыган дөньяви проблемаларга да кагылырга тырышам.*

### Кул гына чыдасын

Кояш байый, кич җитә.
Гаиләбез ял итә:
Әти чумган гәзиткә,
Әни юа тәлинкә.
Кырын ятып, Айрат та
Гитарасын «сайрата».
Кыллары чыңлап тора,
Тәрәзә зыңлап тора!
Чыдасын тик кыл гына,
Чыдасын тик кул гына...

Гаиләбез ял итә.
Әти чумган гәзиткә,
Әни юа тәлинкә...
Минем әни бик эшчән,
Кулы бушамый эштән.
Әле кибеткә китә,
Дәү әнигә сөт илтә...
Сыер сава, көтү куа,
Идән юа, керен уа.
Әнигә эш мул гына...
Чыдасын тик кул гына!

## Әнием самавыры

Әнинең самавыры —
Сабырның да сабыры:

Кайный башласа башлый,
Ярсып ташыса ташый —

Әти күк тузып китми,
Өйдән үк чыгып китми!

## Телевизорга үпкә

Мультик — ул бит
Кызык булырга тиеш,
Озак булырга тиеш...

Тик андагы абыйлар
Белмиләр шул бу хакта.
Мультфильм бетеп куя
Иң-иң-иң кызык чакта,
Башланып китә ул я
Һичбер кызык юк чакта —
Мин торганда почмакта!

## «Тавышлы» мультфильм

Абый фотоаппараты
Корылган гына иде,
Абый үзе бер эш белән
Борылган гына иде,—

Фотоаппаратны элеп,
Эләгәсен дә белеп!—
Чыгып чаптым урамга.
Урамда матур анда!

Кызганмадым тасманы:
Төшердем мин Әсманы.

Әнә Вил тоткан шөреп,
Мөдәррис ясый мылтык...

Мин гел кызык төшереп,
Ясарга булдым «мультик!»

Эшкәрткәчтен тасманы,
Күрерсез сез Әсманы,

Күрерсез агач мылтык —
Әнә шул булыр «мультик»!

...Нәрсә, тавышы юкмы?
Тавышына кызыкма.

Абыем эшне белер...
Тавышы шунда булыр!

# ДИМНЕҢ ҖЫРЧЫ ЕГЕТЕ

Башкортстанның җырларда җырланган, әкиятләрдә сөйләнгән гүзәл Дим буйларында, Салават батырның кылыч айкап дошманнарга каршы күтәрелгән җирендә, халык борын-борыннан легендалар һәм дастаннар тудырган якта — Түбән Хаҗәт авылында 1912 елның 15 августында булачак шагыйрь Рәхим Саттар дөньяга килә. Аңа биш яшь тулганда Октябрь революциясе була. Халык иркле һәм бәхетле тормышка атлый. Түбән Хаҗәт авылы кешеләре дә алпавыт җирләрен тартып алалар. Әбдрәхим сигез яшендә укырга керә һәм беренче көннәрне үк үзенең сәләтле укучы икәнен күрсәтә. Дүртенче класста укыганда инде ул шигырьләр яза башлый. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури шигырьләрен күңелдән белә. Авылда төрле фаҗигале хәлләргә карата чыгарылган бәетләрнең дә авторы Әбдрәхим була.

Җидееллык мәктәпне тәмамлагач Рәхим Саттаров төрле эшләрдә эшли, Кызыл Армиядә хезмәт итә, ак финнәргә каршы сугышта катнаша. Аннан соң Казанга килә һәм «Кызыл яшьләр» газетасында җаваплы редактор урынбасары вазифасын башкара. Бу елларда аның әдәби иҗат эшчәнлеге активлаша. Ул шигырьләр, очерклар һәм мәкаләләр яза, рус һәм Европа классикларын тәрҗемә итә.

Сәләтле яшь шагыйрьнең иҗади үсешен җентекләп күзәткән Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Нур Баян, Абдулла Алиш киңәш биреп рецензияләр язалар.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, Рәхим Саттар үзе теләп фронтка китә. Десантчы булып фашистлар тылында җаваплы заданиеләр үти. Көнбатыш фронтта барган каты сугышларның берсендә 1942 елның 27 маенда чолганышта кала һәм әсирлеккә эләгә. Смоленск, Борисов шәһәрләрендәге һәм Вустраудагы концлагерьларда михнәт-газап чигә. Вустрау лагеренда Абдулла Алиш белән очраша.

«1942 елның азагында Берлин янындагы лагерьда шагыйрьләрдән Муса Җәлилне, Р. Саттаровны («Кызыл яшьләр» газетасыннан) очраттым... (Р. Саттар 1943 елның июнендә качты, аның язмышын белмибез)». Бу җөмләләр язучы Абдулла Алишның фашистлар төрмәсеннән язган соңгы хатыннан. Әйе, патриот шагыйрь Рәхим Саттар фашизмга каршы көрәштә Муса Җәлилнең иң ышанычлы көрәштәше була. Ул концлагерьларда һәм «Идел-Урал» легионында гитлерчыларга каршы листовкалар язуда һәм аларны типографиядә бастыруда, хәрби әсирләр һәм легиончылар арасында таратуда зур активлык күрсәтә. Бу турыда элеккеге хәрби әсирләр болай сөйлиләр: «Идел-Урал» легионында татарча газета чыга иде. Бу газетада шагыйрь Рәхим Саттаров та эшләде. Ул газетада Туган илне яратырга, аңа хыянәт итмәскә, рус халкы белән дус яшәргә өндәп язган иде». Рәхим Саттаров концентрацион лагерьларда да, «Идел-Урал» легионы каршында чыга торган газета редакциясендә дә үзен батыр һәм кыю тоткан, фашистларга, Гитлер ялчылары — ак эмигрантларга җирәнеп караган. Фашистлар табанын ялаучы эмигрант, хыялда гына булган «Идел-Урал» дәүләтенең «президенты» Шәфи Алмаз белән Рәхим Саттаров арасында ызгышлар чыккан. Шуның өчен Шәфи Алмаз гестапога язган доносында болай ди: «Алар газетада өч айдан артык эшлиләр, ләкин хәзергә кадәр большевизмга каршы бер генә пропагандистик мәкалә дә язганнары юк. Аларның хәзергә кадәр бөтен эше татар халкының күренекле кешеләрнең биографияләрен һәм милли шагыйрьләрнең берничә шигырен күчереп язу һәм рус газеталарыннан аз әһәмиятле хәбәрләр тәрҗемә итү белән генә чикләнә. Безнең аларны актив эшкә кушарга һәм антибольшевистик мәкаләләр язарга дәртләндерүебез уңышка ирешмәде, хәтта ачыктан-ачык каршылык

күрсәтүгә очрады...» «Бу каршылык күрсәтү,— дип дәвам итә Шәфи Алмаз,— легионер Саттаровтан башлана. Газетаны ул, большевистик настроение белдерерлек үк булмаса да, һич югында большевизмга зыян китермәслек итеп алып барырга омтыла. Менә аның карашларын чагылдыра торган берничә мисал. Шушы елның мартында большевиклар Кызыл Армиянең татар милләтеннән булган һәм немецларга әсирлеккә эләккән сугышчыларына, уртак Ватан дип атап, Россияне якларга чакырып мөрәҗәгать иттеләр (кызганычка каршы, бу хакта мин шушы арада гына укыдым). Бу өндәмәдә татар милли шагыйре Габдулла Тукайның русларның һәм татарларның бердәмлеген һәм язмыш уртаклыгын мактап җырлаган шигыре искә алына. Нәкъ менә шул вакытта Саттаров «Идел-Урал» газетасы өчен үз мәкаләсен язды. Ул анда рус һәм татар халыкларының бердәмлеге һәм уртак мәнфәгатьләре турында шул ук идеяне әйтте һәм бу шигырьне сүзгә-сүз калдырды... Саттаровның большевикларча эчтәлекле мәкаләсен мин кире кактым һәм мәкалә «Идел-Урал» газетасында чыкмады»[1].

Соңыннан Рәхим Саттаровны редакциядән чыгаралар, хөкемгә тарту өчен кулга алырга тиеш булалар. Ул, җәлилчеләрдән махсус задание алып, лагерьдан кача...

Рәхим Саттарның фашизм оясында — тоткынлыкта язган шигырьләре бар. Бу шигырьләр (кайберләре генәдер бәлки?!) кулдан-кулга күчеп, бик күп илләр гизеп, куркыныч һәм кыен юлларны үтеп Ватаныбызга кайтып җитә алды. Аларда патриот-шагыйрьнең кайнар йөрәк хисләре, соңгы сулышта да Ватан-анага турылыклы булуы ачык күренә:

**Дошман белсен минем күкрәгемдә**
**Нинди ачу, нәфрәт ятканын.**
**Мин сизәмен шушы нәфрәтемнең**
**Нәфис булып чәчәк атканын...**

«Әнкәм», «Әнкәмә хат», «Рухым гали» шигырьләрендә дә Рәхим Саттар халкы, иле өчен утларга керүен, дошман тозагында калса да иленә хыянәт итмәвен, соңгы тамчы канына кадәр фашистларга каршы көрәшәчәген белдерә. Әнисенә мөрәҗәгать итеп, шагыйрь болай ди:

**Бәлки син дә хәсрәт чигәсеңдер,**
**Сатылган, дип, улым дошманга...**
**Юк хәбәргә һич тә ышанма!**
**Дөрес түгел, ялган хәбәр ул,**
**Балаңа бер иманыңда бул!**
**Сиңа биргән изге антында,**
**Туган иленең ирке хакына**
**Биргән антын бозмас халкына!**

Батыр шагыйрь Муса Җәлил кебек, Рәхим Саттар да гитлерчыларны гаепләп, аларның пычрак йөзләрен фаш итеп, үлемсез шигырьләр яза. Ул соңгы сулышында да иле һәм халкының хак эше өчен көрәшә. Бу аның тоткынлыкта язылган «Халкым өчен» шигырендә ачык күренә:

**Ләкин син бел: һәр сулышым,**
**Барлык көчем**
**Синең өчен, Туган илем,**
**Синең өчен!**

...Немец фашизмын җиңүдә Дим һәм Идел егете, патриот сугышчы һәм шагыйрь Рәхим Саттарның да өлеше бар. Шуңа күрә без җитмеш яше тулган елда, аны тирән хөрмәт белән искә алабыз.

**Сәмат ШАКИР.**

---

[1] «Социалистик Татарстан», 7 январь, 1969 ел.

# ОСТА ДА, ОСТАЗ ДА ИДЕ

*Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның тууына 90 ел*

Татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән булып сәхнәгә аяк басканда, Сәхипҗамал төрле кара көчләр тарафыннан каршылык очратачагын, аларның мәсхәрә итәргә тырышачакларын, бәддогага укыячакларын яхшы аңлый. Столыпин реакциясе елларында артистка-туташка бигрәк тә кыенга килә: карагруһчылар башта аны юмалап, байлыкка, рәхәт тормышка кызыктырып карыйлар, аннары янайлар, куркыталар, ә инде алай да барып чыкмагач — үтереп ташларга ук ниятлиләр. Әмма яшь-яшь кызның артистка булу, сәхнәдә хатын-кыз образларын гәүдәләндерү теләге кануннардан өстен булып чыга. Аның халыкны агарту өлкәсендәге фидакарь хезмәтенә берни дә тәэсир итми, сайлап алган кыйбласыннан һич кенә дә тайчындыра алмый.

Гәрчә замандашлары Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның талантына мөкиббән китеп, матбугат битләрендә хәтсез күп хуплау сүзләре яудырсалар да, аның уйнау ысулына, сәхнәдә үзен ничегрәк тотуына, иҗатының бары тик аңа гына хас булган якларына, үзенчәлекләренә бик аз игътибар иткәннәр. Шунлыктан беренче артисткабыз иҗат иткән сәхнә образларына бүгенге көндә әтрафлы бәя бирергә, аның искиткеч зур талантын тулысынча күз алдына китерергә мөмкин дә түгел. Хәзер инде фәкать аның дини-социаль киртәләрнең һәммәсен җимереп сәхнәгә менәргә җөрьәт итүеннән, бүтәннәргә үрнәк күрсәтүеннән, кайсы спектакльләрдә нинди рольләрне уңышлы башкаруыннан чыгып кына, кайбер рецензияләргә һәм фоторәсемнәргә карап кына азмы-күпме фикер йөртә алабыз.

Беренче милли артисткабыз сәхнәдә үзе иҗат иткән гүзәл образлар белән хатын-кызның тигез хокуклы булырга, азат тормышта яшәргә тиешлеген исбатлаган. Әйтик, «Бай һәм приказчик» спектаклендә артистка эифа буйлы, чибәр йөзле, күркәм холыклы, үзенең намусын һәм бәхетен якларга сәләтле Бибиҗамал образын гәүдәләндерә. Кирәк чагында бу тыйнак кына яшь кыз ул заман өчен зур кыюлык күрсәтә: үзен Садыйк байга димли башлагач, әтиләренең иркенә буйсынмый, үз язмышын үзе хәл итә.

Хәер, бу спектакльдә Сәхипҗамалның партнерлары да гаять үзенчәлекле, зур талант ияләре була: Галимҗан бай ролендә Г. Кариев, Садыйк бай — Н. Сакаев, приказчик — В. Мортазин-Иманский. Бу актерларның һәркайсы тумыштан талантлы булу белән бергә заманының иң алдынгы шәхесләре булалар һәм театрыбыз сәхнәсендә реализмга, сәнгать дәреслегенә нигез салып калдыралар. Алар белән аралашу, бергә-бергә сәхнә образлары иҗат итү Гыйззәтуллина-Волжскаяның осталыгын үстерүгә, һичшиксез, уңай йогынты ясый.

Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасын куйганда, Сәхипҗамал кече яшьтән үк рәнҗетелгән һәм кимсетелгән кызларны, байлар тозагына эләгеп рисвай ителгән бичараларны күреп үсә. Һәм ул сәхнәдә нәкъ әнә шундый алданган кыз бала образын гәүдәләндерә. Мескенлеккә төшүен Гайни-Волжская гаҗәеп авыр кичерә, газаплана, әрни, тик инде бу хәлдән һичбер котылу юлын таба алмый. Кыз баланың гомерлек фаҗигасен болай художникларча оста күрсәтү шул заманда яшәп килгән гореф-гадәтләргә, байларның азгынлыгына, бозыклыгына каршы бунт булып яңгырый. Актрисаның шушы драматизмны күрсәтүдәге осталыгы революциягә кадәрге матбугат битләрендә дә чагыла. («Казан мөхбире», 1908, 2 сентябрь).

С. Гыйззәтуллина-Волжская үзенең сәхнәдә уйнавы белән халыкка алдынгы фикер алып килүенә, ул фикерне тамашачыларга дөрес җиткерүенә бервакытта да шикләнми. Һәм әнә шул ныклы ышаныч, изге ният һәм көчле рух аңарга беренче елларыннан ук, әле сәхнә техникасын үзләштереп җиткермәгән чагында ук, рольләрне оста башкарырга, зур популярлык казанырга мөмкинлек бирә. Ә инде, еллар узу белән, сәхнә техникасын да ныклап үзләштергәч, иҗади караш диапазоны тагын да киңәя төшкәч, аның осталыгы камилләшә, ул инде тиңдәшсез актриса булып җитлегә.

Сәхнәдә ул олы бәхет кичерә, һәр чыгышны ул үзе өчен бәйрәм дип кабул итә

Истәлекләрендә дә ул: «Сәхнәдә мин уйнамадым, сәхнәдә мин яшәдем»,— ди. Ул сәхнәдә нурланып, балкып яши, һәм үзе дә нур чәчә, үз эшен бик тә ярата, шуңа күрә үзен иркен тотып, җиңел уйный, тик моңа ирешү өчен хәтсез күп эшләргә дә туры килә. Ул театр сәнгате корифейларының китапларын күп укый, аларның актерлык һөнәрен ничек үзләштерүләре, осталыкка ирешүләре турында уйлана. Үзенә ул көннән-көн таләпчәнрәк килә: һәр яңа рольне ныклап өйрәнә, сәхнәдә үзен бу очракта ничегрәк тотарга, кайчан нинди интонация белән сөйләргә кирәклеген абайларга тырыша, эзләнә, баш вата. Нәтиҗәдә актриса һич кабатланмый, бәлки яңадан-яңа үрләр яулый, тамашачыларны гүзәл уйнавы белән сокландыра, хәйран калдыра.

1912 елда Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская икенче труппа булдыру дәртенә керешә. Мондый карарга елның елында төрле шәһәрләргә гастрольгә чыгып йөргәч килenә: ул халыкның яше-карты театрда тын да алмыйча утырганын, һәр спектакльне әйтеп бетергесез зур кызыксыну белән караганын, сәхнәдә тасвирланган вакыйгаларга һичбер вакытта да битараф калмаганын, кыскасы, халыкның сәнгатькә сусаганлыгын күреп ышана. Тормыш дәресләгән халыкка җиткерүче мәктәпләрнең мөмкин кадәр ишлерәк булуын тели һәм үзе дә өнә шундый яңа бер мәктәп ачарга ниятли.

— «Сәйяр»да сәхнә йолдызы дип танылган остадан әр-яңа эшкә алыну искиткеч зур тәвәккәллек, җитәкче буларак оештыру сәләте таләп итә, әлбәттә: сәләтле артистлар туплыйсы, аларны авырлыкларга бирешми торган итеп тәрбиялисе, чыныктырасы бар; мавыктырырлык та, шул ук вакытта гыйбрәтле һәм кирәкле сәхнә әсәрләреннән торган репертуар төзергә кирәк; театрны яшәтү өчен акча тапмыйча да беркая бара алмыйсың... Күпме кайгы-хәсрәтне бергә-бергә кичергән, күпме куанычюанычларны уртаклашкан иптәшләреннән аерылып китүе дә ансат булмый.

С. Гыйззәтуллина-Волжская җитәкләгән «Нур» труппасы Уфа каласында төпләнә һәм 1912 елның көзеннән беренче сезонын башлап җибәрә. Игътибарга шунысы лаек, Волжская труппадагы артистларны кыска вакыт эчендә театр сәнгатенә чын күңелдән бирелгән, гомерлек фидакарь хезмәткә багышлаган кешеләр итеп тәрбияләүгә ирешә. Социаль каршылыкларны җиңү, зур сәнгатькә омтылу белән бергә, артистлар бер эштән дә йөз чөермиләр: декорацияләрне үзләре хәзерлиләр, костюмнарны үзләре тегәләр, афишаларны үзләре язалар, рольләрне үзләре кулдан күчерәләр... Димәк, Сәхипҗамал үзен зур оештыручы, уңган, акыллы остаз итеп тә күрсәтә. Труппа эшенә юнәлеш билгеләгәндә, ул барыннан да элек художество-эстетик принципларын камилләштерүгә омтыла. Репертуар төзегәндә труппаның художество җитәкчесе һәрвакыт коллективның теләгенә колак сала, шуннан чыгып эш итә. Реалистик планга өстенлек бирелгәнгә, «Нур» репертуарында Г. Камал белән Ф. Әмирхан әсәрләре, классикадан исә Ф. Шиллер белән А. Островский драмалары күренекле урын яулап алалар.

Труппа артистлары өчен Волжская үзе даими рәвештә дәресләр уздыра, һәркайсының индивидуаль үзенчәлекләрен өйрәнеп, киләчәктә шуны үстерергә юнәлеш бирә. Шул рәвешле ул бер фикердәге, бер теләк белән янучы, бер иҗади юнәлештәге коллектив булдыру бәхетенә ирешә.

Художество җитәкчесе буларак, ул һәр спектакльдә катнашучыларның гармоник бер бөтен, ягъни ансамбль тәшкил итүен максат итеп куя. Әмма һәрчак андый уңышка ирешеп тору мөмкин булмый. Фәкыйрьлек кичергән труппа гастрольгә чыкканда мөмкин кадәр азрак санлы бригада җибәрү ягын карый. Шуннан инде ваграк рольләрне башкарырга үзешчәннәрне чакырырга мәҗбүр була. Әлеге үзешчәннәр исә шәһәр саен, авыл саен яңарып, алмашынып тора. Аларның һәркайсына сәхнәдә үзен ничек тотарга кирәклеген, һәрхәлдә иң гади нәрсәләрне төшендереп торуга да режиссерның шактый вакыты сарыф ителә, ә нәтиҗә еш кына шул зур хезмәтне акламый.

Һәр яңа спектакльне әзерләгәндә җитәкче-Сәхипҗамалга, аерым күренешләрне җиренә җиткерү максаты белән, артистларны сәгатьләр буе өйрәтергә туры килә. Нәтиҗәдә аның шәкертләре арасында иң зур уңышка ирешкәне, талантлы актер дигән бәя алганы Ш. Шамильский була. Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» драмасында алар төп рольләрне икәү бергә башкаралар. Луиза-Волжская һәм Фердинанд-

Шамильскийның сәхнәдә искиткеч дәртләнеп, хисләнеп яшәүләрен, көрәшүләрен тамашачылар бик әсәрләнеп кабул итә.

С. Волжская үзенә яңадан-яңа рольләр сайлый, әмма аның бу хезмәтендә иң калку, иң нык ачылган бер төп тема буларак хатын-кызга азатлык даулау темасы һәрвакыт, һәр спектакльдә, һәр рольдә өстенлек алып килә. С. Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» дигән әсәре буенча куелган спектакльдә, мәсәлән, ул төп рольне башкара. Актриса, үзенең бәхете, мәхәббәте өчен аяусыз көрәшүче героиняга карап, тамашачыларда горурлык хисе уятырга тырыша, һәм үз максатына, һичшиксез, ирешә дә. Төрле илдә һәм төрле дәвердә яшәүче Луиза белән Зөбәйдәнең характерында бертөрле уртаклык чагылган сыман тоела.

Гомумән, Октябрьга кадәр иҗат иткән рольләрендә С. Волжская романтикага, хыялга, якты өметкә зур урын бирә, ул рольләрнең һәркайсында оптимистик чаткыны табарга тырыша. Башка спектакльләрне әйткән дә юк, хәтта әле «Үлем кочагында» әсәрен куйган чагында да шушы максатыннан читкә тайпылмый ул: үлем түшәгендә ятучы кызның образын бөтенләй кételмәгәнчә, үзенчә чишә. Пьесада ул кыз — көчсез бер зат, чирдән интегә, әрнүләргә түзә алмыйча, күз яше түгә, мескен хәлендә әкренләп сүнгәннән-сүнә бара... Сәхнә белән тормышның үзара нык‌лы бәйләнештә икәнлеген, бер-берсенә тәэсир иткәнен җаны-тәне белән тойган Волжская пьесаны ул хәлендә куюның ничаклы зарарлы булуын аңлый. Тамашачыны өметсезлеккә төшерүдән ни файда, дип фикер йөртә һәм героиняны елак кыздан батыр, йөрәкле кызга үстерә: ул яңа көн туууына сөенә, кояш нурларын тотмакчы булып кулын суза, яшәүнең тәмен белеп яши һәм ахыр чиктә елмаеп җан бирә.

Кыска гына вакыт эчендә зур-зур сәхнә әсәрләре иҗат итәргә сәләтле коллектив булып оешкан «Нур» труппасы бөтен Урал буйларын, Себер якларын, Урта Азияне әйләнеп чыга.

Шатлыклы Октябрь көннәренә килеп җиткәч, Волжская тагын да рухланыбрак, тагы да дәртләнебрәк эшли башлый. Гражданнар сугышы вакытында аңа Көнчыгыш фронтында оешкан театр труппасына җитәкчелек эшен ышанып тапшыралар. Аның труппасы яшь Совет дәүләтен яклаучы кызылармиячеләргә спектакльләр күрсәтә, аларны яңадан-яңа җиңүләргә рухландыра.

Халит **КУМЫСНИКОВ.**

# САФ КҮҢЕЛ

*Шакир Шамильскийның туууна 90 ел*

Татар театрының зур тарихында кыйммәтле һәм истәлекле сәхифәләр күп. Аларның үзәгендә — кешеләр: һич онытылмас, кабатланмас характерлы сәхнә осталары! Алар бүген дә бик күпләргә, бигрәк тә яшьләргә үрнәк була алалар.

Менә урта буйлы, киңрәк җилкәле, җыйнак гәүдәле Шакир Шамильский. Коңгырт куе чәчләр, килешле генә куе кашлар, җылы карашлы күзләр. Никадәр ягымлылык бу йөздә! Шакирның тавышы беркадәр тоныграк, беренче ишетүгә тембры да ачык түгел төсле. Ә шулай да син аны йотлыгып тыңлыйсың. Чөнки ул саф күңелдән, бик җылы итеп сөйли. Аның сөйләвендә кешелеклелек, кешегә ихтирам көчле. Шамильский тискәре яки уңай образны уйныймы — аның өчен барыбер, ул геройның кешелеклелек сыйфатына басым ясый. Ул начар, усал кешенең дә ниндидер яхшы яклары бар дигән фикер белән эш итә. Шул яхшыны эзли һәм таба.

Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасында ул ат карагы ролен уйный. Ат урларга бару, урлау процессын Шамильский шундый эчке җылылык, сокландыгыч мавыгу белән тәмләп сөйли, монологына шундый ышанасың, сизмәстән үзең дә аның белән яшисең кебек. Аның «Зәңгәр шәл»дә уйнавын соңгы тапкыр мин 45—50 еллар элек караганмын. Ә шул монолог әле һаман да колакта, күңелдә. Ат карагын Ша-

мильский зур эшләр башкарырга, яраткан эшен күңел белән бирелеп эшләргә сәләтле, ялкынлы кеше итеп тасвирлый. Тик ул кешегә иске патша Россиясендә эшләү дә, яшәү дә мөмкинлеге булмаган дигән фикерне артист тамашачыга үзенең уйнавы, сөйләве белән ачык төшендерә.

Шамильский сәхнәдә үзен бик гади тота, аңарда тамашачының игътибарын үзенә карату өчен «тырышу», фальш юк. Моның өчен бик зур осталык кирәк. Шамильский әнә шул осталыкка ирешкән, кешеләрне саф күңелдән яраткан олы җанлы артист иде. Шакир рольләрне «бу кечкенә», «бу зур роль» дип карамый. Тапшырылган һәр роль аның өчен бик кадерле һәм бик әһәмиятле. Ул һәр рольне тирән уйлап, әлеге роль-образның язмышын баштан кичереп иҗат итә, детальләр эзли. Ул театрдан тыш дуслары белән табында очрашамы, яки болай сөйләшәме — сүзне үзенең күңелен биләп алган образ яки берәр иҗади проблема турында башлый. Премьера узганнан соң да әле тынычлана белми. Шул образы өчен нинди дер яңа үзенчәлекләр ачуны, буяулар табуны дәвам иттерә.

Театрда «Шамильский авырый, хәле юк» дигән хәбәр ишетәбез. Спектакль өчен борчылабыз. Кичен, спектакль башланырга берничә сәгать калганда, Шакир инде театрга килгән була. Йөзендә чынлап та сырхау икәне күренә. Шулай да инде грим сала. Менә ул сәхнәдә һәм аны танымыйсың: авырулары, газаплары юкка чыккан. Ул инде образ язмышы белән яши. Спектакль уйнау Шамильский өчен яшәү шатлыгы иде.

Шамильский — партнерның кадерен аеруча белүче артист. Сәхнәдә ялгызың гына яшәү мөмкин түгел, синең иҗатың уңышлы булсын өчен партнерыңның иҗатчы булуы шарт дигән караш белән эш итә иде Шамильский. Шуңа күрә аның белән сәхнәдә булу үзеңә булган ышанычны куәтли.

Артист Шакир Шамильский белән без бик күп спектакльләрдә бергә уйнадык. Хәтеремдә: Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр» драмасында ул — Хәйретдин, мин — Сәрби. Бу образны тудыруда Шамильскийның бик күп киңәшләре, күрсәтмәләре миңа ярдәм итте. Яисә — Шекспирның «Король Лир» трагедиясен хәзерлибез. Миңа корольнең өченче кызы Корделия роле тапшырылган иде. Әмма бу хәл белән килешә алмыйча борчылып йөрим. Минемчә, корольнең беренче кызын уйнау минем өчен отышлырак булыр, ул рольдә уйнау өчен материал күбрәк, көчлерәк төсле тоела. Шул чакта Шамильский миңа Корделиянең күркәм холыклы кыз булуы турында сөйли. Образны ачык гәүдәләндерү өчен нишләргә кирәген дә җай гына әйтеп куя. Шулай итеп, ул эшкә дәрт, туачак образга мәхәббәт уята. Соңыннан Корделия минем иң яраткан рольләремнең берсе булды. Яки Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасында Шамильский — Закир, мин — Гайни. Әнә ул — тормышында яшәү юлын таба алмаган, кызганыч, бай малае Закир. Ул миңа шундый итеп карый, аның интонацияләре шулкадәр төгәл. Аның сөйләшүеннән, үзен тотуыннан мин аның каршында басып торган Гайнине — ул сөйгән хатынны ачык күрәм. Өстәвенә әле репетициягә кадәр Шакир миңа Гайни кебек хатыннар җырлый торгаң бер җырны да җырлап күрсәткән иде. Ул җыр миңа Гайни язмышына үтеп керү өчен ачкыч булды... Репетиция иҗади ялкынлану белән бара. Һәм нәтиҗә безнең икебезне дә куандыра. Тамашачылар Гайни белән Закирның соңгы очрашуларын тын алмыйча күзәтәләр: сәхнәдә татар байларының җирәнгеч, надан тормышы. Шул тормыш баткаклыгында һәлак булган яшьләрнең аяныч язмышлары бит...

Шамильский тирән уйлап эш итүче режиссер, татар телен яхшы белгән тәрҗемәче дә иде. Ул үз белемен күтәрү өстендә өзлексез эшли, күп укый. Әсәр куйганда, аның чорын, вакыйгаларны тирәнтен өйрәнә. Тышкы эффектлар белән мавыкмый. Игътибар үзәгендә кеше, аның язмышын дөрес күрсәтү булды.

Шамильский характерындагы кешелек аның сәхнә образларында гына түгел, үзенең көндәлек тормышында, иптәшләре белән аралашуында да бик зур иде. Ул һәрвакыт иптәшләренә ярдәм итәргә тырыша. Сәхнәдәшләре аңардан бик акыллы киңәшләр алалар. Ялгызлыкны һич яратмый — кайгысын да, шатлыгын да дуслары беләң бергә кичерә. Кешеләр белән очрашу, сөйләшү аны һәрвакыт куандыра. Шамильский яшьләр турында кайгырта. Бүген танылган артистларның бик күбесе өчен Шамильский аларның беренче уңышларын күреп сөенүче, аларны рухландыручы булды. Байтагының иҗади эшчәнлекләре режиссер Шакир Шамильскийның игътибарлы

карашы белән башланып китте. Бакуда ул татар труппасы оештыра. Анда да күп яшьләрне тәрбияли.

Шакир Шамильский заманның алдынгы карашлы әдипләре, җәмәгать эшлеклеләре белән якыннан аралашып яши иде. Ул Фәтхи Бурнаш, Һади Такташ, Салих Сәйдәшев белән якын дус иде. Галимҗан Ибраһимовка ихтирамы ифрат тирән булды. Ул аны репетицияләрдә остазыбыз итеп искә ала, күп үрнәкләрне, фикерләрне Ибраһимов әсәрләреннән, аның гыйльми хезмәтләреннән алып сөйли иде.

Шакир Шамильскийны искә алганда, аның турында уйланганда һәрвакыт бер фикергә киләсең: бик саф күңелле, бик кешелекле иде. Хезмәт сөйде, яшәү мәгънәсен фәкать иҗади хезмәтендә күрде. Шуңа күрә дә еш кына әдипләр һәм артистлар үзара аны хезмәт батыры дип йөртәләр, матбугат битләрендә дә аның исеме белән янәшә «хезмәт батыры» дигән сүзләр языла иде.

**Фатыйма ИЛЬСКАЯ.**

# СӘХНӘ ФИДАКАРЕ

*Касыйм Шамилнең тууына 90 ел*

Октябрь революциясеннән соң башланган яңа тормышка күчү дәверендә халык массаларын тәрбияләүдә татар артистларының, шул җөмләдән Касыйм Шамилнең дә роле зур булды. К. Шамил 1892 елның 30 августында Татарстанның Октябрь районы Иске Әлмәт авылында туа. Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, 1905 ел башында ул «Мәрҗани» мәдрәсәсендә укый башлый. Ләкин шәкертләр хәрәкәтенә катнашкан өчен аны укудан куалар. Шуннан соң инде Касыймның тормыш мәктәбе башлана. Йомышчы малай булу, сәүдәгәрләрдә ялланып эшләү дисеңме — барысы да аның башыннан уза.

Бер көнне, үзе белән мәдрәсәдән куылган бер иптәше: «Бүген приказчиклар клубында татарча спектакль була, әйдә барып карыйбыз»,— дип, Касыймны өнди. Тормышта һәр нәрсә белән тирән кызыксынган Касыймның, бу спектакльне карагач, күңеле күтәрелә, аңарда театрга тирән мәхәббәт уяна. Театрга мәхәббәте һаман арта барса да, бу елларны татар профессионал театры булмаганлыктан, ул артист булып китә алмый әле. Шулай да егетнең күңеле тынмый. Приказчиклар клубында күргән беренче спектакль, ул биргән кызыксыну көчәйгәннән-көчәя.

«Мәрҗани» шәкертләре «Мәдрәсә попечителе» исемле бер тәрҗемә пьесаны да сәхнәгә куялар. Вакыйга моннан тора. Бер мәдрәсә попечителенең Хәдичә исемле үсеп буйга җиткән кызы була. Ә ул кыз шул мәдрәсәдә укый торган яңа фикерле бер шәкерткә гашыйк. Иске фикерле бай бу эшне сизеп ала да кызны карт байга көчләп бирергә тели. Егет белән кыз моңа риза булмыйлар, качып китеп үзләренә яңа тормыш төзи башлыйлар. Ә бай исә шәкертләр арасында көлкегә кала. Касыймга бу әсәрдә Хәдичә ролен уйнау тапшырыла һәм ул үз ролен матур гына башкарып чыга.

Шулай итеп һәвәскәрләр белән уйнап азмы-күпме чыныккан Касыйм 1909 елны «Сәйяр» труппасында суфлер булып эшли башлый. Бу турыда Н. Сакаев бер истәлегендә: «Касыйм Шамил шул елны труппага катнашып суфлерлык вазифасын үти башлады. Әгәр дә сүзен әйтергә өлгермәсә, сүз урынына кашын сикертеп җибәрә иде»,— дип яза.

1912—1913 еллар сезонын тәмамлагач «Сәйяр» труппасы белән гастрольгә киткән К. Шамил авыру сәбәпле Троицк шәһәрендә кала. Шул вакыт аңа Оренбургтан С. Гыйззәтуллина-Волжскаядан үз труппасына чакырып хат килә. Больницадан чыгу белән К. Шамил шунда китә. Алар Уфа, Оренбург һәм бик күп башка шәһәрләрдә гастрольдә булалар. Шулай итеп, Касыйм ага татар театрының ике корифее белән эшләп зур тәҗрибә ала.

К. Шамилнең «Сәйяр» белән «Нур» труппаларында эшләгән вакытындагы барлык рольләренә дә тукталып булмый. Аларның бары берсен — Кулигин образын («Гроза», А. Н. Островский) гына алыйк. К. Шамилнең Кулигины — ул чын мәгънәсендә халык арасыннан чыккан зур талант иясе, оста. Ул үзенең эшенә мөкиббән киткән, хыялга бай һәм кешелекле кеше. Дикойлар, Кабанихалар яшәгән караңгылык патшалыгында да Кулигин шикелле саф күңелле кеше, талант иясе бар икән әле, дип уйлана шикелле автор белән бергә артист та.

Бөек Октябрьдан соң татар совет театрын төзү эшенә керешеп, К. Шамил 1918 елны Казанда (Елга аръягында) беренче эшче театры оештыра. Ныклы нигезгә корылган бу труппа хәзергә кадәр эшләп килә һәм Татарстанның көчле халык театры булып санала. К. Шамил күп еллар буе аларга әзлексез ярдәм итеп килә.

1919 елны төзелгән «Аң» труппасы эшенә дә К. Шамил актив булыша, труппа белән гастрольгә чыга. «Казанда татар хәрби комиссариаты хозурындагы «Аң» труппасы Мамадышка килеп «Тәкъдирнең шаяруы» белән «Галиябану»ны куйды. Табигый, бу пьесада тамашачыларның үз тормышлары, үзләреннән үткән вакыйгалар тәкърарланганлыктан, салкын кан белән утыра алмадылар... Бәдри ролен уйнаучы Шамил иптәш шул кадәр тип биреп уйнады. Ул чын мәгънәсе белән кире, бер катлы Бәдри агай иде»,— дип яза «Кызыл көч» газетасы (1920 ел, 13 октябрь саны). Бу спектакльләр Мамадыш, Алабуга, Бондюг, Кукмара һәм башка җирләрдә куела.

1933 елда Елга аръягы районында фабзавуч мәктәбендә К. Шамил балалар труппасы төзи. Ә 1925 елны инде татар дәүләт театры каршында ул ук оештырган балалар труппасы эшкә башлый. Бу труппаның репертуарында «Тычканга үлем, мәчегә көлке», «Бездә һәм аларда», «Октябрь чәчәкләре» кебек тәрбияви әһәмияте булган пьесалар куела.

Казанда беренче татар дәүләт театрын төзүдә дә К. Шамилнең булышлыгы тиде: ул труппаның режиссеры һәм артисты була.

Сәхнәдә К. Шамил өчен зур яки кечкенә роль юк. Аңа сәнгатьчә эшләнгән сәхнә образы тудыру гына бар. Ә бу тик чын осталарга гына хас сыйфат. Өлкән артист үз гомерендә 300 дән артык сәхнә образлары иҗат итте. Боларның күбесе онытылмаслык образлар. Аның Шәйхулласы (М. Әмир. «Тормыш җыры») — тынгысыз колхоз аксакалы, туган колхозына ярдәм итәргә патриотик тойгы белән алынган чын совет кешесе. Ә суфие (М. Әблиев, «Шәмсекамәр») дини әхлаклык кабыгына яшеренгән бозык җанлы кеше, староста Әхтәрие (Т. Гыйззәт, «Ташкыннар») надан һәм түрәләр өстәленнән төшкән калдыкны җыеп йөрүче куштан бәндә булып гәүдәләнә.

Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында куелганда К. Шамил Кәрим бай ролен башкарды. Анда бик күп ария, дуэт һәм башка музыкаль номерлар бар. Әмма К. Шамил үзенең уены белән бөтен спектакльгә тон бирә иде. К. Шамил чын мәгънәсендә ярминкәләрдә йөргән, күпне күргән, тәтәйләрне дә кулдан ычкындырмаган, шомарып беткән бер мут татар сәүдәгәре образын бик оста иҗат итте — тамашачы аның уенын йотлыгып карый иде.

К. Шамил иҗатының үзенчәлеге нәрсәдә соң? — дигән сорауга кыска гына итеп: «Аның иҗаты үзенең халыкчанлыгы белән аерылып тора»,— диярга мөмкин. Беренче буын татар артистлары халык арасыннан чыктылар. Алар халыкны, аның тойгысын, әдәбиятын, иҗатын һәм башка бик күп сыйфатларын яхшы белә иделәр. Әнә шуңа күрә К. Шамил башкарган образларның һәркайсы тулы канлы һәм тамашачы күңелендә озак сакланырлар.

Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

26 майда язучыларның ачык партия җыелышы булды. Анда Язучылар союзының нәшрият эшләре буенча комиссиясе эше тикшерелде. Доклад белән комиссия председателе, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. Миңнуллин чыкты. Фикер алышуларда С. Хәким, Г. Бәширов, А. Шамов, Г. Шәрәфетдинов, Р. Мостафин, Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев катнашты.

## «ИДЕЛ»ГӘ — КИҢЛЕК ҺӘМ ТИРӘНЛЕК

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең яшь иҗат көчләрен җитәкләү бүлеге һәм идарә каршындагы яшь авторлар белән эшләү комиссиясенең киңәйтелгән утырышы булды. Ул «Идел» әдәби альманахының эшчәнлеген тикшерүгә багышланды.

«Идел»дә басылган проза әсәрләре турында яшь язучылар Қ. Кәримов, Ф. Низамова, Ф. Бәйрәмова; шигырьләр турында — Х. Гайнетдинов, А. Миңһаҗева, Г. Моратов, Р. Низамиев; әдәби тәнкыйть мәкаләләре турында С. Маннапов сөйләде. Альманахның публицистика рубрикасына Н. Гамбәров, сәнгать һәм культура тарихына кагылышлы хезмәтләргә Ә. Мәхмүдов, юмор һәм сатира әсәрләренә С. Шәмсетдинов анализ ясады.

Язучылар Т. Миңнуллин, Ш. Рәкыйпов, Р. Гатауллин, Р. Миңнуллин, Х. Халиков, М. Галиев, Ә. Гаффар, рәссам Э. Зарипов «Идел» альманахының үсеш юллары турында кызыклы фикерләре белән уртаклаштылар.

Утырышта яшь авторлар белән эшләү комиссиясе председателе шагыйрь Ш. Галиев һәм Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов чыгыш ясады.

Утырыш «Идел» әдәби альманахының эшчәнлеген тулаем уңай яктан бәяләп, яңа бурычларга юнәлдергән карар кабул итте.

## МӘСКӘҮДӘ СИБГАТ ХӘКИМ КИЧӘСЕ

12 майда, Мәскәүдә, әдипләрнең Үзәк йортында РСФСРның М. Горький исемендәге һәм ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәкимнең иҗат кичәсе үткәрелде. Шагыйрьгә 70 яшь тулу уңае белән уздырылган бу кичәне РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Н. Доризо ачты. Шагыйрь турындагы сүзне филология фәннәре кандидаты Р. Мөхәммәдиев сөйләде.

Шагыйрьнең үз шигырьләрен укуы башкалабыз тамашачыларының көчле алкышларына күмелде. Кичәнең музыкаль өлешендә Татарстаннан килгән сәнгать осталары катнашты.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»на 60 ЕЛ

Татарстан Язучылар союзы органы, айлык әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал «Казан утлары» чыга башлауга 60 ел тулды. Шушы вакыйга уңае белән 24 майда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәне «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары Ринат Мөхәммәдиев алып барды.

Кичәдә республикабызның танылган әдипләре һәм сәнгать осталары чыгыш ясады.

«Казан утлары»ның 60 еллыгына багышланган бу кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ЕРАКТАГЫ ЯКЫННАР СҮЗЕ

Журналның юбилее уңаеннан төрле иҗат һәм җәмәгать оешмаларыннан, укучылардан котлау хатлары, адреслар һәм телеграммалар алынды. Аларның ерактан килгәннәре дә аз түгел иде. Янган тау санаториясендә дәваланырга киткән баш редактор Зәки Нуридан журналның иҗат бәйрәменә адресланган котлау телеграммасы түбәндәгечә иде.

«Кадерле укучылар, журналның редколлегия члennары, редакция хезмәткәрләре, күп санлы авторлар коллективы — язучылар, композиторлар, рәссамнар, журналистлар һәм галимнәр! Бу тантаналы бәйрәм кичәсендә үземне сезнең арада дип хис итәм һәм барчагызга яз кебек якты, кайнар сәламнәр — котлаулар юллыйм».

Әйе, журналыбыз яңа көннәр мәдәнияттен раслау һәм ныгыту, аңа мәхәббәт тәрбияләү, халыклар дуслыгы идеяләрен, әдәбият-сәнгатьнең партиялелеге һәм халыкчанлыгы идеяләрен пропагандалау эшенә зур өлеш кертте.

Билгеле, бу казанышлар хөрмәткә лаек, ләкин аңа карап тынычланып калырга ярамый. Республикабызның зур һәм көчле язучылар коллективы, күбрәк эзләнү ялкыны, иҗади активлык белән, тапталган сукмакларны югалтудан курыкмыйча, тормышны яңа эшләр һәм яктылык белән тулыландырырга, яңа башлангычларда көч сынап карарга, дигән өндәмә белән яңадан-яңа мәсьәләләрне хәл итәр өчен көч тупларга тиеш.

Сугышка кадәрге, сугыш еллары һәм бүгенге көннәрдәге авторларның берсе буларак, журнал эшендә хәзер төп оештыру-

чы һәм житәкче буларак, мин сезнең белән бергә «Казан утлары»ның зур уңышлар белән узган 60 еллык истәлекле юлы өчен тагын-тагын да куанам.

Киләчәктә дә зур корабка олы һәм якты юл телик!»

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге редакторы Рәдиф Кашфуллович Гатауллинга Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1982 ел, 4 июнь Указы белән «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

• • •

Совет матбугатында нәтиҗәле эшләүләре өчен һәм «Казан утлары» журналының беренче саны чыгуга 60 ел тулу уңаеннан журналның баш редакторы урынбасары Ринат Сафиевич Мөхәммәдиев, журналның техник редакторы Роза Нәгыймовна Сөләйманова Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнделәр.

• • •

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм ТАССР Язучылар союзы органы — «Казан утлары» журналының беренче саны чыгуга 60 ел тулу уңаеннан түбәндәге иптәшләр КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан АССР министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде:

Вәлиев Мөдәррис Харисович — журналның тәнкыйть бүлеге өлкән редакторы.

Бәдретдинова Сәмига Әгъләетдиновна — журнал редакциясенең секретарь-машинисткасы.

• • •

ТАССР Язучылар союзы органы — «Казан утлары» журналының беренче саны чыгуга 60 ел тулу уңаеннан түбәндәге иптәшләр СССР Язучылар союзының Почет грамотасы белән бүләкләнде:

Зәки Нури — журналның баш редакторы; Роберт Миңнуллин — җаваплы секретарь; Фәрваз Миңнуллин — редколлегия члены; Аяз Гыйләҗев — редколлегия члены.

Журналның редколлегия членнары Нил Юзиев, Марсель Зарипов, Рафыйк Нәфиков, Фаил Шәфигуллин, Зөлфәт Маликов, шулай ук проза бүлеге редакторы Марсель Галиев РСФСР Язучылар союзының Почет грамотасы белән бүләкләнделәр.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе «Казан утлары» журналының юбилее уңаеннан тәнкыйть бүлеге редакторы Мансур Вәлиевне, хатлар бүлеге редакторы Рәшит Әхмәтҗановны, проза бүлеге редакторы Солтан Шәмсетдиновны Почет грамотасы белән бүләкләде.

## БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ СЕКЦИЯСЕНДӘ

13 май көнне балалар әдәбияты секциясе утырышында яшь язучы Илдус Гайфуллинның «Табигатьтә кунакта» исемле кульязма китабы турында сөйләшү булды. И. Юзеев, Ә. Баянов, Р. Миңнуллин, Х. Халиков, тәнкыйтьче Р. Кукушкин, яшь язучылар К. Кәримов һәм С. Шәмсиев авторга күптөрле иҗади киңәшләр бирделәр.

## ӘКИЯТЛӘРЕБЕЗ — ВЕНГР ТЕЛЕНДӘ

Моннан ике ел элек Венгрия фәннәр академиясе чыгара торган махсус сериядә татар халык лирикасы үрнәкләре — алты йөздән артык кыска җыр текстын туплаган бер китап дөнья күргән иде.

Күптән түгел Будапештның «Европа» нәшриятында татар халык иҗатына караган тагын бер җыентык басылып чыкты. Яңа китапта фольклорның популяр жанры — әкиятләр урын алган. Бу хезмәт — венгр тюркологлары белән В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләүче татар галимнәре арасындагы иҗади дуслыкның күркәм нәтиҗәсе.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

ВЛКСМның Чаллы шәһәр комитеты һәм Чаллы Язучылар оешмасы яшь иҗат көчләре белән эшләү Советы оештырды. Бу Совет шәһәрдәге яшь язучылар, һәвәскәр композиторлар, рәссамнар, үзешчән сәнгать көчләре, яшь архитекторлар һәм фотосөючеләрне туплау, аларның сәләтен, иҗатын тәрбиячеләргә, КамАЗ эшчеләренә хезмәт күрсәтүгә юнәлдерәчәк. Совет составына Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре Р. Вәлиев, «Ләйсән» һәм «Орфей» берләшмәләре җитәкчеләре Г. Кашапов һәм Н. Алешков сайланды.

• • •

Драматург Т. Миңнуллин, шагыйрь Разил Вәлиев, язучы Г. Кашапов Алабуга педагогия институты студентлары алдында чыгыш ясадылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар. Очрашуда әдәбият белгечләре Т. Галиуллин һәм Н. Лаисов катнашты.

## ГАЛИМНЕ ХӨРМӘТЛӘҮ

Күренекле галим, Ленинград университетының иран филологиясе кафедрасы профессоры Габдрахман ага Таһирҗановка 75 яшь тулды.

Габдрахман ага филологиянең күп төрле өлкәләренә нәтиҗәле эш күрсәткән галим. Фарсы-таҗик әдәбияты классигы Рудакиның тормышы һәм иҗатына багышланган монографиясе, бөек Фирдәүси иҗаты хакындагы хезмәтләре илебез иранистикасында югары бәя алды. Безнең өчен аның эшчәнлеге шул ягы белән аеруча кыйммәт. Ул урта гасыр төрки әдәбиятының күренекле ядкарьләрен фарсы чыганаклары бе-

ләң чагыштырып, аларның мөстәкыйльлек дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итте. Габдрахман ага Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын, Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ен, Фирдәүси һәм Низами поэмалары белән чагыштырып, алга таба тикшерү эшен нык-лы нигезгә куйды. Урта гасыр төрки әдәбиятының әһәмиятле проблемаларын күтәргән, аның тарихында татар халкының лаеклы өлеше мәсьәләсен бөтен житдилеге белән куйган «Тарихтан — әдәбиятка» дигән китабы әдәбиятыбыз тарихын тикшерүчеләр өчен ышанычлы таяныч булып тора.

Ленинград университетының иран филологиясе кафедрасының киңәйтелгән махсус утырышына шәһәрнең күренекле галимнәре, Габдрахман аганың СССР Фәннәр Академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлекчәсендә эшләүче күп санлы шәкертләре килгән иде. Юбилей хөрмәтенә оештырылган бу утырышны СССР Фәннәр Академиясе член-корреспонденты, ЛДУ Көнчыгыш факультетының деканы М. Н. Боголюбов ачты. А. Н. Болдырев, С. Н. Соколов, В. В. Кушев һ. б. галимнәр юбилярның иҗади эшчәнлегенә югары бәя бирделәр. Галимнең иранистика һәм тюркологиягә караган хезмәтләреннән бай күргәзмә оештырылган иде.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган «Казан язы» исемле әдәби-музыкаль кичәләр май аенда В. И. Ленин, Воровский исемендәге, медицина һәм сәүдә работниклары культура йортларында үткәрелде. Аларда язучылар Г. Ахунов, Ф. Миннуллин, С. Хәким, Г. Латыйп, М. Хөсәен, Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, М. Скороходов, Р. Кәрами, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Шәфигуллин, Р. Миңнуллин, Ә. Рәшитов, Ф. Гыйззәтуллина, М. Галиев, Р. Хәмид, К. Кәримов, М. Зарецкий катнашты.

Бәясе 90 тиен.
Цена коп.

Индекс 73210

## *Хөрмәтле укучыларыбыз!*

1983 елда сезне кызыклы әдәби очрашулар көтә. Журналның беренче саны язучы Әхсән Баяновның **«Таш китап»** исемле романы белән ачылачак. Әсәр КамАЗ төзүчеләр тормышыннан алып язылган. Шул ук санда укучыларыбыз шагыйрь Илдар Юзеевнең **«Мәңгелек белән очрашу»** дигән яңа шигъри трагедиясе белән дә танышырлар. Язучы Гариф Ахунов **«Идел кызы»** романының икенче китабын, Мәдинә Маликова **«Шәфкать»** исемле романын, шулай ук Мөхәммәт Мәһдиев, Миргазиян Юныс, Гариф Галиев, Мәҗит Рафиков, Газиз Кашапов, Мәгъсүм Хуҗин, Камил Кәримов һ. б. язучылар үзләренең яңа проза әсәрләрен журналга китерделәр.

Журнал Сибгат Хәким, Мөхәммәт Садри, Ренат Харис, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Нурия Измайлова һ. б. шагыйрьләрнең шигырьләренә киләсе елда да зур урын бирәчәк.

КПССның Май пленумы карарларын тормышка ашыру йөзеннән, журнал редакциясе иң яхшы очеркларга конкурс игълан итә. Конкурс очерклары авыл хезмәтчәннәре тормышын, авыл хуҗалыгы алдында торган проблемаларны яктыртачак. Әдәби тәнкыйть бүлеге исә **«Геройлар һәм проблемалар»** темасына бүгенге проза турында дәвамлы сөйләшү башлап җибәрә.

Шулай ук **«Әдәбият белеме»**, **«Культурабыз тарихына»**, **«Китап күзәтү»**, **«Елмаеп та, көлеп тә»**, **«Нәниләр дөньясы»**, **«Укучы сүзе»** һ. б. рубрикаларда чыгачак әсәрләр дә бүгенге әдәби процессны, республикабызның культура тормышын киң чагылдырып барачак.

Тиздән 1983 ел өчен журналга язылу башланачак. Вакытында язылырга онытмагыз.

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии